# Казан утлары

3.1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ
АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

3

1984

## *Бу санда*

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү . . . . 4
КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш К. У. Черненко речее . . . . 6
КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, СССР Министрлар Советы Председателе иптәш Н. А. Тихонов речее . . . . 13
КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш М. С. Горбачев чыгышы . . . . 15
Константин Устинович Черненко . . . . 16
КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына Мөрәҗәгате . . . . 18

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Г. ВАСИЛЬЕВА. **Алмагачлар илендә** . . . . 21

КЫЗЛАР ҖЫРЫ

С. ГӘРӘЕВА. **Урал сәламнәре.** Шигырьләр . . . . 26
Л. ШАКИРҖАНОВА. **Башланмаган тормыш.** Шигырьләр . . . . 29
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. **Бер кычкырды кәккүк.** Шигырьләр . . . . 32
Б. РӘХИМОВА. **Авылда иртә.** Шигырьләр . . . . 35
Э. СӘСӘНБАЕВА. **Кассандра.** Шигырьләр . . . . 37

Г. БӘШИРОВ. **Күзгә ачы җилләрдә.** Повесть-истәлек . . . . 39

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Казанда Тукай урыннары** . . . . 74
З. РӘСУЛЕВА. **Тукай эзләреннән** . . . . 75

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. **Беренче умырзая.** Повесть . . . . 86
Г. РӘХИМ. **Шигырьләр** . . . . 153

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Э. ЛАРИЧЕВА. **Атомнарга атом бәйләнер** . . . . 158

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Т. ГАЛИУЛЛИН. **Шигърият үрләре** . . . . 161

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

М. МӘҺДИЕВ. **Җиләкле аланнар эзлим** . . . . 168

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Р. ХИСМӘТУЛЛИН. **Тема да бик мөһим** . . . . 170
Б. СӘЛӘХОВ. **Кыюлык кирәк!** . . . . . . . 173

И. КУДАШЕВ-АШКАЗАРСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

һ. МӘХМҮТОВ. **Сәхнә фидакаре** . . . . . . 174
Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. **Башлап йөрүчеләрдән** . . . 178

ЮБИЛЕЙЛАР

М. МӨХӘРРӘМОВ, И. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. **Халык бәхете хакына** . . . . . . . . . . . . . 180
Ф. ИБРАҺИМОВА. **Яктылыкка омтылып** . . . . 183
Ю. САФИУЛЛИН. **Гел истә** . . . . . . . . . . 185

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 189
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*

**ШАМИЛ БИКЧУРИН**
**МАНСУР ВӘЛИЕВ**
**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ**
**РӘИС ДАУТОВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ЗӨЛФӘТ**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**ЗӘКИ НУРИ**
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**АТИЛЛА РАСИХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**НИЛ ЮЗИЕВ**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Информационное сообщение о Пленуме ЦК КПСС. Речь Генерального секретаря ЦК КПСС тов. **К. У. Черненко**. Речь члена Политбюро ЦК КПСС, Председателя Совета Министров СССР тов. **Н. А. Тихонова**. Выступление члена Политбюро ЦК КПСС, секретаря ЦК КПСС тов. **М. С. Горбачева**. Биография Генерального секретаря ЦК КПСС тов. К. У. Черненко. Обращение ЦК КПСС, Президиума Верховного Совета СССР, Совета Министров СССР к Коммунистической партии, к советскому народу.
Выступление директора совхоза «Масловский» **Г. Васильевой** об опыте решения актуальных проблем сельскохозяйственного производства.
8 Марта — Международный женский день. «Песня девушек» — **стихи С. Гараевой, Л. Шакирзяновой, Э. Шарифуллиной, Б. Рахимовой и Э. Сесенбаевой**.
«К 100-летию Тукая»: публикация **З. Расулевой** «По следам Тукая» (окончание), рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
Автобиографическая повесть **Г. Баширова** «Жгучие осенние ветры» (начало). Повесть **Р. Мухаммадиева** «Первый подснежник». Новые стихи **Г. Рахима**.
Зарисовка **Э. Ларичевой** с литературного поста журнала — со строительства ТатАЭС.
«Навстречу X съезду писателей Татарстана». Статья **Т. Галиуллина** о современной татарской поэзии. Продолжение дискуссии «Современная проза: герои, проблемы»: статьи **М. Магдеева, Р. Хисматуллина**, письма читателей.
Юбилейные материалы: к 100-летию **И. Кудашева-Ашказарского**, к 90-летию **К. Якубова** и **Г. Сунгати**, к 60-летию **Р. Бикчантаева**.
«Новости культуры»; «На наших обложках» — творчество художника **Г. Рахманкуловой**.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*.

Производствога бирелде 29.12.1983 ел. Басарга кул куелды 29.2.1984 ел. ПФ 02107. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64184. Заказ Я-517. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.



КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре
**КОНСТАНТИН УСТИНОВИЧ ЧЕРНЕНКО**

# Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

1984 елның 13 февралендә КПСС Үзәк Комитетының чираттан тыш Пленумы булды.

Үзәк Комитет Политбюросы тапшыруы буенча Пленумны КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, Үзәк Комитет секретаре К. У. Черненко ачты.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ю. В. Андроповның вафат булуы сәбәпле, Үзәк Комитет Пленумында катнашучылар Юрий Владимирович Андропов истәлеген бер минут тынлык белән хөрмәтләделәр.

Үзәк Комитет Пленумы, Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, барлык совет халкы авыр югалтуга дучар булды, дип күрсәтеп үтте. Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе, ялкынлы патриот, ленинчы, тынычлык һәм коммунизм өчен армый-талмый көрәшүче безнең арадан китте.

Партия ихтыяры белән партия һәм дәүләт эшенең иң мөһим постларында булып, Юрий Владимирович Андропов үзенең бөтен көчен, белемен һәм гаять зур тормыш тәҗрибәсен партия политикасын тормышка ашыруга, аның массалар белән элемтәсен көчәйтүгә, Советлар Союзының экономик һәм оборона куәтен ныгытуга бирде.

Ю. В. Андропов КПССның XXVI съездында һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнарында эшләнгән линияне — житештерүне барлык чаралар белән интенсивлаштыру, фән-техника прогрессын тизләтү, халык хуҗалыгын идарә итүне камилләштерү, кадрларның җаваплылыгын көчәйтү, оешканлык һәм дисциплинаны ныгыту, халык тормышының материаль һәм рухи дәрәҗәсен туктаусыз үстерү линиясен тормышка ашыруга зур игътибар бирде.

Ю. В. Андропов социалистик бердәмлек илләренең һәрьяклы хезмәттәшлеген үстерүгә, халыкара коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтенең бердәмлеген һәм тупланганлыгын ныгытуга, халыкларның азатлык һәм бәйсезлек өчен гадел көрәшенә булышлык итүгә зур өлеш кертте. Аның җитәкчелегендә халыкара мәйданда партиябез һәм дәүләтебез-

нең ленинчыл тышкы политик курсы — атом-төш сугышы куркынычын бетерүгә, империализмның агрессив казынуларына ныклы отпор бирүгә, тынычлыкны һәм халыклар иминлеген ныгытуга юнәлдерелгән курс эзлекле төстә һәм нык тормышка ашырылып килде.

Пленум, бу кайгылы көннәрдә коммунистлар, барлык совет халкы партиянең ленинчыл Үзәк Комитеты, КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы тирәсенә үз сафларын тагын да тыгызрак туплыйлар, партиянең ленинчыл эчке һәм тышкы политикасын тормышка ашыру өчен фидакарь көрәшергә әзер торуларын белдерәләр, дип күрсәтеп үтте.

Үзәк Комитет Пленумында катнашучылар мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаштылар.

Үзәк Комитет Пленумы КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретарен сайлау турындагы мәсьәләне карады.

Үзәк Комитет Политбюросы тапшыруы буенча КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, СССР Министрлар Советы Председателе иптәш Н. А. Тихонов бу мәсьәлә буенча речь белән чыкты. Ул КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп иптәш К. У. Черненконы сайларга тәкъдим кертте.

Пленум КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп бертавыштан иптәш Константин Устинович Черненконы сайлады.

Аннары Пленумда КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш К. У. Черненко чыгыш ясады. Ул партия Үзәк Комитеты күрсәткән югары ышаныч өчен чын күңелдән рәхмәт әйтте.

Иптәш К. У. Черненко КПСС Үзәк Комитетын, Коммунистлар партиясен илебездә коммунизм төзү бурычларын уңышлы хәл итү өчен, СССРның экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгыту, совет халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, тынычлыкны ныгыту буенча КПСС-ның XXVI съезды куйган бурычларны хәл итүдә, Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте үткәрә торган ленинчыл эчке һәм тышкы политиканы тормышка ашыруда дәвамчанлыкны тәэмин итү өчен бөтен көчен, белемен һәм тормыш тәҗрибәсен бирәчәгенә ышандырды.

Шуның белән Үзәк Комитет Пленумы үзенең эшен тәмамлады.

# КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш К. У. ЧЕРНЕНКО рече

Кадерле иптәшләр!

Миңа күрсәтелгән югары хөрмәт өчен — Үзәк Комитет Генеральный секретаре итеп сайлаулары өчен Үзәк Комитет членнарына чын күңелдән рәхмәт белдерәм. Мин үз өстемә төшәчәк гаять зур җаваплылыкны тулысынча аңлыйм. Алда нинди мөһим, гаять катлаулы эш торуын аңлыйм. Үзәк Комитетны, партияне, күрсәтелгән ышанычны аклау өчен, партиябезнең принципиаль линиясен — Юрий Владимирович Андропов эзлекле төстә һәм нык үткәреп килгән линияне сезнең белән бергә дәвам иттерү өчен үземнең бөтен көчемне, белемемне, бөтен тәҗрибәмне бирәчәгемә ышандырам.

Оештыру таланты, ачык иҗади акыл, теориядә һәм политикада ленинизмга тугрылык, яңалыкны сизгер тою хисе һәм массаларның җанлы тәҗрибәсен туплый белү сәләте, дөньяга карашыбызга һәм яшәү рәвешебезгә, моралебезгә ят булган бөтен нәрсәгә килешмәүчәнлек, шәхси ягымлылык һәм тыйнаклык — боларның барысы да Юрий Владимировичка партия һәм халыкта гаять зур авторитет һәм ихтирам китерде.

Партия аңа катлаулы һәм җаваплы эш участокларын тапшырды. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре һәм СССР Верховный Советы Президиумы Председателе постларында Юрий Владимирович Андроповның иң яхшы политик һәм кешелек сыйфатлары аеруча ачык күренде. Һәрвакыт үз алдында торган бурычлар югарылыгында булырга омтылып, ул үз-үзен аямыйча эшләде.

Юрий Владимирович хәзерге этапта партиянең һәрьяклап уйланган һәм реалистик курсын — нык үскән социализмны камилләштерү курсын эшләү буенча Үзәк Комитетның, Үзәк Комитет Политбюросының коллектив эшчәнлегенә зур шәхси өлеш кертте. КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1982 ел), июнь һәм декабрь (1983 ел) Пленумнары аның җитәкчелегендә үткәрелде, алар партия һәм халык тормышында мөһим вакыйгаларга әверелде. Пленумнар карарларында КПССның XXVI съездында эшләнгән политик линия иҗади яктан тагын да үстерелде һәм конкретлаштырылды.

Совет кешеләренең иҗади хезмәтенә тыныч шартлар тәэмин итү, халыкара мәйданда социализмның позицияләрен ныгыту өчен көрәшкә Ю. В. Андропов күп көч һәм энергия куйды.

Юрий Владимирович партия авторитетының чыганагы аның үзенең җитәкчелек ролен, мактаулы авангардлык ролен халыкка фидакарь хезмәт итүе белән, хезмәт ияләре интересларын төгәл чагылдыра, аларны дөрес марксистик-ленинчыл эш программасы белән коралландыра белүе белән яулап алуында һәм ныгытуында булуын яхшы аңлады.

Бу политиканың бөтен халык тарафыннан кайнар яклануы КПСС үткәрә торган эчке һәм тышкы политиканың дөреслеген, аның заман таләпләренә һәм рухына җавап бирүен ышандырырлык итеп күрсәтүче дәлил булып тора. Партия үзе сайлаган юлдан — коммунизм төзү һәм тынычлык юлыннан нык бара.

Элек шулай булды. Һәрвакыт шулай булыр!

Әмма без, барыбыз да, иптәшләр, бу юлдан бару өчен теләк кенә аз булуын аңлыйбыз. Дөрес максатларны куя белергә генә түгел, аларга нык торып ирешә дә белергә, теләсә нинди кыенлыкларны җиңә дә белергә кирәк. Ирешелгәннәргә арттырмыйча да, шул ук вакытта киметмичә дә реаль бәя бирергә кирәк. Бары тик шундый караш кына политикада ялгышлардан, теләктә булганны чынбарлык итеп кабул итәргә кызыгудан саклый. Ленин әйткәнчә, «безнең нәрсәне «эшләп бетерүебезне» һәм нәрсәне эшләп бетермәвебезне»[1] ачык күрергә мөмкинлек бирә.

Юрий Владимирович Андроповка партиябез һәм дәүләтебез башында бик аз, кызганыч дәрәҗәдә аз эшләргә туры килде, иптәшләр. Без барыбыз да аның юклыгын сизәчәкбез. Ул безнең арадан халык хуҗалыгын үстерүгә куәтле темп бирүгә, 70—80 нче еллар чигендә илебез очраган кыенлыкларны җиңүгә юнәлдерелгән зур һәм киеренке эшнең иң кызган чагында китте. Әмма бу кыска гына вакыт эчендә партиянең никадәр күп эшләвен, никадәр күп яңа, нәтиҗәле эшләрнең гражданлык хокукы алуын һәм практикада ныгып урнашуын без барыбыз да беләбез. Юрий Владимирович җитәкчелегендә башланган эшне дәвам иттерү һәм аны коллектив тырышлык белән тагын да алга җибәрү — аның истәлегенә тиешенчә бәя бирүнең, политикада дәвамчанлыкны тәэмин итүнең иң яхшы ысулы.

Дәвамчанлык — абстракт төшенчә түгел, ә җанлы, реаль эш. Һәм аның асылы, барыннан да элек, тукталмыйча алга барудан гыйбарәт. Элек ирешелгән барлык уңышларга таянып, аны иҗади үстереп, коммунистларның, эшчеләр сыйныфының, барлык халыкның коллектив фикерен, энергиясен хәл ителмәгән бурычларга, бүгенгенең һәм киләчәкнең төп проблемаларына туплап барудан гыйбарәт. Һәм болар барыбызга да зур бурычлар йөкли.

Партиябезнең көче — аның бердәмлегендә, марксизм-ленинизмга тугрылыгында, массаларның иҗади активлыгын үстерә һәм аңа юнәлеш бирә белүдә, сыналган ленинчыл принципларны һәм методларны кулланып, аларны идея һәм оешу ягыннан туплый белүдә. Сез беләсез, иптәшләр, безнең Үзәк Комитет, Үзәк Комитет Политбюросы, Юрий Владимирович Андропов соңгы вакытта дәүләт аппаратының эшен камилләштерү, партия җитәкчелеге стилен яхшырту мәсьәләләренә гаять зур игътибар бирделәр. Шуларның берсе — партия комитетлары функцияләрен дәүләт һәм хуҗалык органнары бурычларыннан ачык итеп чикләү, аларның эшендә кабатлауларны бетерү. Бу — политик әһәмияте булган зур мәсьәлә. Ачыктан-ачык әйтсәк, биредә әле бөтенесе дә кирәгенчә җайга салынмаган. Шулай да була. Советлар, министрлыклар, предприятиеләр работниклары тиешле мөстәкыйльлек күрсәтмиләр, үзләре хәл итәргә тиешле мәсьәләләрне партия органнарына аударалар. Хуҗалык җитәкчеләрен алыштыру практикасы кадрларның күңелен сүрелдерә. Алай гына да түгел, монда партия комитетының политик җитәкчелек органы буларак роле йомшару куркынычы бар. Партия комитетлары өчен хуҗалык белән шөгыльләнү — барыннан да элек, хуҗалыкны алып баручы кешеләр белән эшләү ул. Моны һәрвакыт истә тотарга кирәк.

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 33 т., 189 б.

Иптәшләр! Моннан ай ярым элек, ҮзәкКомитетның декабрь Пленумында, без илебезнең социаль-экономик үсеше өлкәсендәге эшнең торышына һәрьяклап бәя бирдек. Кабул ителгән карарда, хәзер иң мөһиме алынган темпны киметмәү, бурычларны практик хәл итүдә гомуми хезмәт күтәренкелеген саклау, экономикага партия һәм дәүләт житәкчелеге дәрәҗәсен туктаусыз күтәрү, уңай тенденцияләрне активрак үстерү, аларга тотрыклы характер бирү, дип аеруча басым ясап күрсәтелде. Пленумның бу күрсәтмәләрен эзлекле үтәү — безнең турыдан-туры бурычыбыз.

Безнең бөтен тәҗрибәбез шуны раслый: партиянең массалар белән элемтәсе, миллионнарча хезмәт ияләренең гражданлык активлыгы, аларның производстводагы эшләргә, иҗтимагый тормыш проблемаларына хуҗаларча каравы һәрвакыт партия көченең иң мөһим чыганагы булды, хәзер дә шулай һәм киләчәктә дә шулай булачак.

Коммунистлар партиясенең бурычы — үз курсын, үз карарларын, эшләрен, барыннан да элек, эшчеләр сыйныфының фикерләре белән, аның гаять зур социаль-политик һәм сыйнфый сизгерлеге белән даими чагыштырып карау. Владимир Ильич Ленин эшче кешенең турылыгын, аның фикерләренең тормышчан нигезләнгән булуын һәм ачыклыгын һәрвакыт югары бәяләде, аның фикеренә, вакыйгалар һәм кешеләргә бәя бирүенә сизгер колак салды, аларда иң актуаль сорауларга җаваплар эзләде һәм тапты.

Эшчеләр арасыннан, социалистик төзелешнең алгы сызыгыннан чыккан сүзгә колак салу, хезмәт кешеләре белән киңәш тоту — болар бүген дә һәр коммунист-җитәкченең иң беренче бурычы, тирәнтен эчке ихтыяҗы булырга тиеш.

Халык инициативасын, өстәвенә, иң киң мәгънәсендә — хезмәт урынында эшкә хуҗаларча, иҗади мөнәсәбәттән алып дәүләтне, җәмгыятьне идарә итүдә актив катнашуга кадәр — үз вакытында күрә һәм яклый белү — безнең прогрессның иң зур, әйтергә мөмкин, бетмәс-төкәнмәс резервы менә шунда. Безнең экономикабыз үзенең һәр зур казанышы белән теге яки бу дәрәҗәдә хезмәт коллективларының иҗади башлангычларына, аларның шәхси, башкача әйтсәк, өстәмә планнарына бурычлы.

Илебез хезмәт коллективларының декабрь Пленумы чакыруын — хезмәт җитештерүчәнлеген планнан тыш 1 процентка күтәрүгә һәм продукциянең үзкыйммәтен өстәмә рәвештә 0,5 процентка киметүгә ирешергә чакыруын киң яклавы тирән канәгатьләнү тудыра. Хезмәт ияләренең, партия, профсоюз, комсомол оешмаларының бу бурычны хәл итүгә патриотик күтәренкелек, энергия һәм эшлеклелек белән керешүләре уңышның тәэмин ителәчәгенә ышаныч тудыра.

Шушылар исәбенә алыначак барлык средстволарны һәм ресурсларны — ә алар аз түгел — совет кешеләренең хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга, медицина хезмәте күрсәтүгә, торак төзелешенә бирү турындагы мәсьәләне карарга кирәк, дип уйлыйм. Бу — партия политикасының иң югары максатына,— кеше бәхете турында һәрьяклап кайгыртуга тулысы белән җавап бирер иде.

Гомумән, иптәшләр, безгә, хезмәт ияләренең иҗади башлангычларын һәм новаторлыгын материаль һәм мораль яктан яхшырак кызыксындыру турында уйларга кирәк, күрәсең.

Совет строеның нигезендә социаль гаделлек ята. Һәм аның гаять зур көче шунда да. Шунлыктан, көндәлек эшләрдә аның тайпылышсыз үтәлүе — сүз эш хакы һәм премияләр турында барамы, квартиралар яки путевкалар бүлү, бүләкләү турындамы — кыскасы, бөтенесенең дә гадел, һәр кешенең гомуми эшебезгә керткән хезмәт өлешен исәпкә алып эшләнүе бик мөһим.

Бередә, партия, профсоюз, комсомол оешмаларына, хуҗалык җитәкчеләренә эшлисе эшләр житәрлек. Күп нәрсә хезмәт коллективларының үзләренә бәйле. Аларның хәзер закон тәртибендә беркетелгән зур хокуклары бар. Эш бу хокуклардан тулырак файдаланудан тора.

Соңгы вакытта партия социалистик җәмгыятькә җитәкчелек итүнең яңа тәҗрибәсе белән баеды. Без строебыз өстенлекләрен, мөмкинлекләрен яхшырак файдалана башладык. Массаларның оешканлыгы һәм аңлылыгы, һичшиксез, шулар рәтенә керә. Тәртипне, дисциплинаны ныгытуга булган игътибарыбыз да шуннан килеп чыга.

Оешканлык турында, тәртип турындагы мәсьәлә — безнең өчен төп, принципиаль мәсьәлә. Бу хакта ике фикер була алмый. Һәртөрле тәртипсезлек, җавапсызлык җәмгыятькә материаль зыян гына китереп калмый. Алар җитди социаль, әхлак зыяны китерә. Моны без, коммунистлар, яхшы аңлыйбыз, миллионнарча совет кешеләре яхшы аңлый. Һәм хезмәт, производство, план, дәүләт дисциплинасын күтәрү, социалистик законлылыкны ныгыту максатларында партия күргән чараларның бөтен халык тарафыннан чын-чынлап хуплануы тулысынча закончалыклы.

Бу өлкәдә кайбер эшләр башкарылды инде. Моның производство эшләренә, иҗтимагый тормышыбызга һәм шулай ук кешеләрнең кәефенә уңай йогынты ясавын барысы да беләләр. Әмма, инде барысы да эшләнде, дип уйлау дөрес булмас иде. Юк, иптәшләр, тормыш бередә берничек тә йомшарып калмаска өйрәтә.

Экономикабыз үсешенең төп юнәлешләренә килгәндә, алар партия тарафыннан ачык билгеләнде. Интенсивлаштыру, фән һәм техника казанышларын производствога кертүне тизләтү, комплекслы зур программаларны тормышка ашыру — боларның барысы да соңгы исәптә җәмгыятебезнең житештерүче көчләрен сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрергә тиеш.

Экономиканы идарә итү системасы, бөтен хуҗалык механизмыбыз житди үзгәртеп коруга мохтаҗ. Бу юнәлештә эш әле башланды гына. Ул предприятиеләрнең хокукларын киңәйтү һәм җаваплылыгын күтәрү буенча киң масштаблы экономик экспериментны эченә ала. Хезмәт күрсәтү сферасында хуҗалык итүнең яңа формаларын һәм методларын эзләү бара. Шик юк, алар күп кенә файдалы нәрсәләр бирерләр, безгә стратегик яктан мөһим проблеманы хәл итәргә — барлык халык хуҗалыгының нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итәрләр.

Әмма, әйдәгез, үз-үзебездән сорыйк әле: экспериментларның нәтиҗәләрен көтү кайбер хуҗалык житәкчеләре өчен үзләренең пассивлыкларын, искечә эшләргә омтылуларын яшерү өчен генә хезмәт итмиме? Әлбәттә, экономика структураларын яңарту — җаваплы эш. Бередә күптәнге акыллы кагыйдәләрне саклауның зыяны юк: җиде кат үлчә, бер кат кис. Әмма бу үзгәргән шартлар белән, тормышның яңа таләпләре белән исәпләшергә теләмәүчеләрне һич кенә дә акламый.

Барлык дәрәҗәләрдә күбрәк мөстәкыйльлек күрсәтергә, кыюрак эзләнергә, экономиканың нәтиҗәлелеген күтәрү, халыкның тормыш хәлен яхшырту хакына, әгәр кирәк булса акланырдай тәвәккәллеккә бару — без хуҗалык кадрларыбыздан әнә шуны көтәбез.

Сезгә мәгълүм булганча, узган ел КПСС Үзәк Комитеты һәм хөкүмәт экономиканы үстерүнең принципиаль мәсьәләләре буенча күп кенә карарлар эшләделәр һәм кабул иттеләр. Бу карарлар партия һәм хуҗалык органнарына житештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүнең, илнең экономик үсешен тизләтүнең мәгълүм рычагларын бирде.

Хуҗалык әһәмияте генә түгел, бәлки зур политик әһәмияте дә булган бу чаралар һәр партия оешмасының, һәр работникның көндәлек эшенең төп эчтәлегенә әйләнгән очракта гына тормышка ашырылачак.

Без бүгенге көн бурычларын хәл итеп, киләчәкнең тагын да югарырак үрләре өчен шартлар тудырабыз. Бәлки иртәгәге көнебез турында, уникенче бишьеллык турында бөтенваклыклары белән сөйләү әле-гә иртәрәктер, әмма алда торган эшнең төп проблемалары, төп юнәлешләре инде хәзер үк ачык күренә.

Яңа бишьеллык беренче чиратта җитештерүдәге тирән сыйфат үзгәрешләренең башлангычы, халык хуҗалыгыбызның барлык тармакларын интенсивлаштыру эшендә хәлиткеч борылыш бишьеллыгы булырга тиеш. Хәзерге заман материаль-техник базасы һәм идарә системасы яңа, тагын да югарырак сыйфатларга ия булырга тиеш.

Хәзер совет җәмгыятенең экономик, социаль һәм рухи прогрессының үзара тагын да тыгызрак элемтәсен тәэмин итү аеруча мөһим. Моның өчен кирәкле социаль һәм идеологик алшартлар тудырмый торып, экономиканы сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрү мөмкин түгел. Шул ук вакытта социалистик аңны үстерүнең өлгергән проблемаларын да экономик һәм социаль политиканың ныклы нигезенә таянмыйча хәл итеп булмый.

Яңа дөнья төзү — яңа дөнья кешесен формалаштыру турында, аның идея-әхлакый үсеше турында туктаусыз кайгырту ул. Үзәк Комитетның июнь Пленумы, мәгълүм булганча, идеология, масса-политик эш мәсьәләләрен нәкъ менә шул караштан чыгып тикшерде. Аның күрсәтмәләренә таянып, партия бу эшнең нык үскән социализмны камилләштерүнең зур һәм катлаулы бурычлары характерына тулысынча туры килүенә ирешергә омтылачак.

Бу бурычларны аларның бөтен комплексы белән фикерләү, аларны хәл итүнең озак сроклы төгәл стратегиясен билгеләү, агымдагы эшләребезнең коммунистик перспектива белән элемтәсен күрсәтү — партия программасының яңа редакциясе безгә әнә шуны бирергә тиеш. Үзәк Комитет аны хәзерләүгә гаять зур әһәмият бирә.

Иптәшләр! Илебезне киләчәктә үстерү планнарын эшләгәндә, без дөньяда туган хәлне исәпкә алмыйча булдыра алмыйбыз. Ә ул, үзегез белгәнчә, катлаулы һәм киеренке. Мондый шартларда партия һәм Совет дәүләтенең тышкы политикасы тагын да зуррак әһәмият казана.

Ныклы тынычлык, халыклар азатлыгы һәм бәйсезлеге эше өчен көрәш Юрий Владимирович Андроповның һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Үзәк Комитет Политбюросы һәм дәүләтебез властеның югары органнары аның җитәкчелегендә шушы игелекле принципларга җавап бирә торган актив тышкы политиканы формалаштырдылар. Ул политика кешелекне дөньякүләм атом-төш сугышы куркынычыннан коткаруга юнәлтелде. Бу ленинчыл Тынычлык политикасының төп сыйфатлары хәзерге тарихи этапта КПССның соңгы съездлары карарларында билгеләнде, һәм алар совет халкының төп интересларына, алай гына да түгел, дөньядагы башка халыкларның интересларына да җавап бирәләр. Һәм без кискен итеп белдерәбез: бу политикадан бер генә адым да чигенмәячәкбез.

Иптәшләр, тынычлыкны саклау һәм ныгыту эшенең уңышы күп яктан социализм илләренең дөнья мәйданында йогынтысы ни дәрәҗәдә зур булуына, аларның эшләре ни дәрәҗәдә актив, максатчан һәм килештерелгән булуына бәйле икәнлеге көн кебек ачык. Безнең илләребез тынычлыкны яклый. Шушы максат хакына без барлык социалистик илләр белән хезмәттәшлекне киңәйтүгә омтылачакбыз. Социалистик дуслык илләре белән барлык өлкәләрдә, шул исәптән, әлбәттә, экономика кебек мөһим өлкәдә дә бердәмлекне һәм хезмәттәшлекне һәрьяклап үстереп һәм тирәнәйтеп, без шуның белән тынычлык, прогресс һәм халыклар иминлеге эшенә зур өлеш кертәбез.

Тугандаш илләргә мөрәҗәгать итеп, без шуны әйтәбез: Советлар Союзы йөзендә сез киләчәктә дә ышанычлы дус һәм турылыклы союзник табарсыз.

Колониаль бәйлелек богауларын салып ташлаган һәм мөстәкыйль үсеш юлына баскан халыклар белән теләктәшлек безнең партиябезнең һәм Совет дәүләтенең тышкы политикасының төп нигезләренең берсе булды һәм шулай булып кала. Бигрәк тә дөньяның әле бер, әле икенче районында куркыныч канлы көчләү һәм сугыш янгыны учаклары тудыручы империализмның агрессив көчләре һөҗүмнәрен кире кагарга мәҗбүр булган халыклар белән бу теләктәшлегебез, әлбәттә, бигрәк тә көчле. Халыкларның хак эше ягында булу, әнә шундый учакларны бетерү өчен көрәшү — бүген җирдә ныклы тынычлык урнаштыру өчен көрәшнең шундый ук зарури һәм мөһим юнәлеше ул. Безнең партиябезнең бу мәсьәләләрдәге принципиаль позициясе ачык, саф һәм игелекле, без киләчәктә дә шуны тайпылышсыз яклаячакбыз.

Инде хәзер капиталистик илләр белән мөнәсәбәтләр турында. Бөек Ленин безгә иҗтимагый стройлары төрле булган дәүләтләр белән янәшә тыныч яшәү принцибын васыять итеп калдырды. Без бу принципка һәрвакыт турылыклы. Хәзер, атом-төш коралы һәм аеруча төгәл ракеталар гасырында, халыкларга ул әле һичкайчан булмаганча кирәк. Кызганычка каршы, капиталистик илләрнең кайбер җитәкчеләре, барыннан да күренгәнчә, моны аңламыйлар яки аңларга теләмиләр.

Без империализмның агрессив көчләренең акылсыз, авантюристик хәрәкәтләре кешелек дөньясына бүген нинди куркыныч тудыруын яхшы күрәбез, һәм моның турында бар тавышка кычкырып сөйлибез, җир йөзендәге халыкларның игътибарын шул куркынычка юнәлтәбез. Безгә хәрби өстенлек кирәкми, без үз ихтыярыбызны башкаларга көчләп тагарга җыенмыйбыз. Ләкин ирешелгән хәрби тигезлекне җимерергә без юл куймабыз. Берәүдә дә кечкенә генә дә шик калмасын: без киләчәктә дә сугыш чукмарлары булган авантюристларның кайнар башларын суытырга мөмкинлек бирердәй средстволарыбыз җитәрлек булсын өчен илебезнең оборона сәләтен ныгыту турында кайгыртып торачакбыз. Бу, иптәшләр, тынычлыкны саклауның җитди алшарты.

Советлар Союзы, бөек социалистик держава буларак, тынычлыкны саклау һәм ныгыту өчен халыклар алдында ни дәрәҗәдә җаваплы булуын тулысынча аңлый. Без барлык континентлардагы дәүләтләр белән үзара файдалы тыныч хезмәттәшлек итәргә әзер торабыз. Без барлык бәхәсле халыкара проблемаларны җитди, тигез хокуклы, конструктив сөйләшүләр юлы белән хәл итү ягында. СССР халыкара киеренкелекне киметүгә практик эшләре белән булышырга, дөньяда бер-берсенә ышану атмосферасы тудырырга хәзер торган барлык дәүләтләр белән тулысынча үзара килешеп эшләячәк. Башка сүзләр белән әйткәндә, сугыш хәзерләүгә түгел, бәлки тынычлык нигезләрен ныгытуга чын мәгънәсендә үзенең көчен куючылар белән хезмәттәшлек итәчәк. Без болай дип саныйбыз: булган барлык рычаглар, шул исәптән, әлбәттә, тынычлыкны саклау һәм ныгыту өчен оештырылган Берләшкән Милләтләр Оешмасы да тулысынча файдаланылырга тиеш.

Иптәшләр, безнең, совет коммунистларын, кешелекнең тыныч киләчәге һәм прогрессы өчен көрәштә сыйныф буенча миллионнарча туганнарыбыз белән, коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтенең дөньядагы күп санлы отрядлары белән кулга-кул тотынып баруыбыз чын күңелдән сөендерә. Без, пролетар интернационализм принципларына тайпылышсыз рәвештә турылыклы буларак, чит илләрдәге иптәшләребезнең хезмәт ияләре интереслары һәм хокуклары өчен алып барган көрәшләренә кайнар мәхәббәт һәм тирән ихтирам белдерәбез һәм безне бәйләгән җепләрне тагын да ныгытуны үзебезнең бурычыбыз итеп саныйбыз.

Партиябезнең халыкара эшләрдәге линиясе турында бүген менә шуны әйтәсе килгән иде. Һәм без ышанабыз, совет халкы аны бөтен күңеле белән яклый.

Иптәшләр! Совет кешеләре үзләренең барлык казанышларын аерылгысыз рәвештә партия эшчәнлеге белән бәйлиләр. Массаларга чиксез бирелгән партия массаларның тулы ышанычын казанды.

Партия оешмаларында әле яңа гына отчет-сайлау кампаниясе тәгәлләнде. Ул тагын коммунистларның аңлылыгы һәм активлыгы югары дәрәҗәдә булуын күрсәтте. Җитәкче постларга авторитетлы, тәҗрибәле, эшне белүче кешеләр сайланды.

Пленум эшендә партиянең край һәм өлкә комитетларының беренче секретарьлары катнаша. Сезгә, иптәшләр, аерым сүз әйтәсе килә. Үзәк Комитет сезнең вазифаларыгызның, сезнең эшләрегезнең даирәсе ни дәрәҗәдә киң булуын яхшы белә. Безнең агымдагы, якындагы һәм стратегик бурычларыбызны хәл итүнең ни дәрәҗәдә сезгә бәйле булуын белә. Үзәк Комитет Политбюросы ышана: сез промышленность производствосын үстерүнең тотрыклы темпларын тәэмин итү өчен, Азык-төлек программасын уңышлы үтәү, массаларның хезмәт активлыгын күтәрү, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүгә юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле бөтен нәрсәне эшләрсез һәм шуның белән партиянең авангардлык ролен күтәрүне тәэмин итәрсез.

Безнең партиядәге һәр сайлаулы пост — җаваплы пост. Партия комитетына сайлануны партия членнарының үз иптәшләренә күрсәткән ышаныч кредиты итеп карарга кирәктер. Һәм бу ышаныч фидакарь хезмәт белән акланырга тиеш. Булып үткән җыелышларда һәм конференцияләрдә катнашучыларның наказы әнә шундый. Хәзер, СССР Верховный Советына сайлаулар бусагасында торганда, партия бу таләпчән наказны депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән, дәүләт властеның югары органына керәчәк коммунистларга да тапшыра.

Коммунистлар сафларының бердәмлеге — совет коммунистларының бетмәс-төкәнмәс көче ул. Бу көч, Ленин сүзләре белән әйткәндә: «Без, партия членнары, *барыбыз да бер кеше кебек хәрәкәт иткәндә*» [1] бөтен тулылыгы белән ачыла. КПССның ленинчыл Үзәк Комитеты, аның җитәкче үзәге — Үзәк Комитет Политбюросы нәкъ менә шулай бердәм, тупланган хәлдә хәрәкәт итә. Бу — нык тикшерелгән, һәрьяклап үлчәнгән, эшчеләр сыйныфы, крестьяннар, интеллигенциянең союзын, ССР Союзы халыкларының туганнарча дуслыгын ныгытуга илтә торган карарлар кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Юрий Владимирович Андропов чын партиячел, эшлекле һәм иҗади атмосфера булдыруга күп көч салды, менә шул атмосфера партия Үзәк Комитеты эше өчен мәҗбүри шарт булды һәм булып калачак. Ул — КПССның авторитеты тагын да үсүнең, алдыбызда торган коммунистик төзелешнең зур һәм катлаулы бурычларын уңышлы хәл итүнең залогы.

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 11 т., 307 б.

# КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, СССР Министрлар Советы Председателе иптәш Н. А. ТИХОНОВ рече

Кадерле иптәшләр!

Коммунистлар партиясе, безнең халкыбыз, бөтен дөнья коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәте зур югалтуга дучар булдылар. Юрий Владимирович Андроповның — партиябез һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе, социалистик Ватаныбызның ялкынлы патриоты, тынычлык һәм коммунизм өчен ару-талуны белмичә көрәшкән кешенең гомере өзелде.

Юрий Владимирович Үзәк Комитетка аз вакыт, бер елдан аз гына артыграк җитәкчелек итте. Әмма шушы вакыт эчендә никадәр күп эшләнде. Партия, КПССның XXVI съезды курсы белән барып, аны иҗади баетып, КПСС Үзәк Комитеты җитәкчелегендә илебезнең экономик һәм социаль прогрессның барлык юнәлешләрендә ышанычлы төстә алга баруына иреште.

Юрий Владимировичның эшчәнлеге күпкырлы булды, һәм партия ышанып тапшырган җаваплы постларда ул үзенең бөтен көчен һәм белемен халык интересларына хезмәт итүгә бирде.

Юрий Владимировичның Үзәк Комитетның ноябрь (1982 ел) һәм аннан соңгы Пленумнарындагы тирән эчтәлекле чыгышлары һәркайсыбызның хәтерендә, ул чыгышларда социализмның өстенлекләрен тормышка ашыруның, коммунистик төзелешнең актуаль проблемаларын хәл итүнең ачык программасы бирелде.

Ул коммунистларны, барлык хезмәт ияләрен экономиканы тизрәк үстерүгә, халык хуҗалыгын идарә итүне камилләштерүгә, оешканлыкны һәм дисциплинаны ныгытуга туплау өлкәсендә Үзәк Комитетның һәм Политбюроның эшчәнлегенә оста һәм энергияле төстә юнәлеш бирде.

Коллектив тәҗрибәгә таянып, иҗтимагый үсеш ихтыяҗларын төгәл сиземләп, Юрий Владимирович Совет дәүләтенең куәтен ныгыту, совет кешеләренең тормыш хәлен яхшырту буенча партия алып барган эшкә зур шәхси өлеш кертте.

Ул партиянең тынычлык сөючән тышкы политик курсын, атом-төш сугышы куркынычын бетерүгә, империализмның агрессив казынуларына кискен отпор бирүгә юнәлтелгән курсын эзлекле рәвештә тормышка ашыру өчен нык торып көрәште.

Без партиябезгә, бөтен совет халкына килгән зур кайгыны тирән кичерәбез. Әмма ленинчы коммунистларның бурычы — үз сафларын тагын да тыгызрак туплау, партия белән халыкның бердәмлеген ныгыту. Үзәк Комитет Политбюросы, Үзәк Комитет Пленумы партиянең киләчәктә дә дөрес Ленин курсы белән нык һәм эзлекле рәвештә алга бару ихтыяры какшамас булуын бөтен илгә, бөтен дөньяга күрсәтер, дип ышана.

КПССның тарихи XXVI съездында һәм Үзәк Комитетның аннан соңгы Пленумнарында эшләнгән һәм җитештерүне интенсивлаштыруга, экономиканың нәтиҗәлелеген күтәрүгә, фән-техника прогрессын тизләтүгә, Азык-төлек программасын тормышка ашыруга, совет кешеләренең материаль һәм рухи ихтыяҗларын тагын да тулырак канәгатьләндерүгә юнәлтелгән линиясе нык торып һәм максатчан рәвештә тормышка ашырылачак.

Партия эшчеләр сыйныфының, колхозчы крестьяннарның һәм интеллигенциянең какшамас союзын, Ватаныбыз халыкларының туганнарча дуслыгын киләчәктә дә ныгытачак.

КПСС һәм Совет дәүләте тынычлык, барлык илләрнең халыклары арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлек идеалларына, социаль прогресс идеалларына һәрвакыт турылыклы булачаклар.

Кадерле иптәшләр! Политбюро КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре турындагы мәсьәләне тикшерде һәм бердәм рәвештә миңа партиябез Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп иптәш Константин Устинович Черненконы сайлау турында Пленумга тәкъдим кертергә кушты.

Константин Устинович зур тормыш мәктәбен үтте. Ул авыр крестьян хезмәтен дә, солдат хезмәтен дә, авыл райкомының көндәлек эшләрен дә белә.

Ул күп еллар буена Красноярск, Пенза, Молдавия партия оешмаларында, КПСС Үзәк Комитеты аппаратында партия эшенең җаваплы участокларына җитәкчелек итте.

Константин Устинович, кайда гына эшләсә дә, үзен һәрвакыт массаларны талантлы оештыручы, марксизм-ленинизм идеяләрен ялкынлы пропагандалаучы, бөек партиябез политикасын тормышка ашыру өчен какшамас көрәшче итеп күрсәтте.

Коммунистларга, совет кешеләренә Константин Устинович Коммунистлар партиясенең һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе буларак, Леонид Ильич Брежнев һәм Юрий Владимирович Андропов кебек Ленин тибындагы җитәкчеләрнең турылыклы көрәштәше буларак билгеле.

Үзәк Комитет Политбюросында һәм Секретариатында эшләгәндә Константин Устинович партия һәм дәүләт җитәкчелегенең ленинчыл стилен үстерү һәм ныгыту өчен күп эшләде, аңа иҗтимагый үсешнең мөһим мәсьәләләрен тирәнтен аңлау, ирешелгәннәргә һәм хәл ителмәгән проблемаларга бәя биргүгә реаль якын килү, кадрларга карата югары таләпчәнлек һәм шул ук вакытта дустанә мөнәсәбәт, хезмәт ияләренең инициативасына һәм тәҗрибәсенә таяну хас.

Константин Устиновичка кешеләрне ялкынландыру осталыгы, һәр эшкә новаторларча якын килү, иптәшләрен бердәм коллектив эшкә туплау хас.

Аның массалар белән даими аралашырга омтылуын, һәр кеше язмышына — талантлы галимме ул яки атаклы металлургмы, солдат анасымы яки яшь язучымы — һәркайсына игътибарлы булуын басым ясап әйтәсе килә.

Нык үскән социализм җәмгыятен камилләштерүнең зур теоретик проблемаларын эшләүдә, КПССның озак перспективага исәпләнгән идеология эшчәнлегенең тулы концепциясен булдыруда Константин Устиновичның роле зур.

Константин Устинович безнең тынычлык сөючән тышкы политикабызның стратегик юнәлешләрен формалаштыруда, КПССның халыкара коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәте бердәмлеген һәм тупланганлыгын ныгыту өлкәсендәге эшчәнлегендә бик актив катнаша.

Безнең хәрби работникларыбыз Константин Устиновичның илнең оборона сәләтен ныгыту, Кораллы Көчләребезне хәзерге заман техникасы белән коралландыру, армия һәм флотның кешеләр составын идея ягыннан чыныктыру мәсьәләләре белән никадәр күп шөгыльләнгәнен беләләр.

Политбюро, Константин Устинович Черненко КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре постында партиябезнең сугышчан штабына лаеклы җитәкчелек итәр, дип ышана.

Ленинчыл Үзәк Комитет тирәсенә һәм аның житәкче ядросы тирәсенә тыгыз тупланып, партиянең XXVI съезды, аның Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары эшләгән ачык һәм төгәл эш программасы белән коралланган коммунистлар, барлык совет кешеләре киләчәккә оптимизм белән карыйлар һәм үзләренең фидакарь хезмәтләре белән бөек Ватаныбызның тагын да чәчәк атуын тәэмин итәргә әзер торалар.

## КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш М. С. ГОРБАЧЕВ чыгышы

Иптәшләр! Без КПСС Үзәк Комитетының партия һәм халык тормышындагы җаваплы моментта җыелган чираттан тыш Пленумын тәмамлыйбыз. Пленум бердәмлек һәм тупланганлык шартларында үтте. Пленумда җитәкчелекнең дәвамчанлыгы мәсьәләләре партия һәм халык алдында гаять зур җаваплылык тойгысы белән хәл ителде.

Пленум партиянең киләчәктә дә КПССның XXVI съездында, КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1982 ел), июнь һәм декабрь (1983 ел) Пленумнарында эшләнгән ленинчыл курс белән барачагын күрсәтте. Бу иптәш Черненко Константин Устиновичның КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре постына бертавыштан сайлануында, партия һәм дәүләтнең эчке политикасы һәм тышкы политик эшчәнлеге проблемалары буенча аның КПСС Үзәк Комитетының бүгенге Пленумындагы чыгышында әйтелгән положениеләрне һәм нәтиҗәләрне тулысынча яклауда аеруча көчле гәүдәләнде.

КПСС Үзәк Комитеты членнары, Пленумда катнашучылар һәммәсе дә урыннарга, партия оешмаларына кайткач, партия Үзәк Комитетының шушы Пленумына хас булган кебек бердәмлек һәм тупланганлык, югары таләпчәнлек һәм җаваплылык рухында эш итәрләр дип Политбюро исеменнән ышаныч белдерергә рөхсәт итегез.

Сезгә барыгызга да эшегездә уңышлар телибез.

Пленум ябык дип игълан ителә.

# КОНСТАНТИН УСТИНОВИЧ ЧЕРНЕНКО

Константин Устинович Черненко 1911 елның 24 сентябрендә Красноярск краеның Новоселово районы, Большая Тесь авылында туган, рус.

1931 елдан КПСС члены. Югары белемле — педагогия институтын һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы партоештыручылар югары мәктәбен тәмамлаган.

К. У. Черненко үзенең хезмәт тормышын яшьли башлаган, кулакларда ялланып эшләгән. Аның шуннан соңгы бөтен хезмәт эшчәнлеге комсомол, ә аннары партия органнарында җитәкче эш белән бәйле. 1929—1930 елларда К. У. Черненко Красноярск крае, ВЛКСМның Новоселово райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире була. 1930 елда ул үзе теләп Кызыл Армиягә китә. 1933 елга кадәр чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, чик буе заставасының партия оешмасы секретаре була.

Армия хезмәтен тутырганнан соң К. У. Черненко Красноярск краенда: партиянең Новоселово һәм Уяр райкомнарының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, Красноярск крае партия мәгарифе йорты директоры, партиянең Красноярск край комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары, партиянең Красноярск край комитеты секретаре булып эшли.

1943 елдан К. У. Черненко ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы партоештыручылар югары мәктәбендә укый. Укуын тәмамлагач, 1945 елдан партиянең Пенза өлкә комитеты секретаре булып эшли. 1948 елда Молдавия ССРга җибәрелә һәм Молдавия Компартиясе Үзәк Комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп раслана. Бу постта эшләгәндә ул республикада экономика һәм культура төзелешенә, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүгә күп көчен һәм белемен бирә.

1956 елда К. У. Черненко КПСС Үзәк Комитеты аппаратына эшкә тәкъдим ителә, анда ул пропаганда бүлегендә секторга җитәкчелек итә һәм бер үк вакытта «Агитатор» журналының редакцион коллегиясе члены итеп раслана. 1960 елдан ул СССР Верховный Советы Президиумы Секретариаты начальнигы булып эшли. 1965 елда К. У. Черненко КПСС Үзәк Комитетының Гомуми бүлек мөдире булып раслана.

1966—1971 елларда ул — КПСС Үзәк Комитеты членлыгына кандидат. Партиянең XXIV съездында (1971 ел, март) КПСС Үзәк Комитеты члены, ә 1976 елның мартында, партиянең XXV съездыннан соң булган КПСС Үзәк Комитеты Пленумында КПСС Үзәк Комитеты секретаре булып сайлана.

1977 елдан ул — КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат, ә 1978 елдан — КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены. СССРның 7—10 нчы чакырылыш Верховный Советы депутаты. РСФСРның 10 нчы чакырылыш Верховный Советы депутаты. К. У. Черненко Европада иминлек һәм хезмәттәшлек буенча халыкара киңәшмәдә (Хельсинки, 1975 ел) Совет делегациясе члены булды. Венада коралсызлану мәсьәләләре буенча сөйләшүләрдә (1979 ел) катнашты.

Константин Устинович Черненко — Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе. Партия куйган барлык постларда ул югары оештыру сәләтен, партиячел принципиальлеген, бөек Ленин эшенә, коммунизм идеалларына чын күңелдән бирелгәнлеген күрсәтте. К. У. Черненко — совет җәмгыяте тормышында партиянең житәкчелек ролен күтәрүнең, партия һәм дәүләт эше стилен һәм методларын камилләштерүнең, социалистик демократияне үстерүнең актуаль мәсьәләләре буенча күп кенә фәнни хезмәтләрнең авторы.

КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында К. У. Черненко хәзерге шартларда КПССның идеология эшчәнлеген яхшыртуның төп юнәлешләре билгеләнгән доклад белән чыкты.

Ватан алдындагы зур хезмәтләре өчен Константин Устинович Черненко ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды һәм өч Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Советлар Союзының күп кенә медальләре белән бүләкләнде. Ул — Ленин премиясе лауреаты.

К. У. Черненко социалистик илләрнең югары бүләкләре белән бүләкләнде.

# КПСС Үзәк Комитеты,
# СССР Верховный Советы Президиумы,
# СССР Министрлар Советының
## *Коммунистлар партиясенә, совет халкына*
# МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле иптәшләр!

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, барлык совет халкы авыр югалтуга дучар булды. Ленин партиясенең һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе, социалистик Ватаныбызның ялкынлы патриоты, тынычлык һәм коммунизм өчен армый-талмый көрәшүче Юрий Владимирович Андроповның гомере өзелде.

Аның тормышы — партия һәм халык интересларына, бөек Ленин эшенә чын күңелдән бирелеп хезмәт итү үрнәге. Партия кушуы буенча эшләгән барлык постларда Юрий Владимирович Андропов үзенең бөтен көчен, белемен, гаять зур тормыш тәҗрибәсен партия политикасын тайпылышсыз тормышка ашыруга, коммунистик идеяләрнең тантана итүе өчен көрәшкә бирде. Ю. В. Андроповның бөтен күпкырлы эшчәнлегендә — комсомол эшендә һәм Бөек Ватан сугышы елларында Карелиядә партизаннар хәрәкәтен оештыруда, партия һәм дипломатия эшчәнлегенең гаять җаваплы участокларында зур политик җитәкче сыйфатлары ачык күренде. Ул дәүләтебез иминлеген ныгытуга күп хезмәт куйды.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре һәм СССР Верховный Советы Президиумы Председателе постларында эшләгәндә иптәш Андроповның — Ленин тибындагы җитәкченең — гаять зур сәләте һәм оештыру таланты бөтен көч белән ачылды.

Ю. В. Андроповның КПСС Үзәк Комитетына җитәкчелек итү вакыты кыска булды. Әмма бу вакыт эчендә партия, XXVI съезд курсыннан барып, аны иҗади яктан баетып, экономик һәм социаль прогрессның барлык юнәлешләрендә илебезнең алга таба ышанычлы баруын тәэмин итте.

КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1982 ел), июнь һәм декабрь (1983 ел) Пленумнары партия һәм халык тормышында, аларның какшамас бердәмлеген ныгытуда мөһим этаплар булды. Пленумнар карарларында, Ю. В. Андропов чыгышларында партиянең хәзерге стратегиясе — җитлеккән социализмны камилләштерү стратегиясе үстерелде һәм конкретлаштырылды.

Бу чорда партия һәм халыкның тырышлыгы экономиканы үстерүне тизләтүгә, халык хуҗалыгын идарә итүне яхшыртуга, партия, дәүләт һәм хезмәт дисциплинасын ныгытуга, кадрларның җаваплылыгын күтәрүгә, массаларның иҗади активлыгын үстерүгә тупланды.

Партия тарафыннан күрелгән чаралар бер максатка — совет кешеләренең тормыш дәрәҗәсен үстерүгә, Совет дәүләтенең куәтен көчәйтүгә буйсындырылды. Боларның барысында да Юрий Владимирович Андроповның хезмәтләре гаять зур.

Ю. В. Андропов социалистик бердәмлек илләренең һәрьяклы хезмәттәшлеген үстерүгә, халыкара коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтенең бердәмлеген һәм тупланганлыгын ныгытуга, халыкара азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшен яклауга шактый өлеш кертте.

Аның җитәкчелегендә КПСС Үзәк Комитеты һәм Совет дәүләте халыкара мәйданда ленинчыл тышкы политик курсны — атом-төш сугышы



ЮРИЙ ВЛАДИМИРОВИЧ АНДРОПОВ

куркынычын бетерү, империализмның агрессив казынуларына көчле отпор бирү, тынычлыкны һәм халыклар иминлеген ныгыту курсын эзлекле төстә һәм ныклык белән тормышка ашыра килделәр.

Бу кайгылы көннәрдә коммунистлар, барлык совет халкы партиянең ленинчыл Үзәк Комитеты, КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы тирәсенә үз сафларын тагын да тыгызрак туплыйлар. Советлар Союзы хезмәт ияләре Коммунистлар партиясен үзләренең сыналган, коллектив юлбашчысы итеп саныйлар, аның халыкның төп интересларын чагылдыручы эчке һәм тышкы политикасын тормышка ашыру өчен чын күңелдән бирелеп көрәшергә әзер торалар. Партиянең ленинчыл курсы какшамаслык. Партия КПССның XXVI съездында, аның Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнарында эшләнгән ачык һәм төгәл хәрәкәт программасы белән коралланды.

КПСС киләчәктә дә җитештерүне һәрьяклап интенсивлаштыру, фән-техника прогрессын тизләтү, оешканлык һәм дисциплинаны көчәйтү, халык тормышының материаль һәм рухи дәрәҗәсен туктаусыз үстерү линиясен нык һәм максатчан итеп үткәрәчәк. Ул эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм интеллигенциянең какшамас союзын, СССР халыкларының туганнарча дуслыгын ныгытачак, социалистик демократияне үстерәчәк, кешеләрне совет патриотизмы һәм пролетар интернационализм, коммунизмның бөек идеалларына бирелгәнлек рухында тәрбияләячәк.

Хәзерге катлаулы, куркыныч төстә кискенләшә барган халыкара шартларда КПСС, Совет дәүләте тынычлык эшен эзлекле төстә яклауны, түземлелек һәм уяулык күрсәтүне, империализмның авантюристлык планнарын кискен төстә өзүне, илнең оборона куәтен ныгытуны үзләренең иң беренче бурычы итеп саныйлар.

Совет халкы бәхәсле халыкара мәсьәләләрне көч белән хәл итүгә ныклы рәвештә каршы торэ. Безнең идеал — сугышсыз дөнья. Ныклы тынычлык өчен көрәштә тугандаш социализм илләре, коммунистлар һәм эшчеләр партияләре, милли һәм социаль азатлык өчен көрәшүчеләр, атом-төш һәлакәтен булдырмауны яклап чыгучы киң халык массалары безнең белән.

Партиябез һәм дәүләтебез киләчәктә дә иҗтимагый стройлары төрле булган дәүләтләрнең янәшә тыныч яшәү принципларын нык һәм тайпылышсыз рәвештә үткәрәчәк. Без барлык илләр белән тыныч яшәргә, тынычлык хакына намуслы һәм конструктив төстә эшләргә әзер торучы хөкүмәтләр һәм оешмалар белән актив хезмәттәшлек итәргә телибез.

Совет халкы яхшы белә: партия Үзәк Комитеты, аның җитәкче ядросы Ленин байрагына, Бөек Октябрь эшенә какшамас тугры. Партия халык ышанычын изге итеп саклый һәм совет кешеләренең мул тормышта яшәве һәм бәхете турында кайгыртуны үз эшчәнлегенең иң югары максаты дип саный. Партия һәм халык бердәмлеге безнең көчебезнең чыганагы булды, хәзер дә шулай һәм киләчәктә дә шулай булыр.

Юрий Владимирович Андропов коммунистлар, барлык совет кешеләре хәтерендә Маркс-Энгельс-Ленин тәгълиматына чиксез бирелгән, принципиаль һәм тыйнак, хезмәт кешеләре күңеленә якын, аларның ихтыяҗларына һәм сорауларына сизгер, бөтенесен социалистик Ватан интересларына буйсындыра белүче кеше булып мәңгегә калыр.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы, коммунистлар, барлык совет кешеләре үзләренең сыйнфый аңлылыгын һәм оешканлыгын, югары коллективизм сыйфатларын яңа көч белән күрсәтерләр, максатчан фидакарь хезмәтләре белән халык хуҗалыгы планнарын һәм социалистик йөкләмәләрен үтәүне, Бөек Ватаныбызның тагын да чәчәк атуын тәэмин итәрләр, дигән тирән ышаныч белдерәләр.

**Галина Васильева,**

Балык Бистәсе районы «Масловский» совхозы директоры, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы

# АЛМАГАЧЛАР ИЛЕНДӘ

Туган җиребезгә яңа яз килә. Сизәсездер: һаваны бөре, туфрак, дым исе хушландырганнан-хушландыра бара. Күп тә үтмәс, кар китүен дә көтеп тормастан, беренче чәчәкләр күренә башлар. Бу хозурлыкны тагын да күркәмләндереп илне күңелле бәйрәм — Халыкара хатын-кызлар көне 8 Март тантанасы шаулатып ала. Журналның шушы санында чыгыш ясарга тәкъдим булуыннан файдаланып, мин барлык укучы хатын-кызларны: әниләребезне, әбиләребезне, апа-сеңелләрне ихластан тәбрик итәм, аларга бәхет, саулык-сәламәтлек, хезмәтләрендә уңышлар телим. Мәгълүм ки, безнең ил кызлары тел-теш тидерә торган түгелләр, үздереп эшлиләр, вакытның кадерен беләләр, биргән вәгъдәләрендә торалар, гаиләләре бөтенлеген саклау өчен дә кулларыннан килгәнчә тырышалар.

Минем үземнән еш кына: «Галина Павловна, әйтегез әле, совхоз директоры булып эшләү авырмы?» — дип сорыйлар. — Хатын-кыз эше түгел бит инде бу», — дип тә өстиләр. Алдан ук ачыклап куйыйм: миңа бирелә торган бу сорауның адым саен кабатлануының сәбәбе билгеле — совхоз директоры, колхоз председателе кебек җаваплы урыннарда хатын-кызлар сирәгрәк очрый.

Бәлки, моңа охшаш хезмәткә алынган кызларга файдасы тияр — үзем кичергән хәлләр турында тәфсилләбрәк языйм әле.

Соңгы елларда хуҗалык җитәкчеләре шактый тотрыклы була башлады. Бу хәл — председатель, директорларның еш алмашуыннан тәмам туеп беткән авылларга уңай йогынты ясый. Безнең «Масловский»га да егермедән артык җитәкче килеп киткән. Беренче айларда миңа:

— Сигез аеңны тутыра алсаң, бик хуш, — диләр иде. — Бездә шуннан артык тоткарланмыйлар.


Безнең татар кешеләре холкына хас үҗәтлек миндә дә бер олау. Бу юлы да: «Моңарчы башлаган эшне ташлап киткәнем юк иде, карап карыйк, — дип уйлап куйдым. — Бәлки әле, алай тиз генә җайга салып булмас, шулай да чамаламый ярамый», — дим. Әмма ләкин мондагы элек-электән тамырланган гадәтләр мин көткәннән дә сәеррәк һәм шактый тирәнгә киткән иде.

Иң яманы — хезмәт хакы алган кайбер ирләр, бухгалтериягә кереп, эчкече табыны оештырырга өйрәнгәннәр. Ул чакта безнең дирекция ике яклы иске агач йортта иде. Эшләп утырганда ишетәсең: икенче бүлмәдә хахылдашып көлүләр, йодрыклап өстәл төйгән, кычкырышкан тавышлар яңгырый. Карасам — әнә шул «бәйрәм» оешкан икән.

— Ни бу? — дим.

— У-у, Галина Павловна, рәхим итегез! Безнең гадәт шундый, акча алгач, монда кереп, сыйланмасак, күңел булмый,— диләр.

Исереклеккә каршы кискен көрәш башладык. Иң каты җәзаны акча алганда тойдылар: эш сәгатендә эчеп йөрүчеләрнең хезмәт хакы, премияләре киселде, курорт яки ял йорты путевкаларыннан колак какты-лар, квартирага чиратлары чигерелде. Авыл урамында исерекләр күренмәс булды.



*Рәсемдә: «Масловский» совхозы директоры Галина Васильева белгечләргә авылның генпланын күрсәтә.*

Мин монда ундүрт ел эшлим инде. Иң әүвәл ярым җимерек йортлардан торган авылны заманча итәргә, яңартырга, төзекләндерергә кирәк иде. Совхозның парткомы, профсоюз оешмасы, комсомоллар һәм дирекция, җиң сызганып, шул зур эшкә тотындык. Авылга төзүчеләр, берсеннән-берсе куәтлерәк механизмнар килеп тулды. Төзелешләр авылның төсен генә түгел, хезмәт алымын да кискен үзгәртеп, аны промышленностька көйләргә, шәһәрдәге эш ысулларына якынайта төшәргә мөмкинлек бирде. Зур ашханә, балалар бакчасы, мәктәп, мунча, сыерлар асрау комплексы, барыннан да кадерлесе — җиләк-җимеш консервлый торган әйбәт завод салып куйдык. Андый завод илдә дә берничә генә.

Директор вазифасын авырмы-җиңелме икәнен белү өчен, аның нилә белән шөгыльләнүен ачыклау хәерле. Бер нәрсәне генә алдан ук әйтергә мөмкин: булсынга тырышканда, бер генә эш тә җиңел түгел.

Башкалар ничектер, мин үзем, хуҗалыгыбыздагы эшләрнең серенә төшенергә тырышам. Чөнки кешегә эш кушканда, аның ни икәнен дә чамаламасаң, яхшы сыйфат таләп итәргә дә, нинди вакыт эчендә үтәлүен көтәргә дә белми аптырыйсың. Консерв заводы сала башлар алдыннан мин, Краснодарга барып, булачак заводыбызның әзер варианты белән танышып кайттым.

— Ник барына да үзең чабасың?— диючеләр дә табылды.— Инженерларың өйрәнгәч, шул җитмәгәнме инде?

Уйлап куям: ул инженерлар миңа киңәш сорап керсәләр нишләрмен? Заводның ни икәнен дә белмәгән көенчә белгечләрем хезмәтеннән яхшы нәтиҗә көтәргә хокукым булырмы? Минемчә, житәкчеләр мөмкин кадәр күбрәккә өйрәнер өчен тырышырга тиешләр. Авылда төрле яклап төзелеш башланып киткәч, мин төннәр буе шул хактагы китап-журналлар укырга тотындым. «Главтатстрой» кешеләре культура сараебызны эчке яктан сылаганда, аяк терәп, яхшы сыйфат таләп иттем. Көтелмәгәнрәк кисәтү булды, күрәсең — кутәрелеп бәрелделәр.

— Алай бик күп белгәч, алебастрны каян табарга кирәклеген дә әйтерсең, бәлки?— диләр.

Алар сүзендә дә хаклык ярылып ята. Төзелеш материаллары табу юлында әллә нинди оешмаларга йөреп, күпме вакыт югала. Төзү материалларын юллаудагы чуалчык мөнәсәбәтләр директорны тәэминатчы белән тәңгәлләштерә дә куя. Әлбәттә, жаның йоклаган булса, бу — минем эш түгел, дип, тик кенә дә утыра аласың, хужалыгың гына җәфа чигәчәк. Безнең совхоз исә уникаль заводны ике ел эчендә сафка кертте. Мондый предприятиенең булуы бездән такыр юллар, даими газ, ныклы электр челтәре, сууткәргеч, үзәктән җылыту җайланмалары һәм әлбәттә, эшчеләр өчен, заманча җиһазландырылган йортлар таләп итә иде. Бердәмлек булгач, бу максатыбызга да ирештек.

Консерв заводының үзлексез эшләве совхоз байлыгының үзәген тәшкил итүче җиләк-җимеш бакчасына: карлыган, чия, җиләк һәм аеруча алма уңышына бәйле. Җиләк-җимеш үстерү — бу авыл халкының күптәнге шөгыле. Бу хезмәтне яхшы беләләр, яраталар. Әмма...

Ул көннәр турында хәзер уйлавы да кыен миңа. Шактый йончыган хуҗалыкны тернәкләндереп, кешеләрнең ышанычын тоеп, рухланып эшләп ятканда, 1978 елның зәмһәрир салкын кышы килде. Шат күңел белән 1979 елны каршыларга әзерләнгән көннәр иде. 28 декабрьда ябырыла башлаган салкынлык сууткәргечләребезгә, электр чыбыкларына зыян-зарәт салмасын өчен, һәр тарафны ныклы күзәтү астына алдык. Аз гына куркыныч сизелсә, шунда ук чарасын күрә бардык.

Татарстанның башка якларында ничек булгандыр — бездәге суыклык минус илле градустан артып китте. Алмагачлар, чияләр тезелеп утырган бакчага борылып карарга курка башладым, аннан ыңгырашу авазы ишетелә сыман иде. Саташам дип торам.

Адәм баласын, үзәгенә төшеп, җәзалыйм дисәң, кәрәштә аны чарасыз ит икән. Җитмеш тугызның суыгы безне шул хәлдә тотты. Сигез йөз гектарга сузылган бакчаны коткарырга безнең чарабыз юк иде. Гектарына — дүртәр йөз төп алмагач, аларны күктән иңгән коточкыч салкыннан ничек саклыйсың?!

Май аена кадәр өметтә яшәдек, 29 майда илнең иң дәрәҗәле бакчачы биологларыннан оештырылган комиссия тикшерү үткәрде. Алар янында йөрергә кыюлыгым җитмәде. Авыр сүз әйтерләр дә, йөрәгем ярылыр шикелле тоелды. Тик барыбер хөкем карарыннан котылыр әмәл тапмадым. Кабинетыма килеп керделәр дә:

— Юк, Галина Павловна,— дип өзеп әйттеләр.— Бакчаң беткән. Совхозыңны башка берәр тармакка көйләү ягын кара. Бакчаны тергезергә синең гомер генә җитмәячәк: ун ел җирне корыган агачлардан арындырырга китәчәк, дүрт-биш ел яңа үсентеләр утыртсаң, тагын ун елдан яңа уңыш җыярга мөмкин — чирек гасыр кирәк.

Кичергән иң зур хәсрәтең ни дип сорасалар, әйтә алам — әнә шул сүзләрне ишетү булды. Аның авырлыгы совхоздагы төп таянычларымның рухи төшенкелеккә бирелүенә бәйле иде. Борынгы бабалары дәвереннән үк бакчачылык белән көн күргән Масловка халкы тәмам боегып калды. Кайберәүләр шәһәргә күченү чарасына ук кереште. Үзем дә авырып егылдым.

Авырып ятканда төрлесен уйладым. Совхозны терлекчелеккә генә

көйләп җибәрергә дә мөмкин иде. Абзарлар ярыйсы. Аннары яңа комплекс та өлгерәчәк. Экономикага һичнинди зыян килми. Аһ, әгәр кешенең рухи дөньясына экономиканың ныклыгы гына җитсә иде! Хәер, юк, кирәкми. Андый тормыш бик күңелсез булыр иде. Безнең совхоз кешеләре сандугачсыз, алмагачсыз язларны язга да санамыйлар. Ак чәчәккә гашыйк җаннар алар. Корыган агачның ботагы саен акча элеп чыксаң да, күңелләре күтәрелмәячәк иде аларның. Ә күңеле китек авылда мин нишли ала идем соң? Әллә, барына да кул селтәп, китеп кенә барыйммы икән, дип тә уйладым. Бу фикеремә каршы гаять көчле дәлилләр баш калкытты: «Әле авылның бер башына газ да үткәрелмәгән. Урамнар буйлап аркылы-торкылы тирән траншеялар сузылган. Кайсы— газга, кайсы — су өчен, кайсы — телефон кабеленә. Авыл тау-тау өелгән балчык арасында кала. Оятыңнан кая качып котылырсың?..

Кайттым да, бөтен авыл бер булып, бакчага чыктык. Галимнәр исәбе буенча, ун елда чистартылырга тиешле мәйдан, туңнар житкәләгәнче, ботак-тамырлардан арындырылган, сөрелеп, мамыктай күпертелгән иде инде. 1981 елның язында яшь үсентеләр утырттык. Үткән язда беренче чәчәкләр күренә башлады, алмалар пеште. Завод 1983 елда җиләк, карлыган һәм беренче чия, алмалардан кайнатып, кала кешеләренә миллион банка варенье озатты. Кешеләр таң калдылар. Мин үзем моңа гаҗәпләнмәдем. Алмагачлар иленең халкы бу бакча хакына нәкъ менә шундый фидакарьлек күрсәтергә тиеш тә иде.

Яшь алмагачлар яфрак ярып җибәргәч, бакчачы кызларыбыз йөзендә балкыган нурны күрсәгез иде сез! Язгы сулар кипшенүгә, кереп киттеләр бакчага, кар катламы билдән булганчы, өйләренә кайтмадылар. Кайбер көннәрне әйтеп тә карыйм:

— Бүген бик җилле, йөрмәгез, салкын тидерерсез,— дим.

— Юк, Галина Павловна, бармый калырга ярамый,— диләр.— Берничә рәтнең ботакларын тигезләп бетерәсе бар.

Беркөнне, болар нишләп яталар икән, дип, яннарына чыктым. Карап туя алмассың үзләренә: бит алмалары алсуланган, хәрәкәтләре житез, күзләре-башлары елмая. Яшь алмагачлары да үзләре кебек үк җыйнак, пөхтә, матур. Кызларым җаннары теләгән эшнең җайлы баруыннан шулай чибәрләнгәннәр икән!

Бакчабыз бөтен куәтенә уңыш бирә башласа, склadлар хуш исле алма белән тулса, заводыбыз ел әйләнәсенә эшләячәк. Хәзергә исә хуҗалыкның ныклы рентабельлелеге терлекчелектән килә. Керемнәребезнең алтмыш процентын терлекчелек бирә. Сыерларның чиста нәселлеләрен генә асрыйбыз. Алардан хәзергә елына 3800 литрлап сөт савабыз, моны 4000 гә җиткерәсебез бар әле. Җирләребезнең һәр гектарыннан 30—35 әр центнер ашлык җыябыз. Бөртекләләр буенча бишьеллык планыбыз үтәлде инде. Фуражны житәрлек калдырабыз. Мал-туардан рәхәт күрим дисәң, азыгыңны мул әзерлә! Бездә бу хакыйкатьне яхшы аңлыйлар. Әлегә табигать шартларына бәйле булуыбыз гына тез астына суккалап куйгалый.

1981 елның җәендә бик четерекле хәл кичердек. Озын кышларда, яз көттереп килгәндә, терлек азыгы кытлыгы ихтималын белә идем мин. Бу елда исә без җәй уртасында азыксыз калдык. Китә идем кырлар буйлап, әйләнеп кайтканчы, чәчләрем агарып чыга иде. Сыер теленә эләгерлек яфрак юк. Көйгән, корыган барысы да. Авылның өлкәннәре белән киңәштек. Алар су астында калган әлекке болыннарны искә төшерделәр. Киң булып җәелгән Камага ишарәләделәр. Корылыктан аның да суы саеккан, эчтә утраулар хасил булган. Анда ямь-яшел куе камыш чайкала. Алар инде совхоз җире түгел, шулай да тәвәккәлләдек. Беркөнне карасам, авылның 70—80 яшьлек картлары да көлтә бәйләп, камыш урып йөриләр.

— Кем кушты?—дим.— Өегездә тыныч кына утырсагыз, ни була?

— Бер генә көлтә бәйләсәк тә, совхозга файда бит, кызым,— диләр. Ихлас күңелле, изге ниятле безнең халык белән нинди генә кыенлыкны да күтәрергә була. Без хәтта шул корылык елында да бөртекләрдән 16 шар центнер ашлык алдык. Малларның баш саны кимемәде. Сыерларны комплекска күчергәч, терлекчелек ике сменалы эшкә күчәчәк. Керем дә артыр, дип торабыз. Хәзергә безнең хуҗалык чыгымына тотылган бер сум — бер сум да илле биш тиен булып әйләнеп кайта. Совхозның мондый тотрыклы рентабельлелеге кешеләребезнең фидакарьлегенә бәйле. Тора-торып үзем дә хәйран калам — ничек шулкадәр уңган алар! Карлыган җыйганда безгә Казаннан да килеп булышалар. Эшчеләребезне кала кызлары белән чагыштырып йөрим. Казаннылар көнгә биш-алты кило сыешлы чиләкне көчкә тутыралар. Безнекеләр утызар кило җыя. Бу — ифрат авыр хезмәт. Шуңа күрә без карлыган җыйгыч комбайн булдырырга тырышабыз.

Монда эшли башлавымның беренче елларында, авылның өлкәннәргә генә калып баруын сизеп, хафалана идем. Бүген Масловка күзгә күренеп яшәрә. Читтән килүчеләр дә шактый булды, үз яшьләребез дә совхозны үз итә хәзер. Яңа гаилә коручыларга нәкъ шәһәр өйләрендәге кебек квартиралар бирәбез. Авылның төп халкы руслар иде. Аларга украиннар, молдаваннар, чувашлар һәм без, татарлар, килеп кушылдык. Бер-беребезгә ярдәмләшеп, кунакка йөрешеп, күңелле итеп яшибез. Табыннарда һәр халыкның җыры яңгырый. Мин әниемнән отып алган, татарның борынгы җырларын яратам:

*...Ак укалар белән лә һай сары уканы бөкләп салып булмыйдыр сандыкка;*
*Сезнең кебек лә һай дусларны күреп-туеп булмыйдыр тансыкка...*

Без алдагы елларның тагын да хәерлерәк килүенә ышанып яшибез. Дөрес, моңа кадәр башкарылган эшләр дә байтак. Бу очракта мин үз совхозыбызның мул тормышын гына күздә тотмыйм. Сүземне беразаңлата төшим әле. Мин — сугыш чорында үскән кеше. Ачлыкның, өскә башка җитенкерәмәүнең ни икәнен җилкәмдә татып беләм. Әни, фронтка киткән әтиемнең бүреген сатып, миңа күрше авыл мәктәбенә йөрү өчен чабаталар алган иде. Мөмкин кадәр озаккарак чыдатырга теләп, мин аларны авылдан чыкканчы гына, аннары мәктәпле авылга кергәч кенә киям, озын юлны яланаяклап үтәм. Шул чакта, безнең өс-башлар кайчан да бер бөтәер микән, дип уйлый идем. Сугыштан соңгы бер арада урман хуҗалыгында эшләп алдым. Урман кисүчеләрнең ачлыктан интегүен күреп өзгәләнә идем. Землянкага көйләнгән кухняда, чиста суга манный ярмасы болгатып, зәңгәрсу боламык сыман аш пешерәбез. Анысы да кеше саен бер-ике кабымлык кына эләгә. Теләгәнче ашар көннәр булыр микән, дип көтә идек. Хәзерге эштә баш җитмәстәй кыенлыкларга очрасам, еракта калган шул көннәрне хәтергә алам: «Бәхетле син, Галина,— дим үз-үземә.— Халык тырышлыгы җилгә очмады, кешеләрнең нинди рәхәт тормышта яшәвен күрдең!» Үткәнгә борылып карауның шифасы бар. Ул чакта хыял гына булып тоелган теләкләребез тулысынча тормышка ашты. Коммунистлар партиясенең, Совет хөкүмәтенең авыл хуҗалыгын ныгытуга юнәлдерелгән чаралары бу юлда аеруча тәэсирле этәргеч ясадылар.

Безнең совхозда уртача хезмәт хакы йөз илле сигез сум, савымчыларныкы белән механизаторларныкы ике йөз сумнан арта. Шәхси хуҗалыклардагы мал-туар, суган, җиләк-җимеш уңышы да ел саен арта бара. Анысы да илнең Азык-төлек программасын үтәүгә шактый саллы өлеш булып кушыла.

Күңелләрне җиде кат күкләргә ашкындырып яңа яз килә. Мин инде алмагачларыбызның мөлдерәп тулган чәчәк бөреләре җырын ишетәм, көйләрен дә аңлыйм кебек. Бөреләр җырында тоткан юлыбыз турылыгы, эшебезнең хаклыгы, максатларыбызның, киләчәгебезнең җиңүчәнлеге яңгырый сыман. Алар да безнең хатын-кызларыбызны 8 Март тантанасы белән котлыйдыр шикелле.

Салисә Гәрәева

# УРАЛ СӘЛАМНӘРЕ

## Безнең яклар

Ул Чиләбе, Миасс, Кыштым, Әшә,
Урал тавы, Сим һәм Тамерлан,
Таганай, Уй, Караталлы-Аять —
Бөтенесе гел бер тамырдан.

Кунашак та, Аргаяш та монда,
Кызыл Чилек, Гөмби, Әй ага.
Таганайның нәкъ очына кунып,
Малахит Ай карый дөньяга...

Әтәч тавы эри күз алдында,
Урал суы ага. Кисегач
Зәңгәр дулкынында боҗырларын
Куандыра көн дә, кич булгач.

Аргуҗа күл, Сарсаз, Әчеле күлләр
Таңкә булып ята сибелеп —
Исеменнән монда татар, башкорт
Җаны, теле тора сизелеп...

Карагайлы-Аять дулкын кага,
Уфа суы тора уйнаклап.
...Халкыбызның тирән тарихларын
Саклап тора безнең бу яклар.

* * *

*Отговорила роща золотая...*
С. Есенин

«Отговорила роща золотая»,—
Шушы җырга тәмам гашыйкмын.
Ул яңраса, ташлыйм эшләремне,
Юлда булсам, туктыйм — ашыкмыйм...

Сары көзләр булып яктыра ул,
Җылы учак булып кал гына.
Ак җилкәннәр белән алып китә
Ерак калган яшьлек ягына...

Алларыма ал таңкәләр сибә,
Сары көнбагышлар ия ул.
Онытылган газиз исем булып,
Хәтер кылларына тия ул...

Бар җылыны җыйган моңы белән
Үткән гомерләргә илтә ул,
Сары каенсарга канат җәйгән
Җылы җилле көзге иртә ул.

Ягымлы да, моңлы, акыллы да
Мин яраткан шушы матур көй.
Гүя анда Россиянең җаны
Гүя анда — әнкәм торган өй!..

«Отговорила роща золотая...»
Үкендерми ләкин үткәнем:
Истә бары илем куенында
Сөенеп, сөеп гомер иткәнем...

* * *

Урманнарым! Рәхмәт олы җаныгызга,
Агачларым, рәхмәт, рәхмәт барыгызга!
Җилләрдә сез яфракларны көйрәттегез,
Һәрчак мине уйланырга өйрәттегез...

Чишмәләрем, тавышыгыз көмеш-көмеш,
Йөрәгемдә сүнмәс моң бар — сезнең өлеш.
Бала чактан миңа җырлар көйләдегез,
Халкым ничек яшәгәнен сөйләдегез...

Рәхмәт сиңа үскән җирем, мең-мең рәхмәт!
Синең белән һәр очрашу — җанга рәхәт!
Йөрәгемдә ялкын, сөю, моңнар — диңгез.
Бер балаң мин, туган җирем! Мин юк синсез!..

* * *

И, җәйләрнең көзгә күчү чоры!
Ямансу да үзе, матур да!
Көзләр җиткән, тик күңелем әйтә:
— И, яңадан язга кайтырга!..

Кабатлансын иде язгы ташу,
Бөреләрнең яңа саф чагы!
Кыш килмичә генә бар агачлар
Алмаштырсын иде яфрагын!..

Һәм үзем дә... Яшьлегемә кире
Кайтсам иде, үзем сизмичә!
Һәм башласам иде гомеремне,
Мәхәббәттән өмет өзмичә!.

Мөмкин түгел! Ләкин үкендерми
Үткән юлым, шөкер шунсына...
И, җәйләрнең көзгә күчү чоры!
Киләчәккә күңел омсына.

Илләр имин — шөкер шунсына!..

* * *

Үтте яшьлек, күптән чәчәк атты
Күңелемнең яшел үрентесе.
Күз алдымда җәйрәп таулар ята,
Колагымда завод гөрелтесе...

Цехлар шавы, мартен очкыннары
Күтәрделәр мине зәңгәр күккә.
Исемемне язып офыкларга,
Реактивлар уктай очып үткән...

Үтә гомер. Инде җимешләнде
Күңелемнең яшел үрентесе:
Колагымда мәңгелеккә калды
Яшьлек, завод, Урал гөрелтесе...

* * *

Берөзлексез сайрый чикерткәләр —
Тамаклары ничек карлыкмый?!
Җырда сөйли алар бу дөньяда
Кояш, Җир һәм Тормыш барлыкны.

Скрипка сызып мең кулларда,
Яшел җилән киеп, аланда
Чикерткәләр хоры озатып кала
Болын сукмагыннан барганда.

Бу — мәдхия кояш нурларына,
Муллыгына җирдә үләннең.

Алар кебек мин дә җылы җәйнең
Кайнар кояшына кинәндем...

Эссе җәйнең соңгы атналары,
Үләннәрдә соңгы аккордлар:
Озакламый болын өсләрендә
Оча башлар салкын ак карлар...

Табигатьнең законнары каты:
Саубуллашып, җәем баш ия.
Чикерткәләр хоры — матәм маршы,
Чикерткәләр хоры — мәдхия.

## Шигърияткә килдек

Шигърияткә без басудан килдек:
Кояш нурын эчкән идек без,
Илгә сугыш салган афәтләрне,
Газапларны кичкән идек без...

Шигърияткә без басудан килдек —
Буразнада салып итекне.
Фикеребез хезмәт мәйданында,
Халык арасында җитлекте.

Шигърияткә без ашыгып килдек —
Җиң сызганып килдек эшләргә.
Өлкән дуслар ихлас дуслык белән
Кул бирделәр безгә — яшьләргә.

Бодай кыры безгә сәлам бирә,
Завод ишекләре киң ачык.
Тормыш, кайнап, безгә азык бирә,—
Каршы килә, җәеп колачын!..

## Юлларга чык

Поездлар китә еракка —
Гудоклар сызып калэ.
Тәвәккәллә, юлларга чык,—
Язмыштан узып кара!

Гудоклар сызып кала да,
Төтеннәр узып кала.

Тәвәккәллә, юлларга чык,
Хыялы уйнак бала!

Тәвәккәллә, юлларга чык,
Көчеңне сынап кара...
Поездлар бирә сәламен —
Уралдан узып бара.

## Тау түбәсенә менгәч

Кояш нуры тулы тау түбәсе.
Аста — күлләр, таулар, кыялар.
Күл өсләрен бизәп акчарлаклар
Уйнап-уйнап балык куалар...

Чикерткәләр сайрый, тау битенә
Ничек кенә алар менгәндер?
Кантар-кантар җылы ташлар ята —
Болытларга алар мендәрдер?

Башын куеп, ташка, җиләк пешә,
Яшеренә яшел кәлтәләр.
Наратлыктан күке аваз сала
Очкан тиңдәшенә үпкәләп.

Болыт килә йөзеп, уртасына
Кырын ятып кына ак идең!
...Менгән тавым Илмән, йөргән ягым —
Якты Урал дигән як минем!

# Лена Шакирҗанова

## Башланмаган тормыш

Башланмаган тормыш тора алда:
Минем әле бура буратып,
Өр-яңа өй салып кирәсем бар,
Өмә ясап — буран уйнатып...

Түбәсенә аның кояш кунар,—
Нуры төшәр нигез ташына.
Әйдүк, түрдән уз, дип, ашыга-ашыга
Чыгармын күк бәхет каршына.

Тәрәзләре урам якка карар —
Күренеп торсын ыгы-зыгысы.
Капкасыннан йомыш-фәлән белән
Өзелмәсен кече-олысы.

Иданенә аның игелек иңәр,
Түшәменә шатлык түшәлер.
Бирдәнберем дигән бер тиңенә
Насыйп булыр кайнар түшәге...

Башланмаган тормыш тора алда,
Иртә әле әйтү «хуш»ларны.
Мичтән генә чыккан бөтен калач
Табынымда көтәр дусларны...

## Тылсымлы сый

Сыйпамага — телем түгел,
Сыйламага сыем бар.
Күңелемнең иң түрендә
Гаҗәеп бер коем бар...

Бер сәбәпсез күлдерә ул,
Бер шәрабсыз исертә.
Сусауларын җанның баса,
Алҗыганга — көч кертә.

Ул коеның хикмәте бар,
Могҗизалы бер көче:
Туганлашып аерылыша
Суын эчкән һәр кеше.

Көе юкны көйле итә,
Моңы юкны елата.
Моңы тулып, сагыш баскан
Күңелләрне юата...

Хуш киләсез, өем ачык,
Йөзем ачык, мул сыем.
Илһам бирсен әле дуска
Шул коемның тылсымы.

Бу табынга килеп чыккан
һәр кешегә урын бар.
Берләштергән, серләштергән
Татлы сыем — җырым бар.

## Чәчәк җыры

Үләм, бетәм, дигәндә дә
Тылсым табып, терелән мин.
Ничәнче кат инде, янә
Мәхәббәткә бирелә мин.

Ә болытлар җилләр белән
Сүз берләшеп куйганмыни:
Килә ява, килә ява —
Чиләкләрдән коямыни...

Ачылырга һич юк ирек,
Төшми якты, салкын җиле.
Бөреләрем туңар инде,
Ышыкламый кем дә килеп.

Әрәм иттең. Ишетмичә
Калдың тагын чәчәк җырын.
Ярый әле тамырымда
Ага иде кояш нуры...

## Балхаш белән очрашу

Сары-Шаган. Казахстан күге.
Шундый якты монда йолдызлар.
Бер белмәгән чит-ят стансада
Калдыра да китә поездлар.

Балхаш инде ерак түгел, диләр.
Юлдашларым — алар — мондагы,
Көпчәкләрне узып тәгәрәде
Дала буйлап уйлар йомгагым.

Нинди җырлар, димен, көтә икән,
Чыккан саен яңа сәфәргә.
Кемдер дәште: туташ, йокламагыз,
Килеп җиттек инде шәһәргә...

Ят урамнар чумган ай нурына.
Туп-турыга үскән тупыллар
Арасыннан күренеп калды — ярга
Йөзеп чыккан шәрә дулкыннар...

Балкып ята Балхаш, кочагына
Атылырга иде исәбем,

Дулкыннарын оялтырмын, диеп,
Тыеп калдым көчкә хисләрем...

...Аяз көндә Балхаш уйный-уйный
Җиде төрле төскә керә, ди.
Җиде төсен аның җете күзле
Бәхетлеләр генә күрә, ди.

Таңда килермен дә сәламемне
Тапшырырмын аңа Иделдән.
Ә дулкыннар миңа каршы йөзеп,
Җиде төскә кереп җемелдәр...

## Сөйләшү

— Күңелләрең нечкәргән ич,
Ни ишеттең, кемнәрдән?
— Янсаң, җаным, сөйсәң, җаным,
Нечкәрәсең гөлләрдән...

Мәрҗәннәрең чәчелгән ич,
Толымнарың сүтелгән...

— Күпме бушка көтелгән ич,
Шуңа күңелем кителгән...

— Толымнарың бир, үримче,
Мәрҗәннәрең бир, тезим.
— Юк, кирәкми, үз хәлемне
Белим җаным, тик үзем...

## Үзем белән үзем сөйләшәм мин

Үзем белән үзем сөйләшәм мин,
Әңгәмәдәшләрем юктан түгел.
Кайчагында шулай үз-үзенә
Сорау бирә, җавап әзли күңел.

Үзем белән үзем киңәшәм мин,
Теләктәшләр юктан түгел һич тә.
Кеше акыл бирә тора, ә син
Гел үзеңчә ниятлисең эштән...

Сөйләшеп тә, киңәшеп тә була,
Тик серләшеп булмый үзең белән...
Кылган эшләреңне күрә бел син
Намус дигән шаһит күзе белән.

Шунда гына замандашларыңның
Туры карау мөмкин йөзләренә.
Һәм иркенләп гәпләшергә мөмкин,
Кушылырга — дөнья сүзләренә...

Эльмира Шәрифуллина

# БЕР КЫЧКЫРДЫ КӘККҮК

## Мин аңымда

Йөрәгемне таш-кыяга бәрдем,
челпәрәмә килде хисләре.
Мин аңымда ләкин: хәтерлимен
таңнан якты булган кичләрне.
Хәтерлимен
очкан йолдызларның
кинәт туктап, өнсез калуын.
Безне күзләп, Зөһрә гүзәл кызның
зәңгәр күзкәйләре талуын.
Ак каенның ап-ак гәүдәсендә
калтыранып каны тукталды.
Янып торган алсу чәчәкләрнең
сусыл таҗын чорнап ут алды.
Җилли-җилли яңгыр килә иде,
кереп качты урман куенына.
Бер кычкырды кәккүк,
һәлакәт күк —
бер хәбәр күк килер кайгыма.
Бер кычкырды кәккүк,— тынып калды,—
салдылармы элмәк муенына?..
Мин аңымда.
Бар да күз алдымда —
таңнан якты иде кичләре.
Йөрәгемне таш-кыяга бәрдем,
челпәрәмә килде хисләре...

## Кай арада?

Мәхәббәткә яшел болын диеп,
болыннарда ярсу колын диеп
уйладым.
Хыялымда шул болынны гизеп,
хыялымда шул колынны җигеп,
туйладым.
Иртәләрне таң нурына манып,
үземнекен атлавыннан танып,
яраттым.

Чәчкә утлап йөргән хисләремне,
сабый чакта күргән төшләремне
тараттым.
Уйлар кайта, кайта урап-урап,
яшел болыныма бурап-бурап,
кар яуган.
Егәр кергәч кенә беләкләргә,
кай арада безнең йөрәкләргә
кан сауган?..

## Эзлим

Шәүләң йөри көн дә төн дә,
күз алдымда буй-сының.
Йомшак җилләрнең исүе —
гүя сулышың, тының.

Зәңгәр төсләр тетрәндерә —
әллә синең күзләрең?
Торып-торып искә төшә
васыятьтәй сүзләрең.

Хатирәләрне яшәтәм,
яңартамын үземчә.
Синеңчәлек җитми ләкин,
синдә китте синеңчә.
Уйларым хәбәрсез төндә,
колачым ал таңнарда.
Калдырып китә икән бит,
китмәс дигән ярлар да.

Хисләрем кар суларында,
күзем ялгыз айларда.
Ятим җанны бөтен итәр
чама да юк, җайлар да.

Зәңгәр күктә ничә йолдыз —
берәмтекләп санармын.
Һәр сулышта сине эзлим,
эзлим...

Бәлки табармын...

## Әкиятләргә китәм

Сыкрый-сыкрый сызлый бу йөрәгем,
сине эзли моңсу күзләрем.
Чит-ятларга әйтмәс серләрем бар,
чит-ятларга әйтмәс сүзләрем.
Октябрьның кара төнен эзлим,
бәхилләшеп бер сүз әйтергә.
Каныктың ла, дөнья, билләһи дип,
өйрәндең дип, күңел китергә...
Томырылып килеп кергән идең,
минем салмак, тыныч дөньяма.
Тора салып: «Сөям!»— дигән идең,
сөюгә юк иде чик-чама.
Шул ук тизлек белән китеп бардың,
хушлашып та калып булмады.
Өлешемә тигән көмешемне
көне бирде, төне урлады...
...Әкиятләргә китәм, әкиятләргә:
тылсым көтә арган йөрәгем.
Тылсымсыз да кайтыр идең дә бит,
их, белмисең безгә кирәгең!..
Үрсәләнеп шулай йөргән чакта
карурманга кереп адашам.
Миллион елдан гына кире кайтам,
үз-үземә кайтам яшь аша.
Бар ятимне, бар толларны җыеп,
кычкырасы килә илереп.
...Әкиятләргә китәм, карурманга,—
бер могҗиза көтәм тилереп!..

## Күзләреңә чумган гына идем

Иренеңә кайчан кагылдым да,
иңнәреңә кайчан сарылдым?
Шашкын булдым микән мәхәббәттә,
вулкан булдым микән — ярылдым.

Күзләреңә чумган гына идем,
төпкелләргә туры килдемме?
Кайгыларның кара урманында
ешкынлыкка барып кердемме?

Әле генә куенында идем,—
дуенында идем сөюнең.
Газап күрмәгәннәр белми булыр,
Кайгылардан янып-көюне.

Иңнәреңә кайчан сарылдым соң,
иреңнәреңә кайчан кагылдым?
Ялгызлыкка бирмәс өчен, җанны
җырларыңа төрдем, кабындым.

## Сызлану

Бүгенемә калган икән
әчесе сагышларның.
Колагымда шавы тора
син сөйгән арышларның.
Тургайларың кайтты үксеп,
яшьлегең тугаена.
Аргамакларың җилдерә,
искән җил уңаена.
Очты-китте хыялларым —
очтылар чиксезлеккә.—
(Кубарылып сызлый күңел,
юрама көчсезлеккә.)
Бер йолдызларга кагылып,
бер җиргә егылдылар.
Нахак телләр күзгә карап,
җаныңа орындылар.
...Үткәннәргә хәер-дога,
киләчәккә мең савап.
Без сөйгәнчә сөя белеп,
яшәсен берсе кабат...
Гашыйк диңгезче егетнең
дулкында оранннары.
Килсен иде дә кайгылар
дулатып урамнарны,
үтеп китсен иде алар
гүя ки, язда дулаган
сыерчык бураннары.
...Тик үтеп китсен иде дә!..

## Безнең күңел

Безнең күңел нигә моңлы икән,
безнең күңел ничә кыллы икән?—
онтыласы иде тын калып.
Гарасатка кереп югалмыйча,
гөнаһларга гына уралмыйча,
бәхет йөрсә икән укталып.

Безнең күңел нигә моңлы икән,
безнең күңел ничә кыллы икән,
ду купканнар шашкын хисләрем.
Чыгымчылап чапкан ярсу тайдай,
дулкыннарга кунган моңсу айдай,
ярсу яки моңсу кичләрем.
Безнең күңел нигә моңлы икән,
безнең күңел ничә кыллы икән,
кушылырга сайрар кош кирәк.
Җаннан җанга йөри моңнар күчеп...
Тик дөньясы менә булыр ничек?—
Сабырлыклар бирсен... Түз, йөрәк!

## Зәңгәр эңгер

Кагылмагыз, кайнар хисләремә,
кагылмагыз, зәңгәр төсләремә.

Кагылмагыз, минем сөюемә,
үксүемә, янып-көюемә.

Зинһар өчен, зинһар — кагылмагыз,
чит йөрәкләр, безне сагынмагыз.
...Кылану да, кыстату да түгел,
күнми булгач, күнми күндәм күңел.

Кагылмагыз!
Кагылмагыз, изге хисләремә,
мин табынган зәңгәр төсләремә.
Юксынуым — сары сагыш булып,
чыксын әйдә, чыксын төсләремә...

Кагылмагыз! Зинһар кагылмагыз!
Чит йөрәкләр, безгә ягылмагыз!..
Изге килеш, тугры килеш гомер —
күз алдымда торсын зәңгәр эңгер!

*1982—83.*

## Бикә Рәхимова

### Авылда иртә

Иртә таңнан — кояш белән бергә тордым.
Мөгрәп узды сыер көтүе.
Урам якка гына күз салыймчы диеп,
рәхәт икән чыгып китүе.

Урам күллегендә инде кош-корт халкы.
Казлар китә зуррак инешкә.
Кай арада торган үрдәк балалары —
чебен аулый килү-килешкә.

Карт тирәктән күтәрелә карга халкы,
я чумалар оя-куышка.
Ябык мәче үзе белгән разведкага бара,
шәүлә булып җирдән шуыша.

Чык ялтырый — көн аяз һәм җылы булыр.
Игенчеләр инде басуда.
Җир шатлыгы белән яшәвемне тойдым,
кыр ягына аяк басуга.

* * *

*Кемнәрең бар? Кемнәрең юк?*
*Кемнәрең сагындыра?*
Халык җыры

Югалтулар эзләп йөри,
Эзли җанны җентекләп.—
Каным башы юк инде.
Тагын юклар күп инде...

Түгелде дә чәчелде,
чәчелде дә сибелде.—
Сибелгән сагындыра.

Җанга якын кешеләрне
барлап йөрим бөртекләп.—
Якын кешем бул инде.
Шөбһәләрең куй инде!—
Барлаганым — беректе,
беректе дә терелде.—
Терелэр сагындыра!
Тере көе дә үлгәннәр
арта бара көн-көнләп.
Бар караш: терелтүче,
бер карап көйдерүче!
Яндырды ул, көйдерде —
Гомерлеккә сөйдерде.—
Шул караш сагындыра!

## Көтү

Көтү, көтү: балаңны көтү,
Иреңне көтү. Интегеп бетү.
Электән шундый хатын-кыз
хәле:
Гомергә көтү, ярату — көтү...

Берәмләп көтү, бөртекләп көтү.
Берегеп бетү, күнегеп бетү.
Киткәнне көтү, китсә дә көтү.
Кайтаваз: китү, китү һәм китү...

Күз текәп көтү, онытылып көтү.
Тәрәзә бозын керфек эретү,
Яшь тә кушылгач, тынычлап
китү:
Яңа көч сорый фидакарь көтү.

* * *

Диңгез!
Мин сине сөймим —
сине сөючеләр күп.
Минем шушы көнчелек,
бирмәсә дә өстенлек,
нигәдер ул хаклы күк:
сөям
кара күзле күлләрне,—
гашыйкмын үзләренә.
Салдым мин төпләренә
инде күпме серләрне —
каралды күл күзләре.

* * *

Көтмәгәндә, яшен кебек,
сукты мәхәббәт камчысы.
Тәнем күмердәй көйсә дә,
җаным — аның ялчысы.

# Эльмира Сэсэнбаева,

башкорт шагыйрэсе


## Кассандра

Троя патшасы Приамның
Сылу кызы Кассандра...
(Оныта алмый җәфаланам!)

Күрәзәлек кылган аңны
Кара хәвефләр яндыра!
(Нәрсәдәндер — хафаланам...)

Юк, исән газиз җиркәем!
Беләм, хаклыкның җиңәрен —
Ышанам илемә.
Тик менә...

Тыйнаксыз алланың каһәре
Яшь әүлиядән көлдертә халыкны,
Чал акылны калдырып тилегә...

Инәлә Кассандра, елап-сызланып:
— Паристан бәлаләр башланыр,
Кертмәгез калага!

Приам, Приам, колак сал кызыңа.—
Трояны дошман алыр,
Кол булыр балалар!

Кая тыңлау... Әремнән әчесең,
Чал тарих, әүлия зиһенгә,—
Ихтирам-дәрәҗә — исемгә...

...Караңгы вакытлар куенын
Яктырта күрәзә акыллар —
Ил һәм Җир хакына хәвефле факеллар...
Язмышлар — факеллар!

* * *

Чыңрау эңгер назлый сандугачның
Су өстеннән аккан авазын.
Бәллүр һава тоткарламый кичнең
Таулар чагылдырган җавабын.

Май төненең илаһи бер җаны
Нурлангандай була күп төстә.
Аң-тойгыны кошчык адаштырып,
Коелгандай була күк — өскә.

Искә килсәң — хозур әкият иле.
Күз алдыңда — туган авылың.
Ялт-йолт итеп чыңлый төн эчендә
Сандугачның моңнар давылы.

* * *

Арып тынды кеше. Ни уйлый ул?
Тәүбәләрен искә аламы?
Яшьлегенең керсез идеалларын
Берән-сәрән читкә саламы?

Үз-үзеннән көлеп ачынамы,
Картлык акылына ышанып?
Әллә елый микән ялгызлыкта,
Ерак хыяллардан бушанып?

Көрәш ярсуларын урап үткән
Танышлары аннан көләме?
Шул чагында тагын да бер җанда
Киләчәк чаткысы сүнәме?

## Яңалык тойгысы

Һәр кеше дә саклыймы кадерләп
Хәтерендә — үткәннәр яктысын?
Һәр кеше дә яклыймы һәр вакыт
Бүгенгедә — Киләчәк чаткысын?

Һәр шәхестә үсә микән нурлы
Гаҗәп чәчкә — яңалык тойгысы?
Һәр йөрәктә яңгырыймы чыңлап
Саф тавышлы яшьлекнең быргысы?!

*Стәрлетамак шәһәре*

## Гомәр Бәширов

# КӨЗГЕ АЧЫ ҖИЛЛӘРДӘ...

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

Безнең буын хәзерге заманга кискен сыйнфый көрәшләр, бөек сынаулар аша килде, бик күп тарихи вакыйгаларны үз башыннан кичерде. Әнә шул бөек вакыйгалар тормышны ничек үзгәртте, аерым шәхесләр язмышына ничек тәэсир итте, гомер юлында кемнәр белән очраштым, кемнәрдән аерылдым, ниләр күрдем, ниләргә ирештем, кемнәрне югалтып, кемнәрне таптым? Тарих караңгысына кереп югалганчы боларны язып калдырырга кирәктер.

Бу әсәрне язу ихтыяҗын тудырган сәбәпләрнең тагын берсе — укучы, укытучылардан килгән төрле сорауларның күп булуы. Ниләр генә кызыксындырмый аларны! Фәлән иптәш ничек язучы булып киткән? Әдәби әсәрләр язарга ничек өйрәнгән, нәрсәдән башлаган?

Әдәбиятка моннан 50—60 ел элек килүчеләрнең тормыш һәм иҗат юлы аеруча кызыксындыра икән аларны. Чөнки ул чакта хәзерге яшьләргә аңлашылып җитмәү ихтималы булган житди үзенчәлекләр бар иде.

Мәсәлән, югары уку йортында булып узган бер очрашуда миңа шундый сорау биргәннәре бар:

— Нишләп сез укырга соң кердегез, ничек яшь чактарак берәр институтка кереп карыйсы итмәдегез?..

Хәзерге күзлектән караганда, бу бик урынлы сорау, чынлап та, әйе шул! Нишләп?

Бу әсәрнең баш өлеше кыскарак кына булып 1965 елда «Совет мәктәбе» журналында һәм сайланма әсәрләремнең II томында басылып чыккан иде. Хәзер мин аны бөтенләй диярлек яңадан язып чыктым, бик күп яңа вакыйгалар өстәдем.

Үзем кичергәннәр, күреп белгәннәр, башкалардан ишеткәннәр — һәммәсе арттырмыйча-киметмичә, ничек булган булса, шулай язылган.

### I

Тынгысыз һәм ыгы-зыгылы фани бу дөньяга мин шушы гасырның нәкъ башында килергә иткәнмен, нибары бер генә атнага соңга калынган, ягъни 1901 нче елның 7 нче гыйнварында туганмын. Минем дөньяга килүем әти-әниләргә ул кадәр зур шатлык булгандыр дип әйтмәс идем. Чөнки, беренчедән, мин беренче бала да, төпчек малай да түгел, бәлки әнинең өченче, әтинең сигезенче баласы идем. Мәгълүм ки, ата-ана беренче бала туганда беренче дип, тансык булганга куана. Төпчеге

тугач, «аллага шөкер, шат-иншалла, бүтән булмас инде», дип соңгысы булганга сөенә. Икенчедән, адәм баласы дөньяга бик зур дәгъвалар белән туа бит. Аның тамагы да тук булсын, асты да коры булсын. Әйтерсең, аның монда биреп куйганы бар, әйтерсең, бу дөньяда аны гына көтеп торалар!

Мин элекке Казан губернасының Арча волосте Яңасала авылында туганмын. Зур шәһәрләрдән шактый ук ерак торган гадәттәге бер татар авылы инде ул. Яңасаланың табигате, ул тирәдәге башка авыллар белән чагыштырганда, ярыйсы ук бай да, матур да дип әйтергә мөмкин. Янында гына калын урманнары шаулап утыра, урман эчендә — зур аланнары, әрчүлекләре. Зур булмаса да, болыннары, авыл уртасыннан уза торган инеше дә бар. Тыкрык турысы саен саф сулы салкын чишмәләре чыгып тора. Һәр чишмә суының үзенә хас тәме, үзенчәлеге бар. Берише чишмәнең суын чәй кайнатырга, аш-су әзерләргә тоталар, икенче берсен терлек-туарга гына эчертәләр. Анысын «ат чишмәсе» дип йөртәләр. Балачагымнан калган иң матур хатирәләр әнә шул җанга якын ягымлы табигать күренешләре белән бергә күз алдына килә.

Җиде яшемдә абыстайга сабакка йөри башладым.

Безнең укый торган урыныбыз — мөәзиннәрнең аскы өйләре — яртысы җиргә иңгән тынчу һавалы бер бүлмә иде. Салкынрак көннәрне бозау да, сарык бәрәннәре дә безнең янга керәләр. Без, җиде, сигез, тугыз яшьлек бала-чага, малае-кызы шунда бер егермеләп җыела идек.

Иртән караңгылы-яктылыда ук килеп сәке кырыена тезелешеп утырабыз да Фатыйма абыстай биргән сабакны тырыша-тырыша кабатларга тотынабыз. Яңарак кергәннәр «әлиф, би, ти, си...»не такмаклый, «Әбҗәд», «Иман шарты» өйрәнә. Егерме балага калынлы-нечкәле егерме тавыш. Бүтәннәр кычкырганны ишетмәс өчен, һәркем мөмкин кадәр үзе ныграк кычкырырга тырыша. Өй эче гүләп, шаулап тора. Безнең тавыш хәтта өй эченә генә сыя алмыйча, урамга хәтле бәреп чыга торган иде.

Әмма мәгънәсе аңлашылмый, күңелгә бернинди дә азык бирми торган бу ят сүзләрне бертуктаусыз кабатлап утыруның туйдырмыйча хәле юк. Китә шуннан шаярулар, китә төрле җор сүзләр, тел ваткычлар. Берсе шунда, укый торган сабагына ялгап, такмак көйләргә тотына:

Кәлиматен тайбатын,
Безнең әни бай хатын.
Түше тулы тәңкә,
Борыны тулы...

Икенче берсе сабак укыган кыяфәт белән рәхәтләнеп җырлап утыра.

Әлиф-бине дә, әбҗәдне дә ятлыйсың, кыш буенча ясинның да «башына» җитеп, һәфтияккә «төшәсең». Әмма шунысы бик гаҗәп, укыганнарыңның мәгънәсен дә, аларның нигә кирәклеген дә, кайчан да булса бер кирәк булачакмы, юкмы икәнлеген дә белмисең. Чөнки гарәп сүзләрен тәрҗемә итеп аңлатмыйлар, аларны бары тик дин сабагы итеп түкми-чәчми ятлаталар гына иде.

Ләкин моның белән Гайнетдин абзый һәм Фатыйма абыстай истәлегенә тузан кадәр дә күләгә төшерәсем килми. Әгәр шулай аңлашылса, бу минем тарафтан остазларга карата ихтирамсызлык булыр иде. Чөнки алар безне, изге эш эшлибез дип, чын күңелдән тырышып, укыттылар, ничек кенә булмасын, ак өстендә караны иң башта алар аңлатып бирделәр, беренче хәрефләрне алар таныттылар. Кем белә, беренче карауга никадәр кыргыйлык кебек күренсә дә, бәлки әле заманына күрә сабакка килмәгән өчен идән астына ябулар да кирәк булгандыр? Сабагын ташлап ярты көнен урамда уздырган, соңыннан күзенә ак-кара

күренмәстән, бил тиңентен суга батып, пычранып килеп кергән ул малайның азрак шулай кайнарлыгын сүрелдерү, ихтимал, бөтенләй үк файдасыз да булмагандыр? Чыннан да, шуннан соң мин сабакны калдырмаска тырыштым.

Икенче елны мәдрәсәгә кучкәч, дәресләр кызыклырак үтә башлады. Бу вакытта инде 1905 нче елгы революция йогынтысында татар авылларында да мәктәпләр ачылгалый иде. Безнең авылдагы шикелле яңача укытучы мәктәпләрдә, гарәп һәм фарсы теленнән, ислам дине кануннарыннан тыш, география, ана теле һәм хисап[1] та укыталар иде. Дини фанатизм һәм искелек чыганагы булган кадим мәдрәсәләре белән чагыштырганда болай чын фәннең үзен укый башлау, әлбәттә, ул чагында зур яңалык, мәгариф өлкәсендә прогрессив юлга басу һәм алга китеш иде.

Шушы яңача укыту нәтиҗәсендә, без беренче елны ук диярлек укыйязарга, «хисап» чыгарырга өйрәндек.

Шулай да мәдрәсәдә дә күп вакытны дин сабаклары алды. Төрле догаларны, аятьләрне күңелдән ятларга, намаз укый белергә, корьән өйрәнергә, ислам диненең төрле кагыйдәләрен хәтерләп калырга кирәк була иде. Билгеле, болар безнең тормышка бөтенләй ят нәрсәләр иде. Аларның мәгънәсен дә, нигә кирәклеген дә белмәгәнлектән, көчәнеп кенә укый ала идек.

Без — Россия уртасында үскән балалар. Бездә һәр авылның мул сулы елгасы, я инеше, чишмәсе, һич югында күле бар. Ә безне, әгәр «кинәт» кенә чүлгә барып чыксак, ничек итеп ком белән тәһарәт алырга (тәяммем[2] сугарга) өйрәтәләр. Янсә гошер, фытырны кайчан бирергә, күпме бирергә? Ишәк асрасаң ничек тә, дөя асрасаң ничек? Безнең исә ишәк белән дөяне күргәнебез дә юк, без аларны сурәтләрдән күреп кенә белә идек.

Шушы аңлаешсыз һәм эчпошыргыч дәрәҗәдә күңелсез сафсатаны ятлый торгач, ялыкканбыз, күрәсең, хәлфә абый чыгып китү белән без күмәкләшеп яңа шигырьләр укырга, үз телебездә җырларга тотына идек. Безнең шикелле үк шәкертләрнең күңелсез тормышы турында язылган бер шигырь безгә бик тә ошады. Без аны көйләп укый торган булдык. Мин аны соңрак кына белдем: ул шагыйребез Габдулла Тукайныкы икән.

Шулай да мәдрәсәдә укыган елларны һәм хәлфәбез Зәбихулла абыйны мин бик рәхәтләнеп искә алам. Шул берничә ел эчендә мәдрәсә безгә, заманына күрә, ярыйсы ук төпле белем бирде.

Ләкин миңа мәдрәсәне тәмамлап ук чыгарга туры килмәде. Абый солдатка китте, әти исә ул вакытта шактый ук картайган, тормышның михнәтләрен күп күреп, бик йончыган иде инде. Ул еш кына авыргалый башлады. Тормыш итү тагы да кыенлашып китте. Уйлаштылар да мине, «Тамагы да үтәр, һөнәргә дә өйрәнер»,— дип, тегүчегә өйрәнчек малай итеп бирделәр. Бу тегүче аз сүзле, берникадәр йомыграк кеше иде. Без аның белән Ямаширмә авылында кыш буена йорттанйортка кием тегеп йөри башладык. Кем нәрсә тектерә: ярлыраклары бишмәт, чикмән, баерракларга тун, толып, хатын-кызларга җикет, я бишмәт.

Билгеле, минем кебек унике-унөч яшьлек малайга, туган йортыннан, ана иркәсеннән, иптәш малайларыннан аерылып, көзен-кышын көн саен бөкерәеп чыгарып кием тегеп утыруы ансат түгел иде. Тегүче шактый ук оста кеше иде осталыкка. Тегүчелек һөнәренә өйрәтергә булдыра да иде. Әмма никадәр тырышсаң да, әллә ни эләкмәячәге алдан ук билгеле булды.

---

[1] Хисап — арифметиканы ул вакытта шулай атап йөрталәр иде.

[2] Тәяммем сугу — су булмаган урыннарда кулны комгә, я туфракка тидереп «тәһарәт алу».

Шулай да, эшләргә кирәк иде. Иртә белән торып тотынасың, төнге уникеләргә кадәр. Кайчакларны, бигрәк тә төнлә белән, шулкадәр йокы баса, хәтта ялгыш кына йоклап китәсең дә, машинаның кәтүк кадагына бәрелеп, маңгай күпереп чыга. Әмма барыбер тырышырга кирәк. Чөнки яман атлы буласы килми. Безнең әти эшлексезләрне, уңмаганнарны яратмый торган коры кеше иде. Яз көне тегүдән йөреп кайткач, чәй янында ул, мөгаен:

— Я, малай ничек?— дип сораячак.— Кулыннан берәр эш киләме? Әллә бик җебегән бер сөрхәнтәй булып чыктымы?

Юк, минем алай сөрхәнтәй, я уңмаган малай буласым килмәде. Аннан соң ни әйтсәң дә, тегүче малай сабан туенда да юньлерәк киенә инде ул...

Тегүче абыйның иртә таңнан торып ярты төннәр узганчы эшләтүе шактый ук кыенга килде. Ләкин ул да нишләсен? Бала-чагасы ишле, өе иске. Гомер буе шулай эшләп тә, ул тормышының очын-очка көчхәл белән генә ялгый алган.

Мин күңел җылысын китаплардан табарга тырыштым. Ул вакытта инде матур әдәбиятны яратып, тәмен белеп укый башлаган идем. Без кием тегәргә кергән йортларда корьән, һәфтияк һәм башка шундый дини китаплар куя торган киштәләрдән үзем өчен күңел азыгы да тапкалый торган идем. Габдулла Тукайның юка гына шигырь китаплары, шул ук Тукай чыгарган халык җырлары, Хуҗа Насретдин лятифалары, бәетләр һәм хикәяләр килеп чыккалый иде. Тегүче абый икенде-ахшам вакытында ял итәргә дип күрше-күләнгә, я дус-ишләренә чыккалаганда яки җомга намазына киткәндә мин, бөтен дөньямны онытып, китап укырга керешәм. Кайчакны шулай ашык-пошык, кача-поса кечкенә китапларны «йотып» та өлгерә идем.

## II

Укучылар белән очрашканда бездән күп вакыт:

— Сез ничек язучы булып киттегез?— дип сорыйлар.

Шул ук сорауны минем үземә-үзем дә биргәнем бар. Чыннан да, миндә язучы кайчанрак «башланды» икән? Унике-унөч яшьләрдә чагымда Каенсар кешесенең буранда адашып үлүе турында хикәя язгандамы? Әллә тагы да элегрәкме? Әллә соңракмы? Һәрхәлдә, кулга каләм алып аңлы рәвештә әдәби әсәр язарга тотынганда гына түгел. Үзенең нинди эшкә сәләте булуын аңлый алмыйча шактый олыгайганчы төрле һөнәргә тотынып караучы, бик озак арлы-бирле сугылып йөрүчеләр аз булмый. Ләкин шундый вакытта кинәт кенә исенә төшеп, «тукта, язучы булыйм әле!» дип әдәби әсәр язарга керешү мәгънәсезлек булыр иде. Чөнки язучы булу өчен иң башта табигать биргән талант кирәк. Шул табигый талантның бөреләре чәчәк атмас борын ук шиңмәсен өчен, яшь кешегә әйләнә-тирә мохит та, җәмгыять тә, аерым шәхесләр дә ярдәм кулы суза. Билгеле, кыстап торган эчке омтылышка буйсынып, яшь кеше моның ни икәнен чын-чыннан аңлап та җиткермәстән, үзе дә язмышына таба атлый булса кирәк. Унөч яшьтә хикәя язуым, күрәсең, әнә шундый адымнарның берседер.

Минем иң беренче остазларым, мөгаен, тормыш белән табигать булгандыр. Язучы булып өлгергәннән соң әдәби әсәр язарга утыргач, берәр рухи халәтне, я булмаса тормыш вакыйгасын тасвир итәргә кирәк булганда мин андыйларны күп вакыт үз тормышымнан эзли идем. Тормышның кайбер маҗаралары күңелгә шулкадәр тирән кереп калган, аларның күбесе әле хәзер дә истән чыкмый. Бик авыр хәлдә калган чаклар, кимсенү-хурланулар, гаделсезлектән җәберләнгән чаклар да аз булмады. Әдәбият юлына аяк басканнан соң андыйлар үзеннән-үзе әсәрләремә керә барды.

Шулай да, ул вакыттагы тормышны тоташтан кап-караңгы итеп күз алдына китерсәң, бу берьяклылык һәм тар карашлык билгесе булыр иде. Һәр ягыннан житешкән «түгәрәк» тормышта яшәмәсәм дә, шатлык дигән нәрсә безнең өйдә көн саен кунак булмаса да, бу әле бөтен гомер елап-сыктап узды дигән сүз түгел. Куанычлы көннәр дә аз булмады. Сабый чакның мавыктыргыч уеннары, жәен-көзен, кышын-язын ындырларда, су буйларында, бакчаларда, тагын әллә кайларда бөтен дөньяңны онытып «шайтан чабулар» — балачакның берни белән дә тиңләп булмастай якты, гүзәл сәхифәләре түгелмени? Арып-талып, телең чыгарлык булып кайтып кергәндә, анаң сиңа бер жамаяк катык, я салкын әйрән суза, я өстенә май яккан хуш исле икмәк тоттыра. Тагын сиңа ни кирәк!

Мондыйлар бөтен сабыйлык чорын моңсу нур белән яктыртып, ямьләндереп тора.

Мин балачактан ук табигатькә гашыйк булып үстем. Минем балалык тормышыма үзенең жәйге-кышкы, язгы-көзге күренешләре белән ничектер шунда табигать үзе дә үрелеп бара башлады. Табигатьтәге үзгәрешләрне нишләптер берсен дә ваемсыз гына яки күрмичә генә уздыра алмадым. Күкселләнеп торган еракгагы урман өстенә жәйге алсу шәфәкъ иңүенә, гөрселдәп күк күкрәүләренә, ялт-йолт итеп яшен яшьнәүләренә мин, яланаяклы авыл малае, дулкынланып, хәйран калып карап тора идем. Табигатьнең шушындый гажәеп бер кодрәтле дәһшәтендә, йөгәнсез котырынуында үзенә бер матурлык бар иде шикелле. Кайчакларны котың алынырдай булып куркып та каласың. Дөбер-шатыр күкрәп, ут уйнатып килгән таудай кара болытлар бөтен дөньясы белән синең өстеңә ишелер кебек. Әмма шул ук вакытта табигатьнең серле, тылсымлы матурлыгы да нәкъ шунда кебек, бу күренештән беркем дә жиңә алмаслык дәһшәтле кыргый бер куәт ургыла, ул ничектер, минем рухи халәтемә дә тәэсир итә иде.

Тора-бара табигатьнең әнә шундый мәһабәт һәм бөек күренешләрен күңелемә сеңдерепме, языпмы, сурәтен төшерепме, ничектер беркетеп каласым килә башлады. Әмма ничек итеп? Ул ягын мин белми идем әле.

Минем рухи яктан үсүемә, эстетик зәвыгым тәрбияләнүгә, гомумән, дөньяны аңлавыма иң нәтиҗәле тәэсир иткән көчләрнең тагын берсе — һичшиксез, әдәбият булды.

Яхшы китаптан алган тәэсирне көзге караңгы көннәрдә ялтырап килеп чыккан якты кояш нурларына тиңләргә мөмкин булыр иде. Баштарак, сайлап тормыйча, кулыма ни эләксә, шуны укыдым. Тарихи китаплар да күп укылды. «Кыйссасыләнбия», догалыклар, мөнажәтләр, бәетләр, жыр китаплары, фал китабы, төш юрагычлар, хәтта иске календарьлар да калмады. Һәммәсе дә кызык, һәммәсен дә беләсе килә, һәммәсендә дә нидер эзлим, шуларның кайсында булса да мин белмәгән нинди дер бер сер, яңалык ачылып китәр кебек хис итә идем. Ул чакта мин, мөгаен, гомеремдә беренче тапкыр зур шәһәргә килеп, һәммә нәрсәгә исе китеп, кызыксынып карап йөрүче хыялый бер малайга охшаганмын.

Билгеле, ул заман авылында китап дигән нәрсә алай күп түгел иде әле. Булса, шул муллада, хәлфәләрдә, укый-яза белүче тагын берничә кешедә булгандыр. Уңдүрт-уңбиш яшьтә чагымда мин инде үзебезнең якын-тирәдәге китапларның һәммәсен дә укып бетергән идем.

Мәдрәсәдә укый башлагач, Арча базарына барган саен үзем дә икешәр, өчәр, дүртәр тиенлек кечкенә китапчыклар алып кайткалый башладым. Шулай итеп, безнең китап киштәсе торган саен тулылана барды. Һәр яңа китап әлеге шул кичләрдә бөтенебезгә кычкырып укыла торган булып китте.

Әмма бераздан мине алар гына канәгатьләндерми башлады. Шул

елларда ук үзлегемнән рус телен өйрәнергә керештем. Бераз аңлый башлагач ук, күрше рус авылындагы укытучыдан, хәтта күрше авыл побыннан җыңелчә язылган төрле хикәя һәм әкият китаплары алгалый торган булдым. Авыл малаеның бертөрлерәк кенә ага торган сүлпән тормышына китаплар яңалык, сөенеч һәм шатлык алып керделәр. Эшләремне бетергәннән соң, мин көндез дә, кичләрен дә китап укырга утыра идем.

Шундый бер хәл истә калган. Бер елны көз көне Казанга солы сатарга чыгып китәр алдыннан әти ничектер юмартланып алды.

— Әйтегез, Казаннан кайсыгызга нәрсә алып кайтыйм?— дип сорады.

Өйдәгеләр кайсы матур шәлъяулык, кайсы күлмәклек алып кайтуын үтенделәр. Миңа да кием-салымнан берәр нәрсә, әйтик, я кәләпүш, я юньлерәк чалбарлык алып кайту бик урынлы булган булыр иде. Ә минем тел очында башка нәрсә эленеп тора икән:

— Әти, син миңа Әбугалисина китабы алып кайт, яме?— дидем.

Мин «Әбугалисина»ны узган ел ук мөгаллим абыйда күреп кызыгып калган идем. Хәзер инде әтинең шуны миңа алып кайтуы икеләтә куандырды. Бердән, алтмыш яшькә җиткән атамның минем үтенечемне онытмыйча үземә атап китап алып кайтуы, аның миңа ихтирамы, минем теләгем белән исәпләшүе шатландырды, икенчедән, китап шүрлегендә минем тагын бер яхшы китабым артты.

Атны тугарып лапаска бәйләп куйдым да, ашарга-эчәргә дә утырмыйча, китапны укырга керештем. Өйдәгеләр ашап-эчеп йокларга яттылар — мин укыйм. Төннең дә байтак вакыты узды — мин һаман укыйм. Китаптагы вакыйгалар шул хәтле кызык иде, мин чырык-чырык көлә башлаганмын. Әнинең барыннан да бигрәк шунысы борчыды, күрәсең. «Улым, акылыңа зыян килер, тукта инде!»— дип әйтеп карады. Әни сүзен тыңламавыма күңелем рәнҗесә дә, барыбер туктый алмадым. Ахыр чиктә, «Керосинны бетерәсең!»— дигән сылтау белән утны сүндерергә куштылар. Китапның соңгы берничә битен ишегалдына чыгып ай яктысында укып бетердем.

Ләкин китап ахырындагы «Бу вакыйгалар тормышта алай ук булмаска мөмкин» дигән урыны мине чын-чыннан рәнҗетте. Китапта тасвир ителгән төрле гаҗәеп вакыйгаларга мин шулкадәр ихлас күңелдән ышанган идем, китапны язучыга[1] ачуым чыкты. «Дөрес булмагач, нигә аны китапка язып кеше алдарга?!»— дип мин аны «тетеп» ташладым. Бәлки, китап ахырындагы ул җөмләне, чыннан да, язарга кирәк булмагандыр?

Әдәби китаплар укыганда, минем күз алдыма моңарчы үзем күргән, үзем белгәннәргә бер дә охшамаган яңа дөньялар килеп баса, безнең авылда йөз ел буена да булмастай искиткеч вакыйгалар, гаҗәеп хәлләр гәүдәләнә иде. Дулкынланмаслык та түгел бит! Ул чакта мин үземне моңарчы беркем белмәгән серле яңа илләр, яңа җирләр ачкан бәхетле илгизәр кебегрәк хис итә башладым. Яшьтәшләрем минем бу кадәр китап белән «саташуымнан», китапта язылганнарга чын күңелдән ышануымнан көлеп, җае килгәндә үртәп тә алгаладылар. Русча китаплар да укый башлаганымны күргәч, әти мине зур укымышлы кеше булыр, һич югы «писер» яки «перкәшшек» булып китәр дип йөрый иде.

Кыскасы, әдәбият миңа күп нәрсә бирде, әйләнә-тирәдәге тормыш та ничектер яктырыбрак күренә башлады. Әкренләп минем аңымда, тормыш бар җирдә дә бездәге шикелле ярлы һәм караңгы түгел икән, көнкүрешне хәзергедән күп өлеш яхшыртырга, баерак итәргә була икән, дөньяда хезмәт кешеләренең бәхете өчен көрәшүче көчле, акыллы кешеләр күп икән, дигән фикер урнаша башлады.

---

[1] Ул вакытта бу китапны дөньяга чыгаручының Каюм бабай Насыйри булуына игътибар итми идем әле.

1917 нче елны илдә бөек революцион вакыйгалар кузгалгач, бөтен дөньяны тетрәткән бу зур үзгәрешләрнең безнең авыл кешеләрен дә бүтән тормышка, юньлерәк тормышка алып чыгасына зур өметләр багладык.



### III

Менә унсигезенче елның язы да житте. Илнең төрле якларында гражданнар сугышы кабынды. Авылда күкрәгенә кызыл бантик яисә бүрегенә кыеклатып киң кызыл тасмалар таккан кешеләр күренгәли башлады. Безнең авылның аңлырак егетләре кайсы кызыл гвардиягә, кайберәүләре кызыл армиягә язылып фронтларга киттеләр. Минем дә күңел ярсыган чак, ләкин мин армиягә алынырлык яшьтә түгел идем әле, күңелемнең кая ашкынуын, нәрсәгә омтылуын да белми идем.

Шундый көннәрнең берсендә, сабан чәчүеннән төшке чәйгә кайткач, атымны башакка куштым да безнең ак өйдә яшәүче яшь мөгаллимә — Хөршидә янына кердем. Җыйнак кына гәүдәле, ап-ак йөзле бу чибәр кыз безгә Казанның үзеннән балалар укытырга җибәрелгән беренче мөгаллимә иде. Мин Хөршидәдән алып торган китапны кайтарып бирдем дә шул китап турында сөйли башладым. Язучының Дим буенда булып узган хәлләрне шулкадәр ышандырырлык итеп яза алуы, укучының күңеленә шулкадәр тирән кереп, аның тойгыларын, уйларын шулай үзе теләгәнчә астын-өскә китерә алуы мине хәйран калдырган иде.

Мин китапта язылганнарга яшьлек беркатлылыгы белән чын күңелдән ышанып һәм сокланып:

— Их, ничек шулкадәр булдыра алды икән ул?! — дип куйдым. — Менә шулай яза алсаң, ә?!

Күрәсең, бу бертөрле киртәгә дә кермәстәй мәгънәсез шапырыну булып ишетелгәндер, чөнки Хөршидәнең зәңгәрсу кара күзләре тагын да зуррак булып ачылды. Ул, иренен бүлтәйтеп, минем кояшта көрәнсу төскә кергән дәү кулларыма, җил-яңгырда, кояш астында уңып кыр тузаны кунган өс-башыма күз салып, кашларын җыерды. Әйтерсең, мин кемнедер рәнҗеткән, әйтерсең, ниндидер бер изге әйбергә кагылган! Шулай карап торды-торды да кинәт кенә кабынып көлеп җибәрде.

— Яза алсаң дисеңме? Әдәби әсәрме? Ха-ха-ха!

Шунысы кызык, бу хәл һич кенә дә минем кәефемне кырмады. Киресенчә, аңа ияреп мин үзем дә көлә башладым. Чөнки, төпкәрәк карағанда, һич язучы булырга теләүдән әйтелмәгән иде бит ул. Һич юк! Минем андый ихтимал турында хәтта уйлап та караганым булмады. Кая инде ул миңа буй житмәстәй хыяллар белән мавыгу! Минем үз борчуым үземә житкән, миңа ул чакта әтидән калган хәлсез хуҗалыкны аудармыйча-түнтәрмичә, әни белән сеңелемне ач итмичә, ничек тә сөйрәп алып барырга кирәк иде. Бу, ниндидер бер омтылыш яки теләк булудан бигрәк, хәйран калудан, әдәбиятның тылсымлы көченә табынудан туган кайнар хис кенә, йөгәнсез бер яшьлек ашкынуы гына иде.

Минем шикелле үк беркатлы, тәҗрибәсез һәм хыялыйрак бу яшь мөгаллимә шундук миңа Казан язучылары турында сөйләп китте. Әмма аның хикәясендә язучылар ничектер, конфет кәгазьләрендәге сурәт төсле, бик тәти, бик нәзакәтьле, ифрат та нәзберек һәм чиктән тыш сәмави затлар булып чыктылар. Алар ап-ак йөзле, ап-ак куллы булалар икән, алтын балдаклар киеп, ап-ак якалар элеп, кыйммәтле фаэтоннарга гына утырып йөриләр икән. Житмәсә әле, урамга, я бакчага-мазарга чыкканда хәтта иреннәрен дә кызарталар, кашларын да каралталар, имеш...

Моңа кадәр укыган китаплар буенча мин язучыларны бөтенләй баш-

кача күз алдына китерә идем. Минем хыялымда алар тормышның вактөягеннән, андый бизәнү һәм ясанулардан бик югары торучы ниндидер гали затлар, пәйгамбәрләр шикелле бөек акыл ияләре, күпне күргән, ифрат бай тормыш тәҗрибәсе туплаган яхшы күңелле аксакаллар кебек кешеләр иде. Шуның өстенә, безнең шикелле гади кешеләр генә булсалар, сүз көче белән башкаларны шулай сихерли алырлар идемени? Шулай бер көлдерергә, бер елатырга гади кешенең ничек кулыннан килсен? Монысы инде, минем чын күңелдән уйлавымча, әкиятләрдәге тылсым, дин китапларында языла торган могҗиза сыман ниндидер чиктән ашкан бер куәт булырга тиеш иде.

Матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен әнә шулай чиктән тыш ярату, юк, алай гына түгел, әдәби образларга бөтен яшьлек дәрте белән чын күңелдән гашыйк булу, аларны иҗат итүчеләргә сәмави бер көчкә табынган кебек табыну — минем язучы булып китүемә төп этәргечләрнең берсе шул булмадымы икән?

Ихтимал, Хөршидә үзенчә хаклы да булгандыр, ихтимал, ул Г. Камалларны, Г. Тукайларны, шулар кебек халыкка якынрак торган язучыларны бөтенләй күрмәгәндер. Бик ихтимал ки, язучыларның андыйлары да булгандыр. Әмма алар минем күңелемне тартмады. Хөршидәнең мине дөрес аңламавы да, үземнең аңа шундый нечкә нәрсәне чамасызрак ычкындырып җибәрүем дә шундук үкендерә башлады.

Шулай да... Шулай да минем авыздан бу сүзләрнең юкка гына әйтелмәвен сиздем. Күрәсең, күңелнең иң тирән, иң яшерен урынында ниндидер өмет чаткысы бар, күңел нидер көтә, нәрсәгәдер хәзерләнә иде булса кирәк.

Иген эшләре никадәр генә кулны тоткарламасын, иң беренче нәүбәттә миңа белем кирәк иде, белем! Танышларымнан берсе шундый киңәш бирде:

— Әгәр дә укытучы булсаң, Казанга, зуррак уку йортына җибәрәләр,— диде.

1919 елның җәй ахырында волость башкарма комитетының мәгариф бүлегенә укытучы итеп алуларын үтенеп гариза бирдем. Озаклямыйча мине имтиханга дәштеләр. Күзләренең өстенә салыныбрак төшкән калын җирән кашлы, урта яшьләрдәге Хәмзин фамилияле бер абзый арифметика, география, ана теле һәм әдәбияттан минем белемемне тикшерергә тотынды, биш сүздән бер җөмлә язып бирүемне үтенде. Минем үз авылыбыз тирәсендәге табигатьнең гүзәллеге турында, Г. Ибраһимов һәм башка язучыларның китапларындагыча, «матур» сүзләр язасым килде. Яздым мин ул җөмләне. Әдәбият турында сораша башлагач, безнең ара шундук якынаеп китте. Укып чыккан китапларым турында мин аңа, күрәсең, сокланып, дулкынланып сөйләгәнмен. Ул берничә тапкыр урыныннан торды, яңадан утырды, миңа карап-карап алды. Авылда минем китап белән «җенләнүемнән» көләләр, мине «сәер» малай санап йөртәләр иде. Ә менә җитди чырайлы шушы акыллы абзый мине иң якын кешеләремнән дә яхшырак аңлый булып чыкты. Гаҗәеп хәл иде бу! Безне, моңарчы бер-берен белмәгән ике ят кешене, китаплар дуслаштырган була бит! Бу ачышыма бик гаҗәпләндем дә, сөендем дә.

Мин сөйләп бетергәч, Хәмзин абзый байтак кына уйланып торды да:

— Беләсеңме, энекәш, сиңа бик нык укырга кирәк. Әйе, әйе, һичшиксез укырга, укырга!— диде.

Ул нәрсәнедер әйтеп бетермәсә дә, мин аның ни әйтергә теләвен яхшы аңладым. Бөтен барлыгымны яшерен бер шатлык, күңелне канатландыра торган рәхәт, матур бер хис биләп алды. Киләчәктә нәрсә ничек буласын белмәсәм дә, Кәшфеләсрар абзыйның укырга кирәклек турында шулай басым ясап әйтүе минем нәрсәнедер булдыра алача-

гыма һәм үз-үземә ышаныч тудырды. Ул чагында мин, ихтимал, үзенең дә, дәү кошларныкы кебек, канаты барлыгын тоеп чиктән тыш сөенгән кечкенә кош баласына охшаганмындыр. Хәмзингә мин күңелемне үстерергә җылы сүз әйткәне, гомеремдә беренче мәртәбә минем әдәбият белән мавыгуымның нинди дер нәтиҗәсе чыгарга тиешлегенә ишарә ясавы өчен гомерем буе рәхмәт укыдым. Мин аны әле хәзер дә остазларымнан берсе итеп ихтирам белән искә алам.

Кәшфеләсрар абзый Хәмзинне укытучы булгач та берничә мәртәбәләр очраттым. Тагын шунысы да кызык, ул мин тегү тегеп йөргән Ямаширмә авылыннан чыккан кеше, мәгариф өлкәсендә җаваплы эшләр башкаручы карт коммунист иде.

Байтак еллар узып, Казанда яши башлагач, яңа басылып чыккан китабымны куеныма кыстырып, Хәмзинне эзләп барырга җыендым. Минем аңа чын күңелемнән рәхмәт әйтәсем, акыллы киңәшләрен ишетәсем килгән иде. Хәтта ул китапка язасы истәлек сүзләрен дә уйлап куйган идем.

«Кайчандыр Сезнең сәкегез өстендә аягын бөкләп кием тегеп утырган элекке тегүче малайдан...»— дип язмакчы идем.

Ләкин мин бик азга гына соңга калган булып чыктым...

Шулай итеп, мин, ул вакытта әйтелгәнчә, «шкраб»[1] булып киттем. Мине Арча волостеның Урта Бирәзә авылына беренче баскыч (башлангыч) мәктәпкә укытучы итеп җибәрделәр.

Кечерәк кенә класс бүлмәсенә кереп, миннән ни чыгасын көтәрәк күзләрен елтыратып утырган кырыклап бала каршына баскач, Хәмзин тагын исемә төште. Шунда мин бу тиктормас шук балаларның күңеленә, дәресләрдә язылганнардан тыш та, тагы нинди дер яхшы уйлар, изге омтылышлар сеңдерергә тиешлегем турында уйлап алдым. Әйе, мин аларда өмет һәм якты хыял тудырырлык, гомерлеккә күңелгә кереп калырлык, аларны изге эшләргә ашкындырырлык нинди дер очкыннар кабызырга тиешмен. Миңа бу ниятемне гамәлгә ашырырга матур әдәбият ярдәм итәчәк.

Ләкин минем педагогик белемем дә, тәҗрибәм дә юк дәрәҗәсендә аз иде. Миңа шул ук мәктәпнең өлкән сыйныфларында укытучы Иске Кырлайның Һади Дәүләтшин ярдәм итте. Бик чибәр, сөйкемле һәм акыллы педагог иде Дәүләтшин. Ул: «Мөгаллим — җәмгыятьтә иң җаваплы кешеләрнең берсе. Ул һәммә яктан да башкаларга үрнәк булырга тиеш»,— ди торган иде. Мин үз эшемдә һәм тормышымда аңа охшарга тырыштым. Ул минем матур әдәбиятка бәйләнешле таркау һәм буталчык фикерләремне тәртипкә салырга, язучылардан кемнең кем булуын тирәнрәк аңларга булышты.

Бер ай тулгач Арчага үз гомеремдә беренче мәртәбә хезмәт хакы алырга бардым. Борыны өстенә көмеш чылбырлы пенсне элгән карт кассир башын кыегайтып, минем өстемне-башымны күздән кичерде дә янындагы кешеләргә:

— Менә бит хәзерге укытучылар нинди...— дип куйды.— Бишмәтле!.. Колакчынлы!..

Минем аның белән әрепләшеп торырлык вакытым юк иде. Аның турында: «Иске дөнья кыйпылчыгы»,— дип кенә уйлап куйдым. Минем бөтен хыялланганым тизрәк кайтып әнине сөендерү иде. Көзге караңгы кичтә, тездән пычрак ерып, туган авылыма ашыктым. Кайтып җиттем дә минем өчен борчылып көткән әнинең алдына ашъяулык кадәрле әллә ничә керенка[2] чыгарып салдым. Бәхеткә каршы, шул муллык өстенә мин яратып йөргән Хәерниса исемле кызның анасы да килеп кер-

[1] «Шкраб» — школьный работник.

[2] Керенка — Керенскийның вакытлы хөкүмәте чыгарган кәгазь акчаларны шулай дип атыйлар иде.

мәсенме! Әйдә, белеп торсын минем нинди уңган егет икәнлекне! Шул чагында миннән дә бәхетлерәк тагын берәр кеше булдымы икән!

Кыш буена бергә укыткан игълмлы кеше, тәҗрибәле педагог — Һади Дәүләтшин белән мин соңыннан тагын берничә мәртәбә очраштым. Арчада эшләгәндә Иске Кырлай авылында хәтта аның өендә кунакта да булдым. Һәр очраган саен, ул миңа ничектер уңай яктан тәэсир итә, аның белән бик якын итеп, гәпләшеп утырасы килә иде. Беренче китабым басылып чыкканнан соң, табигый инде, шатлыгымны аның белән дә уртаклашасым килде. Китабымны бүләк итеп мин аңа яхшы кеше булуы өчен рәхмәт әйтәсем, «Бик беләсем килә, мин хәзер сезгә ошарлык мөгаллим була алдыммы икән?» — дип сорыйсым килгән иде. Ләкин мин тагын соңга калганмын булып чыкты. Минем китабым аңа барып җитә алмый иде инде.

## IV

Миңа укытучылык һөнәрен дәвам иттерергә туры килмәде. «Ни сәбәпле яшь чагында берәр институтка кереп укымадыгыз?» — дигән сорауга да шушында җавап бирергә туры килә. Революциягә кадәр югары уку йортлары бик аз иде. Шулай ук революциянең беренче елларында хәзерге шикелле синең менеп китүеңне генә көтеп торган башка белем баскычлары да ачылып җитмәгән иде әле. Без, авыл балалары, ул вакытта югары белемнең нindирәк нәмәрсәкәй булуын чама белән генә шәйли идек. Авылга бик сирәк кенә килеп чыга торган югары белемле белгеч — землемерның без, үзеннән бигрәк, тройкада узып киткәндә зәңгәр фуражкасына кызыгып кала идек. Мин үзем, мәсәлән, югары белемле кеше белән 1919 елда укытучылыкка имтихан биргәндә генә кара-каршы сөйләштем. «Чын», игъни дипломлы врачка гомеремдә беренче мәртәбә, егет булып җиткәч, хәрби комиссиядә генә күрендем. Чөнки элекке заманнарда врач дигәннәре авылда түгел, волость үзәкләрендә дә бик сирәк була иде әле. Бәлки шул сәбәпледер, безнең буын кешеләре һәр төрле белемгә әлегә кадәр зур ихтирам саклыйлар.

Өстәге сорауга тагын да конкретрак та җавап бирергә мөмкин. Ул чак революция дошманнарының бик көчәеп киткән еллары иде. Нәкъ укыйсы вакытта миңа гражданнар сугышына китәргә туры килде. 1920 елда Кызыл Армия сафларына алынып, Көньяк фронтта Врангель армиясенә һәм Махно бандасына каршы сугышларда катнаштым.

Укытучылык һөнәре фронтта да ярап куйды. Миңа сугышчылар арасында Кызыл Армия алдында торган зур җаваплы бурычларны аңлату эшләре алып бару, аларга газеталар, төрле брошюралар уку кебек вазифалар йөкләделәр. Тора-бара политрук Садыйковның язу-сызу эшенә булыштым. Миңа «политбоец» дигән исем бирделәр. Шулар өстенә политрук һәм рота командиры укый-яза белмәүчеләр белән шөгыльләнергә дә әмер бирде:

— Без иске армия солдатлары түгел, революция сугышчылары. Безгә надан булып калырга ярамый,— диде.

Шул көннән башлап, солдат уеныннан яки походлардан бушаган арада, нинди дә булса урман аланында яисә берәр лапас ышыгында мин үземнең «шәкертләремне» хәреф танырга, иҗекне иҗеккә кушып сүзләр ясарга, сүзләрдән җөмлә төзергә өйрәтә башладым. «Программаның» төп пункты, иң якындагы максат — һәр сугышчыны үз фамилиясен куярга өйрәтү булды. «Шәкертләр» арасында моңарчы күпне күргән, бөтендөнья сугышын да, гражданнар сугышын да исән-сау чыккан сакаллы абзыйлар да байтак иде. Менә алар катып беткән дәү куллары белән «кечтеки» генә хәрефләрне тырышып-тырышып кәгазьгә

төшерергә азапланалар. Әгәр дә хәрефкә охшаганрак берәр нәрсә килеп чыкса, балалар кебек сөенә торганнар иде. Миңа моның дулкынландыргыч тирән бер мәгънәсе бар кебек тоела иде. Сугыш кырында дошманга рәхим-шәфкать күрсәтми торган кырыс күңелле аяусыз сугышчы монда үзенең чын кешелек асылына кайта. Ул хәзер үзе революция дошманнарыннан саклый торган ирекле яңа тормышның аңлы бер төзүчесенә, шул тыныч тормышка баштанаяк чумарга әзер булган гади бер хезмәт иясенә әверелә иде.

Армиядә булган өч ел эчендә мин ярты Россияне диярлек гизеп чыктым. Беренче тапкыр Мәскәүдә, революция бишеге — Петроградта булдым. Кызыл Армиянең атаклы дивизияләре составында бөтен Таврияне[1] әллә ничә тапкыр аркылыга-буйга җәяү айкадым. Руслар, татарлар, чувашлар, башкортлар, украинлылар һәм яшь Совет иленең башка милләт уллары белән бергә, акларны куа-куа, Кара диңгезгә хәтле барып җиттек. Чал Днепр камышлары арасында, Черек диңгез — Сиваш ярлары буенда сугыштым. Ул чагында безнең командирыбыз гражданнар сугышы елларының атаклы полководецы Михаил Васильевич Фрунзе иде. Без Буденныйның җиңелүне белми торган легендар гаскәре белән янәшә торып сугыштык. Михаил Васильевич Фрунзены якыннан күрүемне, аның сугышчан фәрманын үтәвемне әле хәзер дә дулкынланып искә алам. Бервакыт, Сивашны кичәр алдыннан Строгановка авылында кичке караңгы төшеп килгәндә — Сивашны кичәргә хәзерләнгәндә — өстенә гади солдат шинеле кигән, ягымлы карашлы, көләч йөзле, гаҗәп сөйкемле бу матур кеше безнең строй алдына килеп басты. Ул безнең кәефләрне күтәрергә тырышып һәркайсыбызның кулларын кысты, алда булачак операциядә уңышлар теләде. Фронт командующие махсус килеп үзе озатып кала икән, димәк, бу инде гадәти сугыш кына булачак түгел иде.

Бу — көньякта гражданнар сугышының соңгы көннәре, иң дәһшәтле, иң кызган көннәре иде.

Байтак еллар узганнан соң мин бу онытылмаслык героик көрәшләр турында «Сиваш» повестен яздым.

## V

Әйе, «Сиваш» повесте — ул безнең илебез тарихына эре хәрефләр белән теркәлеп калган зур, дәһшәтле сугышлар турында. Әле менә шул канлы бәрелешләрдән могҗиза белән генә исән калганнар да бар бит, алар башыннан узган тетрәнүләр, җан өшетердәй авыр кичерешләр бар. Аларның, бәлки, йөздән бере генә кәгазьләргә эләккәннәрдер, ә күбесе шул кырыс чорның мәңге онытылмастай истәлеге булып безнең күңелләрдә саклана.

Врангель армиясен тәмам тар-мар китереп Кырымны азат иткәннән соң, безнең 132 нче полк яңадан Сивашның төньягына — Украина җиренә, Таврия далаларына килеп чыкты. Без җәй көне үзебез сугышып алган кечкенә шәһәрчек — мәшһүр Каховка тирәсенә туктадык.

Ул чакта Михаил Светловның:

> Каховка, Каховка,
> Родная винтовка,
> Горячая пуля, лети.
> Иркутск и Варшава,
> Орел и Каховка —
> Этапы большого пути...

---

[1] Таврия — Украинаның Кырым ярымутравы белән чиктәш булган зур бер далалы өлкәсе.

— дигән мәшһүр җыры язылмаган иде әле. Берничә елдан соң шул җырны беренче мәртәбә ишеткәндә мин сәер бер тойгы кичердем. Гүяки аны кем дә булса уйлап чыгармаган, юк! Безнең күңелләрдәге кайнар тойгылар үзләреннән-үзләре шулай ялкынлы җыр булып күтәрелеп чыкканнар!

Каховкага кире әйләнеп кайткач, үзебез сугышып узган кырларны, җимерек окопларны, өзелгән чәнечкеле тимер чыбык киртәләрен карап йөргәндә бездә дә нәкъ шундый горурлык хисе уянган иде.

— Кара баронның[1] беренче булып менә шушында сырт сөяген сындырдык!— диде бер иптәш.

— Каховканы без саклап калдык!

— Врангельнең үлем чәчеп килүче сигез танкысын беренче булып без яндырдык, барысының берьюлы башына без җиттек!— диештеләр иптәшләрем.

Безнең горурланырга хакыбыз бар иде. Чөнки Антантаның ул вакытта иң куркыныч һәм җиңелмәс коралы булып исәпләнгән танкларын гражданнар сугышы тарихында иң беренче булып нәкъ шушында, нәкъ безнең дивизия сугышчылары юк иткән иде!

Тик шунда калкулыктагы яңа каберләргә күзебез төшүгә уңайсызланып башларны идек. Юк, без генә туктатмадык ул танклар атакасын! Гарасат булып җир тетрәтеп килүче үлем машиналарына каршы иң беренче булып безнең белән янәшә әнә шул егетләр дә сикереп чыкты, ул тимер ташкынны әнә шул баһадирларның кайнар гайрәте туктатты! Алар бит без исән калсын өчен дә җаннарын фида кылдылар.

Без мәрхүм иптәшләребезнең баш очына тезләндек. Аларның безгә, безнең аларга әйтәсе сүзләребез күп иде. Алар арасында Казанда бергә сугыш уены өйрәнгән, авыр бәрелешләрдә иңгә-иң торып сугышкан кадерле якташларым да, соңгы сугышка керер алдыннан васыятьләрен әйтеп калдыручы якын иптәшләрем дә бар иде.

— Әҗәлем шушында булса, соңыннан өйдәгеләргә барысын да язарсың инде. Шундый-шундый сугышта вафат, шундый урында үз кулым белән җирләдем диярсең, догада булыгыз, мин һәммәсенә дә бәхил,— дип әйткәннәр иде алар.

Мин ул васыятьләрне үтәгән идем инде. Әмма иптәшләремнең әйтәсе сүзләре алай гына бетмәгән иде әле. Алар бит үзләре җаннарын биреп сугышып алган яңа тормышта яшәп карарга да өлгермичә, киләчәк гомерләрен, татыйсы мәхәббәтләрен, бәхетләрен, яшьлек хыялларын — һәммәсен безгә калдырып киттеләр. Менә хәзер алар сулыйсы саф һаваны үзебез генә сулау, бу тыныч тормыштан үзебез генә файдалану, ничектер, алар өлешенә кергән сыман уңайсызрак иде.

Иптәшләребездән аерыла алмыйча моңаешып утырабыз. Башларыбызда мең төрле газаплы сораулар кайнаша.

Бу мәрхүмнәр, гади эшчеләр, авыл яшьләре хөрриятkә юл ярып барганда иске дөнья белән яңасы чигендә ятып калдылар. Яңа тормышның калканнары, мәңгелек сакчылары алар. Җисемнәре монда калса да аларның рухи образлары, тиңсез фидакарьлекләре халык белән бергә киләчәккә барырга тиеш түгелмени? Киләчәк буын кешеләре мөгаен бездән сорамый калмаслар: «Кемнәр варисы без?— диярләр.— Язмышыбызны кемнәр кояш яктысына чыгарды? Нинди иде алар — безнең кырыс холыклы, батыр йөрәкле революционер бабаларыбыз?»— диярләр.

Киләчәктә биреләсе шушы сорауларга җавап эзләп озак утырдык. Күңел түренә җыела килгән бу уйларымны, Каховкада, Сивашта, Юшуньда ятып калган иптәшләремә булган кайнар тойгыларымны мин

---

[1] Аклар армиясенең командующие булган генерал Врангельне «кара барон» дип атыйлар иде.

тагын унбиш елдан соң «Сиваш» повестенда, анда да бик аз өлешен генә әйтә алачак идем әле.

Ә хәзергә без әле монда — Иске дөнья белән Яңасының чиге салынган урында. Безнең хисләребезнең суынып та җитмәгән винтовка көпшәсе сыман кайнар чагы. Без кичергән канлы бәрелешләргә кайчан да булса җиңелчәрәк кенә карарлар дип, гражданнар сугышын кызыллар белән акларның авылдан авылга куышып йөрүләре сымаграк кына итеп аңлаучылар булыр дип күз алдыбызга да китерә алмый иде. Хәлбуки, илле елдан соң бер очрашуда шундыйракны, чыннан да, ишеттек. Моңа минем бөтен вөҗүдем рәнҗеде. Минем һәлак булган иптәшләремнең истәлегенә күләгә төшерү, аларны түбәнсетү иде бу! Кемдә туарга мөмкин мондый сорау? Йөрәгенә битарафлык мүге үсә башлаган, туган ил өчен көрәшнең изгелеген аңлау сәләтен югалткан кешедә! Тәгаен шулай! Андыйларга каршы мин Кырым өчен булган сугышның соңгы көненнән бер генә сан китердем: 1920 нче елның 11 ноябрь көнне Карпова Балка дигән кечкенәрәк кенә хуторны алыр өчен һөҗүмгә күтәрелгәч, безнең ротадагы җитмеш биш сугышчыдан берничә сәгать эчендә без нибары унсигез кеше генә исән калдык! Ничек хәтерлим мин моны? Чөнки без, акларның иң соңгы окопларын алып, аларны Буденный армиясе куып киткәннән соң ялга туктагач, бөтен ротага дигән икмәкне унсигезгә генә бүлгән идек. Ләкин, ач булуга карамастан, ул зур сыныклар тамагыбыздан үтмәде.

Берничә ай буена көне-төне берөзлексез сугыш зилзиләсендә айкалу тыныч тормышның нинди булуын бөтенләй онытырган икән. Башта Каховкадагы тынлыкка күнегә алмый йөдәдек. Нәрсәдер җитмиме, артыкмы, ничектер сәер иде. Айлы тын кичләрдә аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән чибәр украинкаларның шәһәр читендәге чирәмлектә бергә җыелып җырлаулары безне хыялый тылсым дөньясына алып китә, туган якларны сагындыра иде.

Тик тора-бара гына төшендек: безгә нәкъ шул кирәк икән ләбаса? Туган илебездә тынычлык урнаштыру өчен шулай җаннарыбызны аямыйча сугышып йөрдек түгелме соң без? Якын дусларыбыз, якташ иптәшләребез — Татарстан егетләре ни өчен Перекоп белән Сивашта мәңгегә ятып калдылар? Әнә шундый җырлы-моңлы айлы кичләр Украина халкын гомер буена озата барсын, куанычлы хезмәт, мәхәббәт һәм дуслык, туганлык һәм гаделлек мәңгегә юлдашыбыз булсын өчен!

Хәер, тынычлык безне озак иркәләмәде, кыска гомерле булып чыкты ул. Соңгы алты-җиде ай эчендә беренче мәртәбә шинельләребезне салып, эчке күлмәктән генә йоклау рәхәтен татый башлагач, бер төнне «В ружье!» дигән кискен команда безне дәррәү аякка бастырды. Тагын ун минуттан без инде Днепрга төшеп көймәләргә төялгән идек. Эчкәрерәге бер авылга Махно бандасы килеп ябырылган да совет яклы яшьләрне, укытучыларны аса-кисә башлаган. Безгә моны командирыбыз, көймәдән төшеп төн буе барганнан соң, таң алдыннан шул авылны камап алганда гына әйтте.

— Сак булыгыз! Дошманның шинель кимәгәне дә була. Кыска тун эчендәге обрез белән хәнҗәр пушкалардан хәтәррәк булырга мөмкин,— диде.

Махно бандасына каршы көрәшне безнең батальон шуннан башлады.

Украинаның бик хәтәр коралланган кулаклар бандасы иде бу. Өсбашлары таза, атлары симез, тачанкалары күп. Тачанка саен пулемет, шуның өстенә һәр бандит карабин, парабеллум, я маузер аскан. Берничә сәгать эчендә сиксәнешәр чакрым ара узып, күтмәгәндә өермәдәй килеп баса иде банда. Ябык атларыбызга төялеп без алар туктаган авылга барып җиткәнче, җилләр искән! Алар инде әллә кайларга барып җитеп шабаш ясый башлаган булалар.

Янсә мондый хәлләргә дә юлыккаладык: ап-ачык белеп барабыз —

банданың зур гына отряды бер сәгать элек кенә менә шушы авылга килеп кергән. Аларны разведчиклар үз күзләре белән күргәннәр, атларын, тачанкаларын, пулеметларын санаганнар. Безгә шул гына кирәк тә! Авылны камап алабыз да, винтовкаларны алга төбәп тыкрыклардан, бакча артларыннан авыл эченә агылабыз! Ләкин — гаҗәп! Авыл тып-тын! Хатын-кызлар сиртмәле коены шыгырдатып су алып яталар, ишек алларында әтәчләр кычкыра, дуңгызлар мыркылдый, араннарда атлары керт-керт солы ашый. Банданың эзе дә юк! Әйтерсең, җиргә сеңгән! Тик капка төпләрендә, анда-санда башына йонлач бүрек, өстенә кыска тун кигән тап-таза яшь ирләр генә безгә күз салгалап гамьсез генә кыяфәттә челем тартып утыралар. Командирларның соравына каршы алар туп-туры күзгә карап иңбашларын җыералар:

— Яка банда? Никого нема! Вот Хрестос![1] — дип бик тырышып чукынырга тотыналар. Бактың исә безнең алда бандитның да бандиты, явызның да явызы үзе басып тора икән!..

Бу авыр көрәш бер ел чамасы вакытны алды. Моның иң аяныч ягы шул булды: Перекоп һәм Сиваш өчен барган дәһшәтле сугышлардан исән калган кайбер якташ-иптәшләрем Махно бандитларының почмакка посып аткан хыянәтчел пуляларыннан һәлак булдылар.

Шулай да никадәр генә шәп коралланган булмасын, никадәр генә масаймасын, Махно бандасының көннәре санаулы иде. Чөнки аның халык эчендә таяныр нигезе калмады. 1921 нче елның ахырына таба Кызыл Армия банданың соңгы отрядларын да тузгытып ыргытты. Махно үзе, бер төркем иярченнәре белән, чит илгә качты.

## VI

Шулай, акларны җиңдек. Махно бандасын да юк иттек. Ләкин бу афәтләрдән котылып җитәр-җитмәс, өстебезгә тагын ике дошман — ачлык белән тиф хастасы ябырылды.

Мин, армиягә буыннарым ныгып җитмәс борын ук килеп кергән булсам да, беренче ике дошманга бирешмәгән идем. Әмма өченчесе — кайтмалы тиф[2] миннән көчлерәк, тегеләрдән дә мәкерлерәк булып чыкты. Ул мине 1922 елның язында Украинаның көньягыннан барып тапты. Бу вакытта без продотряд булып Идел буендагы ачларга озату өчен кулакларның яшергән ашлыкларын җыеп йөри идек. Диңгез буендагы Олешка[3] дигән шәһәрчектән безнең батальон урнашкан Николаевка поезд тагын бер атнадан гына китәчәк икән. Яшь чак, тәвәккәл чак. Без җәяү генә чыгып киттек. Мин инде юлга чыкканчы ук авырый башлаган идем. Хәзер дә аңлый алмыйм: ул алтмыш чакрым араны авыру килеш ничек кайтып җиттем икән? Башым ярылырдай булып авырта, күз кабаклары ачылмый, бер шпалдан икенчесенә атларлык та хәлем юк. Бераз гына барам да җегәрем бетеп шпалларга авам. Мин яңадан аңыма килгәндә юлдашларым күз күреме җир алга киткән булалар. Тора-бара минем винтовкам да, солдат капчыгым да иптәшләрем җилкәсенә күчте.

Шәһәргә якыная төшкәч, ниндидер күпер өстендә бөтенләйгә егылдым. Шунда күпер астындагы суга күзем төште. Шулкадәр көйгәнмен, шундый эчәсем килүен сиздем, хәтта шпаллар арасыннан кысылып уза алсам, суга чумарга да әзер идем... Шул урында каршыма килеп мине носилкага салып алып кайтканнар. Күземне ачканда мин инде казармада идем.

Комиссия мине өч айга кайтарырга булды. Нигә авыру килеш юлга

[1] Нинди банда? Беркем дә юк. Менә алладыр әгәр!
[2] Возвратный тиф.
[3] Хәзерге Цюрупа шәһәре.

озаталар, нигә госпитальгә салмыйлар? Чөнки андый мөмкинлекләр юк икән — бөтен шәһәрне тиф баскан, госпитальләрдә урын калмаган.

Кызыл вагоннарга төялеп кайтырга чыктык. Каптенармус юлга икмәк бирә алмады, чөнки юк икән, аның урынына минем солдат капчыгына биш көнлек мамалыга[1] салдылар. Ул икенче көнне үк ачылды. Бүтән азык юк иде.

Хәлем шәптән түгел иде. Бәхетемә каршы, вагонда Балык Бистәсе ягының Иске Арыш егетләре бар иде. Гозеремне аларга әйттем.

— Сездә инде бөтен ышаныч!— дидем.

Хәер, үтенүнең кирәге дә булмаган икән. Алар да минем шикелле үк авыр сугышларда катнашкан, иптәшлекнең, бер-береңә ярдәм итүнең кадерен белүче иркен күңелле юлдашлар булып чыктылар.

— Күрәбез! Борчылма, агайне. Казанга тикле бергә!— диделәр.

Мине янадан приступ бәреп екты. Әмма хәзер минем эшләр бөтенләй үк өметсез түгел. Күземне ачканда юлдашларымның кайсы да булса яныма килә, поезд туктаган арада кайнар су алып керәләр, тамагымны да туйдыралар иде.

Ләкин зуррак станцияләргә туктаганда ак халатлы кешеләр, вагон саен йөреп, авыруларны алып кала башладылар. Бу мине хафага салды. Шулкадәр үз ягыбызга кайтасым килә иде ки, хәлем бик авыр булса да кайдадыр читтә ятып каласым килмәде. Үзенең күп авырлыкләр кичергән сугышчы улын туган якларым докторларсыз да, саф һавасы, тынычлыгы белән дә аякка бастырыр кебек тоела иде. Тагын теге иптәшләргә сүз салдым.

— Бирмәгез мине шул ак халатларга!— дип үтендем. Алар мине аңладылар. Санитарлар кергәндә капчыклар белән күмеп сәке түрендә яшереп кала торган булдылар.

Ләкин Мәскәүгә килеп җиткәндә шулкадәр бетерешкән идем, юлдашларым мине вагоннан күтәреп диярлек алып төштеләр. Курск вокзалының кояшлы дивары буена китереп утырттылар да шундый киңәш бирделәр:

— Синең хәлләр шәптән түгел, якташ. Болайга киткәч, Казанга тикле түзә алуың икеле. Бераз кояшта җылын да, әнә теге ишеккә керерсең!— дип ун-унбиш адымдагы ачык ишекне күрсәттеләр.— Безгә үпкәләмә, Казан поездына ашыгабыз...

Юлдашларым үзләре белән минем соңгы өметемне дә алып киттеләр. Миңа хәзер бу дөньяда берни дә кирәкми, киләчәккә кечкенә генә өметем дә, бер генә теләгем дә юк, тик баш кына авыртмасын иде. Башым шулкадәр бәгырьләргә үтеп сызлый, шуннан котылу өчен мин хәтта үлеп китәргә дә риза идем.

Шулай сүнәр-сүнмәс миңгерәеп утырганда йомылып бара торган күзләремә нәни генә яланаяклар күренде, колагыма нечкә генә кыз бала тавышы килеп керде:

— Лимонад, лимонад, лимонад...

Шунда үләрдәй булып эчәсем килүен сиздем. Күзләрем ачылмый, телем әйләнми иде инде. Эчәсем килүдән тәкатьсез калып, кызыйның мине күрмичә узып китүеннән котым чыгып, ыңгырашып куйдым, иреннәремне дә яладым бугай. Каяндыр дәрман табып, кесәмә дә ишарә иттем шикелле. (Анда күпмедер акча булырга тиеш иде.) Кесәмә сузылдымы ул сабый, әллә юкмы, анысын белмим, әмма минем ни хәлдә булуымны ул яхшы аңлады. Башымны диварга таба борды да лимонад эчерде.

Ялан тәпиле ул сабый, лимонад сатып тамак яллык эшләргә мәҗбүр булган ул бала, исән булса, хәзер житмешләргә якынлашып килүче

[1] Мамалыга — кукуруз оныннан пешерелгән тәбә сыман йомшак төче ризык.

өлкән яшьтәге әбидер инде. Зур үскәч, бәлки, ул завод-фабрика эшчесе, инженер, архитектор яисә бухгалтер булгандыр. Кем генә булмасын, мин аның сүнеп баручы җанга, әкиятләрдәге кебек «тере суы» эчерткән шул шәфкатьле кулларын ихлас күңелдән үбәр идем. Чөнки шул салкынча ширбәте белән ул минем эчемдәге көйдергеч үлем ялкынын сүндереп, яшәү өмете уятып җибәрде. Миңа хәзер урамда үлеп калуга караганда, өстенә кызыл тәреле ак әләм элеп куйган әнә ул ачык ишеккә керү хәерлерәк шикелле тоела башлады.

Ләкин бик ерак, барып җитә алмаслык ерак иде хәзер миңа ул ишек. Врангельне Кырымга куып барганда безнең җәяүләп көненә алтмыш-җитмеш чакрымнар узганыбыз, Сивашны кичкәндә дулкыннарда тончыга-тончыга төн буе җил тиңентен салкын су ерып чыкканыбыз бар. Ә бу унбиш адым алардан күп ары, ул араны үтү күп мәртәбәләр кыенрак иде. Бер кулым белән капчыгымны сөйрәп, икенчесе белән стенага таяна-таяна озак бардым мин ул ишеккә. Әллә ике-өч сәгать, әллә ярты көн. Шул кадәр хәлем юк иде, беренче баскычка барып ябышуга авып кына киттем. Мине күтәреп алып керделәр.

Коридордагы койкага кертеп салгач, өлкән яшьтәге бер түти изүемне актарып култык астыма нидер кыстырды. Минем маңгаем уттай яна, күзләрем атылып чыгардай булып сызлый, күз алдымда укшытып бер өзлексез утлы боҗралар әйләнә иде. Күпмедер вакыт шулай үземне-үзем белештермичә ятканнан соң, колак төбендә генә куркынган тавыш ишетелде:

— Аллакаем, кырык бер!

Нинди кырык бер? Нәрсә ул кырык бер? Ишетүен ишеттем, әмма шуның ни икәнен аңлаганчы яңадан аңымны җуйдым. Мин ул санның соңыннан гына очына чыктым; минем температурам шулай өскә сикергән икән. Термометрдагы кырык берне яшәүнең чик сызыгы, үлем белән яшәешнең кыл уртасы диләр икән...

Күпмедер вакыттан кемнеңдер үзәк өзгеч итеп ыңгырашуына уяндым. Күрәсең, аның хәле авырдыр, ул актык чиккә җиткәндер дә бу аның дөньядан киткәндә ачыргаланып кычкыруыдыр. Шул ыңгырашу җан җиремә килеп тиде дә уянып киттем. Әйләнә-тирәм кап-караңгы иде. Иң әүвәл кулларымның дымлы чирәмдә ятуын сиздем. Япа-ялгызы идем. Шунда гына аңладым: үзем ыңгырашканмын икән бит. Бәлки, мин бая төшеп киткән караңгы чоңгылдан чыгарга азапланып шулай ыңгырашканмын? Авыр төш күреп бастырылганда албастыдан шулай ыңгыраша торгач кына котыласың бит...

Гаҗәп, мин әле һаман да исән икәнмен ләбаса! Күрәсең, минем яшьлегем бирешмәгән, үзем аңымны җуйгач та ул, рәхмәт төшкере, изелеп төшмәгән. Газраилнең үзе белән якага-яка килеп тартыша торгач, мине яшәү белән үлем чигенең бу ягына алып чыккан.

Башым элекке кебек үк авыртмый иде инде, тик кузгалып китәргә торган паровоз сыман яман да чыңлый. Кайда ятам мин, нинди чирәмлек бу? Шунда эчем «жу» итеп китте. Әгәр дә бу зират чирәмлеге булса, мине, үлгән дип белеп, күмәргә алып килгән булсалар? Кабаланып шинелемне, як-якларымны капшарга тотындым. Кулым баш астына салынган капчыкка барып орынды, гимнастерка кесәсендә кәгазьләргә барып тиде. Шунда гына эчемә җылы керде. Юк, зират түгел икән бу! Теге дөньяга озатканда моңарчы берәүгә дә капчык биреп җибәрмиләр иде, чөнки аннан алып кайтасы әйбер юк. Шулай ук документсыз барсаң да кире борып кайтармыйлар...

Әллә кайдагы ут яктысына күзем төште. Түбән генә ниндидер ялгыз ут җемелди иде. Озак та үтмәде, шул яктан кешеләр тавышы ишетелде. Хатын-кыз тавышы:

— Кая соң ул?— дип сорады.

Ир кеше аңа:

— Шушында гына булыр, чирәмгә салган идем,— диде.
Аларның мине күрмичә узулары да ихтимал бит. «Биредә мин, менә монда гына!»— дип кычкырмакчы булдым. Ләкин миннән ниндидер балаларча чинаган тавыш кына чыкты. Шулай да алар мине таптылар. Носилкада тирбәлеп баруны хәтерләп калдым да тагын каядыр төшеп югалганмын...

## VII

Тагын күпме вакыт узгандыр, сәгатьме, тәүлекме, әллә бер атна укмы, анысы миңа билгесез, бәлки ярты гомер үк узып киткәндер, аз-лап-азлап кына, өзек-өзек кенә бик газиз, күңелгә бик якын җыр тавышы ишетелә башлады:

Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә...

Эзлим-эзлим күңелем түреннән, һич кенә дә өзеп әйтә алмыйм: каян бу җыр, кем җырлый? Тел очымда гына тора, менә-менә исемә төшәр шикелле...

Бетсен патша, янсын тәхет,
Безгә сугыш кирәкми шул...

Әһә! Без бит бу, без җырлыйбыз! Игумныйда, Казан янында! Безнең өстә өр-яңа яшел гимнастеркалар, аякта яңа ботинка. Солдат уенын уйнап бетергәннән соң, сугышка чыгып китәр алдыннан казармалар каршысындагы мәйданда, бөтен батальоныбыз белән озын бер сафка тезелеп, маршка җырлап барабыз. Әниләр безне озатырга килгәннәр дә мәйдан кырыендагы агачларга сөялгән хәлдә, күзләрен сөртә-сөртә безнең җырлап узганны карап торалар. Әни турыннан узганда мин башны тагын да югарырак күтәрәм, авызны зуррак ачып кычкырам! Улым сугышка китә, дип күңелен төшермәсен әле! Китәбез икән, без ни җитте сугышка гына китмибез! Акларның дөхетен дә[1] калдырмыйча кырып-себереп, сугышны бетереп кайтырга дип барабыз!

Йөгереп китәрдәй булам шул,
Кайтып җитәрдәй булам —
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә-ә-ә-ә...

Әни миңа кулларын болгый-болгый, өзелеп-өзелеп нидер әйтә, ә мин җыр астыннан аның сүзләрен аера алмыйм. Шунда кинәт бөтен тәнемә кайнар дулкын йөгерде, вөҗүдемне зур куаныч биләп алды: туган телем бит бу! Кайчаннан бирле ишетмәгән газиз телем! Мин туган-үскән якларыма кайтып төшкәнмен түгелме соң? Аяк очымда әни тавышы түгелме? Әллә хәлемнең авырлыгын белеп әни үзе минем янымa килгәнме? Шатлыктан тыным буыла язды. Каты сугышлар башланганнан бирле хәбәрләшмәгән, исән-аман булуын да белмәгән анам, газиз анам! Бу саташуым гына булмагае дип котым очты. Тәнемдәге барлык җегәремне бергә туплап күземне ачтым. Юк, төш түгел, өнем икән бу! Ләкин сөйләшүче хатын минем анам түгел, яше белән дә әни чамалырак, тавышы да анықына охшаганрак, әмма икенче бер якташыбыз икән. Бер елга якын үз телемдә сөйләшергә туры килмәгәнлектән, туган телемне шулкадәр сагынган идем, хәзер бу апа миңа үз анам кебек якын, аның моңлы гына ягымлы тавышы миңа җан рәхәте бирә,

---

[1] Дөхетен дә — эзен дә, берсен дә... (жаргон).

сырхау башыма шифалы дару булып иңә иде. Мин, башым чыңлавын ишетмәскә тырышып, әлеге апаның авызына текәлдем.

Ләкин шатлыгым кыска гомерле булып чыкты. Апаның алмаш-тилмәш күзләрен сөрткәләве башта ук сагайткан иде, хәсрәте, чыннан да, зур икән. Минем белән янәшә яткан ире белән сөйләшә икән ул. Мин шуны аңладым: алар Идел буендагы ачлыктан качып бала-чагалары белән Донбасс ягына барырга чыкканнар. Ләкин әти булган кешеләре юлда авырый башлаган да, аны монда китереп салганнар. Хатыны иреннән аерылу хәсрәтеннән күз яшен тыя алмыйча шуңа өзгәләнә иде:

— Ходаем, нихәлләр итим?! Ул балалар белән синсез кая барып егылыйм?! Бөтенесе аяксыз да к... сез, бит.

Ир кешенең өстенә япкан ак җәймә кырыеннан миңа коңгырт сакалы гына, ябык яңаклары гына күренә иде. Аның тавышы бик зәгыйфь чыкты. Ул иреннәрен ялмаштырып өзек-өзек берничә сүз генә әйтә алды.

— Балалар белән... ниятләнгән җиргә бар инде син... кыен булса да бар...

Хатыны аның караваты янына тезләнеп иңрәп куйды:

— Ходаем! Бу килеш ничекләр ташлап китим сине?!

Әллә аңын җуеп торды ире, әллә ни әйтергә белмичәрәк беравык дәшә алмыйча ятты.

— Алайса... көтегез дүрт-биш көн вокзалда. Тазарсам... бергә китәрбез.— Ул хәле беткәндәй күзләрен йомып беразга тынып калды. Аннары тагын телгә килде.— Дөнья хәлен белеп булмый... Андый-мондый булсам, балалар синең өскә кала. Берүк, ким-хур итмә, рәнҗетә күрмә... Миннән хәер-дога... Ә синнән мәңге бәхил...

Һәркемдә кечтеки генә әүлиалык була, диләр. Хатыны иренең бәхилләшергә дип сузган кулына йөзе белән капланып бөгелеп төште. Мин күңелем тулып күземне йомдым...

Минем үз хәлем хәл иде. Ярылырдай булып башым сызлый, хәлсезлектән күзләрем йомыла. Шулай да минем якташларымны бик тә юатасым килә иде. «Юк, юк! Син тазарырсың, абзый кеше, балаларың хакына тазарырсың! Ничек инде ул! Үзебез кан коеп алган ул яңа тормышта без дә яшәмәгәч, кем яшәр?!— димәкче идем. Аннары минем якташларымнан күп нәрсәләр сорашасым бар иде: халык бик кырылмыймы? Быелгы игеннәр ничегрәк күренә?

Ләкин мин авыз ачып сүз әйткәнче ниндидер рәхимсез көч мине яңадан караңгы чоңгылга алып төшеп китте.

Алтмыш бер ел узганнан соң менә мин яңадан егерме икенче елгы Мәскәүгә, Михаил Васильевич Фрунзе исемендәге госпиталь караватында саташып яткан яшь чагыма әйләнеп кайттым. Күңелем белән, билгеле...

Ни булды икән? Атасыз калган нәни сабыйларның иңрәп елаган тавышлары аңымны югалтканда да җанымны тетрәттеме икән? Әллә тол калган хатынның хәсрәтле күз яше минем йөрәгемә дә тамдымы икән? Ни булгандыр, бу юлы нигәдер хафаланып, шомланып уяндым да, уңдагы караватка күз аттым. Эсселе-суыклы булып киттем. Карават буш, якташым юк иде. Санитарка ул яткан җәймәләрне, ул бөркәнгән одеялларны идәнгә ташлап, алар урынына яңаларын җәя. Күңелемә шом тулып як-ягыма карандым. Кая минем якташым? Икенче палатага күчергәннәрме, әллә...

Сул ягымда яткан урыс агай минем әзләнүемнең сәбәбен аңлады булса кирәк, баш бармагын күккә таба тырпайтты.

— Тегендә инде ул...— диде, чукынмакчы булган иде, миңа күз салды да нидер искәреп кире уйлады.

Минем күзләремә яшь тулды. Гадәттә, сугышчы елак була алмый.

Чөнки сугышта елап торырга ара юк. Анда тешләреңне кысып барлык тойгыларыңны бер йомарлам ачуга, утлы нәфрәткә әйләндерәсең дә тешләреңне кысып үлемнең үзенә ташланасың. Күңел түренә җыелган әнә шул йомарлам хәзер берьюлы чишелеп китте дә, ачы күз яше булып, бәгырьләрне пәрә-пәрә китерә торган кайнар хәсрәт булып тамак төбенә бөялде. Якташларымның вокзал почмагында кая барырга белмичә бөрешеп утырган нәни балалары күз алдыма килеп басты. Карпова Балкада соңгы атакага барганда минем янымда гына маңгаена пуля тиеп тәгәрәп кенә киткән рота командиры үзәгемне өзде. Сивашны чыккач акларның яр буендагы окопларына ташланганда чәнечкеле тимер чыбыкта эленеп калган Митричев тә йөрәкне сызлатты. Кемгәдер рәнҗим дә, кемгәдер үпкәлим. Абый да сугыштан кайтмагандыр, әни дә, сеңелем дә ачлыктан үлгәндер... Ә мин менә монда... Монда, ялгызым, берүзем. Бәлки мин дә...

Күз яшьләре агыла да агыла...

Яшь кенә шәфкать туташы ничектер тавышсыз-тынсыз гына килеп, стаканнан су эчертте. Караватыма сүзсез генә врач килеп утырды. Биләгемдә кулының йомшаклыгын сизү белән гаҗәпләнеп борылып карадым. Менә сиңа, врач хатын кеше икән бит! Аңыма килгән араларда бу ак халатның элек тә күземә чалынганы бар. Әмма моңарчы ул гомумән врач кына иде. Бик сәер булып китте. Ике ел ярым буена гел ирләр дә ирләр, ә бу... Хатын-кыз!... Нишләптер күзләремне сөртеп алдым. Врачның нәфис, җылы бармаклары, йөрәк тибешемне санаган булып, мине иркәлиләр, тынычландырырга тырышалар иде шикелле. Аның йомшак кулын үз тәнемдә сизеп тору миңа бик рәхәт, мин аның янымда озаграк утыруын тели идем. Бераз хәлемне белешкәннән соң врач:

— Кайсы дивизиядән?— дип сорады.

— Элекке Инза дивизиясе. Хәзер Сиваш исеме дә өстәлде.

— Беләм, булганым бар,— диде врач.

Бу мине бик гаҗәпләндерде. Хатын-кыз... сугышта...

— Сезнеңме? Безнең дивизиядәме?!— дидем.

— Әйе. Нәкъ үзендә. Беләм, сезгә бик нык эләкте. Анда бик күпләр ятып калды. Нишлисең бит, сугыш-сугыш инде ул!..

Мин аңа тагын да сынырак карадым. Яшь кыяфәтле булса да, чигәсендә берән-сәрән ак чәч бөртекләре күренгәли иде. Полк походта барганда арбаларга төялеп безнең арттан килүче шинель кигән хатын-кызлар күзгә чалынадыр иде бит. Врач уң яктагы буш койкага башы белән ымлады.

— Якташың идеме әллә?

— Әйе шул...

— Нишлисең бит. Тиф дигәнең бик аяусыз... Ә сиңа ничә приступ булды? Юлда дим!

— Ике.

— Кайларда?

— Олешка белән Николаев арасында, аннары Мәскәүгә кайтканда.

— Монда өч! Барысы була биш! Инде җитте! Бүтән булмас. Молодец син! Сугышта гына түгел, монда да җиңеп чыктың. Хәзер инде яшәргә дә яшәргә!

Яшисе иде дә бит... Кулларым ничектер үзеннән-үзе башыма сузылды. Башта бер бөртек чәч заты калмаган, тап-такыр, колак та саңгырауланган иде. Врач тагын минем кулымны сыйпап алды.

— Борчылма, кызлар янына кайтып җиткәнче яңа чәч тә үсәр, колагың да ишетә башлар.

Комиссия торганда колагым ишетмәүне яшереп калдым, юкса мине чыгармаган булырлар иде. Өч айга өйгә җибәрделәр. Юлга биргән бер икмәкне солдат капчыгына салып Казан вокзалына юнәлдем.

Барып төшсәм, хәйран калдым. Вокзал мәйданын ачлыктан качып китүчеләр баскан. Трамвайлар, автомобильләр күзгә чалынмый диярлек. Вокзал мәйданы бер кырыеннан икенче кырыена кадәр поезд көтүче авыл кешеләре белән тулган. Бар җирдә төтен. Әллә кырык-илле, әллә аннан да күбрәк урынга учак якканнар да солдат котелокларында чәй кайнаталар, барлы-юклы ризыкларыннан нидер пешереп яткан булалар. Мәйданның чуерташы өстенә бишмәтен, я чикмәнен җәеп, аның өстенә мендәрен, ястыгын салган да карт-карчыклар, кечкенә балалар да шунда ук, учак тирәсендә ята. Йорттан алып чыккан кечкенә сандыклар, капчыкка тутырылган төрле кием-салым, йорт кирәк-ярагы да шунда өелгән.

Арлы-бирле сугылып эзләнә торгач, якташларыма барып юлыктым. Арада Тәмте, Саба, Арча яклары да бар иде. Бала-чагалары белән һәркайсы үз учагы тирәсенә җыелган да башларын иеп уйга калып утыралар.

— Икмәкле якка китәргә дә исәп, поезд юк. Менә дүрт тәүлек инде,— диде бер олы кеше. Мин шунда гына искәрдем: карасана! Поездлар гөрелдәве, паровоз гудоклары әллә нидә бер генә ишетелә икән бит! Мәскәү кадәр Мәскәүдә, шундый зур станциядә мондый тынлык бик авыр тәэсир итә иде.

Әлеге агай миңа карап алды да:

— Ә син кая таба юл тотмакчы?— дип сорады.

— Мин өйгә кайтам, Арча ягына!— дидем.

Барысы да бик гаҗәпләнеп күтәрелеп карадылар. Әлеге олы кеше аеруча борчылды.

— Әйтеп торам бит, ачлык анда дип, ачлык! Былтыр бер бөртек икмәк алмадык — янды, көйде. Мал-туарны көз көне үк суеп ашадык. Бер кабым ризык заты калмады. Нәрсәгә дип кайтасың, үләргә дипме?

Бу абзый минем зиһенемне чуалтып җибәрде. Ни хәл инде бу? Нинди канлы сугышлардан исән-амин чыктым, тиф сырхавын җиңдем. Инде туган ягымның ындыр артына кайтып җиткәч, кире борылып китимме? Бу минем башыма сыймый иде.

— Алты-җиде айдан бирле әнидән хат юк. Туганнарым хакында бер нәрсә дә белмим. Бик кайтасым килә шул,— дидем мин.

Теге абзыйга тагын бер кеше кушылды.

— Анда буласы булгандыр инде, энекәш. Син кайтып төзәтә алмыйсың. Күпкә түзгәнне азга калгач кына түз! Кайтма ул якларга! Яңа икмәк өлгергәнче кайда булса да ялланып эшләп тор!

Нишләргә иде соң миңа? Бу абзыйлар акыллы киңәш бирәләр, аларга ышанмыйча мөмкин түгел. Ләкин ялланып мин нишли алам? Аягыма да чак кына басып торам лабаса! Аннары, нишләтим үземне? Кайтырга дигән ниятемне һич башымнан чыгарып ташлый алмыйм бит! Бу агайларның чын күңелдән бирелгән яхшы киңәшләренә колак салмау да егетлек түгел иде.

— Кайтмыйча булдыра алмыйм шул, абзыйлар,— дидем мин аларга.— Халык ни күрсә, миңа да шул... Хәзер май башы. Озакламый какы, кузгалак, балтырган өлгерә. Кычыткан, алабута ашы белән булса да туенып торырмын...

Тагын бераздан Казанга поезд китәргә тиеш иде.

Ачлыктан йөзләре көм-күк булган, иреннәре зәңгәрләнгән якташларым минем киреләгемә сәерсенеп калдылар. Әлеге өлкән яшьтәге агай сулагай кулын селтәп миңа аркасы белән борылды. Мин бу олы кеше алдында ниндидер ярамастай эш кылган гөнаһлы бәндә кебек кыенсынып, атлар-атламас, тезелеп торган кызыл вагоннарга таба юнәлдем.

## VIII

Кайтып төшсәм, йортта безнең гаиләдән беркем дә калмаган. Абыйлар әнине алып Себер ягына киткәннәр. Бөтен хуҗалык тузган, җимерелгән. Мал-туар юк. Икмәк юк, керосин юк, хәтта тоз да табып булмый. Авыл агайлары әйтмешли, «ат юк, арба юк, аннан бүтән бар да юк». Авыл кешесенең сабын белән ситсы күрмәгәннәренә биш былтыр. Яңа күлмәк кигән хатын-кызга шаккатып артыннан баралар иде: каян алган, ничек тапкан, ничек акча җиткергән? Паровозларга утын ягылган чак. Казаннан Арчага бик «фарт» килү сәбәпле генә бер көндә кайтып җитә алдым.

Юлда үзем юк-бар белән туенып уздырсам да, күңелем сиздс, госпитальдә биргән арыш икмәген өйгә кадәр саклап алып кайттым. Шушы гади генә арыш икмәге дөньяда иң кадерле, иң тансык күчтәнәч булып чыкты.

Безнең йортта торып калган туганыбыз — Зифа тәтәй икмәкне юка телемнәргә кисеп башта миңа, җизнигә, балаларына өләште. Хәтта минем белән күрешергә кергән туган-тумачага, күршеләргә дә авыз иттерде. Кергән беренә прәннек тикле генә икмәк кисәге суза да, күзләрен челт-челт йомгалап:

— Бисмиллаһи, менә авыз итегез, Гумәр, рәхмәт төшкере, Мәскәүдән чын ипи алып кайткан, арыш ипие!— дип кабатлый иде.

Авылдашларымның ипи кисәге күрүгә күзләре елтырый, авыз сулары килүгә түзә алмыйча, төкрекләрен йоталар, ләкин ипине капмыйлар, рәхмәт әйтә-әйтә балаларына алып чыгалар иде. Күрше килене Фагыйләнең икмәк сузгач зәңгәрсу иреннәре дерелдәп куйды. Ул икмәк кисәген күкрәгенә кысып шатлыгыннан сөйләнә-сөйләнә ишек төбендә таптанырга тотынды:

— Ай, рәхмәтләр генә яусын! Менә бит, кибегеп беттем, күкрәгемдә бер тамчы сөтем юк, баламны туйдыра алмый интегәм. Нәниемә имезлек салам мин моннан, боерган булса, бер юньле ризык капсын, алла теләсә...

Мин тетрәнеп киттем. Ачлыкның дәһшәтле фаҗигасын, бөтен рәхимсезлеге, үлемнәре белән шунда гына аңлый башладым. Тәнне чиратып зиратта берсе янына берсе тезелешеп киткән яңа каберләр күз алдыма килде. Ачлык газабын үз җилкәмдә татый башладым.

Шул «авыз итүдән» соң, яңасы өлгергәнче, авызга бер генә валчык та «чын ипи» кермәде. Алабута икмәге дә, кычыткан шулпасы да калмады, төрле какылар, балтырганнар, юалар, үлән тамырлары белән дә тукландык, кишер чәе дә эчтек. Тик яңа арыш орлыклана башлагач кына хәлләр бераз җиңеләя төште.

Менә шундый шартларда бер кат өс-баш белән шәп-шәрә йортка кайтып төшүче авыру сугышчыга нишләргә, кая барырга? Ничек көн итәргә? Тормыш дигән бу аяусыз нәрсәне кайсы башыннан тотынып, ничек дәвам иттерергә? Бу сорауларга дөрес җавап табу, шул буталчык яшәеш ыгы-зыгысында үзеңә бердәнбер дөрес, бердәнбер туры юлны сайлап алу һич тә җиңел эш түгел иде.

Минем гомеремнең өченче дистәсе, гомумән, таркаурак, әгәр шулай әйтергә ярасa, әйле-шәйлерәк узды диярго була. Күрәсең, бу хәл баштан ук алдыңа нинди дә булса бер зур максат куймаудан, конкрет бер маякка йөз тотып, шуңа омтылу кебек бер кыйбла булмаудан килгәндер. Хәер, кем күрсәтсен икән миңа ул кыйбланы? Мин исәя генә башлаганда әти үлеп китте. Абыйларымның икесе дә ярты гомерләрен солдат хезмәтендә, сугышта уздырдылар. «Кешенеке кештәктә» дигәндәй, башкаларның үз борчуы үзенә җиткән иде.

Дөрес, революциягә кадәр, ягъни яшүсмер чагында, бөтен хуҗалык минем өскә калганнан соң, җир сөреп, печән чабып, иген эшләре белән

мәш килеп йөргәндә, заманасына күрә минем хыялым юк түгел иде: яхшы ат, шәп дирбия, чибәр өс-баш, ак мунча... Аннары инде шушылар һәммәсе дә көйләнеп, үз урынына килеп утыргач, әнигә акыллы гына, чибәр генә бер килен...

Әмма революциядән соң, бигрәк тә гражданнар сугышында йөреп, ярты дөньяны дигәндәй айкап кайткannan соң, яшүсмер чактагы ул хыял бик кечкенә булып калды. Революция яшьлек дәртенә канат үстерде. Авыл яшьләренең күбесе, бигрәк тә аз-маз укыганы, ул вакыттагы крестьян тормышының тар буразнасына гына сыя алмый башлады.

1925 нче елда Казанда махсус мәктәп тәмамлаганнан соң, беркадәр вакыт эчке эшләр халык комиссариаты оешмаларында хезмәт иттем. Бераздан бу өлкәнең тагын да катлаулырак эшенә күтәрделәр, Арча кантонының җинаятьчеләр эзләү бүлегендә эшләдем. 1928 елда мине халык тикшерүчесе, соңрак халык хакиме[1] итеп куйдылар.

Кайбер укучыларны минем биографиямнең бер өлеше гаҗәпкә калдыра. Алар җинаятьләрне тикшерү органнарының шөгыле белән әдәби иҗатны янәшә куеп карыйлар да болар арасында һичбер бәйләнеш таба алмыйлар. Янәсе, ничек була инде бу? Бер якта ат караклары, бандитлар, тагын шундый бозык юлда йөрүче шәфкатьсез, намуссыз бәндәләр. Икенче якта — поэтик дөнья, нәфислек, кеше рухының нечкә тибрәнешләре...

Бик мәгълүм шундый бер хакыйкать бар: язучы тормышның төрле якларын никадәр күбрәк белсә, никадәр тирәнрәк аңласа, шулкадәр иркенләбрәк, колачын җәебрәк яза ала. Тик моның бер шарты бар: ул яшәешнең нинди генә дәһшәтле, куркыныч өермәләренә, пычрак сазлыкларына юлыкмасын, үзенең иманыннан язмыйча, җанын гарипләндермичә, аларны исән-аман килеш саклап калырга сәләтле булсын!

Бу һөнәрнең, ягъни җинаятьчеләргә каршы көрәшнең мине барыннан да бигрәк сугышчан романтикасы мавыктырды. Тышкы дошманнарга каршы көрәшкәнмен икән, нигә эчкеләренә каршы да көчне сынап карамаска?!

Ул елларда, колхозлар оешканчы, авылларда ат караклары да, кеше талаучылар да очрый торган иде әле. Билгеле, төрле җинаятьчеләр белән эш итәргә туры килде. Үзенә күрә бик җанлы һәм ифрат җаваплы, куркыныч хезмәт иде ул. Һәр урында, һәрвакыт сине шактый ук хәтәр, серле билгесезлек көтеп тора. Син һич көтмәгәндә баш әйләндергеч тизлек белән эшләнә торган гаҗәеп маҗаралар эчендә булып чыгасың. Кайчакларны үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җитеп кыргыйланган, ерткычланган явыз бәндәләр белән эш итәргә туры килә. Бу кешеләрнең чиксез явызлыклары, шундый башсыз кыланышлары, бер яктан ачу уята, шул ук вакытта күңелдә авыру кешегә операция ясарга тиешле булган хирургка хас бер теләк тә кузгата иде. Хирург авыруның чирле әгъзасын кисеп ташлаган кебек, мондый бәндәләрне дә бүтәннәргә зарар итмәслек хәлгә куярга кирәк иде бит.

Бу эшне мин вакытында чын күңелдән, бөтен тырышлыгымны биреп башкардым. Очы бик еракларга яшерелгән җинаятьләрне ачуга бөтен яшьлек көчемне салып эшләдем. Ул чагында төрле холык иясе, төрле язмыш кешеләре белән очрашу, аларның башыннан узган четерекле хәлләр белән таныш булу язучы булгач миңа бик ярап куйды. Теге яисә бу әсәремне язганда, әгәр шундый ихтыяҗ килеп чыга икән, хәтерем тормышта үзем очраткан яки ишеткән берәр вакыйганы, аның кешеләрен күз алдына ук китереп бастыра иде. Кыскасы, мин әдәбиятка буш кул белән килмәдем дип әйтәсем килә.

Әмма бу әле минем җан теләгән эшем түгел иде. Күңелем һаман эз-

[1] Халык судьясын ул чакта шулай атыйлар иде.

ләнә, әдәбиятка тартыла, бөтен сәләтемне, йөрәгем ялкынын, рухи көчемне тулысынча эшкә кушачак чын эшем, мине көткән юлым менә шушында, якын-тирәмдә генә йөридер кебек хис итә идем. Вакыты белән язасым килгән чаклар да булды. Ләкин ничек язарга?.. Суга керми торып, йөзәргә өйрәнеп булмый, ди бит. Моңа ниндидер көчле бер этәргеч кирәк булган, күрәсең.

Хәер, ул вакытларда мин инде үзем күргән, үз башымнан кичкән кайбер әһәмиятлерәк, кызыграк хәлләрне үзем өчен генә теркәп тә бара башлаган идем. Республика матбугатында, Мәскәүдә татарча басыла торган газета-журналларда авыл тормышын яктырткан кечерәк кенә мәкаләләрем, төрле әдәби парчаларым да чыккалады.

Белемем житәрлек булмавы мине электән үк борчый иде. Шуңа күрә үзлегемнән белем алуга тагын да житдирәк тотынырга карар иттем. Кая барсам да, үзем белән гел китап йөрттем. Гражданнар сугышы вакытында походларда чакта да, тыныч тормышка кайткач, командировкаларда йөргәндә дә, китап минем һәрвакыт аерылмас юлдашым, сердәшем булды. Бик тырышып табигать белемен өйрәнергә керештем. Дарвин, Тимирязев, соңрак Мичурин әсәрләрен бик жентекләп һәм «өйрәнеп» укыдым. Болар арасында минем белемемне тирәнәйтергә күп ярдәм иткән әсәрләр, ихтимал, Н. Рубакин[1] булгандыр. Бу галим күп төрле фәнни мәсьәләләрне, табигать күренешләрен жиңел тел белән аңлатып бирә, барыннан да бигрәк, нинди китаплардан тирәнрәк мәгълүмат алырга мөмкинлеген күрсәтә иде. Француз мәгърифәтчеләрнең тәгълиматы һәм утопияче социалистларның киләчәк турындагы фикерләре дә, философлар, тәнкыйтьчеләр дә миңа күп нәрсә бирде. Атаклы кешеләрнең тәржемәи хәлләре, туган илебезнең һәм башка халыкларның революцион үткәне турында да күп укырга туры килде. Билгеле, вакытның иң күп өлешен татар һәм рус матур әдәбиятын укуга багышлый идем.

Үз тәжрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: үзлегеңнән белем алу юлы белән дә күп нәрсәгә ирешергә мөмкин. Бу системаның уңай ягы шунда ки, әллә кайларга таралып китмичә, фәннең нәкъ үзеңә кирәк өлешен, аның да нәкъ хәзер кирәк булган конкрет тармагын алып өйрәнәсең, белемеңне һәр даим, өзлексез камилләштерә барасың. Шундый юл белән мин белемемне ярыйсы ук тирәнәйттем. Рәсми яктан алганда минем урта белемем дә юк иде. Шулай да 30 яшькә житкәннән соң марксизм-ленинизм институтына кергәч, югары белемле иптәшләр белән бер кафедрада укысам да, фәннәрне үзләштерүдә кыенлык сизмәдем.

## IX

Бу вакытта инде татар әдәбияты, классик әдәбиятта мәгълүм булган барлык әдәби жанрларны үзләштереп, киң иҗат мәйданына чыккан, ул үзеңдә бөтен кешелек дөньясына хас житди мәсьәләләр күтәрерлек иҗат тәҗрибәсе туплаган иде. Бөек Октябрьдан соң, безнең әдәбиятыбыз, җиде гасыр буена җыелып килгән бай әдәби мираска таянып, тагын да тизрәк үсә башлады. Халыкның рухи тормышында элек-электән йөзек кашыдай иң күренекле урынны алып килгән Габдулла Тукай иҗатының эстетик байлыгы һәм философик тирәнлеге тагын да ачыларак төште. Революциягә кадәрге әдәбиятның Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Камал, Дәрдмәнд кебек танылган зур вәкилләре сафына Ш. Усманов, К. Нәжми, Муса Җәлил, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы h. б. иҗат көчләре килеп кушылды. Ул елларда заманыбызның трибуны, талантлы шагыйрь Һади Такташның көчле тавышы

[1] Рубакин Николай Александрович — рус галиме һәм язучысы. 1862—1946.

тагын да дәртлерәк яңгырый башлады. Бик үзенчәлекле, киң сулышлы шагыйрьләрдән Фәтхи Бурнаш, Хәсән Туфан һәм бүтәннәр әдәбиятны яңача яңгырашлы көчле әсәрләре белән баеттылар. Атаклы әдип һәм зур галим Г. Ибраһимовның бер-бер артлы яңа романнары, повестьлары басылып чыга башлады. Аның «Казакъ кызы», «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» кебек әдәби көче һәм колачы ягыннан соклангыч романнары, повесть һәм хикәяләре күп халыкларның культура тормышында тарихи зур вакыйга булды. Г. Ибраһимов китапларын без — ул елларның яшьләре киң канатлы революцион пафос белән сугарылган тирән реалистик эчтәлекле яңа әдәбиятның иң яхшы үрнәкләре итеп укый идек.

Ул чагында мин Балтач һәм Дөбьяз районнарында халык тикшерүчесе булып эшли идем. Мәгълүм булганча, 1929—1931 нче еллар бик тә «кайнар» дәвер иде. Кулаклар, аларның ярченнәре хәбәрчеләрне эзәрлеклиләр, активрак кешеләрне кыйнап, хәтта үтереп үк ташлыйлар. Ул да түгел, әле генә оешкан колхозның ашлык амбары янып китә, я тагын шундый берәр хәвефле хәл булып ала. Боларның һәммәсен ачыкларга, кем, ничек, кайчан, ни сәбәпле диган катгый сорауларга тиз һәм дөрес җавап табарга кирәк. Көне-төне чабасың, атлалар буе аяк өстендә буласың. Кайчакларны бик хәтәр хәлләргә юлыккаладым. Минем ишеләрнең кайберләрен мәчет астына да ябып куйгаладылар. Шул вакытта, төрле кыен хәлләргә дучар булып, минем иптәшләрдән яңадан аякка баса алмаслык дәрәҗәдә гарипләнеп калучылар да булгалады.

Табигый ки, эшем буенча һәм коммунист буларак (ВКП(б) сафына мин 1928 елда кергән идем), мин бу вакыйгаларның һәммәсенең эчендә кайнадым. Вакыты белән агитатор да, оештыручы да, район газетасының редакторы да, лектор да булырга туры килгәне бар. Кайбер җыелышларда хатын-кыз бик яман җәнҗал кубара торган иде. «Колхоз булгач, ире-хатыны бер өйдә, һәммәсе беррәттән тезелешеп ятасы икән, алтмыш аршынлы бер юрган ябынасы икән. Шул дөресме?»— диган сорау да биргәлиләр иде. Андыйларга бик җитди кыяфәт белән:

— Юк ла инде, дөрес түгел!— дип җавап биргәләдек.— Хәзерге юрганнарыгызны ташлап әрәм итә күрмәгез. Колхозда да үз өегездә йоклап, шул юрганнарыгызны ябынасыгыз булыр...

Җыеп кына әйткәндә, төрлесе булды. Уңышлары да, шул уңышлардан баш әйләнүләр дә, арттырып җибәрүләр дә...

Менә шул елларда мин йөрдем-йөрдем дә түзмәдем, үз күз алдымда барган шушы бәрелешләр, төрле вакыйгалар тәэсирендә «Канлы бармаклар» дигән хәтәррәк исемле бер хикәя язып ташладым. Бу хикәям 1931 нче елда Мәскәүдә чыга торган «Ударниклар» журналында басылды.

Хәер, шуннан берничә ел элек, журналист иптәшем Кадыйр Урмановның киңәше белән, Сиваш сугышлары турында очерк та язган идем. Вакытында ул басылып та чыкты.

Бервакыт мин, Балтачтан килгән арада, юл уңаеннан «Совет әдәбияты» редакциясенә кергән идем. Шунда Кави Нәҗми миңа, бу очеркны бик ошатканлыгын әйтеп, Сиваш сугышлары турында зур әсәр язарга тәкъдим итте.

— Сезнең язу алымыгыз шундый,— диде ул.— Салмак кына ага торган киң сулышлы алым. Сез гражданнар сугышының бу чоры турында зуррак күләмле, киңрәк сулышлы әсәр дә яза алыр идегез.

Танылган язучының беренче әдәби тәҗрибәмә шундый бәя бирүе, минем киләчәгемә ниндидер өмет баглавы, билгеле, рухландырып җибәрде. Ләкин мин баштарак үземнең сәләтемә ышанып җитә алмыйча йөрдем. Үземнең зәвыкымны канәгатьләндерерлек, үзем сокланып укыган яхшы әсәрләр дәрәҗәсендә торырдай чын әдәби әсәр язарга көчем

житәрлекме минем, юкмы? Һәрхәлдә, чиле-пешле, булыр-булмас нәрсәләр язу белән генә канәгатьләнәсе килми иде. Ул чагында мин үз-үземә каршы төшеп икейөзлеләнгән, әдәбиятка һәм сәнгатькә булган чиксез ихтирамыма үзем үк күләгә төшергән булыр идем.



## X

Минем «Кызыл Татарстан» газетасына килеп керүем, гомумән, матбугат юлына аяк басуым көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты.

1930 еллар башында республикада элекке кантон системасы бетеп районнар оеша башлады. Шул елны миңа Дөбьязга күчәргә туры килде. Бу тикшерү участогына Дөбьяз һәм Әтнә районнары керә иде. Әйткәнемчә, бик тынгысыз вакыт иде ул. Колхозлар бер авылда оеша, икенчесендә тарала. Мин тикшерү эшләре белән йөреп, атналар буе авыллардан кайтып керә алмыйм, ял көннәре хакында хыяллана да алмыйбыз. Дөбьязга кайткан чакларда да төннәр буе эшләргә туры килә торган иде. Дөрес, бераздан мине халык хакиме итеп куйдылар. Тикшерүче эше белән чагыштырганда хөкем эшләре берникадәр җиңелрәк булса да (авылларга ул кадәр еш чыгылмый, күбрәк Дөбьязда эшли идек), моның үз кыенлыклары килеп чыкты.

Авыл хуҗалыгын күмәкләштерү кампаниясенең иң кызган чагы иде. Газеталарда күбесенчә шул хакта язалар, җыелышлар, утырышлар шул мәсьәләгә багышлана, колхозлар, районнар, авыл хуҗалыгын язгы чәчүгә кадәр тоташ күмәкләштерү өчен үзара ярышалар. Шул хакта авылдан алып үзәк оешмаларга кадәр көндәлек сводка бирелә иде. Игенче агай исә һаман башын кашый, уйлана, һаман суза, гариза бирергә бик үк ашыкмый иде. Районнан барган вәкилләрнең кайберләре күмәкләшүнең файдалы якларын аңлатып-аңлатып карыйлар да, алай гына эш чыкмагач, кискен чаралар куллана башлыйлар: ашлык салымы салалар да, түли алмаса, игенчене хөкемгә тарталар. Шул ук вакытта партия Үзәк Комитеты һәм Совет законнары күмәк хуҗалыкка керүнең ихтыяри булуын искәртәләр, юстиция органнары исә бу законның гамәлгә ашырылуын һәр даим күзәтеп торалар иде. Билгеле, әлеге «бөгәргә» яратучы вәкил язып җибәргән актлар гына хөкем карары чыгарырга нигез була алмый. Хөкем утырышында тикшергәндә фәлән игенченең кулак түгеллеге ачыклана. Ә үз көче белән үстергән ашлыктан ул тиешлесен күптән үк тапшырган, шуннан артыгын күтәрергә аның мөмкинлеге калмаган. Билгеле, андый агайны азат итеп, өстеннән гаепне алып ташларга туры килә иде.

Менә шундый киеренке көннәрнең берендә Дөбьяз райкомы бюро утырышына җыелды. Райкомның беренче секретаре Бәйрәмов, күмәкләшүгә бәйләнешле мәсьәләләр хәл ителгәннән соң, безне, бюро членнарын, районнарда газеталар чыгару турында ВКП(б) Өлкә Комитеты карары белән таныштырды. Әмма үз тарафыннан бер тәкъдим дә кертмәде.

— Я, бу мәсьәләне ничек хәл итәбез? Кайсы башыннан керешәбез? Кемдә нинди тәкъдимнәр бар?— диде.

Бюро членнары уйга калдылар. Чөнки аңа кадәр газеталар зур шәһәрләрдә генә чыга, урыннарда газета чыгару көтелмәгән яңалык иде. Газетаның кадрларын каян табарга, җиһазларын, кәгазьләрен каян алырга? Яңа гына оешып килә торган район җитәкчеләре боларның берсен дә белмиләр иде әле.

Уйлашып утыра торгач Бәйрәмов:

— Бәлки, газетаның җаваплы редакторын билгеләүдән башларга кирәктер? Кемне куябыз?— диде.

Шул кышны Дөбьязга «Кызыл Татарстан» газетасының күчмә ре-

дакциясе килгән иде. Культура бүлеге мөдире Фатих Мөсәгыйтов җитәкчелек иткән бу кучмә редакция кумәкләшүгә багышланган аерым сәхифәләр чыгарды. Әшем бик тыгыз булса да сәхифәләрне чыгаруга мин дә ярдәм иттем. Кичләрен редакциядә еш була идем. Ягъни газета эшен бөтенләй күрмәгән-белмәгән кешеләр белән чагыштырганда бу эштән азмы-күпме хәбәрем бар иде димәкче булам.

Минем башка көтелмәгән бер уй килеп төште дә газета редакторлыгына мин үземне тәкъдим иттем. Башта моңа бик гаҗәпләнделәр:

— Ничек өстеңә аласын? Әле син судья да бит!— диделәр.

— Башта икесен дә җитәкләрмен, тора-бара күз күрер,— дидем.

Бәйрәмов минем тәкъдимне хуп күрде.

— Бәширов матбугат эшләре белән таныш кеше. Өстенә ала икән, бик яхшы. Ничек эшлисен үзе белә торгандыр,— диде.

Шулай итеп, мин хәзер туачак газетаның редакторы! Минем тәкъдимем буенча район газетасына «Колхозчы» дип исем дә куштык.

Хөкем эшләрен башкаруны урынбасарыма йөкләдем дә икенче көнне үк Казанга чыгып киттем.

Ул елларда «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы булып Гаяз Ризванов эшли, аның урынбасарлары Закир Гали һәм Шакир Рәмзи иделәр. Ф. Мөсәгыйт Дөбьяздан кайтканнан соң минем хакта нидер сөйләгәнгә охшый иде. Чөнки болар мине бик җылы каршы алдылар. Редактор тәбәнәгрәк буйлы ябык кына ак чырайлы кеше икән. Шакир Рәмзи, киресенчә, зур гына йомры гәүдәле, кара тут йөзле, куе кара чәчле бик чибәр кеше иде. Минем хакта редакторга ул сөйләп бирде. Редактор шактый ук тынгысыз холыклы булырга охшый иде. Кулларын чалбар кесәсенә яшергән килеш миңа карый-карый өстәле артында йөренгәләп, Ш. Рәмзигә сораулар бирде.

— Соң, шуннан?

Ш. Рәмзи һәммәсен дә уйлап куйган икән:

— Иптәш Бәшировны тәҗрибә туплау өчен өч айга редакциядә калдырыйк.

— Ә Дөбьяз газетасын кем оештырыр?— диде редактор.

— Анда редакциядән Сәйдәшевне җибәреп торыйк. Өч ай эчендә газетаны, шәт, җайга салыр...

Шулай итеп, мин һич көтмәгәндә, газета хезмәткәре булып киттем. Шакир Рәмзи мине култыклап бүлмә саен таныштырып йөрде. Ачык чырайлы бу ягымлы кешене мин беренче күрүемдә үк ошаткан идем. Ул миңа карата соңыннан да гел яхшы, гадел мөнәсәбәттә булды. Рәмзи культура бүлегенең ишек төбенә басып:

— Газетаның яңа әдәби сотрудникы Гомәр Бәширов менә шушы егет булыр,— диде.

Кыю гына кыяфәтле бер яшь ханым миңа күз генә төшереп алды да сизелер-сизелмәс кенә иңбашын сикертеп куйды.

— Һе, егет... Ул фамилия белән газетада күренгән иптәшне, язган әйберләренә карап, гел яп-яшь егет итеп күз алдына китерә идек...— диде.

Кызлар, яшь ханымнар өчен утыз яшәр ирнең карт булып күренүе минем өчен яңалык түгел иде инде. Мин көлеп кенә уздырдым. Рәмзи уңайсызланды, ахрысы, бераз «төзәтеп» куйды:

— Сез аңа игътибар итмәгез, Мәфтинең шулай турыдан бәрә торган гадәте бар. Яратып шаяртуы шулай килеп чыга аның...— диде.

Чая телле ханым сүзләреннән мин үзем өчен нәтиҗә чыгардым. Кайсы яхшырак? Төскә-биткә яп-яшь булып та картлык салкынлыгы бәрелеп торган җансыз әсәрләр язумы, әллә киресенчә, бик үк яшь кыяфәтле булмасаң да әсәрләреңнән яшьлек кайнарлыгы бөркелеп торумы?..

Мине редакциянең авыл хуҗалыгы бүлегенә беркеттеләр. Күрәсең,

көтеп алганга күрәдер, мин яңа хезмәтемә дәртләнеп керештем. Барыннан да бигрәк мине журналистлык сәләтем беренче язган әйберләремнән үк ачылып китүе канатландырды. Редакциядә мин үземне баштан ук кирәкле кеше итеп сиздем. Хәер, миндәге бу язу дәртен редакция житәкчеләре дә сизеп алдылар. Дөресен генә әйткәндә, тын алырга да ирек бирмиләр, бер районнан кайтып керүемә икенчесенә җибәрәләр иде. Ә мин йөри бирәм, яза бирәм. Поездга, я пароходка утырып чыгып китәм дә аннан арбага, я тарантаска күчәм, станциядән ерак булмаган авылларга җәяүләп кенә элдерткән чаклар да булды. Тик газетага очерк, я мәкалә язарлык әһәмиятле вакыйгалар гына булсын!

Көне буе басуларда, колхозчыларның эшләгән урыннарында, атлы сабаннар, чәчкечләр, тырмалар тирәсендә, кыр станнарында йөрим дә, кояшта пешеп, җилдә җилләп кичкә таба авылга кайтам. Авыл кешеләре малларын карап, эшләрен бетереп йокларга яталар. Мин исә авыл Советының, я булмаса, уку йортының шәрә бүлмәсендә керосин лампасы яктысында газетага очерк язам, мәкалә язам. Материал күп, язуы рәхәт, җиңел дә языла иде. Кырларда, фермаларда йөри торгач, җанга азык булырдай гыйбрәтле яки кызык хәлләргә юлыгасың, һәйбәт кешеләр белән очрашасың. Күмәкләшүнең беренче елларында колхозчылар тормышында балалар беркатлылыгы белән эшләнә торган төрле наянлыклар, хәйләләр дә булгалый иде. Мәсәлән, үзара ярышучы бригада членнары эшкә иртә чыкканны икенче бригада сизми калсын өчен, берсеннән-берсе яшеренеп, басуга караңгы белән үк тавышсыз-тынсыз ындыр артыннан гына чыгып китәргә тырыша торганнар иде.

Газетаның кайбер саннарында минем икешәр материалым басылган чаклар да булды. Андый вакытта очерк ахырына чын исем-фамилиямне куйсам, хәбәрләрне, репортажларны «Г. Разин» яисә «Г. Рин» имзасы белән чыгара идем.

Кыскасы, мин күп яздым. Барыннан да бигрәк авылдагы зур үзгәрешләр кызыксындыра иде. Күрәсең, начар да язмаганмын. Минем очерк һәм мәкаләләремне укып, гомумән, ничегрәк эшләвемне күзәтеп баручы Шакир Рәмзи берәр айдан соң:

— Сиңа күптән үк матбугатта эшли башларга кирәк булган икән,— диде.

Билгеле, баштарак миңа журналистлык һөнәрен үзләштерергә ярдәм итүчеләр дә булды. Редакциянең авыл хуҗалыгы бүлегендә агроном Габдрахман Байбеков, журналистлар Фәтхи-Балыкчы, Байрашев, Нәби ага Мансуров белән бер-беребезне ихтирам итеп бик тату эшләдек. Шушы иптәшләр арасындагы дуслык миндә онытылмаслык истәлек булып калды. Безнең мөдиребез — зур стажлы коммунист, тәҗрибәле журналист Нәби ага Мансуров ифрат күркәм холыклы, сабыр һәм ягымлы кеше иде. Ул бик кыен чакларда да тынычлыгын югалтмый, авыр сүз әйтми, бирәсе киңәшен дә ничектер хәтер калдырмаслык ягымлы сүзләр белән генә җиткерә иде. Син язганны бераз укыгач ул:

— Әһә, булган бу, шәп чыккан бу, молодец!— дип куя.

Ә үзе синең белән сөйләшә-сөйләшә генә нәрсәнедер сыза, төзәтә, түгәрәкли, шомарта. Кайчакны син язганнарга шундый сүзләр яки җөмләләр кыстырып куя ки, язган нәрсәң тагын да үткенләнә, мәгънәсе тагын да тирәнәя төшә. Шунда гаҗәпкә каласың: туктале, бу ничек минем үземнең башыма килмәгән, нигә башта ук шулай язмадым икән дип уйлыйсың.

Баштарак мин язган әсәрләремнең эчтәлегенә лаеклы исем таба алмыйча җәфалана идем. Монда да миңа күп вакыт Нәби ага Мансуров ярдәм итте.

Шулай поезддан тарантаска, арбага, арбадан җәяүле сукмагына төшеп бөтен республиканы айкап йөри торгач, өч ай узып та китте. Та-

гын ун көнгә калуымны үтенделәр. Тиешле оешмалар белән үзебез сөйләшербез, диделәр. Мин риза булдым.

Бер көнне каядыр бармакчы булып редакциядән[1] чыгып килә идем, тротуар кырыена җиңел пролетка килеп туктады. Күтәрелеп карасам — каршымда Татарстан Баш судының[2] председателе Хак Нәбиуллин үзе басып тора! 1917 елда ук партиягә кергән, гражданнар сугышы елларында партизан отрядларында сугышып йөргән калын тавышлы, зур гәүдәле кеше иде ул. Күрер күзгә кырысрак холыклы кебек күренсә дә, ара-тирә каты гына орышып ала торган гадәте булса да, без — юстиция органнарында эшләүчеләр — гаделлеге, яхшы күңелле булуы өчен аны чын күңелдән ихтирам итә идек. Ул орыша башлаганчы мин ачык чырай белән:

— Исәнмесез, иптәш Нәбиуллин, хәерле иртә!— дидем.

Ул минем сәламемә җавап бирмәстән, ачулана ук башлады:

— Әле син һаман мондамыни? Бу нинди башбаштаклык?! Әйдә, утыр!— дип кычкырды.

Карулашып торуның мәгънәсе юк иде, миңа Нәбиуллин янына пролеткага менеп утырырга гына калды. Пролетка Кремльгә таба юнәлде. Мине каядыр алып барып җиткәнче, Нәбиуллинның кайнарлыгын сүндерергә кирәк иде. Мин ягымлы тел белән аңлатып бирергә тырыштым.

— Болай бит, Хак абзый. Минем практиканы Баш суд җитәкчеләре белән дә, райком белән дә килешеп озайттылар. Минем ул хакта Сездә гаризам да бар,— дидем.

Ләкин иптәш Нәбиуллин мине тыңларга теләмәде:

— Күп сүләнеп маташма! Миңа Обкомда җавап бирерсең!— диде.

Әһә! Председатель мине ВКП(б) Өлкә Комитетына алып бара икән! Пролетка Кремль урамыннан бара торгач, Сөембикә манарасына җитәрәк, чыннан да, аңдагы ак йортка борылды. Мин артык борчылмадым. Чөнки кагыйдәләргә хилаф килерлек бер ни дә кылганым булмады, вөҗданым тыныч иде. Нәбиуллин артыннан мин дә икенче катка күтәрелдем. Без кадрлар бүлеге мөдире Мусин иптәш каршысына килеп утырдык. Башта шактый ук усал сүзләр кыстырып Нәбиуллин сөйләде. Мин кумәкләшү кебек җитди бер сәяси кампания вакытында, сыйнфый дошманга каршы көрәш фронтын ташлап, әллә кайда йөрүче, дисциплина бозучы сансыз бер бәндә кебегрәк булып чыктым. Аның артыннан инде мин аңлатып бирдем. Иптәш Мусин икебезне дә бүлдермичә игътибар белән тыңлады да кем беләндер телефонда сөйләшергә керешә.

Шунда кинәт бер уй сискәндереп аңыма бәреп керде: карасана, минем киләчәгем хәл ителә торган җитди минутлар бит бу! Миңа Дөбьязга кайтып яңадан халык хакиме булырга, колхоз амбарларына ут төртүдән, ат урлаудан башлап, кооператив акчасын туздыруга кадәр һәртөрле җинаятьләргә каршы көрәшергә туры киләчәкме? Әллә кесәмә блокнотымны кыстырып яңадан авылларга чыгып китәргә насыйп булырмы? Әгәр газетада калсам, бу, Нәбиуллин әйткәнчә, көрәш фронтыннан качу булмасмы? Алай дисәң, газета да көрәшә бит, әле ничек көрәшә!..

Моңа кадәр мин, үземне-үзем кайгыртуны мещанлык санап, тормышымның барышын күп вакыт язмыш ихтыярына куя идем. Бу юлы исә киләчәгем өчен үзем дә көрәшергә булдым. Җитте!

Иптәш Мусин безнең редактор белән сөйләшә иде шикелле. Ләкин аның ара-тирә «алай икән», «әнә ничек» дигәндәй өзек-төтек сүз кыстырып куюларыннан, баш игәләвеннән берни дә аңлап булмый иде. Ул

---

[1] Ул елларда «Кызыл Татарстан» редакциясе Ленин урамындагы баш почтамт каршында ике катлы йортта урнашкан иде.

[2] Верховный суд ул чагында Баш суд дип атала иде.

озак кына сөйләште дә, бераз уйланып утырганнан соң минем үземә сорау бирде:

— Ә сез үзегез кайда эшләргә теләр идегез?— диде.

Нәбиуллин, кәефе кырылып, тез башына сугып алды. Чөнки ул моны Мусинның артык либеральлануы дип аңлый иде. Мин канатланып киттем: Менә демократия ничек була ул!

Мин шатлыгымны берьюлы чыгарып аудармаска тырышып, тыйнаклык белән генә:

— Шушы өч ай күрсәтте инде, мин журналист булырга тиеш икәнмен, иптәш Мусин. Редакциядә мин, һичшиксез, файдалырак булырмын!— дидем.

Мусин берни дә әйтмичә икенче бүлмәгә чыгып китте. Миңа аның мәсьәләгә шулай җитди каравы, һич тә ашыкмыйча, барча ягын нигезләп, киңәшеп хәл итәргә тырышуы бик ошый иде. Әйләнеп кергәннән соң икебезгә дә карап алды да Нәбиуллинга кул сузды.

— Шулай, иптәш Нәбиуллин, иптәш Бәшировның редакциядә эшләве хәерлерәк булачак, ул монда кирәгрәк. Бигайбә! Ә судьяны икенчене табарга туры килер! Хуш!— диде.

Мин шатлыгымнан Мусинга рәхмәт әйтергә дә онытканмын.

Нәбиуллинны да рәнҗетәсем килми иде. Пролеткасына утырырга торганда мин аның янына барып хушлашырга кул бирдем.

— Зинһар, ачулана күрмәгез инде. Күрәсез, тормыш шулай китереп чыгарды бит,— дидем.

Ул миңа карамыйча гына кулын сузды да бер сүз дә әйтмичә китеп барды.

Редакциягә кайткач, мин белмәгән бүтән кайбер нәрсәләр дә ачыкланды. Мине тәҗрибә тупларга дип алып калган булсалар да, җитәкчеләр башта ук әдәби сотрудник итеп беркетеп куйганнар икән. Сәйдәшевне исә Дөбьяз газетасының редакторы итеп раслаганнар.

Күңелгә тагын шик төште. Сәйдәшев минем урынга яз көне вакытлыча гына дип киткән иде бит! Бу аны Казандагы хезмәт урыныннан кысрыклап чыгару булмыймы?

Рәмзи мине тынычландырырга тырышты:

— Юк, ул үзе ризалык бирде. Сәйдәшев бит Дөбьяз янындагы Шыпшыйк авылыннан. Шуның өстенә, сәламәтлеге өчен ул авыл һавасын кирәксенә,— диде.

Рәмзинең күзләре бик елтыравы сәбәпле, мин моның нәкъ шулай булуына бик үк ышанып та җитмәдем. Әмма хәзер инде кире сүтеп булмый иде. Мин Казанда калдым.

## XI

Минем гаиләм моңарчы Дөбьязда яшәгән иде. Эшләр болайга киткәч, Казанда квартира кайгыртырга кирәк булып чыкты бит инде. Нишләргә? Каян эзләп карарга?

Хәзерге Татарстан урамының Яңа Бистәгә чыга торган очында Акком асты дип аталган шактый озын бер урам бар иде. Аның буеннан-буена эреле-ваклы агач йортлар тезелеп киткән, аргы башында нәкъ авылдагыча иртә белән сыер һәм кәҗә көтүе туплана, кичен дә шунда ук кайта иде. Бу урамның шәһәртен таратып торган тагын бер үзенчәлеге шул: аның аргы башында «алтын» заводы бар иде. Урамнан төн буе дөбер-дөбер ассенизаторлар узып тора, алар «алтыннарын» әнә шул «заводка» бушаталар, шул сәбәпле бу урамда кичләрен форточкаларны ачу мөмкин түгел иде.

Казанга килеп төшүгә мине шул урамның бирге башында яшәүче

кардәш тиешле кешеләр сыендырып торды. Гаилә белән анда яшәп булмаячак бит инде.

Шул хакта мин хатыным ягыннан «чыбык очы» туган да булган Бари абзый белән киңәштем. Ул да шул йортта яши иде. Бари Вәлиев — егерменче еллар башында Казан өязе, Мәмдәл волость башкарма комитетының рәисе булып эшләгән. Ул яхшы гына мәдрәсә белеме алган, тарихны яхшы белә, мандолинада оста уйный, егет чагында Салих Сәйдәшев оештырган кыллы оркестрда уйнаганы барын сөйли иде.

Бари абзый мине тыңлап утырды да:

— Әгәр ошаса, бер бүлмә чамалап булыр,— диде.

Миңа болай бик ансат вәгъдә итүе сәеррәк тоелды. Ул мине шундук үзе яшәгән ике катлы йортның урам ягыннан бер коридорга алып керде. Без аркылы җеп салып сургуч пичәт белән беркетелгән ап-ак биек ишек янына килеп туктадык.

— Монда Казаков дигән сал йөртүче татар баеның өченче хатыны яшәгән. Бу аның йокы бүлмәсе. Хәзергә хуҗасыз. Әгәр журналист башым белән... дип кимсенмәсәң... шушында урнашырга була. Чамала, ошармы икән соң?

Ошамаган кая инде ул?! Иркәләнеп торыр чакмыни? Хәзергә баш төртерлек бер почмак булса, соңыннан күз күрер иде әле.

Коридорга ап-ак чынаяк мичнең алгы ягы чыга, сары буяулы идән, бизәкле стеналар, коридоры да зур гына...

— Ошавын ошар иде анысы. Тик моңа пичәт сукканнар бит!— дидем.

Пичәт ватып керү өчен җинаять эшләре кодексының кайсы статьясы көтеп торуын мин яхшы беләм бит!

Әмма Бари абзый чаларган мыегын сыпыргалап серле елмайды гына.

— Син ул ягы өчен хафаланма. Барасы җиреңә бар, эшлисе эшеңне эшлә. Калган ягы безнең өстә!— диде.

Кайсыдыр районда берәр атна чамасы йөреп кайткан идем, Бари абзый тантаналы рәвештә миңа ниндидер ачкыч сузды. Бик җитди кыяфәт белән башын ия төшеп:

— Рәхим ит, журналист иптәш, фатирың әзер!— диде.

— Ничек алай бик тиз?

Бари абзый бик матур итеп сөйләшә белүче оста телле, шаянрак холыклы кеше иде. Мине култыгымнан алды да елмая-көлә сөйләнеп әлеге коридорга алып керде.

— Беләсеңме, журналист иптәш, «бирергә теләгән колына, чыгарып куяр юлына», дигән бит. Бәхет басты синең! Күрше хатыны коридордан утын күтәреп узганда ялгыш кына эләктереп нитмәсенме... сургуч пичәтне кубармасынмы!.. Инде нишләргә? Пичәтне яңадан ябыштырып булмый бит! Әллә ниткән берәр юньсез бәндә кереп утырмагае дидек тә...

Мин ышаныр-ышанмасрак бер ишеккә, бер Бари абыйга карап тордым да әчкә уздым. Ни күзем белән күрим, җиһазлы бүлмә! Менә сиңа тамаша! Тәрәзәдән күреп йөрдем бит: мин киткәндә бүлмә эче шәп-шәрә иде. Ә хәзер? Тәрәзә каршысында өстәл, аның өстендә самовар, шунда ук җиз подносы, чәйнеге, чынаяклары, тагын шундый ашау-эчү дирбиялары. Стена буенда өч аяклы карават, ишек янында ямаулы булса да җиз ләгән ялтырый, хәтта мич буена калайлаган иске сандык та кереп утырган...

Ишек янында Бари абый кәефләнеп елмаеп тора.

— Монысы өчен яңа күршеләреңә рәхмәт әйт,— ди ул.— Өй җиһазын алар кертте. Кемдә нәрсә бар... Кайсы тишек, кайсы ямаулы...

— Рәхмәт инде, мәшәкатьләнмәгәндә дә ярыйсы икән.

— Юк, алай түгел, аның хикмәте бар,— ди Бари абый.

— Шулаймыни әле?

— Соң, шулай булмыйча! Син тыңла: коммунхоз агенты килә, карый: Әһә, ишектә йозак, ә бүлмәдә — әйбер-сәйбер. Ул уйлый: значыт, монда кемдер яши. Кем яши? Ничек кергән? Кем ордер биргән? Шуны ачыклаганчы ул бүлмәгә ордер бирми торалар. Сизденме?

Сизүен сиздем, шулай да булсын, ди. Ә мин? Мин ничек җавап бирәм, ди?

Бари абый анысын да уйлап куйган икән.

— Ә син хәзер үк коммунхозга гариза илтәсең: шундый-шундый буш яткан бүлмәгә ордер бирегез, дип... Аңлашылдымы? Бүлмәнең буш ятуы хак. Анысына мена без шаһит.

— Ул агент дигәннәре хәзер үк килеп чыкса?

— Ә син тотылмаска тырыш!— ди Бари абый.

Түзеп булмады, кычкырып көлеп җибәрдем. Күптән түгел генә шундый законга хилаф эшләргә каршы үзем көрәшеп йөргән кеше бит мин! Хәзер, гаепле кеше сыман, кемнәндер качып йөр, имеш!..

Ләкин шәһәр тормышының хикмәтле якларын Бари абзый яхшырак белә иде. Бу гамәлнең законга да, әхлак кагыйдәләренә дә хилаф килмәвен ул хәтта исбатлап та күрсәтте.

— Син мәдрәсәдә гыйлем тәхсил кылган[1] кеше бит, фәйләсуфларча фикер йөртеп карале.

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, ярый, әйтик, «вөҗданым күтәрми» дип, син бүлмәдән баш тарттың ди. Ләкин көт тә тор, иртәгә үк монда нинди дә булса, бер капъйот пикүләй[2] яисә бөлгән нэпман борынын китереп тыгачак. Сөаль: кайсының фатирлы булырга хакы зуррак? Пикүләйнеңме, яшь журналистныңмы?

Мин шатлыктан кулларымны угалап:

— Булды гына, Бари абзый, ышандырды!— дидем.

— Шул-шул менә! «Хәйләсез, дөнья файдасыз». Укыдың бит, хәтта дини тәгълимат та хәйләи шәргыйне бөтенләй үк инкарь итми. Гаиләңне фатирлы итәсең килсә, андыйга гына түзәсең инде.

Хәйләсен дә өйрәттеләр. Бүлмәне иртүк бикләп китәм дә, караңгы төшкәч кенә кайтам. Бер ун көнләп авылларда йөреп үтте. Күршеләр әйтә тордылар: коммунхоз агенты эш сәгатьләрендә килә икән дә мине очрата алмагач, сүгенеп кире китә икән.

Болай качышлы уйнаулар җанымны кыйный, моның бер чиге килеп чыгуын үзем үк тели башлаган идем инде. Шулай булды да.

Бер көнне, типографиядә төнге редактор булып газета чыгару сәбәпле, таң аткач кына кайткан идем, көндәгечә иртәрәк тора алмаганмын. Яман дөбердәтеп тәрәзә какканга уянып китсәм, ир уртасы бер кеше ачулы кыяфәт белән миңа йодрык күрсәтә.

— Под суд бирәм мин сезне! Давай, киенегез!— ди бу.

Ярар, «подсуд» белән мине өркетә алмыйсың, анысына әллә ни исем китми. Әмма икенче ягы бар: ул кешегә ияреп баргач, бүлмәне ничек ычкындырмаска?!. Менә кайда эшләтергә кирәк башны!

Шәһәрнең коммуналь хуҗалык идарәсе ул елларда Бауман урамында хәзерге «Совет» кунакханәсе бинасында урнашкан иде. Әлеге агент мине икенче каттагы зур кабинетта утыручы яхшы гына киенгән бер түрә каршысына илтеп бастырды.

— Менә шушы кеше инде ул!— диде.

Мин кем булуымны, Казанга ни сәбәпле килүемне, коммунхозга күптән үк торак турында гариза биреп куюымны аңлата башлаган идем, ул иптәш мине бүлдереп әлеге агентка:

— Нәрсә көтәсең, яз актыңны!— диде.

Эшләр болайга киткәч, авыз ачып тору ахмаклык булыр иде. Мин

---

[1] Гыйлем тәхсил кылган — белем алган.
[2] Пикүләй — спекулянт (жаргон).

ул кешедән телефонда сөйләшеп алырга рөхсәт бирүен үтендем. Ул миңа шактый ук усал караш ташлап тагын кисеп кенә салды:

— Нинди телефон тагын! Сезгә бернинди телефон да ярдәм итә алмый! Әйткән бит акт язарга дип! Баста!— диде.

Мин үтенечемне яңадан кабатладым.

— Өстемә ташланган гаепне редактордан яшереп калырга хакым юк. Бездә тәртип шулай. Рөхсәт итегез!— дидем.

Редакторның Обком бюросы члены булуын, билгеле, ул белә иде, юашланып китте. Икеләнебрәк булса да телефонга башы белән ымлады.

— Сөйләшегез!— диде.

Бәхеткә каршы, редактор Г. Ризвановның кабинетында чагы туры килде. Мин аңа, күп эзли торгач, Акком асты урамында күптән үк буш яткан тугыз метрлы бер бүлмә табуымны, шуңа ордер бирүләрен үтенеп күптән үк гариза биргән булсам да, мине хәзер ул бүлмәдән чыгарырга җыенулары турында сөйләп бирдем.

Г. Ризванов, кыска гына итеп:

— Аңлашылды. Бирегез әле ул иптәшне!— диде.

Хәзер инде минем урамымда бәйрәм иде. Мин әлеге иптәшнең аягүрә баскан килеш: «Тыңлыйм, иптәш Ризванов», «Аңлашылды, иптәш Ризванов»,— дип әледән-әле телефонга баш июләрен мыек астыннан елмаеп кына карап утырдым.

Әлеге башлык, сөйләшеп бетерүгә, кинәт бөтен йөзе белән яктырып миңа кулын сузды.

— Башта танышыйк, иптәш кем...

— Бәширов.

— Әйе, иптәш Бәширов! Соң башта ук кем икәнне әйтеп сөйләшәләр аны! Һи! Соң, журналист кешегә бер бүлмә җәлмени? Хәзер оформить итәбез аны!

Мин Казан шәһәрендә яңа һөнәремнең абруе биниһая зур булуына кәефләнеп горур гына утырган арада, әллә кайлардан гаризамны да табып китерделәр. Аның өске почмагына әлеге иптәшнең кызыл кара белән кыеклатып резолюция салуын карап утыру да бик күңелле булды. Иртәгә сәгать унда ордер алырга керүемне үтенеп кулымны кысып калдылар.

Шундый мажаралы юллар белән яулап алынган булса да, бу кечкенә бүлмә бик бәхетле булып чыкты. Дүрт-биш елдан аңа тагын бер күрше бүлмә өстәлгәч, ул «квартира» дип аталырлык рәвешкә килде. Без анда егерме ел яшәдек. Җәмәгатем белән ике бала үстердек. Бирелә мин бик күп очерклар, мәкаләләр, хикәяләр, «Сиваш» повестен һәм «Намус» романын яздым.

## XII

Матур әдәбиятка мине журналист һөнәре алып килде диярга мөмкин. Каян беләсең, әгәр дә әдәби сәләтем барлыгын башта газета битләрендә сынап карамаган булсам, бәлки тагын күпмедер вакытым башка тармакларда эшләп үткән булыр иде. Газетада эшләү минем дөньяга карашымны, мохитымны киңәйтте, каләмемне чарлады.

Кая гына барып чыкмый журналист, аны нинди генә истәлекле, нинди генә гаҗәеп очрашулар көтми!

Мине кышкы караңгы төшәрәк ашыгыч рәвештә Казан аэропортына дәшеп алдылар. Берничә минуттан мин даны бөтен дөньяга таралган самолетлар сынаучы В. Коккинаки самолетында булып чыктым. Баштанаяк мехка төренгән, аягына калын унты кигән тыныч карашлы бу җитди кеше мине самолет кузгалып китәр алдыннан очучы креслосында кабул итте. Кабина ярым караңгы иде. Өстеңә йөкләнгән журналистлык вазифасы сине кыю булырга, теләсә кемгә төрле сораулар бирергә мәҗбүр итә:

— Владимир Константинович! Газета укучыларның бик беләселәре килә, әйтегезче, сез бу юлы Төньякка нинди максат белән очасыз?— дидем мин.

Ул тәфсыйллап җавап бирде.

Бу — Арктикада боз таулары кысып ватканнан соң челюскинчылар корабленең боз әсирлегеннән азат ителгән еллары. Арктика геройларының һәр очышы халыкны бик кызыксындырган чагы иде. В. Коккинаки исә яңа самолетларны сынаудагы батырлыклары белән шөһрәт казанган очучы. Шунлыктан аның җавабын типографиянең хәреф җыючысыннан башлап газета редакторына кадәр әллә никадәр кеше көтеп тора, ул җавапка газетаның беренче битендә махсус урын калдырылган иде.

Хәтеремдә, В. Коккинакиның караңгы күккә таба берүзе очып менеп китүе мине ифрат дулкынландырды. Кап-караңгы төндә өермәләргә, давыллы бураннарга каршы бер үзең көрәшкә чыгу өчен нинди батыр йөрәкле, нинди фидакарь рухлы булырга кирәк дип уйлап алдым. Бәлки, әле хәзер дә ул шундый кыен шартларда ниндидер яңа самолетны сынарга чыгып киткәндер?..

Икенче бервакыт СССР Верховный Советы Президиумы председателе Михаил Иванович Калининнан интервью алу бик ачык булып истә калган. Ул безнең ударник колхозчылар съездына республикага орден тапшыру өчен килгән иде. Рус журналисты Тройский белән без аның Казан тимер юл станциясенең бер кырыена тукталган махсус салон-вагонына барып кердек. Михаил Иванович вагоны тирәсендә кораллы сакчылар күренмәве безне гаҗәпләндерде, Михаил Ивановичның үзен бик гади тотуы да безгә бик ошады. Хәер, элекке Тверь губернасы игенчеләре арасыннан чыккан, заводларда гади эшче булган бу сөйкемле картны без үзе белән очрашканчы ук шулай дип белә һәм ярата идек. Ул елларда аны хөрмәтләп, «Бөтенсоюз старостасы» дип тә, партиянең иң талантлы пропагандисты дип тә йөрттәләр иде.

Михаил Иванович авыл картлары кия торган ак тимер кысалы гади генә күзлеген төзәткәләп кулы белән урындыкларга ишарә итте. Без утырдык. Безгә ни кирәген ул алдан ук белеп тора иде, безнең сорау бирүебезне көтмәстән, үзе үк сөйләп бирде. Татарстан колхозчыларының Днепропетровск игенчеләре белән ярышуда җиңеп чыгуларын партия ил күләмендә зур вакыйга дип карый, бу тәҗрибә башка өлкә һәм республика игенчеләренә дә үрнәк булырга тиеш икән, иртәгә ачылачак колхозчылар съезды менә шул яктан да бик әһәмиятле икән...

Икенче көнне мин Михаил Ивановичны ударник колхозчылар съездының президиумында күрдем. Ул В. И. Ленин сеңелесе Мария Ильинична Ульянова һәм Г. Ибраһимов белән янәшә утыра иде, тирән эчтәлекле речь белән дә чыкты.

Мондый очрашулар күңел офыкларымны киңәйтеп, рухи хәзинәмне баетып, минем үземне дә үстерделәр.

Үземне-үзем кыенлык белән табуым хакында язган идем шикелле инде. Аның каруы редакциядә эшли башлагач нәрсә турында язасымны баштан ук белеп керештем. Мине барыннан да бигрәк авыл тормышы, анда да игенче агайның рухи дөньясы, аның яшәешенә тормыштагы яңалыкларның ничек тәэсир итүе кызыксындырды. Бу хакта озакка сузмыйча, зур әсәрләр язылганны көтмичә, көне-сәгате белән көндәлек матбугатта язып бару өчен иң кулай, иң җайлы жанр — әдәби очерк булып чыкты. Шуның өстенә, бу жанр балачактан ук күңелдә җыелып килгән кадерле тойгыларны да, замана сулышын да укучыга үтемлерәк итеп житкерергә мөмкинлек бирә иде.

Ни сәбәпле мине барыннан да элек авыл тормышы кызыксындыруы да аңлашылса кирәк.

Мин — авылда туган, тере туфракның үзе өстендә, аның чирәме өстендә уйнап, буразналары арасында эшләп үскән кеше. Язын-җәен җир-ананың ничек сулыш алуын, аның өстендәге бөтен тереклек дөньясының — үлән сабакларының, яфракларның, бөреләрнең кояш нурына ничек комсызланып сузылуын, шуннан яшәрткеч куәт алып, дәртләнеп үсәргә, чәчәк атарга, үрчергә керешүләрен дә күрә беләм, игенче агайның кытыршы куллары җирнең йомшак тәненә нинди якты өметләр белән үрелүен дә яхшы аңлыйм. Малай чакта мин җирне үз маңгай тиремне түгеп үзем сөрдем, үзем тырмаладым. Шунлыктан, җир белән икмәккә бабайлардан нинди генә хөрмәтләр әманәт булып калган булса, аңа минем үз өлешем дә өстәлә. Бәлки шунлыктандыр, мин гомеремнең яртысыннан күбрәген шәһәрдә уздырсам да, күңелем белән һаман да авыл малае булып калдым.

Авылның авыл булуы өчен яраттыра торган үз матурлыгы, үзенә генә хас мәңгелек поэзиясе бар. Шулай да әгәр авылны шул яклары өчен генә яратсаң, ул әле бер яклырак кына булыр иде. Минемчә иң әүвәл авылның кешеләре ярattыра. Табигатьнең үз эчендә яшәгәнлектән, алар аны тирәнрәк аңлыйлар. Табигать аларга үзенең күркәм сыйфатларыннан мулрак өлеш чыгарган. Аларның холык-фигыльләрендә, үзара мөнәсәбәтләрендә эчкерсезлек, гадилек, самимилек, иркен күңеллелек кебек яхшы сыйфатлар ачыграк сизелә, күренебрәк тора.

Шуларның һәммәсе өстенә, дөнья халкының тамагын туйдыручы, аңа яшәү мөмкинлеге тудыручы игенче һөнәрен мин җир йөзендә иң борынгы һөнәр дип, бөтен халык тарафыннан ихтирам ителергә тиешле иң изге һөнәрләрнең берсе дип саныйм.

Бәлки, бу мәхәббәтне көчәйтүгә матур әдәбият та сәбәп булгандыр? Мәгълүм ки, татар әдәбиятының барлык язучылары да диярлек авылдан чыккан кешеләр. Безнең әдипләребез һәм шагыйрьләребез авылның үзе, аның халкы турында, аның чиктән тыш авыр һәм шул ук вакытта шигъри матурлык белән бизәлгән катлаулы хезмәте һәм тормышы турында элек-электән бик яратып яздылар. Г. Ибраһимов, Г. Тукай һ. б. бик күпләрнең әсәрләре кемнәрне генә рухландырмагандыр! Сәгыйть Рәмиевнең балачакта ук укыган «Авыл» дигән шигырен оныту мөмкинмени?

Әй, авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш!
Нинди иркен, нинди рәхәт,
Нинди бар җир гөл генә;
Синдә төн дә юк, төнең дә
Бер болытлы көн генә...

Ихтимал, бу мәсьәләдә мин берьяклырак фикер йөртә торганмын. Бүгенге шикелле атом һәм кибернетика заманында минем бу карашым кайбер яшьләргә, бәлки, искергән кебек тә тоелыр. Әмма нишлим? Ул минем каныма сеңгән. Минем бу карашымның яшәеш мәйданында тирән тамырлары бар. Бу темага язуны мин җанга рәхәт бирә торган куанычлы бер иҗат эше дип карыйм.

Шулай итеп, мин газетада башта ук авыл тормышы турында язучы очеркист булып киттем. Бу үзе күп көч куюны сорый торган тынгысыз һәм бик мәшәкатьле эш булса да, мин аны бик ярата идем.

Күптән түгел генә колхозга кергән игенче агайның аңында зур үзгәрешләр башланган чор иде бу. Моңарчы аның «үземнеке» дип йөргәне күмәкләшкән хуҗалыкта уртак милеккә әйләнгән, ләкин «уртагы» әле тәмам «үземнеке» булып җитмәгән чак. Ләкин агайның искелек тә бик үзәгенә үткән, аннан да тизрәк котыласы килә, алда торган яңа тормыш та бик кызыктыра. Яңа тормыш буыннан-буынга чиләндереп килгән авыр хезмәттән коткарырга, яңа заман рухында, яңача, җиңел-

рәк тормыш вәгъдә итә иде. Шунын йогынтысында кешеләр, акрын гына, сизелер-сизелмәс кенә булса да үзгәрә баралар кебек иде. Очерклар язганда мине, барыннан да бигрәк, әнә шул яңы кызыктырды.

«Үземнеке», «колхозныкы» дигәннән, Мария Ильинична Ульянованың әлеге колхозчылар съездында әйткән бер фикере мине бик озак уйландырган иде. Мин аны хәзер сүзгә-сүз хәтерли алмыйм инде. Әмма мәгънәсе болай иде:

— Күмәк хуҗалыклар алга китсен өчен, һәр колхозчы, үз хуҗалыгындагы кебек үк, чын күңелдән тырышып эшләргә тиеш...

Мария Ильинична колхозчылар аңлардай гади тел белән күңелләргә үткәреп сөйләде, мин аны игътибар белән тыңладым. Әмма бу фикеренә кушылмадым. Янәсе, ничек инде колхозчы элекке хосусый милекче вакытындагы шикелле генә эшләсен?! Аңлылыгы ягыннан ул бит элекке игенчедән бер баскычка булса да югарырак торырга, хезмәтендә дә аннан әллә никадәр уздырып җибәрергә тиеш...

Шулай уйлый идек. Чөнки ул елларда без чамадан тыш «кызыл», бик тә түземсез бәндәләр идек әле. Игенченең аңын ансат кына үстереп, колхозларны тиз генә баетып алырга да тизрәк коммунизмның ишеген кагарга ашыга идек. Әмма тормышның исә үз закончалыклары, үз логикасы бар икән ләбаса. Кешенең рухи дөньясы без теләгәнгә карап кына алай бик тиз үзгәрми икән. Монархы барлык сыйнфый дәүләтләрнең нигез ташы булып килгән хосусый милек идеологиясе хәзер дә бирешергә теләми. Элек кешедә капъйот комсызлыгы уятып халыклар арасында кан коюга сәбәпче булган, туган белән туганны якагаяка китергән икән, ул хәзер дә шуны ук дәвам иттерергә омтыла. Ул, явыз, адәми затның холкына-фигыленә, аның бөтен тормышына шул тикле тирәнгә кергән, аны куып чыгару өчен яңа җәмгыятькә бик озак көрәшергә туры киләчәк икән әле.

Колхозларда озак йөри торгач, мин шуны аңладым: Мария Ильинична хаклы булган, колхоз эшен үз эшең кебек чын күңелдән яратып эшләү ул заман өчен алга китү булган икән әле ул.

Әмма яңалыклар да, кешедәге үзгәрешләр дә күп очрый иде. Әйтик, гади бер колхозчыда, бригадирда яисә сыер савучы хатында иске авыл кешесендә була алмастай өр-яңа бер күркәм сыйфат чагылып китә. Бу сыйфат кешене эчтән яктыртып, аның рухын, кемлеген бөтенләй көтелмәгән яктан ачып җибәрә. Зур Тарханның ишна Насыйбулла исемле алтмыштан узган бер бабай ярты төннән эшкә чыга, зур фидакарьлек һәм батырлык эшли. Нәрсә рухландырган бабайны? Хезмәт кенәме? Данмы? Юк. Аның үз колхозын алдынгы итәсе килгән.

Яисә мондый хәлгә игътибар итәсең: элек, ялгыз хуҗалык вакытында гомер-гомергә ялкау дип даны чыккан фәлән абзый үзенең тырыш хезмәте белән колхозның хөрмәтле кешесенә әверелә. Ничек алай? «Мине кешегә саный башладылар»,— ди ул. Анда кешелек горурлыгы уянган. Әле күптән түгел генә, бары узган ел гына бер адым җир өчен бер-берсенең якасына ябышкан, бакчасына күрше тавыгы кергән өчен «икмәк шүрлекләренә» бирешкән тынгысыз күршеләр хәзер бер бригадада туганнарча дус яшәп, татулык үрнәге күрсәтәләр. Кыскасы, синең күз алдында күркәм сыйфатлы, ифрат та үзенчәлекле, эш сөючән яңа кешеләр туып килә.


*Ахыры киләсе санда*

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**Калды уң якта «Китаплар ханәсе»,**
**Сулда — «Әльислах» идарәханәсе.**

Г. Тукай. «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш».



1908—1909 елларда «Әльислах» газетасы редакциясе урнашкан йорт. (Хәзерге Тукай урамы, 63.)

Татьяна Зуева рәсеме.

## Зәкия Рәсулева

# ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕННӘН

## Моңлы җыр

*Аитова Фатиха мәктәбе укучысы, соңыннан тегүче булып эшләгән, 80 яшьлек Галия Хәсәновна Халитова истәлеге.*

8— 10 яшьлек чагым булса кирәк, әни тутам белән мине олы абзаларым Муллахмәт һәм Хуҗа Бәдигыйларны чакырып кайтырга җибәрде. Алар китап кибетендә булырлар, диде. Захаровскаядамы, Екатеринскаядамы урнашкан урам чатындагы кибеткә оялып кына барып кердек. Кибеттә кеше юк. Тик эчке якта кемдер җырлый. Артык көчле булмаган матур гына тавыш күңелгә үтә торган моңлы көй җырлый. Без тынычбызны да алырга базмыйча тыңлыйбыз. Җыр байтак дәвам итте. Аннары кинәт тукталды. Эчтән: «Габдулла, ник туктадың? Җырла инде»,— дип үтенгән тавыш ишетелде. Аңа каршы тавыш: «Карале, теге якта кеше бар, ахры, хатын-кызлар керде булса кирәк»,— диде.

Кинәт эчке яктан кибеттә сату итүче безнең якташ егет Рәхмәтулла килеп чыкты. Без аннан: «Кем ул шулкадәр матур итеп җырлады?» — дип сораштыра башлаган идек, яныбыздан ашыгып бер егет чыгып китте. Рәхмәтулла: «Әнә шул кеше җырлады инде. Шул инде шагыйрь Габдулла Тукаев»,—диде.

Мин чыгучыны әйбәтләп карап кала алмавыма бик үкендем. Чөнки шигырьләрен ятлап, күңелдә биклэп һәм һәрчак яратып кабатлап йөри торган шагыйребез Габдулла Тукаевны мин башка бервакытта да күрә алмадым. Ә җырлавы, үзәгемне өзгән моңы әле дә булса күңелемдә.

## «Мөхәммәдия»дә

*РСФСРның атказанган укытучысы Мәхмүт Галиев һәм Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе Закир Шакиров истәлеге.*

Казанның инде картайган Йосыф мулла мәхәлләсенә яшь мулла Галимҗан Галиев билгеләнә. Пороховой бистәсеннән булганга, Галимҗан үзенә «баруди», ягъни гарәпчә «дарылы» дигән атама ала.

Бу мәхәллә мәдрәсәсендә 1882 елдан 1892 елга кадәр кадимчә, 1892 елдан яңача укыта башлыйлар. Мәдрәсәнең даны арта. Шәкертләр саны күбәя. Яшь мулла элеккеге кечкенә мәдрәсә урынына зур итеп, заманча итеп мәдрәсә салдырырга уйлый. Ләкин карт мулла үзенең мәдрәсәсен сүттерергә риза булмый һәм Галимҗан Баруди үзе уйлаган зур мәдрәсәне кечкенә мәдрәсә артына кысынкы гына урынга салдырырга мәҗбүр була. 1900 елда мәдрәсә салынып бетә. Бу мәдрәсә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе яки Галимҗан Баруди мәдрәсәсе дип атала.

Яңа мәдрәсә бик зур, өч катлы була. Искесе исә бер генә катлы, ул ишегалдында кала. Яңасының уң канатындагы өченче этажына шәкертләр «Сахалин ягы» дигән исем тагалар. Мәдрәсәдә укыту үз заманына күрә алдынгы була. Татар халкының күренекле кешеләреннән Хөсәен Ямашев, татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан, шагыйрь Мәҗит Га-

фури, фольклорчы профессор Хуҗа Бәдигый, шагыйрь Әхмәт Исхак һәм башка бик күпләр шушы мәдрәсәдә укыганнар.

Мәдрәсәдә үткәрелгән дәресләрнең берсендә Габдулла Тукайның да булганы билгеле. Замандашларының искә алуына караганда, Тукай тормышның бөтен яклары белән дә кызыксынган. Яшьләрне тәрбияләү, мәктәп, мәдрәсәләрдә фән укытуга ул бигрәк тә зур әһәмият биргән.

Шул заманда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих-география фәннәрен укытучы Закир Шакиров үзенең истәлегендә («Тукай Башкортстанда». Өфе, 1966) дәрестә географик карталар һәм проекцион фонарь белән диапозитивлар кулланылуын, дәресне тыңлап утырган Габдулла Тукайның дәресне бик яратуын яза. Дәрестән соң Тукай «Географияне менә шулай укытырга кирәк аны»,— дигән.

Шул ук Закир Шакиров язуынча, «Мөхәммәдия»дә атна-унбиш көнгә бер тапкыр әдәбият түгәрәгенең җыелышлары үткәрелә торган була. 1908 елдагы бер җыелышка бик күп кунаклар һәм Габдулла Тукай да килә. Җыелыш мәдрәсәнең өченче катындагы зур залда (намаз уку бүлмәсендә) үткәрелә. Бер шәкертнең үзе язган хикәясен укыйлар. Шул чак шәкертләрдән берәү ашыгып кереп: «Будошниклар, приставлар килә»!— дип кычкыра. Ул арада полицейскийлар залга бәреп керәләр. Ә залның «Сахалин ягы» дип йөртелгән уң ягындагы кечкенә ишектән Тукай һәм башка кунаклар чыгып китәргә өлгерәләр. Залда кинәт ут сүнә: шырпы яндырып карасалар, залда полицейскийлар үзләре генә басып калган.

Икенче көнне полицейскийлар мәдрәсәгә килеп:

— Әдәбият кичәсендә Тукай, Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдиновлар бар иделәрме? — дип сорап йөриләр. Ләкин берәү дә «белмәдек», «күрмәдек»тән башка сүзне әйтми.

Мондагы әдәбият кичәләрендә булганда Тукай үз фикерен чыгып сөйләми, бары түгәрәкнең иң актив әгъзалары белән генә уртаклаша. Чөнки Тукайга реакциядән бик сакланырга кирәк иде, дип яза Закир Шакиров шул ук истәлегендә.

## «Шәрык» клубында

Казанда чыга торган «Йолдыз» газетасында, башка хәбәрләр белән бергә, төрле белдерүләр дә басыла:

«... Әдәбият вә музыка кичәсе була. Габдулла әфәнде Тукаевның үзе таэлиф иткән шигырьләрен Габитова һәм Ханәфи әфәнде укыячак. Билетларны «Сабах», «Гасыр» китапханәсендә һәм Шәрык клубында алырга мөмкин».

«Зилзилә (җир тетрәү. З. Р.) фондында якшәмбе көн 6 февральдә Шәрык клубында Җиде су вилаятендә зилзиләдән зарар күргән халык файдасына... музыка кичәсе була... Солтан Рахманколый «Ашказар»ны җырлаячак».

Шул ук көннәрдә газетада «Үткән якшәмбе көн Шәрык клубында Солтан илә Фәйзи әфәнделәрнең «Зиләйлүк», «Ашказар», «Җәмилә бикә» һәм «Гөлчәчәк» көйләрен җырлаулары тыңлаучыларның хушларына китте (42 сум акча җыелды)», дип хәбәр ителә.

Шул ук «Йолдыз» газетасының 1910 ел, 13 апрелендә чыккан санында: «Тиз арада Шәрык клубы залында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты турында лекция укыячак»,— дигән игълан басыла.

Ә инде газетаның 15 апрель саны: «Бүген пәнҗешәмбе 15 апрель кич 9 сәгатьтә Шәрык клубында Габдулла әфәнде Тукаев халык шигырьләре турында лекция укыячак. Билет бәясе 30 тиеннән 15 тиенгә кадәр» — дип хәбәр итә.

Бу лекция турында («Тукай Башкортстанда» дигән китапта) укытучы Закир Шакиров болай дип яза: «Кабан күленә каршы бинада, Шәрык клубында Тукайның халык әдәбияты турында лекциясе булды... Тукайга чаклы, минемчә, бу темага лекцияләр булганы юк иде,— ди. — Габдулланың тавышы артык көчле түгел. Шулай да бик ягымлы... тыңлаучыларда теләгән тәэсирне тудыра алырлык иде. Халык моңнарын телгә алганда, Тукайның «Ашказар», «Тәфтиләү» кебек җырларга аеруча соклану белән тукталып китүе истә калган. Җыелган халык лекцияне гаҗәеп кызыксынып тыңлады. Лекция беткәч, без — аның якын танышлары — Тукай янына килеп зур канәгатьләнү белдердек», — ди.

Ул чакларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте булган Хуҗа Бәдигый «Халык әдәбияты» турында лекция» дигән истәлегендә («Тукай турында замандашлары»): «Газеталарның берсендә Тукайның тиз арада халык әдәбияты турында лекция укыячагы турында бер хәбәр чыкты.

Тукай үзенең бу лекциясен Шәрык клубында укыды. Халык шыгрым тулы иде... Лекция миңа бик ошады. Тукай үзенең лекциясендә... фольклорның чын хезмәт массасы иҗаты булуын төрле мисаллар белән ачты. Шуларны йомгаклау урынына җиткәч:

— Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл вакытлы гына... — дип, хезмәт массасына карата үзенең гаять кыйммәтле бәясен бирде.

Халык җырларына әһәмият бирергә кирәклеген, чын халык телен, чын халык рухын халык җырлары чагылдыруын, фольклор материалларының реаль чынбарлыкны чагылдыруын һәм анда чын халык теле, хезмәт массасының өмет һәм теләкләре шәүләләнүен ачып бирде»,— ди.

Шәрык клубында шулай ук балалар өчен дә кичәләр үткәрелгән.



## Казанда Тукай яшәгән мохит

*Фуат Тимерович Саллави-Соловьевның икенче истәлеге.*

Без 1911 елда гаиләбез белән Казанга килеп, «Болгар» номерларында тора башладык. Килү белән безнең каршыдагы бүлмәдә Габдулла абый яшәгәнен белдек.

«Болгар» нормерлары бертуган сәүдәгәр Рамазановларныкы булып, ул яман аты чыккан «Көфер почмагы», яки, икенче төрле итеп әйтсәк, «Печән базары» дип аталган урында иде. Монда таңнан төнгәчә сәүдәгәрләрнең кычкырулары, ямщикларның акыру-бакырулары, халык шау-шуы яңгырап тора. Рәттән тезелгән кибетләр, лавкалар, йөкләр, үз товарларын мактап кычкырып йөрүче «кырык тартмачы»лар, хәрчәүнәләр, чәйханәләр, трактирлар, куныл чыгу урыннары, кунакханәләр, шунда ук мәчет.

«Көфер почмагы»ннан ерак түгел — Кабан күле. Анда аерым хуҗалар кулында булган кечкенә пароходлар йөри. Алар күлнең бу башыннан кузгалып китеп, Борисково авылы янына кадәр илтәләр. Төрле төстәге вак флаглар белән бизәлгән, гөрләтеп оркестр уйнап торган бу пароходларда шәһәр халкы күлнең аргы башындагы (хәзерге Борисковода) «Аркадия» бакчасына күңел ачарга, Сабан туйларына бара, Ботан бакчасына чыга. Күңел ачулар шунда җәй буе дәвам итә.

Кыш җитеп, күлдә боз каткач, боз өстендә Суконная бистәсе белән Болак артында яшәүчеләр арасында йодрык сугышлары башлана. Сәүдәгәрләр шунда дан алган сугыш чукмарларын котыртып, үгетләп,

сыйлап каннарын кыздыралар, кем җиңүче калыр дип, акчага шау-шулы бәхәсләр башлыйлар.

Казандагы Никитин циркына француз көрәше буенча профессиональ чемпионатта катнашкан көрәшче Карәхмәт килгәч, «Печән базары» әһелләренең милли ыгы-зыгысы иң югары ноктага җитә.

Шушы яман аты чыккан «Көфер почмагы» тирәсендә үк татарча китаплар сатучы вак кибетләр, татарча газета-журналларның редакцияләре, татарча китапларны бастырып чыгаручы матбагалар «Гасыр» («Век»), «Мәгариф» («Просвещение»), «Сабах» («Утро») һәм шунда ук Кәримовларның китап нәшриятлары урнашкан.

Шушында ук шау-шулы Җамали хәрчәүнәсенең нәкъ каршында «Болгар» номерлары. Ул чисталыгы белән дә, уңайлыклары белән дә әллә ни мактарлык түгел, ләкин Казанның таулы өлешенә урнашкан беренче разрядлы «Казанское подворье», «Пассаж», «Франция», «Грандотель»лар шикелле кыйммәтле дә түгел. Номерларының чагыштырмача арзанлыгы белән «Болгар» кунакханәсе кешеләрне үзенә тарта. Патша самодержавиесенең колонизаторлык политикасы нигезендә, Казанның саф һавалы югары ягында татарларга яшәргә рөхсәт ителмәгәнгә күрә, «Болгар» татар дөньясының үзәгенә әйләнә.

Шушы «Болгар» номерларының икенче катындагы 40 нчы бүлмәдә Габдулла Тукай яши.

## Әстерханда

*Рәсулева Зәкия Әхмәтовна язмасы.*

Тукай турында истәлекләр җыю дәверендә, шагыйрьне күреп белгән кешеләрне, һич булмаса аның турында берәр истәлеге сакланган кешеләрне табу максаты белән илебезнең төрле почмакларындагы Тукай булган урыннарга хатлар белән дә мөрәҗәгать итеп җаваплар алдым.

Әстерханга җибәрелгән хатымны шул шәһәрдә яшәүче олы яшьтәге Гатаулла ага Әхтәмовка биргәннәр. Гатаулла ага җавап хатында үзе турында 1925—1931 елларда Әстерхан шәһәре радиостанциясендә татарча радио тапшырулар оештырып һәм татарча тапшыруларда диктор булып эшләвен, Әстерхан шәһәр музеенда крайны өйрәнү буенча кайбер ярдәмнәр күрсәтергә йөрүен яза. Хат белән ике фоторәсем дә җибәрде.

Гатаулла ага хатында яза: «Сезгә Габдулла Тукай Әстерханга килгән вакытта йөргән район урамнарының берсенең фоторәсемен җибәрәм. Күренеп торган мәчет Әстерханда «Идел» газетасының мөхәррире һәм нәшире Габдрахман Гомәри мәчете. Шул мәчет янынннан сул як тыкрыкка борылгач, Гомәринең ике катлы йорты тора. Аның түбән катында «Идел» газетасының матбагасы, югары катында редакциясе урнашкан иде.

Габдулла Тукайның бу җирләрдә һәм «Идел» редакциясендә булуы мәгълүм. Бу урамнарга ул вакытта Бельгия трамвае юлы сузылган иде. Шушы трамвайда Габдулла да редакциягә килеп-китеп йөргән.

Әстерханда безнең күршедә генә Гыйльми Батыршин дигән бер татарның хәрчәүнәсе бар иде. Ул йорт урамга бер ишеге һәм җиде тәрәзәсе белән карап тора, заманында бу хәрчәүнәгә халык бик күп йөри иде. Хәрчәүнәгә килгән юлчылар кунып та чыгу өчен шунда ук мөсафирханәсе дә бар иде. Анда шул дәвер өчен бик модный булган, татар тимерчеләре тарафыннан челтәрләп ясалган тимер караватлар, аңа урын-җир куелган, уртада өстәл тора. Гыйльми абзыйның миңа яшьтәш баласы белән уйнарга мин бу йортка гел керә идем.

Беркөнне кич белән Гыйльми абзый безгә керә дә этигә карап: «Без-

нең мосафирханәгә бер бик үткен телле егет килде. Кунып чыкмакчы. Янына сөйләшеп утырырга бераәр күзе ачык кеше табарга кушты. Безнең йортта аның белән сөйләшерлек синнән башка кеше юк»,— дип этине алып китте.

Әстерханда трамвай йөри башлау хөрмәтенә пәрәмәчне озынча итеп ясап, шундый пәрәмәчне «трамвай» дип йөриләр иде. Габдулла Тукай белән эти дә хәрчәүнәдә үзләренә кайнар шулпа белән шул «трамвай» пәрәмәчен китертеп, озаклап сөйләшеп төн куналар.

Икенче көнне эти безгә: «Кичен сөйләшеп утырганда ул чибәр егеттән кем икәнен сорамаган идем. Икенче көнне иртән киткәндә, атының кем икәнен белү өчен исемен сорадым. Ул миңа: «Синең ишеткәнең бармы Габдулла Тукаев дигән кешене? Мин шул булам инде»,— диде. Мин бу сүзләрне ишетүгә, аяк бөкләп утырган караватымнан егылып төшә яздым»,— диде.

Гатаулла аганың язуына караганда һәм матбугатта басылган истәлекләр белән чагыштырганда, Габдулла Тукайның Әстерханга килүенең бу беренче көне булып, Гыйлмүш хәрчәүнәсе шулай ук Әстерханда шагыйрьнең эзе калган беренче йорт булса кирәк.

## «Ир-ат эше»

*Ләлә Дулат-Алиева истәлеге, 1911 елда туган.*

Яңа бистәдәге хәзерге Мехчылар урамы элек Большая Симбирская дип аталган. Шундагы 37 нче номерлы йорт минем бабам Вахит мәэзин йорты.

Бу йорт эчтән өч өлешкә бүленгән. Йортның аргы бүлемендә Зөһрә әби белән Вахит бабай, урта бүлемдә әтиемнең энеләре, ә капка як өлешендә әнием Нәгыймә белән әтием Мәхмүт Алиевлар яшәгән.

Әтием башта Алиев булып, соңыннан үзенә Дулат-Алиев дигән фамилия ала (әтисе ягыннан нәсел фамилиясе).

Әтием Мәхмүт Дулат-Алиев башта Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Бохарадан мәэзинлеккә имтихан биреп кайта. Ул шәкертләр хәрәкәтенә катнаша. Үзенең Зөһрә әбисе ягыннан туганы, беренче татар революционеры, марксист, 1903 елдан РСДРП члены булган абыйсы Хөсәен Ямашев белән революцион эшкә катнаша. 1907 елда үзе дә большевиклар партиясе сафына керә. Әниемнең сөйләвенә караганда, беркөн безгә Галиәсгар Камал абый килеп керә дә: «Мәхмүт, мин бер җыр чыгардым әле»,— ди. Аннары:

> Яңа бистә урамына
> Кызыл байрак тагылган.
> Дулат-Али маңгаена
> «Большевик» дип язылган.

— дип, җырлап та күрсәтә. Әтиемнәр Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирханнар белән бергә эш алып баралар. 1907 елның көзендә шушы өйдә Габдулла Тукай белән әтием Мәхмүт Дулат-Алиевларның беренче очрашулары була. Әтием Габдулла Тукай катнашында чыга торган «Әльислах» исемле демократик яшьләр газетасын оештыручылардан була.

Әниемнең туганы «Әльислах» газетасының мөхәррире булган Вафа Бәхтияров истәлегенә караганда, безнең өйнең базында, яшерен гектографта РСДРПның Казан Комитеты листовкалары татар телендә басыла.

Шул ук 1907 елның көзендә безнең өйдә Хөсәен Ямашев белән Габдулла Тукай беренче мәртәбә очрашалар.

1910 елда Габдулла Тукай берничә ай безнең чарлакта яши. (Чарлак дигәне ишегалды түрендә өстен чарлак, астын ат абзары итеп тактадан эшләнгән амбар.).

Әнием Тукайны искә алганда: «Габдулла Тукай бик гади киенә торган, йомшак күңелле, йомшак кына сөйләшүче кеше иде. Ул берничә ай безнең әлеге «чарлак» дип йөртелгән җирдә торды. Кич килә, иртән иртүк торып китә. Киткәндә безнең йокы бүлмәсенең тәрәзәсе яныннан үтә, ян тәрәзәгә сак кына чиертә. Аннан әкрен генә тавыш белән: «Мәхмүт, мин үзең белә торган җиргә куйдым»,— дип ишегалдыннан чыгып китә иде. Ул киткәч, мин әтиемнән: «Ул нәрсә эшләп йөри соң, нәрсәне әйтә ул?» — дип сорагач, әтиең: «И, хатын, ир-ат эшен белеп бетермәссең инде аны!»— дип кырт кисә иде»,— дип сөйли иде әни.

Безнең әлеге чарлакта Габдулла Тукайның өч зур кер кәрзиннәренә тутырылган кулъязмалары озак еллар сакланган. Тик әтигә реакция эзәрлекләвеннән кинәт кенә качып китәргә туры килгәч, без Казаннан тизлек белән китеп барганбыз. Шулай итеп әлеге кулъязмаларның язмышы билгесез кала.

## Кинематограф «Буфф»

*Фуат Тимерович Саллави-Соловьевның өченче истәлеге.*

Әтием инициативалы һәм энергияле кеше буларак, Казанның татарлар яши торган өлешендә кинотеатр ачарга дәртләнә. Ләкин байлык булмау сәбәпле, ул зур предприятие ача алмый, дуслардан көтәргә алган акчага хәзерге Татарстан — Каюм Насыйри урамнары чатындагы бер катлы ике склад йортын арендага алып, шуларны кинотеатр итеп җайлаштыра (хәзер ул урында 9 катлы йорт). Тиздән керү ишегенә «Кинематограф «БУФФ» дигән язу да куела. Белдерү язылa: «Сезон яңалыгы. Бүген һәм һәркөн яңа фильмнар (производство студий братьев Пате, Люмьф и студии Ханжонкова). Күренекле артистлар: Макс Линдер, Глупышкин һ. б. катнашында күренекле картиналар. Барлык сеансларда кинохроника. Көн яңалыклары». (Ул чакларда күп татарлар русча укый-яза белмиләр. Аларга аңлаешлы булсын өчен фильм ленталарындагы русча текстлар әниемнен шул эш өчен янып йөрүче энеләре — студент егетләр тарафыннан татарчага тәрҗемә ителә иде. Фойеда, эстрада-экран алдында күренекле татар музыкантлары, җырчылары, артистлары чыгыш ясый. Шушыларны хәбәр иткән белдерүләр урамнарга ябыштырыла.

Казанда чыга торган «Йолдыз» газетасы да 1911 ел 20 февраль санында:

«Печән базарында 17 февральдә Тимерша Соловьев «БУФФ» исемле кинематограф ачты... Ирләр һәммәсе дә уң якка, хатыннар сул якка утырачак»— дип игълан итә.

Башта халык шикләнеп кенә карый бу яңалыкка. Соңыннан яратып йөри башлыйлар. Концертларда шул чактагы күренекле профессиональ музыкантлар Мөхәммәт Яушев, Гали Зайнин, Заһидулла Яруллин (композиторлар Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның әтисе), Хәбибулла Әхмәдуллин катнашалар. Җырчылардан Камил Мотыйгый, хатынкыз тавышыдай бик нечкә тавыш белән җырлаучы Мирфәйзә Бабаҗанов, «Сәйяр» труппасы артистлары, шулардан сәхнә әсәрләрен гаҗәеп матур укучы Габдулла Кариев һ. б. катнашалар.

«Болгар»дан ерак булмаган бу кинематографка Габдулла Тукай да бик яратып йөри. Якыннарымның сөйләве буенча, Тукай кинематограф белән бик кызыксынган һәм берничә мәртәбә үзенең шигырьләрен укып монда чыгыш ясаган.

Кинематограф «БУФФ» халык арасында дан казанган. Русча аңламаган кешеләр өчен экран артыннан фильмның эчтәлеген татарча сөйләп тору да оештырылган. Ләкин бу эшне цензура тиз туктата һәм шулай ук «БУФФ» кинематографы да ябыла.



## «Болгар»да

*Рокыя Мөштәриева. Аитова мәктәбе укытучысы. Ленин ордены кавалеры.*

«Туганнан-туган абыем Габбас Сәйфуллин үзенең мәэзин әтисе белән килешми, өйдән китә. Казанга килеп, «Болгар» номерларында тора башлый. Шунда Габдулла Тукай да яши. Алар икесе бик дуслашалар. Мин Габбас абый янына еш барам. Юарга дип аның керләрен алам. Үзе күрмәгәндә Тукайның да керләрен алам. Ул миңа бик авыр тормышта яши кебек тоела иде. Үзе бик аз сөйләшә иде. Мин Тукай турында Габбас абыйдан: «Нигә ул бик аз сөйләшә?»— дип сорагач, Тукай: «Минем бит эчем тулы илһам, шуңа аз сөйләшәм»,— дия торган иде. Әни таба ашы пешергән көнне аларның икесенә дә өлеш куя. Мин ул ашларны, юылган керләре белән бергә, аларның номерына китерәм. Кайнатып, юып киптерелгән, бәләкләнгән керләрне аларның мендәр асларына кыстырып чыгам, таба ашларын өстәлләренә куеп, тастымал белән каплап чыга идем».

## Тукай янында

*Фуат Тимерович Саллави-Соловьевның дүртенче истәлеге.*

«Болгар»да без Тукай абый яшәгән бүлмәнең каршысындагы номерда торабыз. Габдулла абый инде ул вакытта бик авыру иде.

Татар халкының алдынгы демократик интеллигенциясе һәм укучы яшьләр Тукайны бик яраталар, аңа зур хөрмәт белән карыйлар. Авыру Тукайның хәлен белергә күп кеше килә: аның дуслары һәм талантын хөрмәт итүчеләр килә. Бу кешеләр шулай ук минем әти-әниемнәрнең танышлары булганга, алар хәл белешергә безгә дә керәләр. Шуңа күрә мин аларның күбесен танып та белә идем.

Әнием күренекле татар язучысы, мәгърифәтчесе Фатих Кәриминең туган сеңелесе, тарихчы, галим, язучы Ризаэтдин Фәхретдиневнең оныгы булып, заманына күрә укымышлы һәм татар әдәбияты белән танышып баручы, Тукай поэзиясен хөрмәт итүче кеше иде. Ул һәрвакыт Тукайның хәлен белеп тора иде. Күп вакыт Тукай янына олы гәүдәле, гөрләп торган көчле тавышлы Габдулла абый Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская килә иде. Хөсәен Ямашев һәм Хәдичә апа, китап нашире Шиһап Әхмеров, хатыны Әминә Әхмәрова белән киләләр. (Әминә апа — ул вакытта ук музыкага зур сәләтле икәнен күрсәткән яшь егет Салих Сәйдәшевның апасы.) Әниемнең кече сеңелесе Закирә апа белән ире журналист Борһан Шәрәф, нашир Гыйльметдин Шәрәф, хатыны Рәхимә апа белән Тукай янында булалар. Тукайның хәлен белешергә татар кызларыннан беренче булып женская гимназия тәмамлаучы бертуган Әминә һәм Мәдинә Терегуловалар, шулай ук бертуган Габитова апалар килә. Алар татарча әдәби кичәләр оештыруда катнашучылар, Тукайны хөрмәт итүчеләрдән. Шулай ук «Шәрык клубында», «Яңа клубта», «Эрмитаж»ның җәйге театрында, Панаев бакчасында әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда җиң сызганып йөрүче Гөлсем Камалова, Гайшә Богданова, Зәйнәп Хәсәновалар, Әминә Мө-

хетдинова, Заһирә Әхмәрова, татар кызларыннан беренчеләрдән булып югары белем алган Мәрьям Акимбетова һәм соңыннан гражданнар сугышында беренче татар бригадасы составында Урта Азия басмачыларына каршы сугышта катнашкан икесе дә хәрби Кызыл байрак ордены белән бүләкләнгән бертуган Рабига һәм Зәйнәп Саиновалар (Мулланур Вахитовның туганнан туган сеңелләре) — болар барысы да Тукайны олылаучылар, килеп Тукайның хәлен белешеп торучылар.

Беркөнне әни абыем белән миңа: «Мин сезне үзегез яратып ятлап йөри торган шигырьләрне язган шагыйрь Габдулла Тукай белән күрешергә алып керәм. Ләкин Габдулла абыегыз бик авыру. Шауламассыз, шаярмассыз,— диде. Без кучтәнәчләр алып бүлмәгә кердек, әкрен генә исәнләштек. Бик гади генә озынчарак бүлмә. Габдулла абый караватта ята иде. Без абыем белән парлап исәнләшкәч, көлемсерәп безгә карады, үзе бик ябык, яңаклары сулган, ара-тирә йөткергәли, үзе шуңа оялган шикелле әз генә көлемсерәп куйгандай була. Без аны борчудан куркып, әни Габдулла абыйның хәлен сорашканда тын гына тордык. Әнием зур мәхәббәт белән безгә өйрәткән:

> И туган тел, и матур тел,
> Әткәм-әнкәмнең теле,

— диган шигырьне язган, туган телебезгә, халкыбызга дан җырлаган бөек шагыйребез Габдулла Тукайны күрә алуым белән мин бик бәхетлемен һәм йөрәгемә уелып калган «Туган тел» бөтен гомерем буе күңелемдә яши, Тукайның якты истәлеге булып саклана.

## Далада

*Мәскәүдә яшәүче 80 яшьлек пенсионер Рәүф ага Рәсулев истәлеге.*

Мин 1902 елның январенда Оренбург губернасы Троицк шәһәрендә тудым. 1912 елның язында минем дәүәни белән Фатиха Аитова апаның әнисен дачага кунакка чакырдылар. Дәүәни мине дә үзләре белән алды.

Тарантаслы атка утырып юлга чыктык. Шәһәрдә Габдрахман Рахманкулов йорты яныннан үттек. Байларның дачалары шәһәрнең шаушуыннан читтә салынган. Шәһәрдән чыккач, уңда «Золотая сопка» дип аталган агачлы таулык калды. Кырдан барабыз. Бераздан яшеллеккә күмелгән калкулык күренде. Шунда дачалар урнашкан.

Менә безнең алда бакча белән әйләндереп алынган бер катлы матур йорт. Бу Троицкидагы Габдрахман Рахманкулов дигән мулланың дачасы. Габдрахман мулла үзе зур гәүдәсе, кара чәчле, кара мыеклы, җырлаганда гөрләп торган көр тавышлы, уен-көлке, дан яратучы, һәрчак шат күңелле кеше иде.

Ул күп мәчетле Троицк шәһәренең күп муллалары арасында абруен күтәрергә уйлап, инде татар халкы арасында шөһрәте таралган, үткен телле шагыйрь Габдулла Тукайны үзенә чакыра. Аларның беренче очрашуы Казанда була.

Соңрак Тукай Троицкига килеп төшә. Габдрахман мулла дачасына киләләр. Анда шау-гөр, «көн дә бәйрәм, көн дә туй» дигәндәй, көн дә кунак яки мәҗлес. Билгеле, Тукай бу мөхиттә яшәргә теләми. Дачадан ерактa, яшел чирәмле далада аңа аерым чатыр корыла.

Без ат юырттырып даладан барабыз. Шул чак минем дәүәни: «Габдрахман мулла шагыйрь Габдулла Тукаевны Казаннан хас үзенә чакыртып алдырган. Аның хас үзенә дип чатыр кордырткан. Әнә — карагыз!» — дип бер якка төртеп күрсәтте. Яшел чирәмле далада зур, биек күгелҗем төстәге чатыр күренә иде. Чатырның ишек чабулары күтәрелеп бәйләнгән. Аның янында бер артсыз урындык. Шунда зуррак

малай сыман ябык кына бер кеше утырып тора. Дәүәни: «Әнә, кара, улым, Габдулла Тукаев дигән кеше шул була инде»,— диде. Без юыртып үтеп киттек. Ара алай ерак булмаса да, Тукай безгә әз генә дә игътибар итмичә, уйланып утырып калды.

Габдулла Тукайны мин әнә шулай беренче һәм соңгы кат күрдем.



## Салкын су

*86 яшьлек Миңгалим Миңсафин истәлеге.*

Авылда авыр тормышта яшәгәндә бер абзый мине Казанга алып килде. Үзеңә тамаклык эшләп алырсың, дип «Болгар» номерларында эшләүче Зариф поварга малайлыкка бирде. Мин шунда малайлыкта йөреп, соңыннан үзем повар булып эшли башладым.

Мин шул «Болгар» номерларында булганда бер номерда Габдулла Тукаев та тора иде. Ул урта гына буйлы, гади киенә торган матур гына кеше иде. Күп вакыт яланбаш була, сирәк кенә кара кәләпүш тә кия иде. Сөйләшергә бик ярата, әкрен генә иплəп кенә сөйләшә, һич тавышын күтәрми: сүзгә бик тапкыр кеше иде. Ул үзенә кеше килгәнне бик ярата иде, ахрысы, чөнки бүлмәсенә кеше күп килә иде. Аның өстәле бер дә буш булмый иде. Ул кайчан бүлмәсендә, ә кайчан безнең ашау залына чыгып ашый иде. Бүлмәсендә күп вакыт язып утыра. Язып утыра-утыра да салкын су сорый иде. Кухняны аерып торган стенада ачык тәрәзә бар иде. Ул шул тәрәзәдән башын тыга да, салкын су бир әле, энекәш, җылы су түгел, салкын су бир. Йөрәгем яна, дияр иде.

Тукайның танышы Хөсәен Ямашевны да күреп белә идем. Ләкин танышлыгым юк иде, бик матур, бик кибар кеше иде.

Мине Тимерша Соловьев дигән хуҗа Мәкәрҗә ярминкәсенә повар итеп алып китте. Мәкәрҗәдә озак тордык. Кайтсам, Тукаев Габдулла абый «Болгар»дан «Амур» номерларына киткән иде инде. Күп тә үтмәде «Тукай үлгән» дигән хәбәр таралды, барыбыз да аптырап калдык, бик кызгандык.

## «Бурычым кала бит...»

*Галия Халитованың икенче истәлеге.*

Әтием тормыш алып бару өчен төрле эшләргә ябышып карый. Ахырда, зур мәшәкатьләрдән соң, бер кечкенә генә кибет ачуга ирешә. Сәүдә итә башлый.

Безнең гаилә шактый зур: әти, әни һәм өч бала. Аннан әтинең өч сеңелесе бездә торып укыйлар. Әтинең туган энеләре Әхмәт, Хөсәен, Хуҗа Бәдигыйлар Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып, ял, бәйрәм көннәрендә алар да бездә яшиләр. Бу яшьләр шул вакыттагы шәкертләр хәрәкәтенә катнашалар, халкыбызның культура тормышындагы яңалыклар белән дәртләнеп яшиләр.

Шагыйрь Габдулла Тукаев белән дә әтием шул энеләре аша таныш була һәм аны бик хөрмәт итә.

Тукай кирәк-яракларны гел әтием кибетеннән ала. Ләкин аның акчалы чагы бик сирәк була. Шуңа күрә Тукайның тәкъдиме белән кибеттә аның исеменә бер дәфтәр булдырыла. Тукай алган нәрсәләрен үзе шунда язып китә, акчасы булу белән бурычын китереп түли. Аннан дәфтәргә язу тагын башлана.

Соңрак Тукай авырып больницага керә. Бу хәбәрне ишетү белән әти, күчтәнәчләр алып, аның янына бара, гел шулай хәлен белешеп тора. Тукай янынннан кайткач: «Аның хәле көннән көн начарлана,—

дип борчылып сөйли,— шулай булуга да карамастан үзе мине һәрвакыт шатланып каршы ала»,— ди торган иде эти.

Берсендә эти Тукайга бик матур әфлисуннар табып алып бара. Аларны күргәч Тукай этигә:

— И, Хәсән абый, син миңа бик күп күчтәнәчләр китерәсең. Сиңа бурычым күп. Болай да минем бурычым кала бит!— ди.

— Юкны сөйләмә, Габдулла, син терел генә. Синең бернинди бурычың юк. Ишетәсеңме, бер бурычың да юк. Тизрәк сәламәтләнә генә күр,— ди эти Тукайга. Тукай аны күңеле булып озатып кала.

Бу инде соңгы күрешү була.

## «Исәнлектә күрешик»

*Мәҗитова Разия Зиннәтовнаның өченче истәлеге.*

Көннәрдән бер көнне Габдулла абыйның бик каты авырып киткәнен, Клячкин больницасында ятканын безгә Бишбалтага килеп әйттеләр. Шунда ук әни мине алып, бергәләп больницага киттек.

Безне аның янына кертteләр, ләкин озак сөйләшмәскә куштылар. Габдулла абый аерым бер бүлмәдә ята. Бик ябыккан. Өстендә киң җиңле күлмәк.

Без кергәч ул караватына торып утырды. Мин тизрәк аның янына елыштым. Әни аңа алып килгән күчтәнәчләрне бирде, хәл-әхвәлен сорашты. Габдулла абый: «Хәлем мактанырлык түгел, апай, бик тирлим, хәлем юк»,— диде.

Миңа аның якасы бик сәер тоелды, мин аны тотып та карадым. Габдулла абый көлемсерәп минем чәчемне сыйпады. Аннан ул миңа: «Ятимем, әнә тегене укып кара әле»,— диде. Ул һәр кешегә йомшак итеп «кардәшем», «туганым» дип, читтән килгәннәргә «мосафир» дип дәшә иде. Мин ул күрсәткән караватбашына карадым. Анда журнал бите хәтле кәгазь эленеп тора. Габдулла абый кабатлап: «Әнә шуны алып укы әле»,— диде.

Мин кәгазьне алып укый башладым:

> И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
> Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз ахрысы.

«Аерылабыз» дигәч күңелем тулды, укый алмыйча тукталып калдым. Хәзер елап җибәрәм дигәндә, әнинең миңа йодрык күрсәткәнен күреп алдым. Ул миңа еламаска ишарә ясый иде. Габдулла абый минем хәлне аңлады булса кирәк, «Тукта әле мин сиңа күчтәнәч бирим»,— дип, өстәл торган якка борылды. Ул борылган арада, әни миңа: «Кешегә килгән күчтәнәчне алырга ярамый!»— диде.

Габдулла абыйга бик күп кеше килә икән. Барысы да күчтәнәч китерәләр. Габдулла абыйның тумбочкасы шулар белән тулы иде. Тиздән сестра кереп, безгә китәргә вакыт икәнне әйтте. Габдулла абый белән ике куллап күрештек. Мин аның яңагыннан сөйдем, ул минем аркамнан сөйде: «Хушыгыз, исәнлектә күрешик»,— диде. Мин елый-елый чыктым. Әни: «Җыларга ярамый, күрмисеңмени, Габдулла абыеңның хәле болай да бик авыр бит»,— диде.

Беркөнне безгә мәэзин абзый килеп, Габдулла абыйның үлгәнлеген әйтте. Бу хәбәрне ишетү бик авыр булды.

Дүртенче апрельдә Клячкин больницасы янына килдек. Габдулла абый белән саубуллашырга килгән халыкның иге-чиге юк. Бераздан Габдулла абыйның җеназасын күтәреп Печән базарына алып килделәр, яшел мәчет каршында туктадылар. Ләкин анда җеназа укымадылар. Аннан Мәйдан бакчасы янына килделәр. Монда халык тагы да күп. Хатын-кызлар да шактый. Чәчәкләр бик күп. Абзыйлар җыйнаулашып

җеназа укыдылар. Бик күп кеше күз яшьләре белән елый иде. Бертөркем абзыйлар Габдулла абый җеназасын сак кына иңнәренә күтәрделәр. Шунда мәәзин абзый да бар иде. Мин елап аңа барып сыендым. Ул: «Бала, син кит моннан, ярамый, бар, анаң янына бар!» — диде. Әни елый иде, мине үзенә тартып алды.

Кинәт бөтен халык кузгалды. Габдулла абыйны әкрен генә алып киттеләр. Безгә: «Мөселман хатын-кызларына зиратка керергә ярамый, сез бармагыз»,— диделәр. Без бер төркем апалар белән Мәйдан бакчасы янында елашып, Габдулла Тукай абыйдан аерылып калдык.

## «Олы абыйлар елады»...

*Мәхмүдова Хәдичә Нурмөхәммәтовна истәлеге, артистка.*

Минем кечкенә кызчык чагым иде. Без Казанда «Госмания» мәдрәсәсе ишегалдында торабыз, әти дворник булып эшли, әни байларга кәләпүш чигә иде.

Бертуган Хәтимә апамның ире Габдулла җизни Казандагы Кәримовлар типографиясендә эшли. Алар Габдулла Тукай абый белән танышлар иде, бездә очрашып сөйләшәләр иде.

Мин үземне белә-белгәннән бирле такмаклап биергә, җырларга, шигырьләр сөйләргә бик ярата идем. Тирә-юньдәгеләргә, чәчләремне туздырып, су анасы булып та уйнап күрсәтә идем.

Хәтимә апага, Габдулла Тукай балаларны бик ярата дип әйткәннәр дә, бер көнне мине бик матур итеп киендереп: «Әйдә мин сине Тукай абый янына «Амур»га алып барам»,— дип җитәкләп шунда алып китте.

Без бүлмәгә кергәндә, Габдулла абый караватта ята иде. Без кергәч торып утырды. Апа аның белән исәнләште дә: «Менә бу нәни кыз сезнең шигырьләрне сөйләргә, җырларга бик оста. Шуны сезнең янга алып килдем әле»,— диде. Габдулла абый миңа: «Нәрсә сөйли беләсең соң?»— диде. Бер малай су анасының алтын тарагын урлап киткән бит, шуны беләм, дидем.

«Туган тел»не дә сөйләп күрсәттем. Габдулла абый минем сөйләгәннәремне бик яратты. «Тагын шигырьләр өйрәнергә телисеңме соң?»— диде. Аннан: «Мә, тагын өйрән алайса»,— дип апага бер китабын язып бирде. Без рәхмәт әйтеп, чыгып киттек.

## 4 апрель — саубуллашу көне

*Разия Шакировна Бәхтиярова истәлеге «Әльислах» газетасы мөхәррире Вафа Бәхтияровның хатыны, укытучы. Фатиха Аитова мәктәбен тәмамлаган. Хезмәт ветераны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгән.*

Фатиха апа Аитова мәктәбендә укыганда, 1913 ел, икенче апрель көнне дәрес башларга гына тора идек, класска укытучыбыз Галия апа Һадиева бик күңелсезләнеп килеп керде дә: «Шагыйребез Габдулла Тукаев үлгән!»— диде. Без тып-тын калдык. Ул көн бик күңелсез үтте.

4 апрель көнне укытучыбыз «Бүген Габдулла Тукаевны күмү көне. Хәзер аны «Мәйдан» бакчасына[1] алып киләләр. Без һәммәбез дә аны озата чыгабыз»,— диде. Мәйдан бакчасы, тирә-як урамнар һичкайчан булмаганча халык белән шыгрым тулган иде. Габдулла Тукайның чәчәкләргә күмелгән табутын иң якын кешеләре күтәргән. Җеназа әкрен генә үтә. Без һәммәбез дә елашып, Габдулла Тукайны озатып калдык.

[1] Хәзерге Тукай урамы. «Тукай» кинотеатры каршындагы мәйдан.

**Ринат Мөхәммәдиев**

# БЕРЕНЧЕ УМЫРЗАЯ

ПОВЕСТЬ

## I



Юл түбәнгә таба борылгач, атлар юырта ук башлады. Әкиятнең үзеннән дә серлерәк тоелган бу кич тагы да ямьлерәк, дәртләндергечрәк булып китте. Алдагы ат шактый ук аерылырга да өлгергән икән инде. Калышырга ярамый, малкай, дигәнне аңлатып, Рәхимҗан дилбегәне ипле генә кагып алды. Юртак шактый ук шәп җилдерә башлады. Яңа яуган кар өстеннән чана җиңел уйнаклап китте. Юл буе уен-көлкедән арынмаган, юк кына нәрсәдән дә дәррәү көлешерлек кызык табып кайткан яшьләр тагы да җанланды. Моңарчы җай гына барган чананың әледән-әле чалулый башлавы яңа бер уен, яңа кызыкка сәбәпче булды. Чана бер якка янтая башлау белән, хәзер нидер була дигәнне аңлатып, төрле авазлар чыгарып шаулаша башлыйлар да, юл читенә кинәт китереп бәргәч, дәррәү кычкырышып алалар. Үрәчәдән ак канат булып күтәрелгән кар өермәсен сөзеп бер-икесе көрткә үк очып төшә. Чанада калганнарга — кызык...

— Куала, Рәхимҗан, әйдә, на-а...

Төшеп калганнар уфылдашып, тәмам хәлдән таеп, чана артыннан чаба. Юырткан атны куып җитеп, чана читенә тотыну, йомшак итеп түшәлгән саламга сикерү бердәнбер максатка әверелә. Ә атлар һаман юыртуын белә... Чана табаннары, нидер көйләгәндәй, җырлагандай, яңа яуган кар белән серләшә.

Ул арада чана яңадан чалулап китә, моны абайламый калган кемдер юл читендә тәгәрәп кала.

— Куала, Рәхимҗан, куала...

Башкалар аны-моны уйларга өлгердеме-юкмы, моңарчы сабыр гына чана башында тезәнлекләп кайткан Рәхимҗан, кулындагы дилбегәсен кемгәдер төртеп, түшәк сыман ак карга үзе сикерде, үзе очып төште.

— Рәхимҗанның җылынасы килгән, әйдә, юртак, на-а...— дип болгадылар дилбегә очын.

Көрткә шактый тирән чумган иде егет. Торып кагынган арада, аның яныннан бая чанадан төшеп калган җыйнак гәүдәле кыз җитез җил сыман йөгереп узды. Ул Рәхимҗанны, әйтерсең, бөтенләй күрмәде дә.

— Зәйнәп...— дип, сәер бер тавыш белән эндәшкәнен үзе дә абайлап өлгермәде Рәхимҗан.

— Абау, кем ул,— юл читендә кеше барлыкны әле генә сизенгәндәй итте кыз.— Әллә синме, Рәхимҗан?

Ничек җавап кайтарырга белми бер тын торгач, ул: «Әйе, мин, Зәйнәп»,— дип әйтүдән башканы булдыра алмады.

— Нәрсә булды, кем тия, Рәхимҗан? — дип, чаяланды, үртәгәндәй итте кыз, тавышын суза төшеп.

Кызны бүлдерергә ашыгып, ул янә күңелендә булып та теленда әле оешып ук җитмәгән сүзләр белән дәште:

— Авылга бергә кайтыйк, Зәйнәп...

— Бергә кайтабыз ич, атларны куып җитик, Рәхимҗан,— дип, кыз үзе артыннан әйдәп йөгерә үк башлады.

Дәртсенеп бер-ике талпынуда Рәхимҗан аны куып ук җитә язган иде. Әмма, тагы берәр мәгънәсез сүз әйтмәгәем, дип, тыела төште. Авылга ерак калмаган иде инде, җәяү генә кайтырмын, дип уйлады ул. Ләкин, ап-ак томан эчендәге серле шәүләне хәтерләтеп, инде күздән югала барган Зәйнәп кинәт туктап калды. Шунда егетнең иңнәренә канат чыкты — ул томырылып кыз артыннан йөгерде.

Зәйнәп белән Рәхимҗан. Алар икәүдән икәү генә иде... Чана юлының ике читеннән янәшә атлап авылгача бергә кайтты алар. Берөзлексез кар яуды. Күбәләктәй ап-ак, эре-эре кар бөртекләре бөтерелеп-бөтерелеп аларның иңнәренә, керфек очларына кунды. Кар бөртекләре алар барган юлга ап-ак келәм булып ятты. Болытлар артыннан, якты шәүлә булып, яңа туган ай сирпелеп торды. Сүрән нурларда якты кар бөртекләре йолдыз булып, җемелдәшеп уйнады.

Кар түгел, йолдыз яуды ул кичтә! Ай булып баш очында бәхет балкыды. Җил шатлык булып исте. Ай нурларында чагылып ап-ак бәхет иңә идеме әллә. Юл шундый кыска булды, авыз ачып бер-беренә сүз әйтергә өлгермәде алар. Зәйнәпләр капкасына килеп җитүләрен сизми дә калдылар. Кызга әйтәсе килгән, әмма әйтә алмый йөргән сүзләре күп иде егетнең. Өлгермәде — җай чыкмады, ара һәм вакыт җитмәде. Югыйсә, чанадан сикереп төшкәндә әллә ниләр әйтер кебек иде үзе. Капка төбенә килеп җиткәч тә: «Зәйнәп, бер генә минутка көт әле, ашыкма, сиңа бер сүзем бар»,— дип эндәшәсе килде аның. Әмма тынлыкка шул тикле күнегелгән, кышкы кичнең матурлыгы белән шул кадәр сихерләнелгән,— авыз ачарга кыймады ул. Зәйнәп тә сөйләшмәде, гел елмаеп торды. Шулай да көтмәгәндә бер сорау бирергә өлгерде кыз.

— Рәхимҗан,— диде ул.— Син нигә Рәхимҗан?

Егет аңышмады. Кыз соравын аңлата төште:

— Исемең заманча түгел. Хан заманыннан калган дим... Кем таптан аны?

— Исемне миңа бабай кушкан. Син дә Зәйнәп ич...— дип елмайды егет. Әмма күпкә түгел. Ул арада, болыт артына качкан таң йолдызы сыман, егет янында серле елмаюын калдырып, Зәйнәп капка артына кереп тә югалды. Тимер келә шалтырап төшкәч кенә һушына килгәндәй булды егет.

Тып-тын авыл урамын тутырып кар ява. Күзләрне камаштырып җемелдәшкән ап-ак бөртекләр күктән тоташ келәм булып агыла. Күрше авылда үткән чаңгы ярышыннан кайтып килгән чыгарылыш класс егете Рәхимҗан Айтугановка җемелдәшеп очкан кар бөртекләре, аклык һәм сафлыктан башка берни күренмәде бу кичтә. Дөнья, ул әйтергә теләп тә әйтергә өлгермәгән сүзләр, хисләр кебек, серле матурлыкка, аклыкка һәм сафлыкка төренгән. Бөтен әйләнә-тирә кар бөртекләредәй бии-бөтерелә, ак бишектә тибрәлә иде.

Шул көннән соң Зәйнәпнең, иң өсләрен килешле уйнатып, ак киез итекләре белән вак-вак атлап мәктәпкә килүен түземсезлек белән көтеп ала торган булды Рәхимҗан. Дәресләр тәмамлангач, түбән оч

малайлары-кызлары белән уйный-көлә кайтып китүләрен көнләшү катыш моңсулык белән озатып калды. Үзенең башка урамда яшәве — аларны аерып торган иң зур бәла сыман тоела иде аңар. Мәктәп коридоры янсә урамда кара-каршы очрашырга туры килгәндә кызның күзләренә карарга һәм аңлашырга кирәк дип, үз-үзенә ничә мәртәбәләр сүз куймасын, барып чыкмады. Зәйнәп якынлашып, кызның күзләренә тутырып карар чак җиткәч кенә, ул коелып төшә, каушап кала. Карашы ирексездән читкә юнәлә иде. Күпме генә тырышмасын, Рәхимҗан башкача булдыра алмады — оялды, югалып калды. Чаялыгы белән аерылып торган Зәйнәп аны күргәч җитдиләнеп китә иде шул. Кыз артык сер бирергә теләмәсә дә, Рәхимҗан моны һәрчак сизеп, бөтен күңеле белән тоеп торды. Әлеге сәер оялу, үзара аңлаша алмау мәңге шулай дәвам итәр төсле иде... Ай юлыннан икәүдән-икәү генә кайткан кич исә моңлы бер төш булып кына калды.

## 2

Бөтен гаилә белән өстәл әйләнә утырып иртәнге чәй эчәләр иде. Табадан яңа төшкән коймакны майга манчып алган Төхфәт карт үзалдына зарланып куйды:

— Бу колонка суының бер генә дә тәмнәре юк... Чәйгә дисәң, чәе чыкмый. Чишмә суына җитәме соң... Э-эх, Чегән чишмәсеннән эчкән чаклар...

Олыгаеп җиткән картның вакыт-вакыт сукрангалап алуына күнегеп килгән улы белән килене моны, әйтерсең лә, ишетмәделәр. Ә бу исә картның болай да төшенке күңелен тагы да сүрәнәйтеп җибәрде. Башка дәшмәде ул.

Авыл урамнарына суның әле яңарак кертелгән чагы иде. Бөтен авыл халкы, бигрәк тә хатын-кыз, су буеннан чиләк-көянтәләп су китерүдән арынуларына шатланып туймаган вакытта, бу сүзләр кәефе төшкән картның чираттагы бер зарлануы булып кына тоелды. Шулай да, әти-әнисе эшкә чыгып киткәчтен, бабасының зарын хәтерләп калган Рәхимҗан аның янына килде.

Авылда колхоз төзелгәннән бирле ат караучы булып эшләгән Төхфәт бабайга бер Рәхимҗан гына түгел, күп малайлар тартыла иде. Аларны беренче тапкыр атка атландыручы да, җәйге тымызык кичләрдә ат сугару кебек җаваплы эшне ышанып тапшыручы да ул — Төхфәт бабай...

Яшьтәшләреннән күп элек атка менде малай... Бөтен дус-ишләрен кызыктырып, ат өстендә авыл буйлап узганы да хәтерендә. Аның үзүзен хәтерләве дә ат өстенә менгән шул җәйге көннән башлана иде: аякларын як-якка җәеп ул биектә, югарыда очты шикелле. Чайкалачайкала барды. Иергә генә ышанмыйча, атның ялларына чәтердәтеп ябышып барды. Янәшәдән бәхетле елмаеп бабасы атлады. Бабасы елмайгач, ул да елмайды. Урамдагы малайлар гына түгел, бөтен авыл, өйләр, агачлар сокланып, кызыгып карыйдыр төсле тоелды аңар. Бабасы гына түгел, һәр очраган кеше сокланды, елмаеп карады ул көнне. Аның шулай дәү үсүенә бөтен дөнья хәйран калган сыман иде.

— Бабай,— диде Рәхимҗан,— колонка суын мин үзем алып кердем. Чишмә суы күк чиста, салкын иде...

Бабасы дәшмәде. Оныгының ни әйтергә теләвен аңламадымы ул, әллә көтелмәгән бу сүзләргә сәерсенеп калган идеме — елмаерга да, көләргә дә белми, тик карап торды.

— Чәйне ошатмагач әйтәм...— дип өстәде Рәхимҗан.

Ә карт, гамьсезлек күрсәткәндәй, һаман да дәшмәде. Ашыкмый гына киенеп, ат абзарына барырга җыенды. Бүген ял көне булып, Рәхимҗанның да үзе артыннан иярәчәген белгәнгә шулай иттеме ул...

Ат абзарына барган да, барып житкәч тә алар берни сөйләшмәделәр. Бабасы авызыннан бүген сүз ишетүдән Рәхимжанның тәмам өмете өзелгән иде инде. Төхфәт карт иртән өзелеп калган сүзне ялгап китте:

— Салкын булгач, чиста булгач, суның барысы да бер иш дип уйлыйсыз шул,— диде ул, үзалдына сөйләнгәндәй.— Иллегә житеп киләләр, ә чәй тәмен, су тәмен аера белмиләр... Менәтерәк, житте заманалар,— һәм шунда гына, янында оныгы булуны абайлагандай, Рәхимжанга мөрәжәгать итте.— Әтиең белән әниеңне әйтәм.

— Бөтен авыл эчә бит шул колонка суын, нәрсәсе начар ди аның, бабай?

Җиңелчә генә оныгының җилкәсенә кагылып куйды карт һәм үзе артыннан абзар түренә өелгән печәнлеккә әйдәде.

Абзардагы атлар керт-керт башак ашый. Алар ягыннан берөзлексез җылы пар бөркелеп тора. Тәрәзәләргә кышкы салкын кардан чигү чиккән. Ат абзарының әйтеп-аңлатып бирү җиңел булмаган бер яме була һәрчак. Рәхимжан бабасының нәкъ менә ат караучы булып эшләвенә тагы бер тапкыр шатланып куйды.

— Син дәү кеше инде, Рәхимжан улым,— дип башлады Төхфәт карт. Алар, әйтерсең лә, ат абзарында түгел, эңгер-меңгер чак житеп килгән җәйге болында утыралар кебек иде.— Тиздән ун классны бетерәсең, бәлки тагы укырсың... Бабаң сүзләренә дә колак салсаң икән, улым. Кем булсаң да, бер нәрсәне онытма,— карт шунда янә нидер үлчәгән сыман уйланып алды.— Без авыл кешесе. Шушы җирдән чыккан, шушында туган. Шушы кырларда үскән икмәкне ашап, тау битеннән бәреп чыккан чишмә суларын эчеп үскән. Табигать безгә, балалары итеп, шундый уңдырышлы җир, туфрак биргән. Ниндиен телисез — шунысын эчегез, дигәндәй, берсеннән-берсе тәмлерәк сулы чишмәләр биргән. Нурлы Алан җегетләре һәрчак таза булып үссен, Нурлы Алан кызларының йөзеннән бер вакытта да алсулык китмәсен дип, күпме чишмә агып тора. Авылның буеннан-буена чишмә чыга. Берсенең суы икенчесеннән тәмлерәк. Күңелең кайсын тели, шунысын эч, дигән табигать. Ә без урамнарны җылатып, туфрак җырта-җырта тимер сузып, эрҗин сузып җиде кат җир астында яткан суны суыртабыз. Кайдадыр ерак бер авылда яисә илдә кемнеңдер сусавын басарга тиешле суны суыртабыз. Авызыбызга өзелеп төшкәнне капмыйча, кеше өлешенә керәбез. Кайда бар бездәге чишмәләр... Бер авылга йөзәү, исәпсез-хисапсыз ич алар. Һәркайсының үз тәме бар. Нинди генә тәм соң әле... Моннан соңмы? Моннан ары, улым, үзем түгел, хәтта атларга да эчертәсем жук шул колонка суын. Тимер белән эрҗин исеннән болай да гарык. Дөньясы тулган шул тимер, эрҗин белән, дөньясы...

Бабасының һәр сүзенә игътибар итәргә тырышып тыңлады Рәхимжан. Авыл урамына су керткәндә күңеленнән генә шатланып, канатланып йөргән иде бит, югыйсә. Дус малайлары белән: «Урамына таш җәйсәң, каладан ким җире юк безнең авылның»,— дип сөйләшкәннәре дә яхшы хәтерендә. Өлкәннәрнең: «Чишмә башына төшүдән котылдык»,— дип, куанып сөйләшкәнен дә ишеткәне бар. Тик барыбер бабасына каршы төшеп, аның белән килешмәвен белдерергә җөрьәт итмәде. Ә бабасы, бер тын туктап торгач, янә дәвам итте:

— Элгәре, картлар белми әйтмәс, ди торганнар иде. Беләсеңме ни сөйли торган иде картлар, без яшь чакта... Авылдагы һәр чишмәнең бер шифасы, бер хикмәте бар, ди торганнар иде. Чишмә суында әле без белеп бетермәгән нәрсәләр байтак. Әйтик, Карт тирәк чишмәсенең суы — гомерне озайта. Бакырчы чишмәсе — җегетләргә көч, гайрәт бирә. Фазыл чишмәсе суын эчеп үскән кызлар сылу була, диләр иде... Халык дөрес әйтә, чынлыкта да шулай. Гомер-гомергә Карт тирәк чишмәсенә якынрак урамнарда йөзьяшәр картлар күбрәк булды. Югары

очта исә кызлар сылурак. Фазыл чишмәсе суын эчәләр чөнки. Жырга, гармунга да бик әвәс була шул тирәнекеләр. Инде үзең уйлап кара — Сабантуйда кайсы урам җегетләре батыр кала? Бакырчы чишмәсеннән эчеп үскән түбән оч җегетләреме?.. Шулар!

Рәхимҗан күңеленнән генә боларны барлап, тикшереп барды. Ни дияргә белгән юк, ышанасың киләме, юкмы — бабасының сүзләре дөрескә чыга иде.

Карт елмая төшеп, үзенә ышаныргамы-ышанмаскамы белми торган оныгына карады. Яратып карады.

— Кызлар чибәр җирдә җегетләр дә житез, җылгыррак була, улым. Монысы да су хикмәте, чишмә хикмәте бик беләсең килсә. Чибәр кызны, җылгыр булмасаң, борын төбеңнән алып китәргә дә күп сорамыйлар аны... Саный китсәң, барлый китсәң, ул хикмәтләрнең очына чыгарлык түгел, улым,— дип дәвам итте ул, яңадан уйчан бер рәвеш алып.— Әллә нинди чир-сырхаулардан да дәвасы бар безнең авыл чишмәләренең. Шуны белгән-аңлаган кешеләрнең кими баруы кызганыч менә, яшьләрнең моңа кул селтәп каравы кызганыч...

— Кызык...— дип куйды Рәхимҗан үзалдына. Тик барыбер бабасы күңелендәгеләрне аңлап, төшенеп житкерми иде әле ул.— Соң, алай булгач, Чегән чишмәсе суының хикмәте нәрсәдә?

— Чегән чишмәсеме,— дип кинәт тавышын үзгәртте карт, җанланып китте.— Чегән чишмәсе — ул бөтенләй башка... Безнең нәсел тамырында Чегән чишмәсенең шифасы йөгерә, улым. Минем тамырда, синең тамырда...

Моннан күп еллар элек булган бу. Төхфәт картның этисе — Айтуган һәм энисе — Гөлйөзем, көтмәгәндә бер-бер артлы авырып китәләр. Әле кырыкны яңа тутырып килгән ир белән хатын тәмам борчуга төшә: берсеннән-берсе кечкенә биш кыз, үлә-нитә калсак, кемгә калыр, диешәләр икән болар. Болай да шатлыклы көннәре санаулы гына булган гаиләне өметсезлек томаны урап ала. Ә авырулары һаман көчәйгәннән-көчәя генә бара икән боларның, урын-җирдән тәмам тормас булалар. Шул көннәрдә авылга чегәннәр килгән дигән хәбәр тарала. Бер дистә йомырка яки бер йомарлам майга, кем сораса шуның язмышын уч төбендәгедәй күреп, әйтеп бирәләр икән, имеш. Моны ишеткән Айтуган, сыкрана-сыкрана булса да сәкесеннән торып, Гөлйөземе белән киңәшкәннән соң, түбәтәенә йомырка тутырып, әлеге чегәннәрне эзли китә. Тегеләр су буендагы яшел тугайлыкка урнашкан икән. Шунда төшеп житәр-житмәс үк Айтуганны җете кызыл итәкләрен уйнатып бөтерелгән, боргаланган, шат йөзле, ут күзле чегән кызлары уратып ала. Үзен иң зур башлыкларына күрсәтүне үтенә ул алардан. Кызлар аны кара мыеклы, киң җилкәле бер өлкән ир янына алып киләләр.

— Миңа самый глауный чегән давай,— ди ул тегеңәр дә.

Кара мыеклы русчаны, татарчаны бергә кушып җавап бирә икән:

— Чегәннәр все главный,— ди. Мужик үзен тинтерәтә башлагач кына: — Мин главный чегән,— дип әйтергә мәҗбүр була.

Татарча аңлаган чегән шундук охшый Айтуганга. Аның күзләренә өмет йөгерә, һәм тизрәк үз гозерен аңлатырга керешә ул.

— Гадать ни нады, благородие чегән,— ди,— карчык сырхау, мин сырхау — умирать будем. Ыскажи эле, пожалыста, карчык умирать ни нады, миңа да умирать ни нады, как ни умирать.?. Биш дивочка бар, одна бәләкәй другуй — умирать ни нады, благородие чегән...— ди.

Моны тыңлап торган чегән шунда кычкырып көлеп җибәргән.

— Нурлы Аланда жить... и умирать...— дип көлә ул Айтуганга карап. Һәм көлеп туйгач, сорап куя: — Яшең ничә синең?

— Көзгә кырык будет,— ди Айтуган.— Җәмәгатькә утыз сигез.

— Миңа за шестьдесят. Еще жить да жить,— дип, үзенең калын

күкрәкләренә дөп-дөп суккалап ала чегән.— А тебе стыдно,— ди, Айтуганга елтыр күзләрен төбәп.— Нурлы Аланда жить и умирать — стыдно.

Бер көязлек белән елмаеп, уйнап торган чегән шулай да бу бетеренгән кешенең хәленә керә. Аның сүнеп барган күзләренә бер тын сынап карап торгач, билбавыннан кулларын алып, жилтер-жилтер үзе белән читкәрәк алып китә. Яр читенә җиткәч чегән балакларын сызгана, Айтуган да ул кушканча эшли — балакларын сызгана. Һәм шарлама булып аккан йөгерек инеш уртасыннан яланаяк килеш атлыйлар. Айтуганның йон чөлкә эченнән чыккан хәлсез аякларын салкын су өтеп алгандай итә, табан асларын су төбендәге вак ташлар авырттыра. Шулай да тыңламый чарасы юк, барын да чегән кушканча эшли ул. Тау куеныннан чишмә бәреп тора. Юка кабыгыннан ясалган нәни генә улак куелган җирдә алар туктап кала. Монда улак юк иде, чегәннәр эше икән, дип уйлап ала Айтуган. Шул чишмә каршындагы таш өстендә торган калай кружкага су тутырып башта үзе эчә чегән, аннары чишмә суын Айтуганга тәкъдим итә.

— Нурлы Аланда мужик здоровый должен быть. Это не вода, а чудо! Знай, мужик, чегәннәр не зря сюда отдыхать едут,— дип, үтмәс пычкы белән имән кискәндәгедәй каты тавыш белән сөйли аңа чегән.— Сам пей, жена пей, дети пей, Нурлы Алан пей — все жить будут. Все как цыган смеяться, петь и плясать будут...

Өенә юнәлә Айтуган. Күргәннәрен, ишеткәннәрен кайтып хатынына сөйли. Билгеле инде, ышанмыйлар, чегән ялганлаган дигән фикергә киләләр. Шулай да, ятып калганчы атып калыйк дигәндәй, чегән күрсәткән чишмәдән чиләк-көянтәләп көн дә су алып кайта башлыйлар. Салкын көе дә эчәләр суны, чәйне дә шуның белән кайнаталар, ашны да. Һәм, атна-ун көн дигәндә, Гөлйөзем белән Айтуган бер-бер артлы аякка да басалар.

Айтуган, үзенең куанычы белән уртаклашырга, яңадан теге чегән башлыгы янына төшә. Чатырларын җыйнап, атларын җигеп маташкан чаклары була тегеләрнең. Күченеп китәргә җыенулары икән. Чегәннәр башлыгы үзенең танышын әллә каян күреп ала.

— Айтуган дус пришел. Айтуган здоровый, Айтуган батыр,— дип, аның җилкәсеннән кага-кага исәнләшә карт чегән.

— Благородие Чегән, бальшуй рәхмәт сиңа,— дип, кабат-кабат кулын кыса аның Айтуган.— Что нады, проси — сыер отдам, проси — алашаны отдам. Мине коткардың, карчыкны да коткардың, биш дивочканы... Проси гына — бер нәрсә дә ни жәлке,— ди.

Айтуганның соңгы атын да, сыерын да алмаган чегән. Аның җилкәсенә кулын салып: «Хатыныңа әйт, Айтуган,— дигән,— биш дивочки янына надо биш джигит»,— дигән. Һәм үзләренең Нурлы Алан авылына бик ераклардан шушы чишмә суын эчәр өчен генә махсус килүләрен әйткән. Аерылышып киткәндә генә, кире борылып, Айтуганга үзенең соңгы серен чишкән: Моннан алтмыш еллар чамасы элек аны әнисе нәкъ менә шушы су буенда, шушы кабык чишмә каршында тапкан булган. «Чегәннәрнең дә туган җире була. Айтуган дус,— дигән ул, мөлдерәп торган күз яшьләрен тыеп.— Я — цыган, уезжаю. Нурлы Алан кала, син каласың, Айтуган. Прощай, Айтуган, прощай Нурлы Алан»,— дигән. Һәм кесәсеннән кулъяулык чыгарып, аңар бер уч туфрак төреп тыккан. Күзендәге кайнар бөртекләрне яшерә алмыйча, бөркәүле арбалар артыннан җил-җил атлап китеп барган.

Шул урында Төхфәт карт тирән итеп сулыш алды. Аның күңеле тулган иде, ахры. Күзләрен яшерергә тырышып эндәште ул онычына. Тавышы сабыр һәм тын иде аның.

— Чегәннәр китеп бер ел чамасы үткәчтен мин дөньяга килгәнмен. Тугач та кендек әбием, әти белән әни үтенечен тыңлап, авызыма бал

кашыгы белән Чегән чишмәсе суын каптырган.— Һәм Төхфәт карт шунда гына, бу гыйбрәтле тарихның онытына нинди тәэсир ясавын белергә теләгәндәй, текәлеп Рәхимҗанга карады.— Менә шулай, улым, табигать ул чишмәләрне бер дә юкка гына бирмәгән. Һәм борынгы бабайлар да килеп урнашканда юкка гына шушы чишмәле тау итәген сайламагандыр. Юкка гына авылга да Нурлы Алан дип исем кушмаганнар. Аланның да нурлысын, чишмәлесен, су буендагысын сайлаганнар...

Төхфәт карт, үз уйларына чумып, сүзсез калды. Бабасы сөйләгәннәр Рәхимҗанның күңелен дә моңлы бер дулкынга көйләделәр. Үткән белән бүгенге арасында торган мәһабәт зур күпер итеп хис итте ул бабасын. Әлеге күпернең киләчәккә дәвамы булырмы? Ул күпер каршы ярга җитми өзелеп калмасмы?.. Үзенең каршылыклы, әмма чишелеше күренмәгән уйлар, сораулар чоңгылына төшеп баруын аңышмый да калды Рәхимҗан.

Юк! Ю-ук, чишмәләр турында гына сөйләми иде, ахры, бабасы.

## 3

Иртәгесен, бидон салынган чана тартып, су буена юл тотты егет. Чегән чишмәсенә төшкән тыкрык тирән кар астында калган иде. Коймалардан да биегрәк итеп, бурап-бурап салган иде кар. Урамнан себереп төшкән дә өйгән, себереп төшкән дә өйгән. Рәхимҗан тәвәккәллек белән алга омтылды, әмма шундук бил тиңентен карга батты. Йөзе белән кар тавына килеп терәлде. Каршысында үзеннән күп биегрәк ак кыя-тау тора иде. «Нишләргә, артка чигенергәме? Юл күмелгән, чишмәне табарлык түгел, таба алмадым дип, кире кайтыргамы?» Әллә каян гына килеп, күңелендә шундый сорау калкынып алды аның. Һәм ул да түгел, шул ук күңел, үз-үзенә көч биреп: «Табам дигәч, табам!» — дип, каршы төште. Бу җавап аңар гайрәт өстәде — туп-туры ак кыяга таба омтылды ул. Аяклары, куллары белән алга ыргылды, әмма кыя бирешмәде. Олы-олы дулкыннарга каршы торырга азапланып, йөзәргә итенгән кешедәй хәрәкәтләр ясап карады — өстенә өем-өем кар ишелеп төште. Чана авып китте, бер читкә тимер бедон тәгәрәде. Ул тагы алга ыргылды... Һәм, инде менеп җиттем дигәндә генә, кар дулкынына ияреп янә кире шуып төште. Ничек кенә булмасын, инде бирешү турында уйларга да ярамый иде. Шундук, муенына, итек куныччларына кереп тулган карны да кагып тормастан, яңадан биеклеккә омтылды. Тезәнлекләп үрмәләсә үрмәләде, тырманса тырманды, барыбер үзенекен итте — авыл белән чишмә арасында калыккан ак кыяны үзенә буйсындырды егет! Һәм, тыкрыктагы кар тавы өстенә менеп баскач, канәгатьлек белән як-ягына каранып торды. «Үземнекен иттем ич. Менәм дигәч мендем, үземнекен иттем»,— дип горурлану иде бугай бу. Әмма кем алдында горурлана соң әле ул? Тирә-юньдә адәм заты юк ич... Шуннан соң гына, язмышын чана ихтыярына тапшырып, күзләрне камаштырып торган ап-ак чиксезлеккә шуып төшеп китте.

Шуып төште... Чишмә түгел, инешнең кайда икәнлеген дә абайламый аптырап торды баштарак. Серле тынлык белән ак яктылык кына эленеп тора иде тирә-юньдә. Ник бер чаңгы яки чана эзе булсын! Күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләрдәге аксыл-зәңгәр дәрьяга адашып килеп чыккан диярсең. Вакыт һәм ераклык төшенчәләре монда бөтенләй юктыр сыман тоелды Рәхимҗанга. Күңелен аның сәер бер рәхәтлек урап алган иде. Киңлек һәм иркенлек сокландырды аны монда. Шушы ак иркенлектә, зәңгәр киңлектә онытылып каласы, онытыласы

һәм кош булып очасы килде аның. Ике канатка охшатып, ирексездән, як-якка кулларын җәйде. Бер талпынды, ике талпынды — һәм, үзе дә уйламастан, җирдән аерылды, оча башлады. Зәңгәрсу аклыкка төренгән дөнья торган саен зурая һәм иркенәя барды. Шунда күз алдындагы киңлектән башы әйләнеп киткәндәй булды аның. Әллә ул, әллә дөнья әйләнде шулчак — җиңелчә чайкалып куйган Рәхимҗан ак болытларга барып кунды. Бишек сыман йомшак, мамык сыман ап-ак иде аны үз кочагына алган болыт. Ә җир өсте һаман яктыра, ул яктыра барган саен андагы аклыкта зәңгәрсулык өстенлек ала бара төсле тоелды. Җир белән күк, ак болыт белән көрт аермасын онытыр дәрәҗәдә бәхетле һәм шат иде Рәхимҗан шул минутта.

Кинәт каядыр янәшәдә генә колагына серле аваз чалынгандай булды. Болытлар арасында агып яткан чишмә челтерәвен хәтерләткән аваз иде бугай бу. Болыт булып үзен кочагына алган кар түшәктән торып аягына басты ул. Очы-кырые күренмәгән ак зәңгәрлекне ерып, шул аваз килгән якка төбәп китте. Болытлардан болытка күчеп оча идеме ул, әллә тирән көрт ерып бара идеме — байтак вакыт үзе дә аңышмады. Челтерәү авазы якыная төшкәч кенә, үзенең җирдә булуын, бакчалар артында гына агып яткан инеш буйлатып чишмәгә таба баруын төшенде.

Җылы пар бөркеп, челтерәп агып яткан чишмәне күргәч, таң калды егет! Гаҗәпләнмәслек тә түгел: бөтен дөнья — урам һәм тыкрыклар, киртә һәм коймалар, инеш һәм су буйлары кар астында йомылып яткан бер мәлдә дә чишмә күмелмичә калган! Нурлы аланлылар үзен күптән онытканн булуга да карамастан, чишмә тирән кар катламын ярып яктыга чыккан — тибеп тора. «Юк, мин алай гына бирешә торганнардан түгел, мин әле яшим һәм яшәргә тиеш»,— ди иде сыман ул.

Җылынып киткәндәй булды егет. Тимер кисмәккә шаулап аккан салкын чишмә суыннан да җылы пар бөркелә иде. Билдән карга батып үргә чана тартып менгәндә дә, урамнардан үткәндә дә шул җылылык аны озата барды. Өй эчен дә шул җылылык тутырды шикелле. Кичен табын түрендә җылы пар бөркеп утырган самавыр әйләнәсендә гаилә белән җыйналып чәй эчтеләр алар. Чегән чишмәсе суының тәмлелеген һәммәсе мактады. Эштән арып кайткан әтисе дә чәйне гомер булмаганча яратып эчте бугай. Әледән-әле кулына тастымал алып, маңгаена бәреп чыккан эре-эре тир бөртекләрен сөрткәләп торды. Күңелендәге күтәренкелекне күзләрендә, иреннәрендә генә чагылдырып бетерә алмаган әнисе чәй ясарга өлгерми иде. Борынгыдан калган җиз самавырны мактады ул, чәйгә шундый тәмле су алып кайткан улын мактады. Төхфәт карт исә берөзлексез елмаеп утырды. Җай чыккан саен оныгына карап, хәйләкәр генә күз кысып куя иде. Һәр яңа чынаякны бушата барган саен бабасы күзләрендәге якты очкыннарның дөрли баруын, җыерчыклар баскан йөзендә уйнаган алсу нурларның ялкынланыбрак януын күреп утырды Рәхимҗан. Гомер булмаганча җылы һәм рәхәт иде кышкы бу кич. Төшендә дә бөтен тирә-якка җылы бөркеп торган чишмәне күрде ул.

Иртәгесен тагы чана тартып су буена төште Рәхимҗан. Көн кояшлы һәм якты иде. Ак кар өстеннән күзгә күренер күренмәс кенә зәңгәрсу рәшә йөгерә. Гаҗәп, нәкъ җәйге челләдә иген кырында гына була торган рәшә кебек. Иген кыры белән чишмә буе арасында нинди уртаклык бар соң?.. Анда икмәк, монда су — кеше өчен бер үк дәрәҗәдә кирәкле һәм кадерле булган хәзинә түгелме соң алар?..

Чишмә янындагы кар өстеннән рәшә йөгерүен күрдем дип, берәү сөйләгән булса, ул ышанмаган да булыр иде әле. Нинди көч хәрәкәтләндерә, ни куә икән ул зәңгәр дулкыннарны — кояш нурларымы, әллә сизелер-сизелмәс кенә исеп торган оялчан җилме? Әллә муллык һәм хозурлыктан куанган күңел тибрәнешеме бу...

Уйланып килгән җирдән кинәт гаҗәпкә калды Рәхимҗан. Чишмә тирәсендәге аяк эзләре, чишмә тирәсенең кардан чистартылган булуы аптыраашта калдырды аны. Якынрак килгәч, чишмә әйләнәсендәге бозның балта белән чабып, таймас хәлгә китерелүенә тагы бер каг гаҗәпләнде. Ул кабаланып як-ягына каранды һәм хәйран калды — кар астында калган бәрәңге бакчалары аша чишмә яныннан бормаланып киткән тар сукмак сузылган иде. Әле кичә генә сукмак түгел, чыпчык эзе дә юк иде бит су буенда. Рәхимҗанның карашы, зәңгәрсу аклык эчендә эреп югалганчы, шул сукмак буйлап йөгерде.

Бакчалар эчендәге карлы офык артына чиләк-көянтә аскан ниндидер сыгылмалы шәүлә кереп югалгандай тоелды аңар. Күрде, әмма үз күзләренә үзе ышанмады — кояшлы зәңгәр рәшәнең күз бууга охшаш шаяртуы гына булды, ахры. Ай күрде, кояш алды дигәндәй, зәңгәр офыкка барып тоташкан сукмак буп-буш иде инде. Су алырга төшкән таң йолдызы Чулпанның чиксез галәмгә ашуы булдымы бу...

Инеш аша сузылган озын улак буйлап су йөгерә. Вак ташлар аша сикереп-уйнап йөгерә, нәни дулкыннар таратып челтери чишмә. Кая ашыга, кая шулай ашкына икән ул... Рәхимҗан төшкәнче дә шулай аккан, тимер кисмәкне тутыргач та шулай агачак. Ул туганчы ук шулай уйнаклап аккандыр чишмә, әтисе туганчы, бабасы туганчы да... Кайчаннан бирле ага икән ул шулай? Киләчәктә дә аның сулары берөзлексез сәфәрдә булыр... Күпме су — күпме шифа, дип хәйран калып торды ул. Көндезен дә, төннәрен дә туктаусыз агып тора чишмә... Әнә, инде аның бидоны тулды да, уйнаклап аккан су як-якка чәчри башлады. Үз толымын урап алган боз-коймага чәчри, агымына яңакларын куеп торган төрле зурлыктагы ташлар өстенә ага. Ага да ага. Һишлисең, китми булмый дигән сыман, теләр-теләмәс кенә кар түшәк астына кереп югала. Агымга ияреп китәргә теләгәндәй, вак таш кисәкләре кузгалып-кузгалып ала, ком бөртекләре кайный...

Шул чишмәгә төшә торган юлның беркемгә дә кирәге калмаган. Аны онытканнар. Кайтыр юлына карап, шул хакта уйлап куйды Рәхимҗан. Аннары бакчалар эченнән офыккача бер якты нур булып сузылган тар сукмакка төште аның күзе. Күңелен янә зәңгәр яктылык иркәләп узды, чишмәдән күтәрелгән пар җылытты. «Күпме шифа, күпме шифа»,— дип кабатлады ул үзалдына. Кайтып-кайтып күңеленә тынгылык бирмәде шул хактагы уй. Тауны менеп, иркен урамнарга килеп кергәч, башта бидондагы су шапылдавы, аннары табан астындагы карның салкынлыгыннан зарланучы чана эләктереп алды шул авазны. Сызгыру һәм шыгырдауга охшаш тавыш белән бөтен авылга сөрән сала сыман иде чана табаннары: «Күпме шифа, күпме шифа...» Урамнан үтеп баручылар әлеге авазны ишетеп чана артыннан борылып карап кала, капкалар шыгырдап ачыла, ишекләр, тәрәзәләр — һәммәсенең карашы Рәхимҗан артыннан ияргән чанага төбәлгән. Аның табаннары туктарга, тынычланырга һич уйламый, торган саен ярсыбрак аваз сала: «Күп-ме... ши-фа. Күп-ме... ши-фа...»

Көн дә Чегән чишмәсенә суга төшү Рәхимҗанның гадәтенә керде. Тик чишмә юлында күпме йөреп тә һичкемне очратмау тынгылык бирмәде аңарга. Әмма көннең кайсы гына вакытында төшмәсен, чишмәнең тирә-ягы кардан-боздан чистартылган, серле сукмакка яңа эзләр салынган булыр иде. Бу билгесезлек белән килешәсе килмәде аның, беркөн кич җиткәч, йолдызлар калыккач кына төшәргә булды ул суга. Бәлки, чынлап та, әлеге сукмактан таң йолдызы Чулпан яисә ай кызы Зөһрә йөри торгандыр чишмәгә.

Тыкрыкта инде көпшәк кенә булса да чана юлы салынып килә икән. Тик болар бары да аның эзләре. Чишмә юлы онытылган — чаңгыда яисә чанада шуучы ник бер малай күренсен! Чишмәдән су алгач та, аның серле челтерәвен озак кына тыңлап торды Рәхимҗан. Аяз күктә йол-

дызлар калыккан иде инде. Баш очында гына Җидеган йолдыз балкый. Нурлы Алан кешеләре аны Чүмеч йолдыз диләр.

Җидегән йолдыз торган саен аңар якыная баргандай тоелды. Күе зәңгәр төскә чумган күк йөзеннән кемдер шул чүмечкә чумырып чишмәдән су алырга җыена иде кебек. Йөзен зәңгәр яулык чите белән каплаган Зөһрә йолдыздыр ул бәлки. Әмма әкияти кыз нигәдер кыймады, егеттән оялды, уңайсызланды кебек — Чүмеч йолдыз хәрәкәтсез калды.

Хыял канатларында җиңелчә тибрәлеп, шулай байтак кына басып торды ул чишмә каршында. Җидегән йолдызның юлдашларына күчте аның карашы. Ерактагы якты бер йолдызга текәлеп калды ул. Аның җемелдәве үк башка һәм үз иде. Шактый вакыт сокланып торгач кына Рәхимҗан әлеге йолдыз җемелдәве белән йөрәге тибешенең бер ешлыкта булуын чамалады. Нигә әле исемсез булырга тиеш шундый йолдыз... Әнә таң йолдызының татарда гына да ничә исеме бар: Зөһрә, Чулпан, Венера... Һәм күңеленнән генә әлеге йолдызга исем эзләде егет. Иң лаек исем — Зәйнәп иде, билгеле. Исемсез йолдызга Зәйнәп дигән исем бирергә булды ул. Чынлап та әйбәт исем ич: Нинди йолдыз(?) дигәндә, Зәйнәп йолдызы(!) дип җавап бирсәләр. «Зәйнәп йолдызы, Зәйнәп...» дип пышылдады ул үзалдына.

Шулчак егет күңеленә кайчандыр исендә калган бер җырның сүзләре килде: «Һавадагы йолдызларны туйганчы санамадым шул, Зәйнәбем, Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем...» Җырның башка сүзләрен белми иде ул. Гаҗәп, нинди матур җыр! Нәкъ менә шушы кичтә, шушы чишмә каршында, йолдызлы зәңгәр күк астында әле генә аның күңелендә туган җыр сыман яңа һәм гүзәл җыр икән бит «Зәйнәбем». Ә моңарчы ул шуны тоймаган.

Чишмәгә төшкән серле сукмак бер генә минутка да тынгылык бирмәде Рәхимҗанга. Аны кем салды икән? Ни өчендер, Зәйнәп салгандыр, ул сукмактан Зәйнәп су ташый торгандыр сыман тоела иде. Торулары да шул тирәдә генә. Теге чакта күренеп калган сыгылмалы шәүлә дә һаман күз алдына килеп, аны хәтерләтә. Зәйнәп белән чишмә янында очрашу теләге егет күңелендә кинәт кенә туып, бер генә көн, бер генә сәгатькә дә сүнеп тормады. Гел үсә, арта гына барды очрашу теләге. Су алырга төшкән саен, сукмактан, иң өсләрен җиңелчә уйнатып төшеп килгән Зәйнәпнең күренүен көтте ул. Ләкин, элеккечә үк, чишмә янында түгел, хәтта якын-тирә су буенда да бер җан иясе очратмады. Авылның буеннан-буена сузылган тау итәгеннән бәреп чыккан дистәләгән башка чишмәләр кебек үк, Чегән чишмәсе дә онытылган, ташланган иде. Хәер, Чегән чишмәсен ташланган дип әйтү ярармы? Аны бит кемдер бервөзлексез карап, һаман хәстәрләп тора. Әмма кая? Кем ул игелекле җан?..

Көннәрдән бер көн, мәктәпкә барганчы иртән иртүк төште ул су буена. Зәйнәпне очрату иде уенда. Әле төнге караңгылык таралып өлгермәгән бер вакыт иде. Чишмә тавышы тау башыннан ук ишетелеп тора. Төнлә бераз яңа кар төшеп, себереп тә үткән. Яңа яуган кар өстеннән атлауның бар рәхәтлеген тоеп барды ул. Әмма чишмә янында таныш эзләр күренми иде әлегә. Су буенда беренче тапкыр яңа-ялгыз итеп тойды ул үзен. Зәйнәпкә бер-бер хәл булганмы әллә, дип борчуга калды. Чишмәгә салынган сукмакның Зәйнәпнеке булуына аның һичбер шиге юк иде.

Карлы җил исеп торганлыктан, чишмәнең як-ягына шактый гына боз җәелгән. Сыр-сыр булып каткан бозлавыкта аздан гына таеп егылмый калды ул. Балта яисә көрәк салып төшәргә кирәк булган икән, менә бит ул әзергә-бәзер йөрергә күнеккән. Чишмә янының чистартылган булуын күреп, Зәйнәп тә куанган булыр иде...

Шулчак якын-тирәдә чиләк шалтыраган тавыш ишетелде. Килә, кемдер, суга төшеп килә!.. Бар дөньясын онытып, сагаеп тыңлады Рә-

химжан. Башындагы бүреген салып тыңлады. Аның колакчыннарын күтәрде, кабаланып, астарланган йон бияләйләрен кесәгә яшерергә ашыкты. Чынлап та, кемдер төшеп килә иде сыман, көянтәгә эленгән буш чиләкләрнең җиңелчә чайкалып, атынган тавышы тагын, тагын ишетелде. Ниһаять, калкулык читеннән аның шәүләсе дә күренеп китте. Җил-җил атлап ул суга төшеп килә иде. Аның Зәйнәп булуында Рәхимҗанның аз гына шиге юк. Ул, әлбәттә, ул! Тиктомалга кабалана башлады егет. Инде күптән тулы килеш улак астында торган бидонны җәһәт кенә күтәреп алды. Капкачын ябып, чанага таба өстерәде. Үзе кабаланды, үзе ашыкмады — вакытны сузды. Ничек итсә итте, кызның су буена төшеп житкәнен көтте. Аяк тавышыннан, сулышыннан ук таный ич ул аны. Әнә, инде гел төшеп үк житте бугай. Егет, берни ишетмәгән, тоймаганга сабышып, чана тирәсендә әвәрә килүендә булды. Күтәрелеп карамады. Беренче булып аның — Зәйнәпнең дәшүен көтте. Дәшсен генә, аннары инде ничек һәм ниләр сөйләшергә икәнлеген ул белер. Бу юлы җебеп калмас...

— Бәй, таң тишегеннән кем йөри дисәм, син түгелме соң, Рәхимҗан,— дип эндәште ягымлы тавыш.

Тынлык куенынан ишетелгән тавыш егетне сискәндереп куйды. Чишмә башына төшкән кыз Зәйнәп түгел иде. Күтәрелеп карагач кына, ул Зәйнәпнең классташын, унынчы «Б» кызы Фаягөлне таныды.

Кызның алсуланып пешкән бит алмалары, кар бөртекләредәй яктырып уйнап торган күзләре, таң чыгы кунган иреннәре чишмә буена иртәнге нур һәм яктылык алып төшкән иде. Егетнең күз алды караңгыланып киткәндәй булды... Рәхимҗан көткән нурлар түгел иде шул бу.

## 4

Бабасы Рәхимҗанга, җай чыккан саен, авылның үткәне хакында сөйләргә тырыша. Нурлы Алан чишмәләре, инеш һәм коры елгаларының исеме каян килеп чыккан, теге яисә бу тауны, юлларны нигә шулай атаганнар — Төхфәт карт һәммәсен мавыктыргыч вакыйга-истәлекләр аша күз алдына китереп бастыра иде. Авылдагы һәр агач һәм ерганакның да үзенә күрә үткәне, гыйбрәтле бер тарихы бар икән ләбаса!

Бабасы сөйләгәннәрдән рухланып китеп, беркөн Рәхимҗан әйтеп салды:

— Нигә мәктәптә туган авыл тарихын укытмыйлар икән?.. Син сөйләгәннәрне, бабай, күпләрнең ишеткәне дә юк бит,— диде. Әйтерсең, бу Төхфәт карт кына хәл итә торган мәсьәлә.

— Барын да ничек укытып бетерергә кирәк, улым,— дип, маңгаен сыпырып алды карт,— болай да укудан башыгыз чыкмый. Ничек итеп барын да укытып бетерергә кирәк...

Соңгы сүзләрен әйткәндә карт тагы да уйчанлана төшкән иде. Оныгының хаклы булуын тану идеме бу, аңламассың...

— Мәктәптә бит, бабай, күбрәк борынгы Рим һәм Греция тарихын өйрәттеләр безгә. Үз авылың, аның кешеләре, чишмә һәм урман-сулары турында сөйләшергә вакыт калмый. Кызык килеп чыга... Син сөйләгәннәр хакында минем бүгенгәчә ишеткәнем дә юк иде әле, бабай.

— Житәр, улым, андый чаклар да житәр,— дип тынычландырырга ашыкты Төхфәт карт,— балаларга туган як, туган-үскән җир тарихын белүнең кирәклегенә дә төшенерләр бер. Һәр көн иртән классларга җыелгач та авыл һәм аның су буйлары, кырлары, игенче һөнәре хакында сөйләүдән башларлар берзаман... Авыл кешесе, игенченең

кадере көне түгел, сәгате белән арта барган заман житте, улым. Барысына да чират житеп килә... Соңламасак...

— Әнә, Жәкедә мәктәп музее ясыйлар икән,— дип, бабасын тынычландырырга ашыкты Рәхимжан.

— Бервакыт безнең Нурлы Аланның да үз тарихын өйрәнерләр. Болгар чорыннан ук килгән зур тарихы булган аның. Кайчандыр шактый ук билгеле шәһәр-крепость булган бит ул. Нурлы Алан-Кирмән дип тә йөрткәннәр аны шуңар. Кирмән — крепость дигән сүз, беләсеңдер... Музейлар да булыр, истәлек урыннары да...

Рәхимжан, бабасы сөйләгәннәргә күңеле булып, үзенең уйларын уртаклашырга ашыкты.

— Әнә ич, авыл советы каршында Ватан өчен үлгәннәргә нинди шәп Истәлек куелды.

— Дөрес, улым, дөрес,— диде карт. Оныгының бу хакта сүз кузгатуына ул тагы шатланып куйды.— Ике рота булырлык менә дигән жегетләрнең исеме язылган анда. Мин бит аларның барысын да күреп белгән кеше... Аркаларыннан сөеп озаткан идек үзләрен.— Төхфәт бабайның күңеле нечкәреп куйды. Ләкин ул моны Рәхимжанга сиздерергә теләми иде.— Кешеләрнең жөрәге мүкләнүдән генә куркырга кирәк, башкасы куркыныч түгел. Һәммәсенә дә чират житәр, улым. Житәр! Жөрәге мүкләнгәннәр кулына калдырасы килми шул авылны. Саклыйсы иде аны, тамыры нык әле аның... Тамыры нык!

Шулчак, соңгы вакытларда гына классларында булып узган бер вакыйга хәтеренә килде Рәхимжанның. Математика дәресе иде. Укытучы Фоат абыйларының кәефсез чагы. Үч иткәндәй, чүп өстенә чүмәлә булып, өйгә бирелгән бер мәсьәләне чишә алмый килгәннәр. Бөтен класслары белән. Укытучының шуңа жен ачулары чыкты. Башта кулындагы акбурны идәнгә атып бәрде ул, аннары журналның буеннан-буена «ике»ле тезеп чыкты.

— Имтиханда күрсәтермен әле,— дип янады үзе берөзлексез.— Игелек күрсәтер дип уйламагыз... Мин тагы, укып кеше булсыннар, дип тырышкан булам, пнимаешь. Барлы-юклы «өч»леләрегез белән алдылар ди сезне институтка... Керәгегез бар ди. Берегезнең дә кирәсе юк! Сезгә әнә — дуңгыз котәрсез, фермадан тирес чыгарырсыз... Сездән юньле кеше укытып булмасмы, белем биреп булмасмы дип йөргән — мин юләр, пнимаешь...

Фоат абыйлары тәмам кызып, тузынып китте. Туктау турында уйламый да иде әле. Берәүләр карашларын идәнгә төбәп, өнсез калды. Ә арткы рәтләрдә утырган берничә малай, түзә алмыйча, яшертен генә көлешә башлады. Моны сизеп алган укытучы, тавышын тагы да күтәрә төшеп, аларның барысына да басарга кушты.

— Нәрсә анда, Айтуганов,— дип Рәхимжанга мөрәжәгать итте ул беренче булып,— син дә шул жыен шалапутка иярергә булдыңмыни?.. Математикадан «өч»ле чәпәсәм, ерак китә алмассың, небучь... Ат жигәргә жыенмыйсыңдыр бит, пнимаешь...

Ни әйтсәләр дә түзгән булыр иде Рәхимжан, «ат жигү» дигәч, тыелып кала алмады — аннан-моннан китап-дәфтәрләрен жыештырды да, ишекне каты ябып, класстан бөтенләй чыгып ук китте. Үзе өчен түгел, бабасы өчен рәнжегән иде аның күңеле. «Ат жигүче, ди бит,—...ат жигүче...»,— дип мыгырданды ул өйләренә кайтып житкәнче. Бабасы өйдә юк иде. Атларны һәм бабасын сагынып шундук ат абзарына таба чыгып киткәнен дә абайламады үзенең...

Иртәгесен аны директорга чакырдылар. «Фоат абыеңнан гафу үтен. Кемнән-кемнән, ләкин синнән моны көтмәгән идек»,— диделәр.

Ул бер сүз дәшми түбән карап торды. Каршы да килмәде, ризасызлык та белдермәде.

Чыгарылыш имтиханында Фоат абыйсы аңар «биш»ле куйды һәм егетнең иңбашыннан кагып: «Һич икеләнми университетка бара аласың, Айтуганов»,— дия-дия мактап та алды әле үзен.

Кайчакларда үз-үзенә урын таба алмады Рәхимҗан, күңеленә килгән уйлар чоңгылыннан җиңел генә котылырлык түгел иде. Авылдан китү, югары уку йортына керү — ни өчен кешенең иң зур максаты саналырга тиеш икән? Кеше булуның, җәмгыятькә файда итүнең башкача юлы юкмы икәнни соң? Элегрәк аның бу хакта әллә ни уйланганы юк иде. Башкалар китә ич — мин дә китәрмен, башкалар укый ич — мин дә укырмын, дип кенә йөри иде.

Әлегедәй хәтерендә: сабый чактан ук «зиһенле бала, үскәч калага китәр, укып зур нәчәльник булыр», дип сөйделәр аны. Укырга йөри башлагач, инде үзенең күңелендә сәяхәтче булу, инженер яисә очучы булу турындагы хыяллар бер-бер артлы уянып, үзара тарткалашты. Әтисе: «Геолог булырсың, улым, табигатьне, сәяхәтне бик яратасың»,— дия килде, әнисе улын җиңел машиналарда гына утырып йөри торган инженер итеп күз алдына китерә иде. Инде хәзер аларны киләчәк турында уйларга укытучылар берөзлексез «кыстый» башлады. Физика укытучысы авиация институтына барырга киңәш итте, химия укытучысы: «Киләчәк химиклар кулында»,— диде. Әдәбият дәресләрендә аларны шигырь язарга, шагыйрь булырга димләделәр, чит тел укытучысы— төрле илләргә тәрҗемәче булып йөрү турындагы татлы хыялларга нигез салды. Физкультура дәресләрендә булачак чемпионнарны эзләделәр. Яхшы спортчыга теләсә кайсы институт ишеге ачык булуы, теләсә кайсы шәһәрдә чиратсыз фатир бирелүе дә искәртелә килende. Бик сирәк очракларда гына педагогия яки медицина институтлары хакында сүз чыгып, укытучы һәм врач һөнәрләренең дә җәмгыятькә кирәклеге турында әйтелгәли торган иде. Ләкин, әлегәчә, Рәхимҗанның һичкем авызыннан «авылда калырга, иген игәргә...» — дигән сүз ишеткәне булмады. Имтихан диделәр, югары уку йорты диделәр, институт диделәр... Дөньяда институт һәм имтиханнан башка һичнинди әһәмиятле нәрсә юктыр сыман иде. Классташлары белән үзара сөйләшүләр дә күп очракта шул төшенчәләр тирәсендә әйләнде. Бер-берсенә су тамчыларыдай охшаш андый сөйләшүләр унынчыларның канына сеңгән иде инде. Тәнәфес арасындагы кыска аңлашуларда да бер үк сүзләр диярлек яңгырады. Әйтик, болайрак сөйләшә иде алар:

— Университеткамы?

— Университетка!

— Синең «биш»леләр шул...

Яисә:

— Кайда барырга җыенасың?

— Авиационныйга... (Бу урында «химикога», «торговыйга», «финансовыйга» кебек җаваплар да еш кабатлана.)

— Синең планнар зурдан. Шә-әп!

— Кералмасам, заводка урнашам да, подготовительныйга... Барыбер керәм шул авиационныйга.

Нурлы Алан зур авиация үзәге икән, дип уйлый күрмәгез тагы. Юк, Нурлы Алан туфрагына һава лайнерлары түгел, «кукурузник»ның да төшкәне юк. Хәтта бу авыл өстеннән үтә торган һава юлы да юктыр әле. Әмма «авиационный» дигәнең — иң еш ишетелә торган җавап.

Я булмаса болайрак та сөйләшәләр:

— Укырга исәп бармы?

— Кереп булса...

— Булмаса?..

— Нишлисең инде, шәһәр җирендә бер-бер эш табылыр әле...

Һич югында, әнә, Фаяз сыман гына сөйләшәләр. Ул да җавапка аптырап тормый. «Укырга җыенмыйсыңдыр ич...» — дигән сынаулы сорауга:

— Безне кем алсын,— ди, кулын кесәдән чыгарып тормый гына.

— Авылда каласыңмыни?..

— Таптың... Калага, һич булмаса абый янына Урал шахталарына элдерәм,— ди Фаяз, башны югары тотып.

Бернечә тапкыр, юри генә, авылда калам дип әти-әнисен куркытып караганы да булды Рәхимҗанның. Билгеле инде, уларын кайгыртучан ата-ана: «Шуның өчен укыттыкмы, шуның өчен үстердекме...» — дип, дәррәү күтәрелеп бәрелделәр. Күрше-күлән һәм авылдашлары алдында үзләрен хур итмәскә үгетләделәр. Бердәнбер бала үстереп, диделәр.

Озын сүзнең кыскасы шул — әле моннан ун-унбиш еллар элек кенә югары белемле кешеләре кулдагы бармаклар санына да җитмәгән Нурлы Аланда шәһәргә китеп югары уку йортына керү иң зур дәрәҗә санала башлаган иде. Шуңа күрә, теге яисә бу институтка керә алмаган егет һәм кызлар да авылга кире әйләнеп кайтырга бик ашыкмый, теләсә нинди шартларга да риза булып, шәһәрдә ябышып калу җаен эзлиләр. Авылда чакта ишегалды себерүнең ни икәнен белмәгән егетләр дә, урам себерүче булып эшләсә эшли, әмма кире әйләнеп кайтмый. Чөнки Нурлы Алан кешеләренә аерым бер горурлык сыйфаты хас, алар бер-береннән ким-хур булырга яратмыйлар.

Ял арасында шәһәрдән агылып кайталар авылга — түл җыярга кайткан кебек. Шуларның берише фермада яисә кырларда эшләүче яшьтәшләре яныннан муенын туры тотып, эре генә атлап үтә. Мине күрәсезме, янәсе, шәһәрдән кайттым ич, күрәсезме... Шунда «Сорочка»дан алган чуар язулар ябыштырылган джинса чалбар кесәсеннән ялтыравык кәгазьле «жвачка» чыгарып чәйнәп тә җибәрсә, исең-акылың китәр.

Рәхимҗанның да шәһәрдән кайткан егетләргә, кызларга көнләшеп караган чаклары булмады түгел. Аз гына вакыт эчендә үзгәртә дә куя иде шәһәр аның авылдашларын. Тизрәк унынчыны тәмамларга да, шулар кебек олы юл чатына чыгып басарга, юлаучы машиналарга кул күтәрергә... Һәркемне серле һәм яңа тормыш көтәдер төсле иде ул юлларның баш-башында. Бер якта — Якты Яр. Икенчесендә — Зур Кала...

Шулай да ни өчен гомер бишекләре булган авылдан чыгып китүне бернигә санамый икән аның авылдашлары?.. Гомер-гомергә шулай булачакмы бу? Әллә аларның буынына гына хас вакытлы бер мавыгумы?! Туган авыл шәһәргә китеп урнашу җаен чыгара алмаган яисә югары уку йортларына керү әмәлен тапмаган «бәхетсезләр» өчен сыенып бер почмак кынамы әллә? Моның белән килешәсе килми иде егетнең. Ә үзен барыбер шәһәр турындагы уйлар канатландырды. Ата-ана һәм мәктәп аларны ничә еллар буе бер максат — югары белем алу максаты белән куандырып тәрбияләде ич. Аягыңда нык басып тору өчен, чын кеше булу өчен югары белем кирәк, диделәр. Кеше булу өчен... Ә авылда кемнәр? Икмәк үстерүче чын кеше түгелмени? Ит-сөт җитештерүче үз аягында нык басып тормыймыни?.. Бала чакта җен-пәриләр белән куркыткандай, нигә әле аларны берөзлексез авылда калу белән куркыталар...

5

Нурлы Аланда иң матур чак, мөгаен, яз көнедер. Язның да әле яңа башланган чагы. Апрель керсә, авыл каршындагы тау түбәсен көннән-көн буена кояш нурлары җылытып тора. Беренче булып кар шунда

көпшәкләнә, шунда эри башлый. Урамнарга гөрләвек авазлары кергәнче үк түбәтәй кадәр генә урын кышкы җәймәдән арчылып та өлгерә тау башында. Малайларга җитә кала — дөньяларын онытып, алар шунда йөгерә. Балакларын тез тиңентен сызганып, яланаяк калып, кар суларын ерып уйнаклыйлар. Бил тиңентен чишенеп, яңа чыгып килгән яшел чирәм өстенә сузылып ятуның да тәүге рәхәтлеген шунда — тау башында татый алар. Югарыдан торып урамнарны, авылга килгән юлларны, тирә-як басуларны күзәтүнең рәхәтлеген әйтеп, сөйләп бетерерлек түгел. Бөтен дөнья, бөтен әйләнә-тирәне кар сарып алган, ә син тау башында яшел чирәм өстендә сузылып ятасың. Язгы кояш нурларында кызынасың. Авылның аргы башындагы олы юлдан тызбыз машиналар чаба. Аларда утырып барган юлчылар күрәме икән Нурлы Алан малайларын? Күрмимә соң, күрәләр, әлбәттә. Менә бәхетләләр, дип, кызыгып та куялардыр, нигә без дә Нурлы Аланда тумаган һәм шул тау башларында уйнап үсмәгән, дип тә уйлыйлардыр әле...

Шунда михахайлап ат кешнәгән аваз ишетелеп китә. Ат тавышларына кайсы малай битараф калсын соң — күңел җилкенеп куя. Аккош кебек, казлар кебек җилпенеп авыл ягына оча күңел... Әнә — Миңлегали ерганагы буена урнашкан ул ат абзары. Аның тәрәзәләреннән җылылык, җиңелчә пар бөркелгәндәй булып тора — ат исе чыга торгандыр... Аранда тайлар җыйналган. Арт аякларын сикертеп чабып узалар, башларын болгап, тешләшкән сыман итеп берөзлексез уйнашалар. Язгы кояш нурларында иркәләнүләреме шулай, әллә араннарын тарсынып, зуррак дөньяга чыгарга ашкынуларымы?.. Тулпар ат кебек ялларын җилфердәтеп бәйгедә сынашыр чакларын көтәләрме алар... Бер урында тора алмый малайлар, уйный-сикерешә, яланаяклап йөгерешә-йөгерешә үзләре дә шул тайларга охшатып кешнәгән булып куялар. Кем яхшырак кешни янәсе: безме, тайлармы...

Ишек алларында бозау һәм сарык бәрәннәре куышып уйнаклый икән. Алардан куркышып, су чәчрәгәндәй, пырхылдашып тавык-чебеш читкә сибелә. Гайниҗамал түтиләрнең су буена карап торган болдырыннан каз күренде. Ана каз, күкәй салып чыккан — әнә бит ничек җилпенә, дөньяны кырган диярсең. Бу минутта аңардан бәхетлене табам димә. Ул арада, бу шатлыкта минем өлеш тә юк түгел дигәндәй, әлеге куанычны бүлешергә муенын сузып ата каз да килеп җиткән. Дөньяда алар гына сыман, берсен-берсе уздырырга тырышып «коккок» каңгылдашалар, муеннарын сузып үзара макташалар.

Рәхимҗан, тау башына карап, байтак кына шундый уйларга биреләп торды. Башка бөтен нәрсә турында онытып, яланаяк яшел чирәм өстеннән йөгерешеп чапкан чакларын сагына идеме ул. Малай чакның ул кояшлы көннәре, шулардан соң аяк-кулларга чыккан «чеби»ләрне санап үткәргән йокысыз төннәре онытылмас. Юк, онытылмас...

Ә шулай да тәрәзәләргә тулып язгы кояш кергән сәгатьләрдә класста дәрес тыңлау җиңел эш түгел икән. Күзләр берөзлексез урамга, кыектагы сөңге бозлардан тамган тамчыга һәм тау башына тартылып тора. Шундый көннәрнең берендә, дәресләрдән соң Чегән чишмәсенә суга төшкән җирендә, Рәхимҗан тагы Фаягөлне очратты.

— Урманда умырзая чыккан, тал песиләре...— диде кыз, үзенең яңалыгын Рәхимҗан белән уртаклашырга ашыгып.

— Чынлапмы?..— диде егет, Фаягөлгә туры карап. Бу аның, үзенчә, шаяртуы янсә бер үртәве булырга тиеш иде, әмма барып чыкмады. Ни көлмәде, ни үпкәләмәде кыз.

— Берсекөнгә ял көне бит... Без урманга барырга торабыз, чәчәк җыярга,— диде ул, куе керфекләре арасыннан зәңгәр караш ташлап.

Рәхимҗанның моңар да исе китмәде, аңар барыбер иде. Зәңгәр

булмагае, шунда әллә нинди караш ташласын. Моның миңа ни мөнәсәбәте бар соң дигәндәй, ул тагы бер кабат кызга карап алды. Ә Фаягөлнең күзләрендә шулай да сер бар иде. Зәңгәр сер. Балкып торган йөзендәге елмаюны да нигә юрарга белмәссең.

Фаягөл башка сүз катмады. Көянтәгә эленгән пар чиләккә җәһәт кенә су алды да үз сукмагыннан юнәлде. Бераз киткәчтен, борыла төшеп, болай сүз уңаеннан гына дигән кебек, әйтеп куйды:

— Зәйнәп белән барабыз...

...Ял көне дә житте. Рәхимжанны тәрәзәдән төшкән кояш нурлары иркәләп уятты. Соңга калмагаем тагы дигәндәй сискәнеп, ул шундук сикереп торды. Өстенә жиңел куртка салып ишегалдына чыкты. Әнисе лапас каршында сыер сава иде. Җылы сөт чиләктәге күбек өстенә тигез бер ритм белән сызгырып төшә. Сөт турындагы уй аның күңеленә яңа дәрт, беләкләренә өстәмә көч китерде. Шул минутта ул үзендә жир жимерерлек, тау кубарырлык жегәр булуын тойды. Һәм кулына тимер лом алып, эх дигәнче, болдырдан капка төбенә кадәрле жирнең бозын кубарып атты. Көн жылынып китте. Кыектан яңа көннең беренче тамчылары тамды. Аяклары өй түбәсенә менә торган баскычка тартты, күзләре берөзлексез урман юлында булды. Каерылып-каерылып карады ул урман юлына, үзе күрергә теләгән ике сылу гәүдә һаман күренмәде.

Шунда ян як тәрәзә ачылып, аннан әнисенең жылы сөт эчәргә чакырган ягымлы тавышы ишетелде. Өйгә кереп, бер литрлы банкага салынган сөтне мичтән яңа чыккан ипи кыерчыгы белән ашап куйды. Ул арада аны эзләп дусты Фаяз килеп керде.

— Сине алырга килдем. Эш .бар,— диде ул коры гына. Әнисе күрмәгән арада, Рәхимжанга күз кысып, елмаерга да өлгерде. Һәм ул да түгел,— ашыгыйк, соңга калырга ярамас, малай,— дип өстәп тә куйды.

Дустының тапкырлыгына тагы бер кат сокланып куйды Рәхимжан. Чөнки аның соңгы сүзләре очраклы рәвештә туган тынлыкны юкка чыгару өчен бер хәйлә иде. Юкса, Рәхимжанның ашыкканын болай да күреп тора ич ул. Шул сүзләр тагы беразга кичеккән булса, көт тә тор, әнисе телгә киләчәк иде. «Ул ниткән эш тагы, имтиханга кайчан әзерләнерсез?» — дип аркылы төшәчәк иде. Аннары инде аңлатып кара син...

— Онытыла язган бит, малай...— дип сөйләнә-сөйләнә Рәхимжан Фаязга иярде. Кызлар белән урманга чәчәк жыярга менәм дип әйтеп булмый бит инде әни кешегә...

Урманга Жәке каенлыгына илтә торган юлдан менеп бара иде Зәйнәп белән Фаягөл. Шактый жир киткәннәр инде. Ләкин Фаяз белән Рәхимжан өчен арамыни бу — аякларын тыярлык түгел иде аларның. Үзәнлеккә житкәч, авыл кинәт күренмәс булды. Шунда кызларның үкчәләренә үк басты алар. Урманга да ерак калмаган иде инде.

— Пиип, пи-пип,— дип тавыш бирде Фаяз,— юл бирегез, тапталасыз...

— Каян килгән, каян килгән — сезгә тагы,— дип балкыды артына борылган Зәйнәп. Фаягөлнең дә челтерәп көлгән тавышы кушылды аңар.

— Әә-ә-ә, сез әле шулаймыни? — дип кабынып китте Фаяз һәм мотоцикл авазы чыгарып, янәшә атлаган кызларның уртасыннан жанфәрманга чабып үтте. Бераз киткәч кенә шып тукталып, кызларга йөз белән борылды.

Барысына да кызык иде. Иң беренче, әлбәттә, Фаяз үзе рәхәтләнеп көлде.

— Каян килгән, каян килгән — сиңа тагын мотоцикл,— дип үртәде аны Зәйнәп.

— Миңамы?..— дип, чынга алды Фаяз. Җитдиләнеп китте.

— Сиңа булмый... Әле генә «пытырдап» безне узган калай әтәч син булдың, лабаса,— дип, бәйләнүен дәвам итте Зәйнәп.

Ә Фаяз исә, торган саен, бу сөйләшүне чынга ала барды. Ул инде шаяруын да онытткан иде бугай.

— Укулар гына бетсен, күрерсез әле менә... Икенче көнне үк шәһәргә чыгып китәм. Киләсе ел Сабан туена «Ява»га утырып кайтмасам, исемем Фаяз булмасын... Кызыл «Ява»га утырган джинса чалбарлы, фирменный күлмәк кигән егет күрсәгез — ул мин булырмын... Билләһи менә, әйтте диярсез...— дип сөйләнде ул. Шул кадәр бирелеп һәм чын күңелдән сөйли ки, мөгаен, үзен шул минутта мотоциклда очып барган сыман хис итә иде ул.

Урманга да җиттеләр. Фаязның үртәлүе онытылды. Ул төрле кызык хәлләр турында сөйләде. Кызлар аның һәр сүзеннән диярлек рәхәтләнеп көлде. Кызлар көлгәч, Фаязга да рәхәт иде — атлап түгел, йөгереп йөрде ул агачлар арасыннан. Рәхимҗанның да күңеле күтәренке иде. Кардан арчылган якты аланнарга керәп, язгы урманның беренче чәчәкләрен эзләде алар. Алсу-зәңгәр муенсага охшаш чәчәкләр очрады. Кызлар аны, муенса итеп, түшләренә куеп карады, колак очына алка итеп элделәр. Әмма күңелләре һаман алгысынып торды, алар яңа аланнарны эзләделәр.

Гел уйламаганда Зәйнәпнең инеш челтерәвен хәтерләткән ягымлы тавышы ишетелде:

— Умырзая таптым, умырзая...

Бер-бер артлы Зәйнәп янына йөгерешеп килделәр. Шатлыгы күңеленә сыймый иде Зәйнәпнең. Күбәләк сыман җиңелчә җилпенеп, кулларын як-якка җәйде ул.

— Ашыкмагыз... өзмик,— диде. Яшьтәшләренә нинди дер зур сүз әйтергә җыена иде сыман ул, үзе сәер бер халәткә кергән.

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү — күрегез, күр, дүрт умырзая,— дип сокланды Фаягөл.— Әйдәгез, һәркайсыбыз күңеленнән генә үзенең иң зур теләген әйтсен... Аннан соң гына берәр чәчәк өзәргә...

Зәйнәпкә дә ошады иптәш кызының тәкъдиме.

— Иң-иң зур теләкне теләргә... Иң зурысын гына,— дип күтәреп алды ул.

Һәркайсына хуш килде бу — барысы да кабаланды, ашыкты. Ләкин, шул ук вакытта, беренче булып өзәргә уңайсызланып, кыймый да тордылар. Унҗиденче язларының беренче умырзаясына бер-бер артлы дүрт кул үрелде. Зәйнәп өзде башта — үзалдына гына нидер пышылдаган сыман итте. Аның йөзе уйчан һәм җитди иде. Фаягөл дә үз умырзаясын сайлап кулына алды һәм, гаепле кешедәй уңайсызланып, бер иптәш кызына, бер Рәхимҗанга карап куйды. Фаяз исә һич икеләнеп тормый өзде үз чәчәген. Һәм соңгы булып, узган елның көрән яфракларын аралап чыккан, әле яртылаш кына ачылырга өлгергән бердәнбер умырзаяга Рәхимҗан үрелде. Чәчәкне өзде һәм, үзе дә уйламаганда, оялудан кызарып китте ул. Әйтерсең, аның ни уйлавын, аның күңелендә ни булуын һәммәсе дә сизенә иде. Күңелендәге бердәнбер исемне умырзаяның аксыл-шәмәхә таҗларына иңдерергә теләгәндәй, озак кына текәлеп торды ул.

— Безнең әби әйтә: язның беренче умырзаясын өзгәндә күңелдә булган уй чынга аша, ди. Ләкин бер шарт бар — ул сер булып калырга тиеш...

Фаягөлнең кулындагы умырзаяны иркәли-сөя әйтелгән бу сүзләре аларны тагы бер тын ялгыз гына уйланырга, хыял канатында тибрәлеп торырга мәҗбүр итте.

— Ә ул теләк чынга ашмаса...— дип сорады Фаяз. Аның калын тавышыннан үзләре генә түгел, бөтен урман сискәнеп куйгандай булды.

— Ашмыйммы соң?.. Аша, аша!.. Һичшиксез, тормышка аша,— диде Фаягөл. Күрәмсең, үз сүзләренең дөреслегенә ул иң элек үзе ышанырга, үзен ышандырырга тели иде.

— Алэй булгач, ике айдан абзагыз әллүр... калада булачак,— дип, түземсезләнеп кычкырып җибәрде Фаяз. Ике кулын кесәсенә тыгып, шәһәр урамыннан үткән җилле егетләргә охшарга тырышып, бер-ике атлап та күрсәтте.

— Ярамый, әйтергә ярамый...— дип, кисәтергә ашыкты аны Фаягөл. Булдыра алса, шул минутта ике куллап Фаязның авызын каплар иде ул. Әйтелгән теләкләрнең сер булып калуын ул башкаларга караганда да нигәдер тырышыбрак яклый иде.

— Ә минем секрет юк... Калага дигәч, калага, нигә яшерергә аны. Үч итеп китәм, «кырга тирес чыгарырсың» дигән укытучыларга үч итеп китәм. Тиресне үзләре чыгарсын, миңа ни...— абыйларым минем рабочий класс,— дип, үзе сөйләгәннән үзе тәм табып сөйләде Фаяз, бар тавышына яңгыратты туган як урманын.

Аланнан-аланга күчеп озак йөрде алар урманда. Әмма бер чәчәк тә очратмадылар башка. Шулай да чиста көзгене хәтерләткән урман күлдәвекләреннән көнозын шат һәм бәхетле йөзләр карады. Көмеш сыман чиста кар суларында бер түгел, икешәр кояш балкыды... Авылга кайтышлый Чегән чишмәсе янында тукталып кулларындагы дүрт умырзаяны язгы ташуга агыздылар. Умырзаялар күздән югалды, үнҗиденче язда туган уй-теләк һәм хыял-омтылышлар сер булып күңелләрендә калды.



## 6

Унынчы классны тәмамлаучыларның чыгарылыш кичәсе быел Сабан туе белән бер көнгә туры килде. Мәйдан буласы урынны — Бакырчы чишмәсе тугаен — бала-чага гына түгел, авылны сагынып кайткан кунаклар да әллә ничә кат урап узган иде инде. Су буеның бу төбәге бер әүләрне якынлашып килгән бәйрәмнәре белән мавыктырса, икенчеләр анда үзләренең яшьлеген һәм тәүге мәхәббәт эзләрен барлап йөри.

Авыл читеннән аккан инешнең дугайланып, бормаланып килгән урынында ул тугай. Язгы сулар китеп, ташулар тынгач та анда яшел чирәм һәм бәбкә үләннәре күкрәп чыга. Җәйнең җәй буена үзенең шул сусыл яшел төсен югалтмый тугай. Айлар буе яңгыр яумыйча, бөтен тирә-якны киптереп, саргайтып бетергәндә дә мондагы яшел чирәм рәхәт бер салкынлык бөркеп тора. Тугайлыкның тауга житеп, үргә менә алмыйча туктап калган урынында чишмәлек бар — шуны Бакырчы чишмәсе диләр Нурлы Аланда.

Бакырчы чишмәсе, авылдагы исәпсез-хисапсыз башка чишмәләрдән аермалы буларак, тау битеннән агып чыкмый, ә җир астыннан кайнап күтәрелә. Күбекләнеп, сары ком бөртекләрен бөрөзлексез биетеп, дистәләгән нәни фонтанчыклар булып бәрә аның суы. Ләкин моны якыннан, чишмәнең читенә килеп караганда гына күрергә мөмкин. Югарыдан, тау башыннан исә, ул әкиятләрдә генә очрый торган тылсымлы көзгене хәтерләтә. Дию пәриен эзләп тулпар атта очкан Таң батыр әле генә кулыннан төшергән диярсең — күзләрне чагылдырып куя... Кунак табыны сыман иркен шул көзгедән инешкә таба күперер торган куе яшел түтәл сузылган. Бөтнек түтәле булыр ул, аның уртасыннан тавыш-тынсыз гына салкын чишмә суы ага. Бакырчы чишмәсендәгедәй бөтнек башка һичкайда юк. Сабагының биек һәм куе булуы, яфракларының эрелеге һәм калынлыгы белән хәйран калдыра ул. Ә исе... Аны Бакырчы чишмәсе тугайлыгында булган, шундагы һа-

ваны күкрәк тутырып сулаган кеше генә аңлый алыр. Бөтнек чәчәк аткан мәлдә су буеннан авылга таба җил дә исеп куйса, бөтен авылга шифалы хушбуй бөркелә. Урамнарны тутырып, ачык тәрәзәләрдән өйгә кереп, күңелне, җанны иркәли аның исе.

Бакырчы чишмәсен бик борынгы, диләр. Күп гасырлар элек монда килеп урнашкан ерак бабайлар ул урында бакыр чыгарып, комган, самавыр кебек тормыш кирәк-яраклары, савыт-саба ясаган. Нурлы Алан бакырчылары ясаган комганнар бик ерак җирләрдә мәгълүм булган. Зур ярминкәләрдә шикәр, тоз кебек кирәк-яракка алыштырып кайтканнар аларны. Шуңар Нурлы Аланлыларның комган осталары дигән даны таралган. Хәзерге чишмә урынында бакырчы алачыгы һәм тирән баз булган диләр. Җир астыннан су чыга башлагач, бакырчылар башка урын эзләп киткән. Улларына, оныкларына әнә шундый шигъри матурлыкка ия чишмә калдырган Нурлы Аланның бакыр осталары.

Нурлы Аланда комган һәм җиз самавыр осталары хәзер юк инде. Бакырчы һөнәре дә күптән онытылган авылда. Җиз самавырны дөнья бетереп эзләгәндә дә табарлык түгел. Ләкин Бакырчы чишмәсе һәм аның әйләнәсендәге яшел тугайны онытырлык түгел. Элек-электән монда яшьләр кичке уенга җыелган. Беренче танышу, бүтәннәрдән яшереп кенә кул кысышу, кара-каршы биюләр шушында башланган. Кызлар — егетләргә чигүле кулъяулык, егетләр затлы хушбуй һәм башъяулык бүләк итешкән монда. Пар чиләген асып төшкән яшь киленнәр көзге сыман су өстендә үзләренең гәүдә сылулыгын күреп куана торган булган. Печәннән кайтып килгән таза ирләр бирегә тукталып сусавын баскан. Авыл карчыклары аның әйләнә-тирәсеннән әле дә булса ел буена җитәрлек шифа — бөтнек яфраклары җыя... Инде Сабан туйлары якынлашып килгән көннәрдә аяклар берөзлексез су буена, шушы тугайга тартыла. Малайлар каешлары өзелеп беткәнче көрәшкә әзерләнә монда, йөгерешә, уйный, сикерә. Арып хәлдән тайгач, йөгереп барып чишмә суын ятып эчә, кәҗә сакалы, кукы, чыпчык кузгалагы ашый. Кызлар сөзәк тау битендә каен җиләге җыя — аларның барыр юлларына алсу нурлар булып миләүшә чәчәкләре тамган.

Ниһаять, алсуланып җәйге таң атты — Сабан туе иртәсе җитте. Таң әтәчләре тынып өлгергән идеме, юкмы — түбән оч ягында тальян тавышы яңгырады. Шуны гына көтеп торгандай, дөнья җанланды, хәрәкәт башланды. Урам яктан кемнеңдер, бәйгегә ашкынып тыпырдаган атын тыя алмыйча, «тыр-р, тыр-р-р...» дигән тавышы ишетелеп узды. Аты барыбер үзенекен итә — бер урында таптанса таптана, әмма тыпыр-тыпыр биюеннән туктамый. Сезгә бәйрәм, ә без лапаста ятарга тиешме, дигәндәй, көтүгә чыкмаган сыер мөгерәп куйды. Торырга инде күптән вакыт икәнлеген яхшы аңласа да, бәйрәмгә ашкынган авылның җанлануын ачык тәрәзә аша шулай тыңлап яту рәхәт иде Рәхимҗанга. Шушы бәйрәм шатлыклары артында ниндидер авыр моң, аерылу газаплары, югалтулар сагалап торадыр төсле тоелды. Әмма нинди моң, каян килгән газап һәм югалту — тәгаен генә үзе дә белми, аңыша алмый иде. Сикереп торуың булыр, җылы урыныңны шундук кемдер тартып алыр һәм аны башка бервакытта да кире кайтармас кебек тоела иде. Урын гына булса бер хәл, шуның белән бергә бала чагыңны, үсмер елларыңны да мәңгегә тартып алырлар күк. Бүген торырсың да, башка һичбервакыт, һичкайчан кайта алмассың ул бәхетле матур көннәреңә. Ата-ана өендә шулай борчу-хәсрәтсез яшәгән көннәреңә кайту булмас. Сагынган чакларың күп булыр — аз гына булса да суза төш үсмер чагыңның кабатланмас соңгы бу иртәсен, дип пышылдый кебек иде кемдер. Туган өйнең түшәм тактасындагы ботак эзләренә бер

карап кал ичмаса... Карап кал... Матчага кыстырылган кәгазь кисәкләрен күздән кичереп чык, әлеге саргайган кәгазь кисәкләренә бик тә карыйсың килгән чаклар булыр. Ләкин торырга вакыт, торырга. Бер түгел, ике бәйрәм көтә ич аларны бүген, ике бәйрәм!

Ә бәйрәм ул — күңелгә үз һәм якын булган җыр кебек, аның ничек узып киткәнен сизми дә каласың. Алай дисәң, җырны отып калып, каткат яңадан җырларга да мөмкин. Бәйрәмнәр кабатланмый, бүгенге бәйрәм дә кире кайтмас...

Авылның кайсыдыр ерак бер почмагында иртән яңгырап узган гармун тавышына яңалары килеп кушыла торды. Таң әтәчләре диярсең, берсеннән икенчесе уздырыбрак, берсеннән икенчесе моңлырак итеп уйный Нурлы Алан гармунчылары. Читтән килгән берәү тыңлап торса, бу авылда гармун уйный белмәгән ир-ат, гомумән, бармы икән, дип гаҗәпкә калыр иде. Нурлы Аланда гармун уйнау — үсеп егет булу дигән сүзгә тиң. Менә бүген дә иртәнге сафлыкка киереп ачылган тәрәзәләрдән нур булып акты гармун моңы. Гармунчылар берәм-берәм ишегалларына, бакчаларга чыгып уйнады. Халык көйләре, койма һәм киртәләр артында гына сыеша алмый, берәм-берәм урамнарга алып чыкты гармунчыларны. Капка төбендәге бүрәнәләргә утырып тартты алар гармуннарын. Авыл өстендә дулкын булып моң тибрәлде, моң йөзде. Шул моң Нурлы Алан кешеләренең җанына үтеп керде, иңнәренә канат булып сарылды. Һәм, моң канатларында тирбәлеп, урамнар, тыкрыклар тоташ агым булып берьюлы хәрәкәткә килде. Шулчак басу капкасыннан машина һәм атка төялешеп күрше авыллар җырлап килеп керде. Авылга кергән һәммә юлдан кунаклар агылды Нурлы Аланга. Моңлылыкта чишмәләр белән узышырга теләгәндәй, гармун тавышлары су буена агылды. Чишмәләр челтерәшүе гармунчыларның күңеленә тагын да дәрт-өстәп җибәрде, яшел тугай, аллы-гөлле бизәкләргә төренеп, торган саен җанлана барды.

Мәйданга беренче булып Нурлы Аланның дүрт-биш яшьлек батырлары чыкты. Җитен сакаллы Сөләйман карт кендек буе көрәшчеләрнең кулларына ап-ак сөлгеләр тоттырды һәм, авыз эченнән генә, «Бисмилла рахман ирахим, хәвеф-хәтәрсез, имин уза күрсен Сабан туебыз...» — дип кабатлады. Яшь әтәчләр кебек ярсып тотынды нәни көрәшчеләр. Сөлгегә куллары тигәч, аларны инде бер-береннән Сөләйман карт кына түгел, әллә кемнәрең дә аерырлык түгел иде. Әүмәкләшеп йомшак чирәмгә егылдылар. Өстә калганы «чертләтеп» бер читкә төкереп алды да, кулларын биленә куеп, авызын ерып җибәрде. Аста калганы да шундук сикереп торды — күзләрендә яшь бөртеге, кулындагы сөлге белән һич кенә дә аерылышасы килми үзенең.

— Аяк чалды, аяк чалды бит ул, Сөләйман бабай,— дип, картның күзләренә текәлде. Егылуы белән килешәсе килми, көрәшергә атлыгып тора.

Билгеле инде, Сөләйман карт — өлкән кеше, хәйлә һәм алдау белән көрәшергә ирек бирмәс ул.

— Җә, тагы бер алышып карагыз әле алай булгач, аяк чалышмый гына түлке. Чү-чү, ашыкмагыз!..

Тегеләр картның сүзләрен ишетүдән узган, яңадан бер-берсенә очып кундылар...

Икенче бер читтә гармун тартып җибәрделәр, кызлар тыйнак кына «Саубуллашу вальсы»н җырлый башлады:

Ак алъяпкычларда ак канат,
Күңел оча, гүя акчарлак.
Ак канат иңнәрдә,
Җилферди җилләрдә,
Күңел оча ерак җирләргә.

Тора-бара җырга егетләр дә кушылды. Аларның тамак төбеннән чыккан калын тавышыннан көйнең төзеклеге бераз югала төшсә дә, хисләр төенләнеше һәм табигый моң көчәйгәннән-көчәя генә барды. Тегендә-монда шыгырдашкан гармун тавышлары берьюлы тынып калды. Мәйданга да ишетелә иде җыр тавышы. Аның әйләнә-тирәсендәге шау-шу, чыш-пыш басыла төште. Чыгарылыш класс укучылары тавышы бер дулкын сыман агып килде һәм мәйдан өстендә байтак кына тибрәлеп, эленеп торды. Ак тәкәнең язмышын хәл итә алмый хәлдән тайган ике батыр, билләрен турайтып, бер-бер артлы җыр килгән якка борылдылар. Аксакаллар янәшәсендә утырган Төхфәт карт та, маңгаена кулын куеп, үрелеп-үрелеп карады җыр авазы килгән якка. Ә батырлар сөлгеләрен урап тоткан килеш арлы-бирле йөренделәр, хәл җыйдылар. Әледән-әле каш астыннан бер-беренә сынаулы караш ташлап ала иде үзләре.

Бер көчәеп, яңадан тына, салмаклана төшеп яңгырый иде җыр тавышы. Әмма моң, артканнан арта барып, Бакырчы чишмәсе тугаен тулысынча урап алган, алай гына да түгел, бөтен су буена таралып, чиксез ераклыкларга барып тоташкан иде инде. Ул берөзлексез шулай яңгырап торыр, тынмас, аның агышын бар табигать тыңлап туймас сыман тоелды ул мизгелдә. Ләкин шунда, хисләр, кичерешләр иң югаргы ноктасына менеп җитте дигәндә генә, җыр кинәт туктап калды.

...Хыяллар — ак җилкән,
Кузгалырбыз иртән.
Ерак юлга чыгар чак җиткән.

Сүзләр кинәт өзелеп калды. Җыр туктады... Әмма су буен тутырып, тугай өстендә эленеп торган моң тынмады, дәвам итте. Дистәләгән чишмәләрнең челтерәү авазлары кушылды аңарга, тирә-юньгә бөтнек исе таратып исеп куйган кыска җил дә күтәреп алды ул моңны. Хәтта бар дөньяны яңгыратып кешнәгән ат тавышы да шул моң булып сискәндерде.

Көрәш карап утырган Төхфәт картның янәшәсендәге кордашы сукранып куйды: «Фчүтеки үзләренекен итәләр бит, ә? Ерак юлга чыгар чак җиткән» диләр бит, ә?..»

Төхфәт картның да күңеле тулган иде. Кара-кучкыл тоскә кергән зур куллары белән тагы беркат чәчләрен сыпырып алды ул. «Ни теләсәң, шул бар бит хәзерге авылда. Эше дисәң — эше. Ашы дисәң — ашы. Ял итим дисәң — ялы. Ә аларга, имеш, шәһәр кирәк. Авыл дигәнең карт-коры һәм грамыт чамалы булганнар өчен генә булып чыга микәнни инде?.. Дөрес түгел бу! Юк, болай була алмый! Болай дәвам итә алмый!.. Ул үзе дә яшь чагында аз йөрмәде, билгеле. Тик аларны нужа куа, нужа йөртә иде. Ә боларга ни җитми соң? Боларга ни җитми? Нинди дер хата бар монда — кайчан һәм кем җибәргән аны?.. Авыл, кырлар, шушындый су буйлары кемгә калыр? Сез шәһәр тулай торакларында җыелып ятсагыз, кем ашатыр, кем туендырыр үзегезне?.. Кем авылда яңа йортлар салыр? Кем туй итәр? Кем башка чыгар — әллә бу сүз бөтенләй онытылырмы? Кем бала табыр? Әти-әниләрегезне кем кайгыртыр? Кем аларны соңгы юлга озатыр? Кем... Кем... Кем...»

Үз уйларында үзе чуалып бетте Төхфәт карт. Кинәт аның күз алды караңгыланып китте, куллары белән ике чигәсенә ябышты ул. Күкрәгендә чәнчеп-чәнчеп йөрәк тибә, йөрәк тыпырчына. Ә колак төбендә һаман сорау артыннан сорау яңгырап тора: «Кем?.. Кем?..» Шул сорауларның берсенә, хет берсенә җавап бирә алса икән...

## 7

Нурлы Алан чишмәләре ятим калды. Урта белем алган авыл яшьләре август җитәр-җитмәс шәһәр юлына агыла башлады. Хәстәрләп,

зур өметләр белән, уңыш һәм бәхетләр теләп озатты ата-ана калаг укырга киткән улларын-кызларын. Бакырчы чишмәсе тугаенда узган кичке уеннар гармунчысыз, җырчысыз калды. Парлап бисе килгән егетләргә китереп басар кызлар табылмады. Егетләрен калага озаткан чибәрләр бер җаннарын кая куярга белми иза чикте. Арыш суктырырга чыккан комбайнчылар ярдәмчесез калды, печәнчеләр сафы сирәгәйде, җәйләүләрдә уен-көлке авазлары басыла төште.

Авыл читендәге олы юл чатында гына ыгы-зыгы һәм хәрәкәт артканнан арта барды. Урам һәм тыкрыклардан яшьләр, үсмерләр берөзлексез шунда агылды. Бу галәмәтне читтән, югарыдан, әйтик космик биеклектән берәү карап, өйрәнеп торса, валлаһидыр менә, үз күзләренә үзе ышанмас иде — дистәләгән кан юлларыннан тәндә калган сәламәт канның соңгы тамчыларын сыгып чыгаралармыни — берөзлексез агыла да агыла яшьләр. Агыла да агыла... Ә туган авыл кала. Атаана кала. Һәммәсенә канат биргән җылы нигез кала. Басуларда, тулган башларын түбән иеп, арыш, бодай башаклары моңсуланып кала. Савылмаган сыер, чабылмаган печән... Бакчаларда өлгергән карлыган, мәмрәп пешкән чия, тау битендә җир җиләге, болыннарда чәчәк — бары да кала...

Авыл яшьләренең җанын, хыялын тартып торганы — кала! Юлдан узып киткән һәр машинага кул күтәреп алар «тавыш» бирә. Ә машиналарның күбесе туктамый, әйтерсең, язмыш үзе, тагын бер уйлар өчен, аларга күпмедер вакыт чыгарырга тели.

Асфальт кызганнан кыза барды. Кояш төшлеккә күтәрелеп җиткәндә ул тәмам кызган таба хәленә килде. Үзләреннән кайнар җил калдырып берөзлексез машиналар үтә торды. Инде күпме вакыт ачык һавада, кояш астында торган Рәхимҗанның тамагы кипте. Ул әледәнәле каерылып авыл ягына карангалый башлады, чоланда калган катыклы салкын су исенә төшеп берөзлексез тамак төбен, иреннәрен кытыклап торды. Юлга терәлеп диярлек торган бәрәңге бакчаларының куе яшел төсеннән күңеленә җиләслек, саф рәхәтлек бөркелгәндәй булды. Күңелгә, җанга бөркелде бөркелүен, әмма сусауны басмады. Аяклары, ирексездән, юлдан ерак түгел генә коры елга куентыгыннан агып чыккан Изгеләр чишмәсенә алып китте.

Чишмә яны тып-тын, анда һичкем юк иде. Башта, түбәнгәрәк төшеп, битен-кулын юды, аннан, күлмәген салып бер читкә куйгач, муенына, күкрәкләренә тидерде салкын суны. Шундук тәненә көч, җанына рәхәтлек кайтты. Чишмәнең кайнап чыккан җирендәге тигез ак таш өстенә кемдер матур бизәкләр төшерелгән ак фарфор касә куйган. Монда һәрчак шулай ниндидер савыт була. Элек-электән авыл карчыклары бер дә савытсыз тотмый Изгеләр чишмәсен. Юлдан үткән кеше монда туктап хәл ала, чишмә суы белән сыйланып уза — изгелек тамчыларын татый.

Нәкъ шул вакыт, юлдан узып барган бер автобус, тизлеген киметә төшеп, коры елгага таба борылды. Аның артыннан «Жигули» һәм тагын бер автобус иярде. Машиналар, елга читенә килеп җиткәч, бер-бер артлы туктап калдылар. Ерак юл килеп әлсерәгән яшьләр барысы да чишмәгә ашыкты. Ашыга-кабалана чират торып касәдән су эчтеләр — шау-шу, уен-көлке башланды. Чишмә әйләнәсе җанланып китте. Гитара тавышы, шыңшып җырлау авазлары яңгырады. Консерва банкалары, аннары бер-бер артлы шартлап шәраб шешәләре ачылды. Изгеләр чишмәсендә бигүк изге булмаган сүзләр дә ишетелгәли башлады. Бушап калган шешәләр, консерва банкалары, газета кисәкләре кайда эләкте шунда тәгәрәде, оча торды. «Жигули» хуҗасы, машинасын чишмә янына ук төшереп, мазутлы иске чиләк белән су чумырып алды һәм машинасын юарга кереште. Чишмә суында калай банкалар йөзде, бензин һәм май таплары зәңгәрләнеп акты.

Бер читтә югалып, хәйран калып торган Рәхимҗанны, әйтерсең, күрүче-искәрүче дә юк иде. Өнме бу, әллә чынлап та төш кенәме? Артык түзә алмады ул, кулындагы майлы чүпрәкне чишмә янында сыгып маташкан җиңел машина хуҗасына таба йөгерде.

— Кемнәр сез? Нишлисез!? Хәзер үк туктатыгыз, китеп югалыгыз,— дип кычкырды ул бөтен көчен җыеп.

— Ә син үзең кем? — дип сорады машина хуҗасы тыныч кына. Башкалар исә аны бөтенләй ишетмәделәр дә.

— Мин шушы авылныкы...

— Бик әйбәт. Нишләп йөрү инде, кая барыш?

Шундый тыныч һәм ипле итеп сөйләшкән ир уртасы кешегә ул инде тавыш күтәрә алмады. Әмма ярсуы да басылырлык түгел иде.

— Шәһәргә китеп бару, укырга керергә,— диде Рәхимҗан.

— Ә безнең авылга кайтыш, энекәш, уңыш җыюда ярдәмгә! Сезнең авылга! — диде машина хуҗасы, һәр сүзенә басым ясап һәм мәгънә өстәргә теләп. Мыскыл итә идеме ул, чынлап сөйләшә идеме — аңламассың...

...Нурлы аланлылар арасында уку йортларына керүчеләр тагы да күбрәк иде быел. Институтка булмаса, техникумга керделәр. Алай да барып чыкмаса, югары квалификацияле игенче яисә терлекче исеменә лаек егетләр-кызлар завод-фабрикаларга өйрәнчек булып урнаштылар. Бер җыенып чыгып киткәч, кире авылга әйләнеп кайтуы әллә ничек, уңайсыз тоела.

Рәхимҗан авиация институтын сайлаган иде. Трактор һәм комбайнны соңгы шөребенәчә белгән Нурлы Алан егете очу аппаратларын өйрәнергә кереште. Урынны тулай торакның тугызынчы катыннан бирделәр. Бүлмәдә үзе кебек үк авыл малайлары, әмма бераз тәҗрибәлерәкләр — югары курслар.

Көн аралаш дип әйтерлек, кичләрен Зәйнәп белән очраштылар. Кыз шәһәрнең икенче очында торучы апаларында яши иде. Ул элек тә җәй саен аларга кунакка килә торган булган. Зәйнәпнең белмәгәне юк — шәһәрнең тарихи урыннары, истәлекле йортлары белән таныштырды ул аны. Зәйнәп белән шулай икәүдән-икәү генә җитәкләшеп йөрү Рәхимҗанга бик тә рәхәт тоелды. Күбәләк кар явып торган айлы кичтә Зәйнәп белән бергә кышкы чана юлыннан кайтуларын әледән-әле искә төшерде ул. Теге чакта Чегән чишмәсенә салынган сукмактан суга йөрүче нигә Зәйнәп булмады икән, дип борчылды. Урманда язның беренче умырзаясын өзгәндә Зәйнәп нинди теләк теләде икән дип баш ватты...

— Менә бу «Акчарлак» рестораны,— дип бүлдерде кыз аның уйларын.

Үз истәлекләреннән аерылырга өлгермәгән егет «ә-ә...» дип сузды. Ул ресторанның ни өчен шулай аталу хикмәтен белергә теләгәндәй, як-ягына каранып алды. Якын тирәдә дулкынланып торган зур су һәм аның өстендә уйнап очкан акчарлаклар күрергә тели идеме ул...

— Як-ягыңа алай каранма, авылныкы икәнеңне белерләр,— дип кисәтте Зәйнәп.

Як-ягына башка каранмады ул, башын туры тотып кына барды. «Белсәләр ни була?» Әмма күңеленә килгән сорауны бирә алмый калды. Атлаган саен биек үкчәләре белән әллә асфальтка, әллә аның йөрәгенә шак-шок басып барган Зәйнәп шәһәр белән таныштыруын дәвам итте:

— Шәһәрдә иң яхшы варьете шушында инде.

Варьетеның нәрсә белән ашый торган әйбер булуын белмәсә дә, Рәхимҗан тагы башын гына какты. Вареньега охшаш нәрсәме ул,

дип сорамакчы иде дә, җөрьәт итмәде, үзенең наданлыгын күрсәтүдән куркып, сүзне тизрәк икенчегә борды.

— Әнә теге ике катлы пыяла йортта нәрсә? — дип сорады, зур кызыксынучанлык күрсәтеп.

Зәйнәп, яңагына килеп кунган кигәвенгә селтәндемени, егетнең күтәрелгән кулын җәһәт кенә тартып төшерде. Муенын туры тоткан килеш, кеше-кара күрмәдеме дигәндәй, ялт-йолт як-ягына күз салып алды үзе.

— Бармак белән төртеп күрсәтү авыл гадәте, мин барында бүтән кабатлыйсы булма,— диде Зәйнәп кырыс тавыш белән. Ләкин күпме генә кырыс булмасын, егет өчен иң-иң кадерле һәм үз тавыш иде бу.

Аны кызыксындырган пыяла йорт «Сыраханә» икән. Өстә кызыл зал — өч тәңкә түләп керәсең, аста яшел зал — анда шул ук сыраны тәңкә ярымга аласың икән. Нигә кызылында ике мәртәбә кыйммәтрәк икәнен сорарга кыймады Рәхимҗан. Зәйнәп аңар шәһәр яшьләре ял итә торган башка урыннар турында сөйләп китте...

Рәхимҗан өчен бик бәхетле көннәр иде бу. Зәйнәп янынннан ул соң гына, урамнар буйлап йөри-йөри аяклары тәмам талып беткәч кенә кайта иде.

— Вәт, молодой, йөреп тә күрсәтәсең үзең,— дип гаҗәпләнде бүлмәдәшләре.

— Юк ла, мин классташ кыз белән генә идем бит...— дип аклана аякларын бөкләп караватка менеп утырырга өлгергән Рәхимҗан.

— Чибәрме соң үзе?..

— Матур.

— Исеме ничек?

— Зәйнәп.

— Безгә кайчан күрсәтәсең соң үзен?

— Белмим...

— Күптән йөрисезме?

— Күптән дип, әле безнең рәтләп йөргән дә юк. Болай, очрашабыз гына бит без.

— Вәт, молодой! — дип, гаҗәпләнүен белдерә арадан берсе, кара сакал җибәргәне.— Болай гына, имеш... Болайның тегеләйдән аермасы юк инде аның хәзер.

— Без бит дуслар гына,— дип, утырган җиреннән аңарга таба борыла төшә Рәхимҗан, кулындагы катык шешәсен болгата-болгата.

— Кызлар янына баргач тик торып булмый,— дип серле елмая сакалбай.— Бер-бер артлы барысына да чират җитә ул.

Рәхимҗанның кәеф китә, билгеле. Үзенең аңлата алмавына, ә бүлмәдәшләренең аңларга теләмәвенә кәефсезләнә ул.

— Без бит аның белән болай гына, дусларча, авылдашлар итеп кенә, шәһәр карап кына йөрибез...

— Менә сиңа мә...— дип, мәгънәле генә кеткелдәп куя икенче бүлмәдәше, аякларын күтәргән килеш караватында фильтрлы сигарет суырып ятканы.— Дусларча гына очрашабыз, авылдаш итеп кенә үбешәбез, кочышуны исәпкә дә алган юк... Кальцийларның калие и так далее... була инде ул. Ха-ха-ха-ха....

Сакалбай да авызын ера, аңа да кызык булып китә.

— Вәт, молодой!..

— Ярар инде, калдырыгыз берлеккә, тимәгез егеткә,— дип, өстәл артында проект сызып утырган дүртенчесе кушыла.

— Бетте, бетте...— дип килешүен белдерә сакалбай һәм кулына китап ала да актарына-актарына үзалдына сөйләнгәндәй генә мыгырданып өстәп куя: — Дон-Жуан булып чыктың әле син, молодой...

Бүлмәдә берәзга тынлык урнашып ала. Ләкин күпкә түгел. Калач

белән зур шешәле катыкны ашап бетергәнен көтеп кенә торган диярсең, сигарет пыскытучысы тагын телгә килә:

— Дөрес, молодой, яшь чакта — дәрт бар чакта, ут уйнатырга кирәк кызлар белән. Ут! — Ул тавышын күтәргәннән күтәрә барып, үз сүзләренең ялкынына үзе үк түзә алмагандай, сикереп үк торды.— Ут уйнатырга кирәк! Молодец! Түлке җебеп торма! Җебеп калсаң, йомшаклык күрсәтсәң — беттең!..— үзен тыңлыйлармы-юкмы, анысы әллә ни кызыксындырмый да иде ахыры. Карашын бер ноктага төбәп, шул юнәлешкә бөҗра-бөҗра төтен өреп, зур гыйлем ияседәй, һәр сүзенә басым ясап һәм аерым мәгънә бирергә тырышып сөйләвен белде ул.— Иң әһәмиятлесе — тезгенне үз кулыңда тотарга, тезгенне ычкындыру ярамый... Юкса, ерак китә алмассың. Уйларга вакыт, каприз күрсәтергә җай калдырмаска кирәк кызларга. Кулларың ут уйнатсын, кул кесәдә йөрү өчен түгел — монысын да киртеп куй хәтереңә. Сиңа моны мин әйтәм, молодой! Беренче көнне үк кочакларга һәм үбәргә, икенче көнне — кул күшекте дигән булып, җылы урын эзләргә. Алга таба нишләргә икәнен үзең чамаларсың — анысы иҗат эше. Хе-хе, хе-хе... Вәт тәк, молодой, минем сүздә торсаң, ак сакаллы карт булырсың. Кем дисең әле кызыңны?.. Ә-ә, Зәйнәп бит әле, Зәйнәп... Онытма, минем киңәшне тотсаң, син аның артыннан түгел, Зәйнәп синең арттан йөгереп йөри башлар...

Акыл өйрәтүләр еш кабатланып торды аларның бүлмәсендә. Яшәргә, студент һәм егет булырга өйрәттеләр. «Юкса,— диделәр, сызым өстәленә күрсәтеп,— әнә шунда утырып биш ел гомереңне узып киткәнне сизми дә калырсың».

Аларның һәр әиткәне күңелдән, хәтердән китми азаплый иде. Әллә дөрескә чыга инде болар әйткән, дип, Рәхимҗанның вакыт-вакыт икеләнеп калган чаклары да булгалады. Зәйнәп көннән-көн үзгәрә, егеткә һаман да югарыданрак торып карый төсле иде. Ләкин Рәхимҗан шиккә төренгән, андый ямьсез уйларын тизрәк куарга керешә, Зәйнәп хакында шулай уйларга җөрьәт итүе өчен үз-үзен тиргәп, битәрләп ташлый. Зәйнәп бит бер генә, ул башкалар төсле түгел. Зәйнәп булмаса, ул бу шәһәрдә бөтенләй яши дә алмаган булыр иде. Алай гынамы икән, дөньяда яшәүнең яме дә булмас иде кебек Зәйнәпсез. Ярый әле Зәйнәп бар бу якты һәм искиткеч матур дөньяда!

Әнә, бүген дә таш урамнар буйлап, светофор утына туктап калган тиз йөрешле машиналарны узып университет ягына кем йөгерә дисез? Ул — Рәхимҗан! Бу сәгатьтә дөп-дөп итеп кем йөрәге тибә дисез? Аныкы — Рәхимҗанныкы! Кулына чәчәк тотып, кая йөгерә, кая ашыга икән бу егет дисезме? Зәйнәп янына!.. Аны бу шәһәрдә, юк-юк, бу шәһәрдә генә түгел, бөтен җир йөзендә иң-иң, иң-иң... булган, гүзәл кыз Зәйнәп көтә.

Дөрес, чәчәк кибетендә розаларга чират торып, егет беразга кичекте кичегүен. Шулай да зыян юк, аның кулындагы чәчәкләрне күргәч, куанычыннан ни дияргә дә белмәс Зәйнәп. Чөнки ул аңарга иң-иң матур чәчәкләрне алып килә... Әнә сәгатенә карый-карый басып торган кыз кемне көтә дисез? Аны — Рәхимҗанны! Озаграк көттерде бугай шул... Шундый сылу кызны болай көттерергә ярыймыни инде... Кулындагы чәчәкләрен аркасына яшереп, кызга якынлашты ул. Чәчәкләрне сузып, көтмәгәндә-уйламаганда шатландырасы килә аның Зәйнәпне. Шунда әллә каян гына күкрәгенә язгы ташу кебек ярсу бер дәрт килеп керде. Дулкын булып үз канатларына суырып алды әлеге дәрт, очындырып, тибрәндереп куйды. Һәм бөтенләй үзе дә уйламаган җирдән күңеленә җыр килде. Күңеленә килгән шатлык шундук телен тибрәндерде:

Бакчадагы гөлләремнең
Тамырлары бер генә шул, Зәйнәбем.
Ал Зәйнәбем, гөл...

Ялт-йолт тирә ягына караный алган кыз егетнең бу кыланышыннан светофор утыдай кызарып чыкты.

— Тукта!..— диде ул, «Зәйнәбем...» дип әйтергә җыенган авызны иске бияләй белән каплагандай, нык ачуланып.— Шул җыр гына җитмәгән... Син нәрсә, бабаң бригада җыелышына килгәндәй соңарып йөрисең?..

Әйе, Зәйнәп тавышы иде бу. Егетнең муенына чүмеч тутырып салкын су койдылар диярсең! Аңыша алмый торды ул бер тын, кадакка эләгеп тишелгән туп хәлендә калды — күңелгә килгән дәрт һәм моңның тамчысы да калмады, күз алдында бушый барды ул. Колагы чыңлап торды, әйтерсең, тишелгән тупның һавасы шулай сызгырып чыга... Соңга калуы да хак, җыры да урынсызрактыр. Тик бер нәрсәгә күңеле кителде аның: нигә «бригада җыелыш»ын һәм аның бабасын шулай искә алды соң әле кыз? Аның бабасымы соңга калып йөри торган кеше?.. Колагы ишетсә дә, күңеле ышанмады Рәхимҗанның, Зәйнәп алай димәс! Юк, алай димәс Зәйнәп! Дисә дә, аңлашылмаучанлык кына бу. Бәлки, шаяруы гына булгандыр әле... Елмаерга тырышты егет һәм аркасына яшерелгән чәчәкләрен чыгарып кызга сузды.

— Зәйнәп, бу чәчәкләр сиңа...

Көттерә төшеп кенә чәчәкләрне кулына алды кыз. Егет өчен исә әлеге көттерү чиксезлек сыман озын һәм озак тоелды. Әлләниләр уйлый башлаган иде инде, ярый әле бары да яхшы булып бетте. Розаларның үзеннән дә алсурак булып янган иреннәренә чәчәк бәйләмен китерде. Иреннәре генә түгел, аның күзләре дә кинәт нур чәчеп балкыр, яктырып китәрләр төсле тоелды.

— Ә нигә дүртәү?

Бу сүзләрне ишеткәч, Рәхимҗан берни аңламады, киресенчә, гаҗәпләнде, бөтенләй коелып төште. Дүрт чәчәк аз буламы икәнни?.. Белгән булса, күбрәк алыр иде... Ни дип җавап бирергә дә белмәде ул. Зәйнәпкә исә егетнең уңайсызланып, шулай чарасыз калып торуы кызык тоелды, урнашып алган тынлыкны ул бик теләп һәм махсус суза төште.

— Беләсең килсә,— диде ул,— кызларга я өч, я биш чәчәк бүләк итәләр. Чәчәк һәрчак так санда булырга тиеш.

— Ә-ә-ә,— дип, баш какты егет. Аның башка чарасы юк иде. Һәм хәтеренә төшерде: чәчәк кибетендәге сатучы да өч чәчәк төреп биргән иде. Дүртенчесен, әнә теге ап-агын, ул бит үзе яңадан сайлап алды. Зәйнәпкә шунысы аеруча охшар, дип өстәгән иде ул аны. Менә ничек икән...

— Шулай да рәхмәт, мин розаларны яратам,— дип, кыз тагын чәчәкләрне янып торган иреннәренә тидереп алды.— Тик менә дүртәү булгач, тотып йөрү генә уңайсыз булыр инде. Мә, монысы сиңа булсын,— дия-дия теге ак розаны җәһәт кенә егетнең үзенә тоттырды.

Алар шулай, кулларына чәчәк тоткан килеш, тын-матур урамнар буйлап янәшә атлап киттеләр, тора-бара кулга кул үрелде, җитәкләштеләр.

Як-якта зәңгәр таң булып неон утлар кабынды. Алар атлыйсы юлга алтын-сары юка яфраклары коелды. Табигать алтын-сары бишектә тибрәнә иде. Зәйнәп, гадәтенчә, урамнар, истәлекле йортлар белән таныштырып барды, шундый зур һәм борынгы шәһәрдә яшәүнең рәхәтлекләренә сокланып сөйләде. Рәхимҗан әле һаман үзен борчыган сорауга җавап таба алмый интегә иде: нигә якын кешеңә бүләккә өч чәчәк ярарга тиеш тә, ә дүрт чәчәк ярамаска тиеш? Кем уйлап чыгарган моны, чәчәкләр нигә дип так санда гына булырга тиешле? Табигать бит һәр очракта пропорцияне, парлы булганны ярата... Кеше дә үзенә тиң пары булганда гына бәхетле, һәммә тереклек тә... Ә нигә чәчәкләргә ярамый парлы булу? Күпме генә баш ватмасын, күңелен

юатырлык җавап барыбер табылмады. Зәйнәптән сорарга уңайсызланды... Шәһәр кешеләре эшсезлектән уйлап чыгарган бер нәрсәдер әле, дип нәтиҗә ясаудан башка чарасы юк иде аның. Авыл кешесенең чәчәкне санап җыйганын кемнең күргәне бар? Болын чәчәкләренең иң матурларын бер бәйләм итеп туплыйлар да, җан теләгән кешеңә бүләк итәләр. Урман һәм болын чәчәкләрен бераүнең дә, тукта, ничәү икән монда, дип санап маташканы юктыр.

Шулай да матур иде, серле иде көзге бу кич. Шуңадыр, алар вакытның ничек узганын да сизмәделәр, гадәттәгедән озаграк йөрделәр бу кичне. Зәйнәпнең апалары янына җиткәч тә әле берничә кат йорт тирәсен әйләнеп чыктылар. Урамнар буйлап шулай икәүдән-икәү генә җитәкләшеп йөрү Зәйнәпкә дә ошый иде бугай. Ишек төбенә җиткәч тә ашыкмады алар, озак кына бер-беренә карашып тордылар. Бер сәбәпсезгә дә шаярасы килеп торды Зәйнәпнең, ул берөзлексез чаяланып көлде, күзләрен зур ачып егеткә карап торды, алсу иреннәрен бүлтәйтеп елмайды, иреннәрен тешли-тешли елмайды. Аның бит алмалары алсуланганнан алсулана барды, көлгән чакта ирен читләре тартышып-тартышып алды. Рәхимҗан бәхетле иде шул мизгелдә, ишеккә сөялеп торган Зәйнәпнең күзләрендә чагылып уйнаган ай нурларына карап сокланды.

— Зәйнәп...— диде ул, кайнар сулышын тыярга тырышып.

Кыз, үзе дә белешмичә, аңарга тартылып куйды, шомырт кара күзләр дугайланып килгән озын керфекләр артында качыш уйнап алды.

— Әйе, Рәхимҗан... Без монда икәү генә...

Мондый ягымлы тавыш бары тик Зәйнәптә генә. Егет берни дәшә алмый торды, ни дияргә дә белмәде. Кызның толым булып сузылган чәчләреннән, бит очларыннан сыйпап аласы килде аның шунда, ләкин үпкәләтүдән курыкты — тыелып калды. Инде ничәнче кат күзе Зәйнәпнең яңа бөредән чыккан яфрак сыман чагылып-чагылып алган иреннәренә төште. Бөтен җаны-тәне белән кызга табан омтылды егет. Әмма шундук үзендә көч тапты, бүлмәдәш егетләр коткысына бирелү булып чыкмасын дип, бөтен ашкынуларын тыярлык өстәмә көч тапты.

— Әү, Рәхимҗан...— дип кабатлады кыз, башын ия төшеп. Ирексездән кулларын егеткә таба сузды. Алар кайнар иде, шундук өтеп алдылар.

— Синнән бер нәрсә сорыйсым килә иде...

— Я, сора, без монда икәү генә — син дә мин генә.— Зәйнәп үз сүзләре белән, аны гына түгел, үзен дә иркәләгән сыман, күзләрен ярым йома төшеп пышылдый иде.— Без икәү генә, Рәхимҗан, син дә мин генә.

— Тик бер шарт белән, дөрес җавап бир, ярыймы, Зәйнәп.

— Я, Рәхимҗан,— дип, сузып, ягымлы пышылдавында булды кыз,— ул нинди сорау тагы, я, әйт... әйт инде...

— Дөресен генә әйтерсең... әйтергә ярамаса, бөтенләй эндәшмәссең, ярыймы, Зәйнәп...

— Мин ялганлый белмим, Рәхимҗан. Соравыңны әйт.

— Урманга умырзаяга менгән көнне хәтерлисеңме?

— Шуннан...— кызның тавышы кинәт кырыслана төште, үзгәреп китте. Мондый сорауны көтмәгән иде ахрысы ул.

— Син дүрт умырзая тапкан идең... Дүртебезгә дүрт чәчәк өзеп, без иң зур теләкләребезне юрарга сүз куешкан идек, хәтерлисеңме?

— Хәтерләмәскә... хәтерлим.

— Сер булмаса, әйт әле, Зәйнәп, язның беренче умырзаясын өзгәндә, син нинди теләк теләгән идең?

— Сер дип, нәрсәсе сер булсын инде аның хәзер, иң зур теләгем чынга ашты ич инде — укырга кердем.— Ул канәгатьлек белән елмая төште әлеге сүзләрен әйткәндә. Күпме генә якты булмасын, сизелер-сизелмәс кенә салкынлык та бар иде кебек ул елмаюда.

Шунда югары катларның берсенчән Зәйнәпне чакырган тавыш ишетелде.

— Хуш...— диде кыз һәм егеткә артык берни әйтми, капылт кына борылды да баскычтан менеп йөгерде.

Кулындагы ялгыз ак розаны ни эшләтергә белми бөтерә-бөтерә, Рәхимҗан урыныннан кузгала алмый торды. Зәйнәп кире борылыр, я булмаса этажлар арасындагы ачык тәрәзәләрнең берәрсеннән башын тыгып нидер әйтер, кул болгар дип көтте ул. Кызның аяк тавышлары тынган иде инде. Салмак адымнар белән трамвай тукталышына табан юнәлде Рәхимҗан.

8

Студент тормышына ияләшә алмый газапланды ул. Нурлы Аланны сагынды. Күңеленә үз һәм якын булган авылдашларын, су буйларын, тугайларны, басу һәм урманнарны юксынды. Нурлы Алан чишмәләренең челтерәве, арандагы тайлар кешнәве төшләренә кереп йөдәтә иде. Зәйнәпне дә шул чишмәләр, шул табигать кочагында итеп күз алдына китерде ул. Хыялында йөрткән, аны берөзлексез үзенә тартып торган Зәйнәп әле хәзер дә Нурлы Аланның су буенда яисә урман аланнарында йөридер, аның тизрәк кайтуын көтәдер сыман тоела иде аңарга. Нурлы Алан урманындагы беренче умырзаяны сагынды ул һаман...

Көннәрдән бер көнне институт каршында һич уйламаганда ул Фаягөл белән очрашты. Бит алмаларына хәтле көләп торган, һәр сүзе, килеш-килбәтеннән үк ягымлылык бөркелеп торган авылдашы Фаягөл иде бу.

— Бәй, Рәхимҗан, син түгелме?.. Ашыгып баруым иде, күрми кала язганмын,— дип гаҗәпләнгән булды кыз. Ә үзе инде ничә көннәр аны очрату уе белән йөри иде.

— Фаягөл... Син дә мондамыни, Фаягөл?

— Әйе, «Спартак»ка урнаштым. Кичләрен хәзерлек курсларына йөрим. Бер балл аркасында калдым...

— Авылны сагынмыйсыңмы?

— Сагынудан ни файда. Яшьтәшләрең таралып беткәч...

Бу очрашуга алар икесе дә шат бугай. Авыл хәлләрен сораштылар, классташлары турында сөйләштеләр. Фаягөл әле бу ялда гына авылда булып килгән икән, шуңа күбрәк ул сөйләде. Һәм шулай гәпләшеп барган җирдән, кинәт нәрсәдер искә төшереп, җитдиләнеп калды ул. Сынагандай Рәхимҗанга карангалый башлады.

— Ишеткәнсеңдер ич...— диде ул, шул карашларның берсендә туктала төшеп,— анда исерек Гимай синең бабаңны таптаткан.

— Нәрсә?!.— дип кычкырып җибәрде Рәхимҗан үз-үзен белешмичә. Көтелмәгән бу хәбәрдән аның ике чигәсенә берьюлы ике яшен ташы китереп суккандай булды.— Кемне, минем бабайнымы?..

— Бәй, беләсең дип уйлаган идем бит мин, әйтмәгән булыр идем... Ул тикле борчылма, ул бит исән, район больницасына илткәннәр аны.— Акланырга теләгәндәй кабаланып, үз-үзен битәрләп сөйләде Фаягөл. Авыр хәбәрне шулай капылт кына әйтеп ташлыйлармы инде, их мин — юләр, дип тирги сыман иде ул үзен.

Рәхимҗан кискен бер нәтиҗәгә килеп, Фаягөл белән саубуллашырга ашыкты. Хәтта кызның: «Рәхимҗан, туктале...» — дип әйтергә теләгән сүзен дә тыңлап бетермәде.

Тулай торакка кайтып өстен-башын алыштыргач та тизрәк чыгып китәргә ашыкты. Түр почмактагы өстәлгә сеңә-сеңә сызым сызып

утырган бүлмәдәшенең үз эше эш иде, аңарга игътибар да итмәде. Әмма караватта кырын яткан сакалбай сүзсез каламы соң! Егетнең болай ашыгуы сәер тоелды аңарга.

— Син кая, молодой, болай ашыгасың, сүгәнең янынамы? — диде ул мыскыл итәргә азапланып.

— Өйгә,— диде Рәхимҗан коры гына.

— Инде өй дә юнәттең, димәк, урамда йөрүдән туйдың, димәк... Менә ичмасам бу аңлашыла миңа!..

— Бабай авырып киткән, үлем хәлендә,— дип аңлатырга тырышты Рәхимҗан.

— Булса... Карт кеше үлми нишләсен тагы...— дип хихылдады сакалбай.

— Машина бәрдергән, больницада, хәлен белергә кирәк,— дип һаман аңа төшендерергә омтылды Рәхимҗан.

— Димәк, капут, бабай капут!.. Машина бәргәч исән калу юк! Ничу кайтып йөрергә.

— Син нәрсә? — Рәхимҗанның йөзенә кан йөгерде, караватта акыл сатып яткан сакалбайга ачулы күзләрен текәде.— Син нәрсә!

— Мин шул көе, элеккечә. Ә син чашкансың! Кем инде бабай күмеп йөри. Син хәзер студент, ташла шул мужиклыгыңны.

Рәхимҗан, ни әйтергә белми, бер мәл аптырап карап торды аңарга.

— Йөрмә кеше көлдереп, авылны онытырга вакыт. Йөрмә бишмәт сыман! — дип акыл сатты сакалбай аның саен һәм караватыннан сикереп үк торды.

Рәхимҗанның түземе беткән иде, ул, чыгырдан чыгып, юлына аркылы баскан сакалбайга бар ачуы белән селтәнде. Ияк астына кундырды һәм, «синең урының шунда» дигән сыман, аны караватына кире аударып, ишеккә юнәлде...

...Больницага аны икенче көнне генә керттеләр. Авылдан әтисе дә килгән иде. Өч ир-ат, бер урынлы җыйнак палатада калып, байтак кына үзара карашып, хәл белешеп утырдылар. Картның хәле чынлап та бик җитди иде. Авыртуын күпме генә яшерергә тырышмасын, улы белән оныгы барын күреп, тоеп утырдылар. Аның хәлсез иреннәре чак кына ачыла, күзләреннән нур качкан иде инде. Шуңа ата белән бала, сүз берләшеп кергәндәй, артык борчымадылар картны. Әледән-әле ул үзе генә эндәшеп куя иде.

— Кайттыңмы, улым,— диде Рәхимҗанны әле яңа гына таный төшеп.

— Кайттым, бабакай,— дип җавап кайтарды егет, күңелендәге авыр тойгыларын бабасына сиздермәскә тырышып.

— Әйбәт иткәнең, улым... Бөтенләйгәме инде?..— диде дә, җавап биргәнне дә көтмәстән, иркен сулыш алды. Андый нәтиҗә ясарга, югыйсә, һичнинди нигез юк иде кебек. Күрәмсең, күңелендә йөрткән шундый теләге булган, дип уйлады Рәхимҗан. Ул, бабасының күз карашын тотып, «әйе» дигәнне аңлатып ым какты. Күңелендә йөрсә дә, бөтенләйгә кайту турындагы уйның әле башына килеп тә караганы булмады югыйсә. Әтисе дә, ул да дәшмәделәр. Карт күзләрен йомып хәл ала иде бугай, бераздан яңадан телгә килде:

— Судлашып йөрмәгез, улым! Гимай белән дим... Балалары җәл...

— Борчылма, эти! Ул турыда уйлама, анысы качмас,— дип җавап кайтарды Рәхимҗанның әтисе. Егеткә исә аның җавабы ошамады — ачык итеп, бабасының күңеле булырлык итеп килешергә дә мөмкин иде ич.

Палатада тагы авыр тынлык урнашты. Кайдадыр, бүлмәнең бер почмагында, ялгыз чебен безелдәгән аваз гына ишетелеп торды. Җан-

ны газаплый торган тынлык иде бу. Тетрәндергеч тынлык! Күкне томалап алган болытлар арасыннан сирпелеп киткән нурлар сыман, картның күзләре янә ачылып алды. Рәхимҗан барын күреп, аңлап утырды, авырая барган керфекләрен күтәрү торган саен кыенрак, газаплырак иде бабасына. Кургашындай авыр иде инде аның керфекләре.

— Зиратның түбән башына күмәрсез,— диде ул. Аннары өстәп куйды: — Су буеннан чишмә тавышы, атларымның су эчкәндә пошкыруы ишетелеп торыр...

«Юк, Бабакай, әле үлмисең, әле синең яшисең бар. Нурлы Аланга син шундый кирәкле бит әле, Бабакай»,— дип кычкырасы килде Рәхимҗанның. Бөтен дөньяга оран салырга әзер иде ул. Тик аның сүзләреннән бабасына җиңел булса икән...

Палатаның кайсыдыр ерак бер почмагында һаман теге чебен безелдәде. Ялгыз чебен. Пәрәвез җепләренә эләгеп буталган, чарасыз калып язмышы хәл ителгән чебен идеме ул? Җанны өшеткеч бер үк аваз чыгарып, һаман безелдәде дә безелдәде бичара. Башка бернинди аваз ишетелмәде, әйтерсең лә бу мизгелдә бөтен дөнья сулыш алырга да куркып тынып калган иде... Ә чебен тагы бер тапкыр, ычкынырга теләгәндәй, нык кына безелдәп алды да тынды. Башка безелдәмәде.

Әтисенең муен уртасында зур бер төер калкып чыкканын һәм шул төернең торган саен зуррак тизлек белән бер аска төшеп, бер өскә күтәрелеп сикергәли башлавын, тыпырчынуын аермачык күреп утырды Рәхимҗан.

Көпә-көндез палата тәрәзәсендә кинәт кояш сүнде. Алар утырган җыйнак палатаны караңгылык урап алды. Шул караңгылыкны таратырга, дөньяны яңадан яктыртырга теләгәндәй, ата белән улның күзләре берьюлы ике пар нәни кояш булып кабынды шикелле... Чыклы нурлар аркылыга да буйга да йөгерә-йөгерә айкап гизделәр караңгы бүлмәне. Бер стенадан икенче стенага, идәннән түшәмгә, түшәмнән идәнгә күчеп яктырттылар алар. Гөлт-гөлт балкып алып, идәнгә тамды яктылык, борыннарын, иякләрен яндырып узды аларның. Ләкин дөнья элеккечә яктырмады, тирә-як кояш тотылган көнне хәтерләтә иде.

## 9

Бабасының җидесен уздыргач, ул үзенең авылда калырга җыенуын, бөтенләйгә калырга ниятләвен белдерде. Ата-ана Рәхимҗанның сүзләрен башта чынга алмады. Болай гына әйтүедер, бабасын бик үз итә иде, нык кайгырды, арыгандыр, дип кенә уйладылар. Кайткан көе тагы бер-ике көн ял итсен дә, аннан озатырбыз, диештеләр.

— Китмим дигәч, китмим,— дип өзеп куйды ул, тагы берничә көннән, әнисенең үгетләвенә җавап итеп.

— Тилермә, улым, акылыңа кил,— диде ана.— Шундый институтка кергәч ташлап китәләр ди мени...

— Авылда мең кабат яхшырак. Барыбер миннән җүнле инженер да чыкмас,— дип әнисен тынычландырырга тырышты егет.

Көзге каршында кырынып торган җирдән тукталып, сөйләшүгә әтисе кушылды:

— Сине кеше булсын, диләр. Югары белемсез ни эшләргә, кая барырга уйлыйсың?..

— Авылда эш бетмәгәндер әле. Хәзергә бабайның атларын карармын.

— Тилебәрән орлыгы ашамаган диген аны... Сине үгетләгән мин юләр,— дип кул селтәде дә, кырынуын дәвам итте әти кеше.

— Улым, акылыңа кил, кешедән оят... Күрше-күлән нәрсә уйлар

Институтыннан куып кайтарганнар икән, дип чыгарырлар. Акылына кил,— дип, үгетләүдән туктамады әнисе.

— Димәсләр, әни, борчылма. Авылда да менә дигән итеп яшәүчеләр аз түгел ич,— диде ул тагын бер мәртәбә әнисен юатып. Алай да булмагач, иң өстенә курткасын салып ишеккә юнәлде.— Председатель янына барам, борчылма да, үгетләмә дә, әни, хәл ителгән!

— Кемнәрнең күзе тигәндер инде, бала, бала...— дип калды ана.

— Акылына килер,— дип, кырт өзде ата. Һәм икәүдән-икәү генә өстәл артына утырып чәй эчтеләр. Авыз ачып бер-беренә ләм-мим сүз әйтмәделәр башка.

Председатель колхоз идарәсеннән аның каршына үзе килеп чыкты. Егет, исәнләшеп, сүзне нидән башларга белми тора иде. Биреләчәк сорауны сүзсез аңлагандай, председатель үзе сорап куйды:

— Нәрсә, калага барырга машина белешмәкче идеңме? Бүгенгә жук! Иртәгесен баралар, утыртырлар.

Колхоз житәкчесе, гадәтенчә, ашыга иде ахры. Ул инде китеп барганда Рәхимжан янә аның каршына чыгып басты.

— Мирзанур абый, мин бит сезгә киңәш сорап төшкән идем.

— Жә, нәрсә бар, нинди киңәш тагы?

— Сездән бер-бер эш сорарга дип төшкән идем.

— Нинди эш ул? — Председатель аңышмады.

— Колхоз эше...

— Нәрсә, кудыларммы әллә? — Председатель гажәпкә калды.

— Үзем бармаска булдым.

— Кешегә әйтеп адәм ышанмасны сөйләп торма, энекәш, шаярышып торырга вакытым жук,— дип, кул селтәде председатель.— Мин сер саклый беләм, жә, тиз генә әйт тә нәрсә өчен куганнарын... Аннан ары киңәш итешербез.

— Ипидер, Мирзанур абый, кумадылар. Үземнең барасым килми.

— Кая кергән идең әле? Бөтен авыл югары белем дип котырган, сезне белеп тә бетермәссең...

— Авиационныйга.

— Охо! Ошамый дисең инде алайса,— сынагандай карап алды ул Рәхимжанга,— ошамый дисең... Әйдә, утыр машинага. Төзүчеләр янына ашыгам, юлда киңәшербез.

Председатель үзе руль артына утырды. Һәм кузгалып та киттеләр. Машинаны ул Рәхимжан белә-белгәннән үзе йөртә торган иде. Өлкән яшьләрдә булуына да карамастан, председательнең житезлегенә сокланып барды егет.

— Син миңа үпкәләмә, жегет,— дип сүз башлады ул.— Бу — заманнан артта калган абзый икән, дип уйлый күрмә. Югары белемнең кирәген мин үзем дә яхшы беләм. Сиңа да ташларга киңәш итмим. Тик мине икенче нәрсә борчый — югары белем алган кеше авылга кайтудан курка, эшләмәскә өйрәнә, жирдән бизә.

Рәхимжан ни дияргә дә белмәде. Беразга тынлык урнашып торды, һәм аннары председатель тагы сүз кузгатты.

— Көн чабасың, төн чабасың,— диде ул, егетне үз иткәнен аңлатырга теләгәндәй.— Кырыкмаса кырык эш башланган килеш ята. Кемне кая куярга белгән жук, кеше житми, энекәш, кеше... Мәктәпне елның елына кырык-илле кеше тәмамлый килә, күз ачып йомарга өлгермисең, ком астына киткән су кебек юкка чыгалар. Кая китәләр шул тикле, башыма сыйдыра алмыйм... Ун елга биш йөз, егерме елга бер мең чамасы дигән сүз бит... Шуларның хет яртысы, чирегe калса икән. Кая китәләр, кая шулай кабалана-кабалана авылдан качалар, чуртым белсен... Ә югыйсә һәммәсе авылын сагынып яши. Киткәненә үкенә

кубесе, кире әйләнеп кайту уе белән яши. Тик кайта гына алмый... Менә шундый хәлләр, энекәш.

Рәхимҗан ничек утырган булса, шул урыныннан кымшанмый тик тыңлап барды. Председательгә ияреп нидер әйтергә, яисә аның сүзләренә каршы төшәргә ул үзен хокуксыз сыман тойды.

Сүзеннән туктагач, син мондамы соң дигәндәй, председатель аңа күз чите белән генә карап алды. Газны киметә төште. Тамак кырып алды һәм түзмәде, тагын дәште:

— Кем малае диден әле? Айтуганов бит... Бабаңны күмәргә кайткан җирдәнме?

Рәхимҗан баш какты. Председатель, үзалдына сөйләшкәндәй, акрын гына дәвам итте:

— Шәп карт иде... Әле җир җимертеп эшләп йөри иде... Биш-алты кешегә алыштыргысыз иде... Әнә бит ничек килеп чыкты... Бер исеркбаш аркасында... Эчмим, дип, кат-кат антлар иткәч, гаиләсе хакына дип кенә утырткан идек рульгә... Кем уйлаган аны. Алыштыргысыз кеше иде Төхфәт бабай...

Фермаларның аргы башына җиткәч, ул кинәт тормозга басты. Машинадан чыккач, кулларын болгый-болгый, ниндидер таныш булмаган кешеләр белән сөйләште. Төн җир актарган экскаватор гөрелтесеннән, бетон плиталар бушатучы кранлы машина тавышыннан, аларның нәрсә турында шулай кызып бәхәсләшүен аңларлык түгел иде. Председатель, актарып ташланган котлованны әйләнеп килгәч, тегеләргә тагы ниләрдер әйтте, кисәтүгә охшаш ишарәләр ясады. Рульгә утырып кузгалып киткәч, янә үзалдына сукранып алды:

— Авылның менә дигән җегетләре таралып бетә, чит җирләрдә каңгырап йөри. Ә монда әнә шундый, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип йөрүчеләр белән эшләргә кала. СМУныкылар, фермага азык кухнясы төзеп маташу.

Узып барышлый, төзелеш эшләре тәмамланып килгән ике этажлы культура сарае янында тукталып алдылар. Кире кергәндә председательнең кәефе бу юлы бермә-бер шәбрәк күренә иде. Канатланган сыман җил-җил атлап килүеннән үк сизгән иде моны Рәхимҗан. Ялгышмаган булып чыкты.

— Молодцы, күңелдәгечә була монысы. Шәп җегетләр! — дип мактады председатель клуб идәненә паркет җәючеләрне.— Әйтәм бит, авыл кешесе үземә була дип эшли шул ул. Эш башка — сыйфат башка.

Шунда гына янәшәсендә Рәхимҗан утырып йөргәнне, аның йомыш белән килгәнлеген исенә төшерде.

— Исемеңне ни атлы дидең әле?

— Рәхимҗан.

— Ә-ә, синмени инде ул Рәхимҗан?

— Нигә алай дисез, Мирзанур абый?

— Болай гына... Узган кыш, көрткә бата-чума чишмәдән су ташый, дип сөйләгәннәр иде. Мәзәк итеп... Синме инде ул?

— Әйе! Нигә, начармыни?

— Начар димим, чишмә суына җиткәне юк.— Һәм ул шунда, сүз башын искә төшерепме, сорап куйды: — Ашыкмыйсыңдыр ич?

— Кая ашыгыйм...

— Хәзер, чаптырып кына ремонт мастерскоена барып килик тә, аннан иркенләп киңәшербез.

Ул арада машина, тимер койма белән уратып алынган зур ишегалдына кереп, трактор һәм чәчкечләр тирәсендә уралган кешеләр янына килеп туктады. Кара мазутка буялган дәү һәм таза ир-атлар белән кызып-кызып ниләрдер киңәште председатель, әледән-әле, ниндәндер кызык табып, дәррәү көлешеп тә алдылар. Рәхимҗан исә һаман да кабинада утыра бирде — авылдашлары янына чыкса, чит итәрләр

төсле тоела иде аңарга. Шуңарга ул аларны түгел, тимерчелек каршында торган ватык чәчкечтә аркасын кашып маташкан озын мөгезле карт кәҗә тәкәсен күзәтте. Көтмәгәндә, председательнең монда булуын абайламыйчарак булса кирәк, янәшәдәге тимерчелектән стакан һәм шешә тоткан ике-өч адәм шаулашып килеп чыкты. Машинаны күргәч, үзләре шундук каушап та калдылар, әмма кире чигенергә өлгермәделәр, соң иде инде. Кәҗә тәкәсе, алардан шүрләп, сискәнеп, читкә сикерде. Барысы да шул якка борылдылар. Председатель дә борылган иде, ул да күреп алды.

— Марш өйгә!..— дип тавышын күтәрде ул, тегеләр аны-моны уйлап өлгергәнче.— Техника тирәсендә эзегез булмасын!

Гаепледәр үзара карашып алдылар, ык-мык боргаланырга да иткәннәр иде, барып чыкмады. Сүзсез дә аңлашыла дигән сыман, буйсынулы кыяфәттә капкага юнәлделәр.

— Эш вакытында эчмәсәгез...— дип, нәфрәтләнеп тешен кысты председатель. Әллә ниләр әйтеп тузынасы, тегеләрне эттән алып эткә саласы килә югыйсә үзенең, әмма башка берни дәшмәде. Машина урыныннан кузгалгач кына, күңелен бушатырга теләп, янәшәсендәге егеткә борылды.

— Уф, туйдым шул исерекбашлардан. Бер стакан эчмәс борын шайтанга әвереләләр бит, шайтанга... Эчмәгәндә иплә генә, җүнле генә кеше үзләре. Менә шундыйлар белән дә эшләргә туры килә инде, энем... Бабаң башына да шул шайтаннар җитте. Нишләргә дә белгән юк. Кайчан акыл керер безгә...

Идарәгә җиткәнче башка дәшмәделәр. Машинадан төшеп, кабинетка кергәч тә сүз башлавы, ничектер, уңайсыз сыман тоелды. Урын тәкъдим иткәч, председатель үзе дә урындык алып аның янәшәсенә килеп утырды.

— Мин сине җүри шулай утыртып йөрдем. Күрсен дидем... Менә шулай яшибез инде, энекәш. Хәл ителәсе нәрсәләр дә, эш тә муеннан. Хет иртәгесе көннән — кайда ошатасың, шунда тотына аласың. Техникага утырасың килсә — укытырбыз. Яңа машина бирергә тиешләр — телисең икән, синеке булыр. Вәгъдә!.. Уйлан, киңәш ит тә, әйтерсең үземә.

— Мирзанур абый, мин уйлаган инде.

— Я-я, нәрсә уйладың?

— Бабай урынына, ат карарга...

Нәрсә-нәрсә, әмма моны көтмәгән иде ахры колхоз җитәкчесе. Гаҗәпләндеме, әллә уйлануы идеме, ул баш артын кашыгандай итеп торды.

— Атлар янына дисең инде, алайса. Күңелсез булмасмы соң, яшь кешегә.

— Мин уйлаган инде, рәтен дә беләм,— дип әйтергә ашыкты Рәхимҗан, икеләнергә урын калдырмаска тырышып.

— Соң, атлар булгач — атлар,— дип ризалашты председатель.— Атларга да хуҗа кирәк, алар да колхозныкы.

Һәм, аңлаштык дигәндәй, икесе дә канәгать булып кул бирештеләр.

## 10

Кыш буе атлар карады Рәхимҗан. Салкын димәде, буран димәде, иртә таңнан кичкә кадәр атлары янында булды. Ашатты, эчертте, көрәк һәм себерке тотып абзарларын чистартты, эшкә яраклы атларны озатты һәм каршы алды. Әмма кеше күзенә артык ташланмады, ипле

генә үз җаена эшләп йөргәндә булды. Үз-үзен тотышын төрлечә юрадылар аның. Институтыннан куганнар икән, дип тә сөйләделәр. Бабасын югалтудан айный алмый йөри, бичара, дип кызганучылар да бар иде. Ул узып киткәндә, колонкага суга чыккан хатыннар пышын-пышын гына: «Бу егеткә ни булган, ниткәнме әллә?..» — дип, бер-берснә карашып та алдылар. Нурлы Алан өчен шәһәргә бер киткән кешенең шушы яшьтә кире авылга әйләнеп кайтуы гайре табигый күренеш иде. Институт кадәр институтны үз теләге белән ташлап киткән дигән сүз берәүнең дә башына сыймады.

— Типсәң — тимер өзәрлек чагың, егет башың белән нигә ат абзарында кайнашасың? — дип, чын күңелдән киңәш итүчеләр дә булды. Аны аңламадылар, гомер буе ат сыртында яисә арбада йөргән шәпшәп кешеләр дә аңламады аны. Техника тирәсендә булса — аңларлар иде, ә менә атны яратуына ышанмадылар. Менә бит хикмәт!..

Язын аңар, авылда беренче булып, повестка кәгазе килде. Армиягә озатырга яшьтәшләре җыелды. Ял көне иде, шәһәрдән кайтучылар да байтак. Алар арасында Фаяз, Фаягөл һәм, әлбәттә инде, Зәйнәп тә бар. Озату мәҗлесенә алар өчәү бергә җитәкләшеп менделәр.

Табында утырганда берәүнең карашы Рәхимҗанның күзләрен, күзләрен генә түгел, бөтен җанын, бәгырен эледән-әле көйдереп торды. Ул Зәйнәп карашы иде. Күпме генә сер бирмәскә тырышмасын, бу караш алдында үзенең көчсез булуын торган саен аңлый барды Рәхимҗан. Шәһәрдән кайткан кыз тагы да сылурак һәм тагы да сөйкемлерәк булып тоелды. Тар джинсы чалбар һәм килешле алсу кофта кызның гәүдәсендәге һәммә чигелешне үтә бер нәфислек белән ассызыклап тора иде. Зәңгәр сөрмә салынган күзләрнең куе озын керфекләр арасыннан балкып китүен бер күрү шундук бөтен җаныңны уята. Нур чәчеп торган алсу иреннәр ерактан ук утлы күмер сыман пешереп алыр кебек. Бер Рәхимҗан күзләрен генә камаштырмады Зәйнәп. Кызлар аны көнләшеп күзәтсә, башка егетләр дә телиме-юкмы карангалап алдылар. Тик берәү дә Зәйнәпкә соклануын башкага сиздермәде. Хәер, табын артында Фаяз да бар иде бит әле. Дустын озатырга дип кала тикле каладан кайткан Фаяз гына күңелендәген яшерә алмады. Дөресрәге, аның күңелендәге телендә иде һәрчак.

— Ну, Зәйнәп,— диде ул, тирә-ягында егетләр һәм кызлар утыруын бөтенләй хәтереннән чыгаргандай дәртсенеп уч төпләрен уа-уа.— Матай алган көнне үк үзеңне утыртып урам әйләндерәм. Билләһи гәзим дим, Зәйнәп!

Аның сүзләренә игътибар итмәгәнгә сабыштылар. Зәйнәп исә Фаязга табан борылып карамый булдыра алмады, назлы гына күз кысарга да өлгерде.

Табындагы сый ни кадәрле генә мул булмасын, башта ишегалдына, аннан урамга, урамнан — тыкрыкка һәм су буена тартылды күңел. Рәхимҗаннар тыкрыгыннан төшкәч тә, Фазыл чишмәсе тугае башлана. Язгы ташу быел да чишмәнең улагын агызып киткән. Улаксыз булса да, чишмә яңы матур, тугай ямьле иде. Хәер, тугай диярлек зур урын да түгел ул үзе. Бакырчы чишмәсе янындагының уннан бере генә. Яшьләр шул тугайга — инешнең аргы ягындагы дугайланып килгән нәни ярымутрауга чыктылар. Бу тугайның иң зур матурлыгы — аның тынычлыгын саклагандай як-ягында калкып торган ике кызыл яр. Кабаланып аккан инеш бер-беренә ике игезәк сыман охшаш шул ярларга җиткәч тә кинәт тынычланып, уйчанланып кала. Ике кызыл ярның нәкъ урта бер җирендә тау битеннән чишмә бәреп тора. Авылдагы чишмәләрнең иң дәртлесе, иң ярсуы диләр аны. Ә ни өчен Фазыл чишмәсе дип аталуын болайрак аңлаталар:

Авылда беренче егет була Фазыл. Эшкә батыр, сүзгә тапкыр, үзе гармунчы, үзе җырчы дигәндәй, коеп куйган табигать баласы. Һәм

авылның беренче чибәре булган кызга гашыйк була бу көннәрдән бер көн. Кыз да егетне ошатып йөргән була. Бер-берсен бик яратышалар болар, ай нурында чишмәләр челтерәп торганда мәңге-мәңге бергә булырга дип сүз дә куешалар. Ләкин бергә булырга, кавышырга язмаган күрәмсең: кызны тирә-якта дан тоткан күрше Алкин баена көчләп кияүгә бирәләр. Егет ялгыз кала — җанын кая куярга белми газаплана, бердәнберен сагына. Һәр кичне бакчалары артындагы су буена төшеп бер ялгызы гына моңлана — җырлый, гармун уйный. Авылда таныш булган көйләр белән генә баса алмый башлый ул үзенең юксыну газапларын, бер-бер артлы яңа көйләр чыгарып уйный башлый. Моңарчы ишетелмәгән, яңгырамаган моңга тулы була ул көйләр. Төнге тынлыкка чумган авыл урамнарына бәреп керә, ачык тәрәзәләрдән үтеп өйләргә күчә моң. Шундый моңлы кичләрнең берсендә тау итәгенә утырып гадәтенчә моңлануы була егетнең. Башка сыймас бер могҗиза була шунда — егетнең аяк очыннан гына чишмә бәреп чыга. Егет моңар хәйран кала билгеле, һәм уйнавыннан туктап, хикмәтле чишмәнең дәртле челтерәвенә колак сала. Һәм шунда үзе дә белмәстән, чишмә агышына кушылып, яңа бер көй уйнап җибәрә. Егетнең уйнавыннан чишмә тагын да ярсыбрак ага башлый, чишмә ярсуына егет ияРә, егеткә — чишмә, чишмәгә — егет... Чишмә агышыдай дәртле, егет күңеле сыман ярсу яңа көй әнә шулай туа. Аны ишетеп инештәге балыклар ай нурлары белән кулга кул тотышып бии башлый, күктә бәхетле йолдызлар җемелдәшә, шундый ямьле җәйге кичтә күзләренә йокы кермәгән егетләр-кызлар урамнарга йөгерешеп чыга, бии-җырлый башлый. Нурлы аланлылар әлеге көйне отып калалар һәм «Фазыл чишмәсе» дип атыйлар. Шулай итеп, бу ярсу һәм дәртләндергеч көй дөньяга яңа чишмә булып туган.

Әле менә бүген дә, шул егетне искә төшергәндәй, Нурлы Алан яшьләре бергәләшеп «Фазыл чишмәсе»н җырлап алды:

> Өздереп нигә карадың,
> Ник тоттың чиләгемнән?
> Суларым түгел, ялкыным
> Түгелде йөрәгемнән...

Бу җыр аларны канатландырып җибәрде, үзләренең табигать баласы, шушы җир, шушы авылныкы икәнлекләрен искә төшерде булса кирәк. Дәртсенеп киткән авылдашлар кулга-кул тотышып гармунчы тирәсендә әйлән-бәйлән уйнадылар.

Җыр җырлап әйләнделәр, чират такмакка җиткәч, уртага чыгып парлашып биеделәр. Әйлән-бәйлән уены нәкъ менә шушындый яшел тугайларда, су буйларында уйнау өчен генә чыгарылган икән, аңар кушылмау мөмкин түгел. Җырлый беләсеңме-юкмы, җырчы булып китәсең. Бии беләсеңме-юкмы, әйлән-бәйлән уйнаганда үзеңне биюче итеп хис итәсең. Шулай да бу уенның да үзенә күрә осталары була. Нинди генә осталары әле! Әнә, Ахун Илфаты... Ул үзенә китереп басканны бәйгегә ашкынган аргамак сыман көтеп кенә тора. Кул чабып тик торганда да бөтен җаны, бөтен кыланышлары белән үк бию көенә тибрәнә. Берәүнең аның каршысына килеп тыпырдавы була, ике иң өстенә канат чыга Илфатның: сикереп, очып, атылып чыга уртага. Тыпыр-тыпыр биегәндә күзләре очкынлана, авызын җыеп ала алмый. Шулай дәртсенеп биегәндә ни кыланса шул аңарга килешеп тора. Инде туйганчы биеде дисең, юк, ул гына җитми, түгәрәкне тагын бер, кабат-кабат әйләнеп чыга. Өстәвенә, һәммәсе кул чаба, дәртсендереп тора. Гармун туктагач та әле биюдән тиз генә арына алмый ул. Үзе генә булса бер хәл, парлап биегән кызны да җибәрмичә, мутланып чүгәли-чүгәли аның тирәсендә «Билләреңә сары каешлар булып уралаем...» — дип такмаклап әйләнә. Башка берәү кулларына шулай ирек

куйса, кызы да аның инде әллә кайчан үпкәләгән, бернс чалтыратып җибәргән булыр иде. Ә Илфатка үпкәләмиләр. Аның кылануы да шулай табигый һәм ипле килеп чыга әйлән-бәйлән уйнаганда. Үзенә генә түгел, башкаларга да рәхәт булып китә ул биегәннән соң.

Гармунны магнитофон алыштырды. Дөньяларын онытып, тез буыннары талганчы заман ритмнарына биеделәр. Һәркем үзенә бер ләззәт белән биеде. Рәхимҗан урта бер җирдә дулкын сыман берөзлексез уйнап, чайкалып торган Зәйнәпне сокланып күзәтте. Тәненә сыланып торган киемнәр, иңнәренә таратып салынган чәч аның биюенә өстәмә ямь һәм сер өстәп тора. Ә югары чөелгән куллары белән ул, әйтерсең лә, тугайлыкка төшкән ай нурларыннан толым үрә иде...

Кызлар һәм егетләр төркем-төркем таралышты. Зәйнәп белән икәү генә Фазыл чишмәсе янына килеп салкын су эчтеләр. Сусаулары басылгач, бер-беренә су чәчрәтеп уйнадылар. Зәйнәп көлә-көлә читкә йөгерде, Рәхимҗан аны куып тотты. Сулышларына буыла-буыла көлделәр, шаярдылар...

Алар икәүдән-икәү генә су буеннан атладылар. Барыр сукмакларын, калышырга теләмичә йөгереп аккан инешне тулган ай яктыртып торды. Колак төбендә чишмәләр челтерәде. Бер чишмә авазын икенче чишмә күтәреп алды, аны яңалары алыштырып торды. Зәйнәпләр тыкрыгына җиткәч кенә туктап калдылар.

— Китәсең килмидер? — дип сорады кыз.

— Моңсурак шул...— диде егет, кызның кайнар кулларын учына алып.

Зәйнәп аңа якынрак елышты. Аяк очларына басып кына егеткә үрелде. Егетнең кулы кызның биленә күчте, ул аны тагы да үзенәрәк тарта төште. Кофта күтәрелгән төштә ялангач тән белән дәртле кул кавышты. Тыгыз нечкә бил калтыранып алды. Кулдан яшен ташы йөгереп узды. Рәхимҗанның иреннәре янды. Зәйнәп елышканнан-елыша гына барды, тыгыз тәне аның кинәт йомшап китте. Ул да түгел, кыз егетнең кулына авып төште. Зәйнәпнең ярым ачык күзләрендә ялтыраган тамчыларны күреп, егет каушап калды, ни дип юрарга белмәде аларны. Тартылган пружинадай хәрәкәт ясап, кыз янә аңарга үрелде. Рәхимҗан бу юлы аны күтәреп үк алды. Зәйнәпнең йөрәк тибеше дәүдәү икс алма булып талпынды. Пар алмага ашкан йөрәк үзләрен кысып торган алсу кофтаны тарсына иде, иреккә омтылып җан тартышты, тыпырчынды алар.

— Нишләтергә җыенасың мине, Рәхимҗан... Рәхимҗан... кирәкми,— диде кыз, тәмам йомылырга өлгергән керфекләрен ачмый гына.

— Бер нишләтмим, карап кына торам...

— Рәхимҗан...— дип пышылдады кыз, тагы да назлырак һәм сулпанрак тавыш белән.— Кирәкми, Рәхимҗан...

— Сокланып кына карыймын, Зәйнәп...

Кыз янә пружина сыман тартылып алды, аның йомшак, кайнар тәне янә тыгызланып калды. Күзләре ачыла төште. Аларга бөтен күк йөзе — ай һәм йолдызлар сыйган иде. Егет дәшми-нитми байтак кына карап торды аңарга, тирән итеп сулыш алырга да уңайсызланып карады. Аннары кызны җиргә ипле генә төшерде.

Зәйнәп күз тирәсен сыпыргалап алды, башын артка ташлап чәчләрен рәтләде һәм, тирән итеп сулыш алганнан соң, егеткә эндәште:

— Иртәгә үк китәсеңме?

— Иртәгә.

— Иртүкме?

— Әйе, иртүк...

Ә су буенда инде туар көннең беренче нурлары, ак җепселләре томлана башлаган иде. Алар һаман иртәгесен дип сөйләштеләр.

— Мине искә алырсыңмы соң, ә Рәхимҗан? — Үзе, назланырга те-

ләгәнен яшермичә, башын егетнең күкрәгенә куйды. Күзләрен тутырып аңар карады, үрелеп-үрелеп карады.

— Хат алышырбыз... Мин сиңа көн дә язармын. Әгәр теләсәң, көненә берничә хат... ишетәсеңме, Зәйнәп?..

— Ярар, ишетәм,— диде кыз. Һәм берара сүзсез торгач, өстәп куйды:

— Институтны ташламаган булсаң, армиягә дә алмаган булырлар иде менә.

Егет дәшмәде. Кыз моны үзенчә аңлады:

— Үкенәсеңдер?..— диде.

— Юк,— диде Рәхимҗан.— Армиягә алмыйлар, мин үзем китәм! Солдатта хезмәт итмәгән ир-ат буламы?!.

— Шулаен-шулай да бит,— диде кыз. Әллә килешүе булды, әллә... Аңламассың. Күзләрен тутырып озак кына Рәхимҗанга карап торды. Һәм гел уйламаганда, кинәт кенә үрелеп егетне үпте дә тыкрыкларына кереп йөгерде.

Иплә генә шыгырдап капка ябылганы ишетелде бары. Хәтта тимер келә дә шалтырамады — тимер келәне кыз сак кына тотып төшерде. Ә Рәхимҗанга исә тимер келә, һичшиксез, шалтырап төшәргә тиешле иде кебек...

## 11

Хәрби диңгез флотында өч ел хезмәт итте ул. Зәйнәпкә, вәгъдә иткәнчә, хатлар язды. Көттереп булса да, кыздан да җавап килгәләде баштарак. Ләкин ярты ел чамасы узгандырмы-юкмы, Зәйнәп язмас булды, туктап калды. Җанын кая куярга белми йөргән шул көннәрдә классташы Фаяздан хат алды егет. Анда түбәндәге сүзләр язылган иде: «Рәхимҗан дус, сәлам! Матай алдым тәки, эшләр ярыйсы болай. Зәйнәпне эзләп барган идем, килеп чыкмады. «Жигули»га утырып, кул болгап китеп барды. Хәзер «Жигули»га җыям. Сау бул!»

Бу хатны укып бер моңайды, бер елмайды Рәхимҗан. Фаяздан икенче хат килгәнче ул аны һаман укып торды. «Зәйнәп бер хәрбигә кияүгә чыкты. Матайны саттым. «Жигули»га да җыймыйм»,— диелгән иде монысында. Күзләренә ышанмый кат-кат укыды да хатны утка салды Рәхимҗан. Башына сыймады аның бу хәбәр. Фаяз ялгышкандыр, алай булмас, дип тынычландырды үз-үзен. Һәм тора-бара шуңарга үзе дә ышана башлады. Зәйнәп көтәдер, хатны болай гына язмый торгандыр сыман тоелды аңарга.

Җәй башында, срогын тутырып, авылга кайтып төште ул. Нурлы Алан тагы да матурайган, яктырган. Икенче көнне үк колхоз идарәсенә төшеп, Мирзанур абыйсы янына керде. Кочагын җәеп, шатланып каршы алды председатель.

— Танырлык та түгел, Рәхимҗан, синме бу,— диде, улын каршы алгандай кочаклап.

— Исәнмесез, Мирзанур абый,— дип, кул сузды егет. Ә күзе председательнең чигәсенә төште. Анда бер бөртек кара чәч тә калмаган иде инде. Өч ел эчендә танымаслык булып үзгәргән, картаеп киткән.

— Вәт, моряк дисәң дә моряк ичмасам! Молодец! — дип, егетнең җилкәсеннән какты председатель.

— Үзегезнең хәлләр ничек, Мирзанур абый, бер көеме?..

— Анысы качмас... Җә, сөйлә, ничек хезмәт иттең, планнар ничек?

— Ничек дип, әйбәт инде... Менә, эшкә тотынырга кирәк, шуны киңәшергә төштем.

— Синең кебек морякларга эш табылмыймы соң... Эш җитәрлек. Укыйм дисәң, анысына да җибәрәбез.

— Мин, каршы килмәсәгез, шунда, атларым янына кайтыр идем,— диде ул, ике уйларга урын калдырмаска тырышып.— Өч ел буена тере ат күргәнем булмады, сагынылды...

— Каршы килеп булмас, ихтыярың,— диде председатель. Бераз уйланып торды.— Анда Дада абзаң эшләп йөргән була иде. Ул инде пенсиядәге кеше, сәламәтлеге дә мактарлык түгел.— Һәм, нидер искә төшереп, үзалдына елмаеп куйды.— Әле беркөн генә карчыгы зарланып кергән Дада абзыйның: «Гомер буе гади эштә эшләде ул, начальник булу ярамый аңар, алыгыз шул атлар начальниклегеннән, ди. Шунда гына эчәргә өйрәнде, ат кирәк булган саен ярты кыстырып киләләр, кешелектән чыгардылар Дадамны»,— ди. Кайда эшләгәнеңне белеп тор! — дип, серле генә елмаеп алды ул.

— Дада абый да эчәргә өйрәнгәнме? — дип гаҗәпләнде егет.

— Җүнсезлеккә өйрәнергә күп кирәкме...— дип кул селтәде председатель. Һәм бер карарга килеп, өстәп куйды.— Уртак тел тапсагыз, ул да эшли торсын. Җәйләрен мәшәкать күп, печәнен, саламын да әзерлисе булыр. Болай көйле кеше ул...

Бөкерәйгәндәй, бераз иелә төшеп теркен-теркен атлап йөргән җыйнак гәүдәле бу кеше элек-электән ошый иде Рәхимҗанга. Ат абзарына килеп кергәч үк аның Рәхимҗанга әйткән сүзе шул булды:

— Атларың исән, синнән бер ярты, энем.— Үзе кеткелдәп көлә.

— Син нәрсә, Дада абзый, әллә эчәргә өйрәнгәнсең инде,— дип гаҗәпләнгән булды егет.

— Кунних начәлниге бул да, эчмә, имеш. Эчмәгәч, нинди начәлник ул, ике көннән артык тотмый эшеңнән алырлар...— дип, канәгать кенә елмая-елмая бер учлам сакалын сыпырып алды.

— Синең кебек матур картка эчү килешәме соң инде,— диде Рәхимҗан аның түгәрәк сакалына ымлап.

Карт күңеле булганчы кеткелдәп көлеп алды һәм, билгеле, җавапсыз кала торганнардан түгел иде ул:

— Мин бит, моряк энем, заманча карт — сакалым картларча булса да, эчүем заманча минем.

— Чынлап та хикмәт бар икән...— дип куйды Рәхимҗан, ни әйтергә белмичә.

— Сакалы бар, акылы юк, дигән мәкальне беләсеңдер, минем турыда инде ул,— дип, тагын кызык тапты карт. Һәм шундук йөзенә житдилек кучте.— Миңа, моряк энем, ат бирерсең инде, сорап менгәндә буш калдырмассың, яме.— Ә үзе, кулына себерке алып, абзар алдын себерергә керешкән иде инде.

— Хушлашырга мени инде исәп, Дада абзый? Атлар белән дим.

— Хушлашырга дип... Минем ни, «Карчыгым да үз янымда, пенсиям дә җитәрлек» дип, җырлап йөрер чагым бит...

— Председатель әйтә: Дада абыең белән бергәләп эшләрсез, ди, күңеллерәк булыр, ди.

— Димәс, димәс, юкны сөйләмә, мине яратмый ул.

— «Төшергәнгә» күрәдер?..

— Аңар гына булса бер хәл,— дип, себерке сабына таянып туктап калды карт.— Аның тагы бер хикмәте бар әле, моряк энем.

— Нинди хикмәт тагы?

Сорауны көтеп кенә торган икән, башындагы салам эшләпәне бер читкәрәк кыйшайтып куйды да шундук сөйли башлады. Сүзен башламас борын елмаеп та җибәрде үзе.

— Болай булды ул. Кәнсәләргә барганыем, беркем юк. Персидәтел бүлмәсендә чырылдап тилефун шалтырый. Ишеге дә ачык калган, мин әйтәм, керим әле, алыйм трубкасын. Бер-бер кирәкле кешеседер дим, үзе дә кереп җитәр дим. Кереп, колагыма куюым була, колак ярырлык итеп кычкырып җибәрмәсенме теге: «Кем әле бу, синме, Мирзанур?» —

ди. «Дада»,— дим мин. «Урынында булу яхшы булды әле, менә нәрсә,— ди теге тавыш.— Вручай,— ди,— районның ит планы тулмый, бер ун баш үгез һәм артык атларны җибәр»,— ди. Атлар дигәч тә ачуым чыкты. «Артык атлар юк, мин әйтәм, тот капчыгыңны...» «Син нәрсә, Мирзанур, кем белән сөйләшкәнеңне онытасың»,— дип тавыш күтәрмәкче бу миңа. Сүзен әйтеп бетергәнне дә көтми, мин тегеңә болай дип кенә җибәрәм: «Нәрсә анда Мирзанур, Мирзанур... Дада, дидем бит инде, башыңа тай типмәгәндер, Да-да!. Иҗекләп әйттем югыйсә, аңламый. «Син нәрсә, Мирзанур»,— дип, телсез кала язды. «Түгел, мин әйтәм, Дада дигәч Дада инде». «Үгезләргә ризамы соң хет?» — ди. Мин тагын кабатладым: «Дада булды бу, Да-да»,— дидем. «Нигә аны баштук шулай димисең, рәхмәт»,— дип, тегенең трубканы куюы булды, персидәтел үзе килеп керде. Сөйләп күрсәткән идем — ул бер көлде, бер ачуланды. Райун нәчәлствосы булган, минем өчен үзенә яхшы ук эләккән дә булса кирәк... Ә атларны барыбер бирмәдем, кызык иттем үзләрен,— дип, рәхәтләнеп тагы көлеп алды Дада абзый.

Дада абзый белән көннәрнең ничек узып киткәнен сизми дә кала иде алар.

## 12

Атна-ун көн эшләгәч, Рәхимҗан идарәгә кагылды. Председатель кызып-кызып телефоннан сөйләшә. Тагы нидер сорыйлар, таләп итәләр иде булса кирәк, кәефе кырылган күренә. Тыңлап торган чакта ул «да.. да.. да» дип җөпләп бара да, ахырда гына «җук бит, җук, нишләтим», дип өстәп куя иде. Аның «да, да...» дип кабатлый башлавын ишетеп, Рәхимҗан ирексездән елмаеп җибәрде. Дада абыйсы сөйләгән теге мәзәк хәл исенә төшкән иде аның.

— Бусагада торма, кер, Рәхимҗан, түрдән уз,— диде председатель, трубканы куеп. Ләкин үзе әле генә телефоннан сөйләшкән сүзләреннән аерыла алмый газапланды. Тамагын кыргалап, тәрәзәгә карангалап алды, әйтерсең, анда кемнедер эзли иде ул. Ниһаять, егеткә борылды, елмаерга иткән булды.— Тыңлыйм. Я, моряк, авылга күнегеп буламы соң?

— Була,— диде ул. һәм шундук, үгезне мөгезеннән эләктерергә ниятләп, йомышына күчте.— Киңәшәсе нәрсәләр бар иде бит, Мирзанур абый.

— Ну,— диде председатель, «я, сөйлә» дигәнне аңлатып.

— Хәзер бездә илле ат, сигез тай һәм алты колын бар, беләсездер...

— Беләм,— дип баш какты председатель.— Атлар түгел, авыл тирәсендә ничә күгәрчен, ничә чыпчык барын да чамалыйм анысы... Кымыз җитештерергә, кымыз цехы ачып җибәрергә дисеңме?..

Председатель егетнең нинди йомыш белән килүен чамаларга тырыша иде.

— Кымыз җитештерергә дә була, сездән ярдәм генә кирәк,— диде егет.— Ә бүгенгә мин башка нәрсә турында сөйләшмәкче идем, тагы да җитдирәк нәрсә турында.

— Ну?..— дип кенә алды ул тагы.

— Илле ат дидем бит, шуларның унысы гына җигелә хәзер. Калганнары көннән-көн буена арка кыздырып ята, эшсезлектән иза чигә. Ат өчен эшсезлектән дә олырак газап юк. «Ат кебек эшли» дип юкка гына әйтмәгәннәрдер...

— Башкаларын иткә озатырга дисең инде алайса.

— Алай димим.— Егет үз уйлары белән артык мавыгуданмы, шаяруны аңлаудан ерак иде.— Атларны авылда киңрәк файдаланырга кирәк дим.— Үзен бүлдерүдән курыккандай, тизрәк сөйли башлады ул.—

Авыл урамнарына карарлык түгел, бер чирәм заты калмаган. Яңгыр явып китсә, җиңел машиналар түгел, тракторлар, К-700 ләр буксовать итә. Кая карама — чокыр-чакыр. Бульдозер белән тигезләп чыгасыз, икенче көнне үк яңадан актара башлыйлар, тагын элекке хәленә төшә...

— Тәк... тәк...— дип, чынлап кызыксынуын белдерде председатель.

— Велосипед, мотоциклны авылда житәкләп кенә йөрергә туры килә. Ат арбаларында тәгәрмәч чыдамый, шуңа авылны читләп йөрергә тырышабыз. Авыл урамында бала арбасын тартып йөрү дигән нәрсәне онытканнар, мөмкин түгел чөнки... Төшке аш вакыты җитсә, һәр өй каршына диярлек трактор, машина килеп туктый. Бер такта кирәксә дә, тавыкларга ярты капчык ярма кирәккә дә машина һәм трактор чаба. Кибеткә ярты алырга да трактор йөри. Шуны туктатырга иде бит, Мирзанур абый, авыл эченә трактор-машинаны бөтенләй кертми торган итәргә иде... Авыл эчендәге, өй тирәсендәге вак-төяк йомышларга атларны файдаланырга да була бит...

Егет туктап калды. Председатель исә уйланып утыра иде.

— Идеясе шәп шәбен,— дип көрсенеп алды ул, байтак вакыт сүзсез торгач.— Ләкин ничек итеп шуны тормышка ашырырга соң?.. Тыюлар, киртә куюларны авыл кешесе болай да бик өнәп бетерми, тәкъдимең нинди?..

— Бик җиңел,— дип, эләктереп алды Рәхимҗан, яшьләргә генә хас житез уйлавы белән тиз-тиз сөйләп китте.— Сез, идарә исеменнән, техниканы авыл эченә кертмәскә дигән закун чыгарасыз. Техника бит колхозныкы! Ферма һәм амбарлар авылның читендә. Менә дигән юл бар авыл әйләнәсендә.

— Ә урманнан бүрәнә, утын, печән төяп кайтучылар нишләргә тиеш синеңчә?

— Печәнне ат белән кайтартып та була. Өй, мунча бурау кебек эшләрне авыл читендә башкарып була. Инде, гел булмаса, анда кайтып җиткәнне ат белән дә ташып була ич... Утынны да шулай.

— Моңар авыл кешесе риза булыр дисеңме?

— Башта риза булмас, ләкин тора-бара күнегер. Яшел чирәм үскән урамда бәбкә көтеп йөргән яланаяклы улын күргәч, әле бервакыт куанып туймас.

— Юк,— дип, баш чайкады председатель,— бакча артына төшеп җиткән йөкне машинадан бушатып, атка төяргә өйрәтеп булмый хәзер авыл кешесен. Юк! Бу хыял гына, ләкин әйбәт хыял.

— Соң, алайга китсә, печән белән утынны коеп яңгыр яуганда ташымыйлар бит. Көн коры булганда бер-ике тапкыр машина кергәннән генә әллә ни булмас,— дип, ризалыгын белдерде Рәхимҗан. Әмма шундук искәртеп куйды.— Тик моны сирәк очракларда, авыл советы рөхсәте белән генә эшләүне гамәлгә кертергә кирәк... Инде алайга китсә, урамны коры көндә түгел бит, яңгырлы вакытта яисә язын-көзен актаралар.

— Анысы дөрес! — дип раслап куйды председатель.— Шарикларың дөрес тәгәри. Авыл советы хәл итеп, тыңламый калмаслар. Тәртип сакларга кирәксә, милиция дә бар бит әле авылда... Бәлки, уйлап карарга ярыйдыр...— Тик, белмим шул, риза ашырлар микән? Аңлата алырбыз микән?..

— Ә ат җигүчеләрне, авыл эчендәге йомышка ат йөртүчеләрне үзебез табарбыз, анысы... Дада абзый белән киңәштек, картлар белән сөйләшергә булды ул. Каникулга чыккан малайларны мин үз өстемә алам, атны яратучылар гел бетмәгән әле...

— Ул ягы турында уйлавың әйбәт. Кешесе булса, кызыксындыру чараларын табарбыз, теге чаклар түгел. Шөкер, очын очка ялгамый калган юк әле.

Бу сүзләрне хуҗаның хуплавы, үзе белән килешүе дип аңлады Рәхимҗан. Ирексездән елмаеп җибәрде.

— Берәр атнадан идарәгә куеп киңәшербез, аңарчы кылларын тарткалый килермен,— дип, кул бирде ул егеткә.

— Рәхмәт!

Егетнең куанычы күңеленә сыймый иде. Ул хушлашып чыгып барганда председатель тирән уйга батып калды.

Идарәгә кеше байтак җыелган иде. Башка вакытта да шулай була микән, беренче тапкыр мондый утырышта катнашуы булгач, анысын чамаламады Рәхимҗан. Ишек янындагы буш урындыкка тыйнак кына кереп утырды. Һәммәсе аңар карый, «ник килгән» дип, аны күзәтә төсле тоелды егеткә. Көн тәртибендә башка мәсьәләләр дә бар иде, аны кызыксындырганын махсус соңгы итеп калдырды председатель. Чөнки монда бәхәссез, шау-шусыз гына булмаячагын күңеле сизенә иде аның. Шуңамы, бүген берәүнең дә кәефен кырмаска, күпләрнең салпы ягына салам кыстырырга тырышты ул.

Соңгы көн тәртибен игълан итеп, мәсьәләне аңлатырга керешмәс борын кабинетның төрле почмакларында пышын-пышын сөйләшүләр башланды. Бер почмактан икенче почмакка дулкын булып йөрде пышылдаулар. Кайберәүләр үзалларына елмаеп кына утырды — «булмастай нәрсә бу» диләр идеме... Икенче берәүләр һаман да мыдыр-мыдыр килеп үзара киңәште. Сүзен тәмамлаганчы председатель берничә кат металл ручкасы белән графин кагарга мәҗбүр булды. Сулы графин тавышы бик тонык чыкты, аның шылтыравын ишеткәне ишетте, ишетмәгәне юк.

— Вәт, шундый житди мәсьәлә тора, иптәшләр,— дип тавышын күтәрә төште ул.— Авылыбызның Нурлы Алан дигән исеменнән оят юкса... Чокыр-чакырлы димәгәннәр бит, Нурлы Алан дип кушкан бабайлар. Без шул исемгә лаек авылда яши алмыйбызмыни?.. Я, иптәшләр, кем нәрсә әйтергә тели?

Беренче булып ферма мөдире сикереп торды.

— Кызларны җәйләүгә алып төшүче автобус та кермәскә тиешме авылга? — дип авызын ерды ул. Чөнки сыер савучыларның һәркайсын капка төпләренә килеп алу һәм китереп кую гадәткә кергән иде.

— Башка сүзең булмаса, бу вак мәсьәлә, утыр, Зиннәт,— диде председатель, дилбегәне кулдан ычкындырмаска омтылып.— Су буена җәяү төшкәннән генә берни булмас, билләре сыгылмалырак булыр кызларның...

— Моңарчы ничек башка килмәгән бу, дөрес идея, шәп идея бит, иптәшләр,— дип, мәктәп директоры сүз алды.— Бер яңгыр явып киттеме, тездән балчыкка батып килә балалар мәктәпкә. Карарга кызганыч. Мәктәп коллективы исеменнән без моны биш куллап хуплыйбыз, иптәшләр. Кирәк икән, ярдәм итәргә дә сүз бирәбез...

— Тарих тәгәрмәчен кирегә әйләндерү була түгелме бу, Мирзанур абый.— Нурлы Аланга әле узган ел гына яшь белгеч булып килгән баш механик шулайрак сөйли башлады.— Бер кергән техниканы ничек инде авылдан кире куаларга мөмкин. Кайчан диген әле, фәнни-техник революция чорында бит...

— Техниканы авылдан куалау турында бармый сүз, урамнарны, безнең туган өебез булган авылыбызны чиста тоту хакында,— дип төзәтте аны председатель.— Урам чиста булса, бәлки, биек үкчәле ак түфли киясе килгән кызлар да күбрәк калыр иде авылда. Кызлар булса, баш механикның трактористлары, шоферлары да качмас иде шәһәргә. Бәлки, кем белә, буйдаклыгыңны ташлап, үзең дә башлы-күзле

булып куяр идең...— дип, серле генә елмаеп куйды ул баш механикка карап.

Шаяруга күңеле булды баш механикның, үзегезгә карагыз — авыл сезнеке, дигән сыман елмайды да кире урынына утырды.

— Күптән уйлап йөри идем әле үзем дә, бик урынлы, бик дөрес булачак бу,— дип сөйләде авыл советы председателе Вагыйз абый.— Шәп тәкъдим, дөрес тәкъдим бу. Без моны махсус өйрәнеп, быелгы җәйдә үк чарасын күрергә керешәчәкбез... Кара аны, элгәрәк башка килмәгән бит, югыйсә мин аны үзем дә күптән шулайрак уйлап йөри идем...

— Ә без, төзүчеләр, нишләрбез икән,— дип сорау бирде прораб, урыннан тормый гына.— Бетон плиталарны, краннарны атка төяп ташырбызмы?

— Уйлашырбыз,— диде председатель,— үзәк урамнарны күтәртеп, асфальтларга дигән план барын миннән яхшырак беләсез. Җайга салынып, төзелешкә зыян килмәс. Яңгыры да гел явып кына тормас, алты ай кыш барын да онытмыйк әле...

— Ат җигүчеләрне кем табачак? — дип сорап куйды бригадирларның берсе.

— Атларга гына калса, тоткарлык булмас, безнең анда Рәхимҗан эшли,— дип, егеткә ым какты председатель. Егет моны үзенә сүз бирү дип аңлады.

— Авыл картларыннан унбиш-егерме кеше хет бүген ат җигәргә әзер,— диде Рәхимҗан, солдаттагыча рапорт биргәндәй.

— Бүсерләре чыкса кем җавап бирә,— дип көләргә итте бригадир. Аңа ияреп тагы кемнәрдер пырхылдап куйды. Рәхимҗан сүзен әйтергә ашыкты, җавапсыз калырга ярамый иде.

— Бергә-бергә күтәрешербез. Сез дә ярдәм итәрсез,— диде ул.

— Кайчаннан бирле әле куних бригадир өчен җавап бирә башлады. Бригадирга йөк күтәрешеп кенә йөрисе калган, башка эш беткән, ди...

Бригадир иркенләп гәпләшергә жыена иде булса кирәк. Егет исә тынычлыгын җуймады, сорап кына куйды:

— Бригадирга күтәрергә ярамыймыни, ул да кеше ич?

— Юк, ярамый! — дип өзеп куйды бригадир.

— Бүсерегез барын белмәгән идем... — диде егет, тынычлыгын саклап.— Ә картлар өчен борчылмагыз, алар эштән курыкмый.

Ул кире урынына утырды. Шаулашып көлеп алдылар... Бригадир колакларынача кызарып чыкты, күркә сыман кызарды. Бер председательгә, бер егеткә таба борыла иде ул. Бер яктан ярдәм көтсә, икенчесен терелəй тотып ашарга әзер иде шул минутта — бригадирлык дәрәҗәсе генә рөхсәт итми.

Председатель исә Рәхимҗан өчен куанып, күңеленнән генә аны хуплап утырды.

Яңа тәкъдимне идарә бертавыштан яклап чыкты. Ә берничә көннән җәмәгать урыннарына һәм төрле яктан килгән юлларга Нурлы Алан авыл советының «Авыл эчендә автомобиль һәм тракторларга йөрү тыела!» — дип эре хәрефләр белән язылган өр-яңа карары эленде.

## 13

Колхоз идарәсе һәм авыл советының бу яңа карары байтак сүз һәм бәхәсләргә сәбәп булды. Кибет һәм каравыл өе тирәсендә жыелып әңгәмә коручыларның теленнән төшмәде ул, көтү куарга килгән хатынкыз да пышын-пышын гел шуны сөйләште. Кызык итеп, мәзәк ясап йөрүчеләр табылган күк, аны чын күңелдән яклаучылар да күп иде.

һәр өйдә, һәр гаиләдә аның уңай һәм тискәре якларын бизмәнгә салып үлчәделәр. Шулай да урамнарның тузан һәм техника гөрелтесеннән арынуына, тынычланып калуына күңеленнән генә куанып йөрүчеләр көннән-көн арта барды. Чокыр-чакырларны бульдозерлар тигезләп чыккач, урамнар киңәеп, иркенәеп киткәндәй булды. Як-ягына агачлар утыртылган тыныч урамнарга чыгып бала-чага уйнады, капка аръягындагы тормышка тавык-чебеш иләшә башлады.

Ләкин көннәр, атналар үтә торса да, зарыгып көтелгән чирәм генә тишелеп чыгарга ашыкмады урамнарга. Ә чирәмне зарыгып, зур түземсезлек белән көтте Нурлы Алан кешеләре, тыкырыкларда булса да күренер, дип өмет иттеләр. Кычыткан чыкты, анда-монда алабута шытты. Каз үләне һәм чирәм күренмәде. Каз үләне су буендагы тугайлыкларда сакланып калган икән, аны шуннан кәзләп күчерергә булдылар. Аерым урыннарга төшәлгәч, үзеннән-үзе үрчер, диде картлар.

Ә чирәм табылмады. Кайчандыр Нурлы Алан урамнарының мактанычы саналган куе яшел төстәге, көдрәләнеп торган борчак-борчак яфраклары белән сабыйларга — йомшак келәм, бәбкәләргә татлы бишек булган чирәмнең тамыры, нәселе корган булып чыкты. Урамнарда гына түгел, су буйларында, авыл читендәге чокыр-чакырлар әйләнәсендә дә күренмәде андый чирәм заты. Картлар, җай чыгарып, күрше авылларны әйләнеп кайтты. Анда да кайчандыр булган, ләкин байтактан күренми икән инде андый чирәм. Районны яшелләндерү хуҗалыгына кеше җибәреп карадылар — барган кеше буш кул белән кайтты. «Чирәм юкмы?», «Чирәм табарга ярдәм итегез?» дигән үтенеч кәгазьләре республика үзәгенә, тагы да еракларга китте. Төрле-төрле җаваплар килде, әллә нинди үләннәр тәкъдим ителде. Ләкин бер җирдән дә Нурлы Алан урамнарын әле моннан ун-унбиш еллар элек кенә хәгфәдәй түшәп торган чирәмне вәгъдә итмәделәр. Шул чирәмнең тамыры булган уч төбе кадәрле кәз кисәгенә дә риза иде югыйсә Нурлы аланлылар, чирәм табылмады. Чирәм юк иде. Чирәмнең тамыры корган булып чыкты.

Чирәм эзләү вакыйгасы башта бер кызык кына булып тоелды. Әмма тора-бара ул күпләрне уйланырга мәҗбүр итте. Ничәмә-ничә буыннардан күчеп мирас булып килгән, ерак бабаларның ядкаре булган һәм хуш исле, җәйге көн кызуында тәнгә бер салкын рәхәтлек биреп, аяк табаннарын иркәләп торган чирәмнең тамыры корган булуга һичкемнең ышанасы килмәде. Шулай гел юкмы икәнни, бер кайдан да табып булмый микән, дип киңәште, баш ватты нурлы аланлылар. Дингез аръягыннан булса да табылыр дип өмет иттеләр — бу югалту белән берәүнең дә килешәсе килмәде. Үз балалары һәм оныкларының, киләчәк буын авылдашларының, андый чирәмне бервакытта да һәм берничек тә инде күрә алмаячагын башларына сыйдыра алмады алар.

...Ничек соң шулай килеп чыккан? Авылның буеннан-буена иксезчиксез зурлыктагы келәм булып сузылган яшел хәтфә әле кайчан гына һәр урамның, һәр тыкрыкның куанычы, мактанычы иде бит югыйсә. Кая киткән ул? Шулай итеп, моннан ары һичкем хәтфә сыман күпереп торган яшел чирәм өстенә басып йөри алмас микәнни. Тып-тып атлап китәр көннәре әле алда булган сабыйларны ул рәхәтлектән, балачакның шундый зур бәхетеннән кем аерды?.. Кем? Үзебез үк түгелме?.. Шул чирәм кебек тагы бик күп, бик күп нәрсәләргә гамьсезлек күрсәтеп, без аларны кайтарып алмаслык дәрәҗәдә югалта, оныта бармыйбызмы... Нурлы аланлыларның күңелен шундый уйлар биләп торды.

Авылдашларының урамдагы чирәм өчен бакчадагы бәрәңгедән дә болайрак борчылуын, янып-көеп йөргән күрү Рәхимҗан күңелендә матур өметләр дә уятты. Авыл язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәгенә битараф булмаганнар байтак икән бит...

Тракторлар авыл эчендә гел күренмәс булды. Шоферлар да кирәләнеп әллә ни кыра алмадылар, авыл советы карары кушканча эшләделәр. Шәхси машиналар өчен авыл читендә гараж төзергә урын билгеләнде. Сорап килгән кешегә җигүле ат һәрвакыт әзер торды. Дада абзый белән Рәхимҗан берәүнең дә үтенечен кире какмады.

Бүген алар үзенә күрә бер өмә үткәрделәр — яңа арбаларга тәртә куеп, тәҗе тарттырдылар, тәгәрмәчләрнең кигиен ныгыттылар.

— Дада абзый,— дип эндәште Рәхимҗан эш арасында,— синнән бер нәрсә турында сорыйсым килеп йөри.

— Җә-җә, аракы белән акча гына сорама түлке.

— Нигә алай?

— Үзең беләсең, мин ышанычсыз кеше бит хәзер. Карчык акчаны миннән җыеп йөри башлады, мин аракыны аннанераграк йөртәм,— дип кеткелдәп алды ул. Үзе шундук серен дә чиште.— Печәнлеккә яшерәм.

— Без бәләкәй чакта сине аучы диләр ие, Дада абзый...

Егеттән мондый сүз көтмәгән иде ахры ул. Эшләпәсен бер читкәрәк этеп куйгач, җанланып китте карт.

— Әмин мылтыкны болай гына асып йөрдем аны, урманчыга ансыз килешмәс дип кенә. Гомеремдә бер куян атканым булмады. Әаучы дигән даным чыкты. Мылтыкка буш гилзәдән башка нәрсә кормадым...

Һәр сүзеннән тәм табып, яратып сөйли иде карт.

— Ә без, аучы сүзе чыккач, күз алдына гел сине китерә идек бит, Дада абзый...

Карт кеткелдәп көлде. Юмарт һәм игелекле иде аның көлүе.

— Кенәген урманга менгән идем бит,— дип башлады Рәхимҗан, нидәндер дулкынлануын яшерә алмыйча.— Болан башы очраттым шунда. Яшь кенә, боланның да әле баласы гына булгандыр. Дүрт аягын, башын чабып калдырганнар, ә гәүдәсе юк. Яшереп тә тормаганнар, ачыклыкта ята...

— Браконьерлар кулы. Ит ашыйсылары килгән, сөяге тамакларына тыгылгыры,— дип кәефсезләнде Дада абзый да.— Җиңел машина белән булганнар, димәк, багажникка тыкканнар.

— Безнең авылда кемнәрдә мылтык бар?

— Дүрт мылтык бар авылда, ләкин берсе дә болан ата торган кешеләр түгел,— диде карт, бераз уйга батып торгач.— Юк, безнең авыллар түгел!

— Кемнәр соң?

— Аучылык җәмгыяте дигән бер оешма бар. Бөтен браконьер шулар тирәсендә җыелып ята. Алар белән нишләп тә булмый. Урынында тотсаң да, кесәләрендә икешәр-өчәр печәтле кәгазь була аларның...

— Нинди җәмгыять соң ул, болан баласы атып йөргәч,— дип ачынды егет.

— Менә шундый җәмгыять инде... Әллә кайдагы шәһәрләрдән килеп, авыл янындагы урманга хуҗа булып йөриләр, лапастагы сыерыңны атып алып китмәсәләр, рәхмәт әйт инде... Урман тавыкларын, кыр үрдәкләрен атып бетерделәр, кыр казларын да күрсәң — төштә генә күрерсең... Яшь болан баласы дисең, ә... шулай иткергеләре,— дип кызып китте карт. Һәм, шундук, үзенең сүгенә башлавын чамалап, туктап та калды. Бераз уйланып торгач, янә авызы ерылды аның.— Мин бер елны кызык иттем аларның үзләрен дә,— дип, җанланып сөйли башлады ул.— Бурсык елгасы янында шул җәмгыять кешеләрен очраттым. Дүртәү болар, дүртесенең дә иң башында ике көпшәле өр-яңа мылтыклар. Оптик приборларына тиклем бар. «Үрдәк кайда күп?» — дип сорый болар миннән. Ә үзләре үрдәкнең оясына, таллыктагы бәләкәй күлләргә төбәп баралар. Туктале, мин әйтәм, кызык итим әле боларны, дим. Үрдәк сез барган күлләрдә дә бераз булырга тиеш,— дим.— Атып

бетермәгән булсалар, дим. Сизәм: боларга аз кирәкми, күп кирәк. Сер итеп кенә әйтәм, дим, әнә, күрәсезме, дим, шул чокыр буйлап бер биш-алты чакрым урман эченә керсәгез — шунда бер күл булыр. Вәт, мин әйтәм, анда үрдәк ичмасам... «Булмас,— диләр болар,— анда күл юк бит»,— диләр. Әһә, дип уйлыйм эчемнән генә, күле бар шул, үрдәге генә юк — димәк, бу тирәне начар белә болар. «Үзең күрдеңме?» — диләр... Сез нәрсә, мин әйтәм, кичә генә менә шушы мылтык белән бер капчык үрдәк алып кайттым. «Ну-у» диләр, күзләренә ул-бу күренми башлады. «Ничек ул кадәр аттың»— диләр. Шулай, минәйтәм. Менә шушы бер көпшәле мылтыкның ике көпшәсен берьюлы кордым да, «пах» бер көпшәдән, «пах» икенче көпшәдән. Баш өстендәге үр-дә-ә-әк!.. минәйтәм, болыт кебек. Корып өлгереп булмый башлады, тагы бер-бер артлы ике көпшәдән аттым да корып тормый гына ата башладым, минәйтәм, өлгерерлек түгел, янәсе... Тегеләр шаяруны аңлаудан узган иде, күзләре кызганнан-кыза барып, бер шакмакланды, бер түгәрәкләнде. Барган юлларыннан кырт борылып, шундук тирән чокыр буйлатып урманга кереп йөгермәсеннәрме... Рәхмәт әйтү юк, сау бул юк... Ну атканнардыр үзләре дә үрдәкне — чытыр-чатыр арасыннан күлгә җиткәнче дә әле анда, ай-һай...

Арба үрәчәсенә көяз генә менеп утырган Дада абзый тагы матур итеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

Шул көннәрдә Рәхимҗан Фаяздан хат алган иде. Анда мондый юллар язылган:

«Туган көнне монда гына уздырдык. Егерме ике тулды — картаябыз, малай, Рәхимҗан! Тулай торактагы малайлар белән шашлык ясадык, биш тәңкәдән биш кило ит барып алган идем. Итеннән безнең урманда үскән усак кайрысы тәмнәре килеп тора, малай...»

## 14

Ат абзарындагы эшләрне җайга салгач, Рәхимҗан кече Басу астындагы печәнлектән тайларга көн дә яшел печән чабып кайта торган булды. Юл уңаеннан җәйләүдәге кызларга агач кисмәк белән чишмә суы алып төшә.

Ризван каеннары чишмәсеннән теш сындырырлык салкын су тутырып, бүген дә җәйләүгә юл тотты ул. Амбар тавыннан күтәрелеп җиткәндә генә каршы яктагы бакчалар артыннан кулын болгый-болгый үзенә таба кемнеңдер йөгерүен күреп, атын тыя төште. Йөгерүче Фаягөл иде. Әле күптән түгел генә шәһәрдән кайтып сыер сава башлаган иде Фаягөл.

— Кызлардан калганмын, автобус көтми төшеп киткән,— диде ул, куып җитеп икенче як үрәчәгә менеп утыргач та. Еш-еш сулап, чүәкләре эченә кергән тузанны кагарга кереште.

— Бергә-бергә төшәрбез, миңа да күңеллерәк булыр,— диде егет, җавапсыз калырга теләмичә.

Ат үз көенә иплэп кенә теркелди бирде. Тынлык урнашты. Әледән-әле чыелдап алган арба чәкүшкәсе тавышы һәм кисмәктәге су шапылдавы гына ишетелгәләп куя иде. Фаягөл күлмәк итәкләрен тарткалап куйды, кабаланмый гына иң өсләренә салынган коңгырт чәчләрен тарады.

Рәхимҗан исә авылларының тау башыннан күренгән матурлыгына сокланып барды. Су буена тикле салынып төшкән иркен бәрәңге бакчалары, инде август урталары булуга да карамстан, әле һаман күкрәп торган куе яшел төсен югалтмаган. Авылны, яшел бөҗра сыман, һәрьяктан бәрәңге бакчалары урап алган икән. Авылның матурлыгына ямь өстәп торган бизәк икән бит бәрәңге бакчасы. Югарыдан караганда

бакчаларны аерып торган койма һәм киртәләр күзгә ташланмый. Авылның үз урамнарыннан йөргәндә күренми бу матурлык...

— Бабайлар акыллы булган,— диде ул, Фаягөлнең барлыгын бөтенләй хәтереннән чыгаргандай үзалдына сөйләнеп.— Авылны кая һәм ничек салырга белгәннәр, өйләр — тау астында ялга кунаклаган кыр казларымыни...

Фаягөлнең җәлт кенә борылып үзенә карап алуын тоймады ул. Авылга текәлгән дә үз уйларына чумган: «Авылны әледән-әле шушы биеклектән менеп карыйсы килгәндер бабайларның. Ә күпләрнең хәзер монда менәргә вакыты җитми... Ишегалларын, бакчаларын биек койма, киртә белән уратып аласы бар аларның. Авылдашларны ешрак мендерәсе иде монда. Аның ихтыярында булса, иң элек шушы тау башына мәктәпне салдырыр иде ул. Малайлар һәм кызлар Нурлы Аланның нинди матур авыл икәнлеген кечкенәдән күреп үсәр иде.

Әле кичә генә Фаяздан килгән хаттагы юллар хәтеренә килеп төште: «Авыл сагындыра, Рәхимҗан малай. Кайтасы килә, кайтсаң, күңелсез — кая барырга белми башлыйсың. Өйләр дә бәләкәйләнеп калган, тездән генә кебек. Ә китәргә өлгермисең, тагы сагындыра башлый. Нигә шулай, һич аңламыйм, малай».

Ат үз көенә атлый бирде. Егетнең күңеленә әллә нинди хыял-уйлар бер-бер артлы килә торды, китә торды: «...Илләр, материклар арасындагы чикләрне дә шулай бәрәңге бакчалары әйләндереп алган булса, ничек булыр иде икән? Бәрәңге бакчасына туптан атарга, бәрәңге бакчасын таптап узарга берәү дә кыймас иде...»

Шунда, уйларының таркау һәм беркатлы булуына төшенеп, үзалдына елмаеп куйды ул. Ярый әле аны берәү дә ишетми, аның ни уйлавын янәшәсендә утырып барган Фаягөл дә белми ич. Җир шары картасын бәрәңге бакчалары бүлеп тормауның үчен кайтарырга теләгәндәй, үзен дә белешмичә, дилбегә очы белән атка кизәнеп алды ул. Ат сискәнүдән кинәт тартылып куйды. Койрыгын кигәвен кугандагыдай болгап алды. Фаягөлнең кыска җиңле юка күлмәгенә кисмәктән чайпалып су чәчрәде.

— Сәер кеше син, Рәхимҗан,— диде ул, тыныч һәм сабыр гына.— Аңлап булмый сине...

Аның сүзләре егетнең бер колагыннан ничек кергән булса, икенчесеннән шундый ук тизлек белән чыгып та китте.

— Ашыгасыңдыр, бераз тизләтикме әллә,— диде ул, кызга җилкә аша караш ташлап.

Кыз ашыкмый иде. Байтак кына ара тагы сөйләшми бардылар. Авыл каршындагы тау читеннән үткән юл, кинәт борылып, Кече басуга таба алып китте. Урамнар, бәрәңге бакчалары һәм өйләр бер-бер артлы күздән югалды. Юлның бер ягында — кукуруз басуы, икенчесендә — язгы бодай.

— Басулар матур быел,— дип куйды Рәхимҗан үзалдына.

— Шул матурлык белән генә яшәп булса икән...— диде кыз, сүзләренә аерым бер мәгънә салырга теләп.

— Кырда уңыш булса — шуннан да олы бәхет юк, матурлык та юк. Мин шуны әйтәм...— дип, тәфсилләргә ашыкты егет.

— Ә син, Рәхимҗан, бәхетлеме соң үзең?

Фаягөл, ярым борылып, егетнең карашын очратырга талпынды. Сизелер-сизелмәс кенә, ялгышып кына, бармаклары белән аның иңбашына кагылып алды. Рәхимҗан кинәт сискәнеп куйды — йомшак һәм кайнар иде Фаягөлнең нәфис бармаклары.

— Бәхетле булмаска, мин үз авылымда ич, авылдашларым арасында...

— Мин дә чит авылда түгел ич... Кайттым.

— Соң, шулай булгач, ни җитми?

— Житә... Ник кайттың дип сорар идең...
— Барыбер түгелмени...
— Бала-чага булып кыланасың син, Рәхимҗан,— дип бүлдерергә ашыкты аны Фаягөл.— Яшьтәшләрең күптән өйләнеп бетте, ә син һаман малай булып кыланасың. Беләм бит, ялгызлыктан җаның үрсәләнә синең, Зәйнәпне оныта алмыйсың.
Зәйнәп исемен ишеткәч тә, тәне эсселе-суыклы булып китте егетнең, әмма сер бирәсе килмәде.
— Кем газапланадыр бит әле,— дип кенә куйды ул, төртмәле итеп. Дилбегәне тарта төшеп, атны куалагандай итте. Ат моны абайламады да, ничек барган булса, шул көйгә теркен-теркен атлавында булды.
— Куалама әле,— дип, егетнең дилбегә тоткан кулына ягылды Фаягөл. Теге җылы наз бу юлы аның бөтен тәне буйлап йөгерде.— Куалама, зинһар, болай да килеп җитәбез ич инде.
Бер тын тагы сүзсез бардылар. Тәгәрмәч тавышы һәм кисмәктәге суның ипле чайпалуы ишетелеп торды бары. Күз чите белән генә Фаягөлне күзләде егет. Ул элеккедән әллә ни үзгәрмәгән, бераз түгәрәкләнә һәм тазара төшкән иде бугай. Бит алмалары шулай ук алланып тора. Табарга теләсә дә, искитәрлек зур үзгәреш таба алмады ул Фаягөлнең тышкы кыяфәтеннән.
— Сине кияүгә чыккан дип сөйләгәннәр иде бит,— дип әйтеп куйды Рәхимҗан, ишетмәсәң ишет... дигәндәй.
Кыз сискәнеп куйды, әмма шундук үзен кулга алды.
— Чыккан дип...
— Ташлап кайттыңмыни?
— Әй, болай гына бит ул, кем әйтте аны...
— Бөтен авыл сөйли.
— Ярты еллык курсларга килгән иде, Якты Ярда хатыны, ике баласы булган...
— Бай кешене эләктергәнсең икән,— дип шаяртмакчы булды егет.
Кыз шаяруны аңларга теләмәде, исе китмәгәндәй әйтеп кенә куйды:
— Авыл кешесенә сөйләргә гайбәт кенә булсын.— Һәм бер тын сүзсез баргач, өстәде:— Көтәр кешем юк иде бит... Институтка керергә дә булышам дигән иде.
— Шул ялганчыңны сагынасыңмы?
— Күрәсем дә килми.
— Соң, шулай булгач...
Тагы су чайпалуы һәм тәгәрмәч чыйкылдавы гына ишетелеп торды. Сүзне Фаягөл башлады.
— Сиңа охшаган иде ул, Рәхимҗан... Нәкъ син, коеп куйган Рәхимҗан иде менә...
Ул арада Кече басу астына да төшеп җителгән. Җәйләүгә килеп керүгә Фаягөл, ак төенчеген алып, уйнаклап йөгерә-йөгерә терлекчеләр йортына юнәлде. Ат, ияләнгән гадәте буенча, дүрт-биш төп үсеп утырган карамалык күләгәсенә барып туктады. Рәхимҗан аның аркалыгын төшерде, чөелдереген чишеп җибәрде. Алдына арба астында килгән бер кочак тукранбаш китереп салды.
Сулы кисмәкне җиргә төшерү өчен арбага terәтеп куя торган күсәкләрне эзләп маташканда әле генә Фаягөл кереп киткән вагончыктан ике-өч кыз йөгереп чыкты.
— Оҗмах егетебез килгән, хур кызлары, чишмә суы эчәргә чыгыгыз,— дип оран салды арадан берсе. Исмәгыйль хатыны чәрелдек Нурсылу булды, ахры. Рәхимҗан янына беренче шул килеп җиткән иде. Аның артыннан кружка яисә катыклы су ясарга әзерләнгән банка тотып тагы бер төркем хатын-кыз күренде.
— Инде югалткан идек үзеңне,— дип эндәште арадан кемдер.
Җавапны да үзләре үк кайтардылар:

— Фаягөл белән шул тикле җир бергә төш тә, югалма да, имеш...
— Автобуста күренмәгәч тә, уйлаган идем аны,— диде кайсыдыр.
Телләре ни әйткәнне колаклары белән үзләре дә ишетмичә, чыр-чу килеп гайбәт сатуларында булды хатыннар. Рәхимҗан, ишетмәгәнгә сабышып, елмаюын белде, ат тирәсендә йөргән кигәвеннәрне куды, шлеяның чукларын рәтләгән булып торды.

Бераздан әбер-чәбер килгән авазлар сирәгәя төште. Суның тәмлелеген, салкынлыгын мактарга кереште кайберләре. Икенчеләре аның кайсы чишмә суы икәнлеген гоманлый башлады. Һәркайсына үзләренә якынрак чишмәнеке булып тоелды, имеш, шул чишмә суы гына әлегедәй тәмле икән. Бәхәсләшә үк башладылар һәм Рәхимҗанның сүз әйтүен көттеләр.

— Шуны да белмисезме,— дип, катыклы суын болгатып торган Сапиятти сүзгә кушылды.

— Әнә, Сапиятти әйтсен,— диде егет, тел ярып. Үзе берөзлексез атының ыңгырчак суккан төшенә җыелган кигәвеннәрне чыбык белән куалап торды.

Сапиятти, үзенә төбәлгән карашларны зарыктырасы килмичә, суны бер-ике мәртәбә йотып куйды.

— Бумы,— диде ул, җитдиләнә төшеп.— Бу — Ризван каеннарыныкы. Шулай бит, Рәхимҗан...

Егет хәйран калды, Сапияттинең шулкадәр төгәл әйтеп бирүен көтмәгән иде ул. Егет раслагач, кызлар да шаккатты. Ничек белдең дә, ничек белдең, дип тинтерәттеләр үзен.

— Ничек белдең, дип, авызыгыз тәм тоядыр лабаса?..

— Миңа ни, су булгач — барыбер, иң тәмлесе колонкада — ишегалдына чыгасы да аласы,— дип кеткелди башлады Нурсылу.

— Син ялкауга,— диде кемдер, төртмәле итеп,— шуңа артың җиргә тигән дә инде.

— Тигән шул, бик тигән, шундый сиртмә булсын иде әле үзегездә,— дип кеткелдәвендә булды Нурсылу.

Арба читенә килеп таянган Сапиятти нидер сөйләргә җыена иде бугай, кызлар аңар таба борылдылар.

— Мондый су Ризван каеннарында гына,— дип башлады Сапиятти.— Аның салкынлыгы да башка — тешләрне сындырырлык, әмма тамак төбен һичбервакыт туңдырмас. Сусауны аның кебек баскан чишмә юк.

Сапиятти, сөйләп торган җиреннән нидер искә төшергәндәй, туктап уйга калды. Ак халатлы кызлар, кетәклеккә кунган тавыклардай, тыныч кына аның ни әйтүен көттеләр.

— Ул чишмәгә төнлә суга төшкәнегез юкмы?— дип сорады Сапиятти.

— Юк,— диеште кызлар. Төнлә түгел, көндез дә суга төшүнең ни икәнлеген онытып баралар иде шул алар.

— Анда суга төшкән кызлар элек-электән «ах» итә торган булганнар. Айлы төндә ул чишмәнең суы йолдыз булып ява, кызлар,— Сапияттинең күзләрендә серле очкын уйнап алды.— Ә чишмәнең ни өчен «Ризван каеннары» дип аталганын беләсезме соң?

— Ишеткән юк...

— Кем белгән инде аны, сөйлә әле, Сапиятти,— диеште кызлар.

— Моннан күп еллар элек,— дип башлады Сапиятти, арбадагы йомшак печән өстенә иплә генә менеп утыргач,— безнең авыл каршындагы тау өстеннән бер юлаучы егет узып бара икән. Патшага хезмәт итеп, туган ягына кайтып баруы булган инде моның. Җәйге төн икән. Ап-аяз төн, авыл урамнары тынлыкка чумган. Күктә бер ялгызы яңа туган ай йөзеп йөри икән. Талган аякларын бераз ял иттереп алырга дип, яр читенә чүгәләве була егетнең, тау астына күзе төшеп, телсез,

өнсез кала. Ул хәл алырга утырган тау итәгендә чишмә агып ята икән. Нәзек улактан төшкән шул чишмәнең суы вак ташлар өстенә челтер-челтер йолдыз булып·коелып тора икән. Монысы бер хәл... Шунда су буена чиләк-көнятә асып төшеп килгән бер кызны күрә ул. Башлары әйләнеп китә егетнең: йөзе тулган ай, күзләре таң йолдызы булып балкый икән кызның. Ике иңбашыннан билләренә сузылып төшкән толымнары мәмрәп пешкән шомырт тәлгәшләредәй кап-кара, ул сылулыклары... Бөтен җире килешкән-тулышкан, пута кысып торган билләре тал-чыбыктан нәзек икән моның. Авыз ачып эндәшергә тели егет — тавышы чыкмый, капчыгыннан зәңгәр яулык чыгарып шуны болгап карый — кыз күрми, абайламый. Кызның чиләкләренә челтер-челтер йолдыз коелган, чиләкләр мөлдерәмә тулган. Һушына килә алмый калган егет, Нурлы Алан сылуы, сыгылмалы көянтәсен иңенә салып, тыкрыктан кереп югалган.

Шул утырган җирендә таңны каршылаган егет, икенче кичне көткән. Йолдызлы чишмәгә теге сылу тагын килер дип өметләнгән, ә кыз күренмәгән. Егетнең өмете өзелмәгән, ул һаман көткән, көткән... Айлар, еллар буе көткән, тау башына бура бурап, өй салып кергән. Һәм өйнең көнгә караган тәрәзәләре каршына өч каен утырткан. Берсе — ул, берсе — үзем, ә өченчесе — минем сөю билгесе булсын дигән. Ул ак каеннар берсеннән икенчесе сылуырак булып үскәннәр. Ризван атлы егет, шул рәвешле, хәл алырга дип утырган җирендә бер ялгызы гомер иткән, бер күрүдә килгән мәхәббәтенә тугры калган... Чишмәле тау өстендә ул утырткан өч каен әле дә булса исән, аларның ничә яшьтә булуын да белүче юк авылда. Мәхәббәтнең мәңгелеген раслап, әле һаман Нурлы Алан сылуының чишмәгә төшкәнен көтәләр алар... Менә шулай, кызлар.

Соңгы сүзләре белән Сапиятти хикәятне сөйләп бетерүен аңлатырга теләде. Шушы авылда туып, шул су буйларында уйнап үсеп тә, аларның бу хакта ишеткәннәре юк икән. Тынлык әле байтак дәвам иткән булыр иде, чәрелдек Нурсылу гына түзеп тора алмады:

— Һи-и-и, хәзер чишмә түгел, колонкага да чыгасы килми. Чишмә башына төшеп йөргән ди,— дип чәпчеде.

— Әллә ул сылу син иденме соң? — дип, шундук кемдер аның үзен чеметеп алырга да өлгерде. Дәррәү көлешеп алдылар. Авыз ачып ник сүз әйттем дияр көнгә калды, үзе әйтмешли, сиртмәле Нурсылу.

Егеткә, шундый тәмле су алып төшкәне өчен, кат-кат рәхмәтләр әйтеп, кызлар берәм-берәм эш урыннарына таралдылар. Килешле итеп тегелгән ак халат кигән, иң өстенә чиста ак сөлге салган Фаягөл дә аларга иярде. Аның үтеп барышлый яулык читеннән генә Рәхимҗанга аткан карашын һичкем абайламады. Кызның күзләрендә ниндидер очкын кабынган иде, сәер очкын...

## 15

Фаяздан хат килә торды. «Авыл сагындыра, малай, шулай да кайтмыйм. Дөрес, шәһәрдә дә җанны кая куярга белми йөргән чаклар була. Ләкин барыбер, киткән-киткән, кире кайтып булмас ахыры. Берни майтара алмаган икән, диярләр... Әгәр икенче гомер бирелсә, анысын һичшиксез авылда үткәрер идем. Ярый, Рәхимҗан малай, хәзергә. Яз!» — диелгән иде аларның соңгысында.

Ә авылда тормыш үз җаена акты. Көннәрнең берендә урамнар буйлап: «Нурлы Аланга мелиораторлар килгән»,— дигән хәбәр таралды.

Мелиораторлар киләсе, колхозда зур мәйданда сугарулы җирләр буласы, дигән сүз күптән йөри иде инде. Арыш-бодай каерылып уңачак, күпьеллык үләннәр дүрт-биш тапкыр чабылачак, имеш. Авыл

янында гына аркылыга колач җәеп чыга алмаслык зур диңгез хасил булачак дип, шаккатып, исләре китеп сөйли иде нурлы аланлылар. Олысы-кечесе туган авылларында гөлбакча ясарга тиешле шул мелиораторларның килүен көтеп яшәде.

Һәм, ниһаять, «килделәр» дигән хәбәр. Бала-чага иртүк су буена шул мелиораторларны күрергә йөгерде. Ә өлкәннәр — басуда, ындыр табагында. Уракның кызган чагы. Кинәт кызуга киткәнлектән, арышны суктырып бетермәс борын, бодай өлгергән, башагында тулышып арпа коела башлаган көннәр.

Фермага, ындыр табагына һәм авыл эчендәге йомышларга билгеләнгән атларны озаткач, Дада абзый тайлар ябылган аран янына килде. Анда Рәхимҗан Йолдыз Кашканы җигеп маташа иде. Карт аның янына килеп житәр-житмәс үзенең шатлыгын уртаклашырга ашыкты:

— Диңгезнең башланган жире нәкъ безнең бакча башында булачак — түбән очта,— диде ул, балаларча куанып.

— Чынлапмы? — дип сорады егет, куанычны уртаклашкандай.

— Дада абыеңның белмәгәне юк,— диде карт, уенын-чынын кушып.— Кичәгенәк караңгы төшкәч бульдозерлар, жир ташый торган машиналары безнең бакча башына килеп туктадылар.

— Буа шунда булачакмыни?..

— Булмаска, су буеның иң тар жире безнең Карт тирәк чишмәсе турында бит. Мәшәкатьләнеп торасы да юк, ике яктан ишәсе дә төшерәсе генә балчыкны — буа әзер дигән сүз.

— Ә чишмә, Карт тирәк чишмәсе? — дип, сискәнеп куйды егет.

— Карале, чынлап та бит,— дип, гажәпсенеп калды карт, шул сораудан кинәт аңына килгәндәй.— Мин карт тиле ул хакта бөтенләй уйламаган. Чишмәне — жимерәләр ызначыт... Менә карт тиле, куанып йөргән булам тагы.

— Ничек, жимерәләр?..

— Бульдозер белән ызначыт... Менә карт тиле.

Егет, ниндидер карарга килгәндәй, ашыга, кабалана башлады. Камыт бавын тарттырып, аркалыкны күтәрде дә дилбегәне кулына чорнап тоткан көе арбага сикерде.

— Киттек, Дада абзый, киттек! Кичегергә ярамый! — дип кычкырды ул, әмер биргәндәй.

— Менә карт тиле,— дип сукрана-сукрана Дада абзый да арбага кунаклады.

Алар утырган ат урамга чабып чыгып китте. Абзар капкасын ябарга да оныттылар. Алгы күчәр, берьяктан имән баганага эләгеп, уч төбедәй йомычка каерып чыгарды.

— Вәт, карт тиле, шуны да уйламаган,— дип, һаман үзен сүкте Дада абзый. Арба дыцгырдавыннан аның тавышы калтырап, бүленеп-бүленеп ишетелә иде. Төшеп калмыйм тагы дигәндәй, үзе четердәтеп, ике куллап үрәчәгә ябышкан, аякларын арба төбенә җәелгән кабыкка ук күтәреп куйган.

Рәхимҗан исә утырып тора алмады. Башта тезәнлекләп карады. Әмма бераздан, ашыгудан үзен кая куярга белмичә, арба өстенә торып ук басты. Дилбегә очын берөзлексез пропеллер урынына баш өстендә әйләндереп куалады атын. Йолдыз Кашка томырылып чабуын белде.

— Ә Бакырчы чишмәсе белән ни була? — дип кычкырды егет, атка дилбегә очы белән кизәнеп.

— Су астында кала, ызначыт,— дип җавап бирде карт, арба эчендә аякларын сузып утырган жирдән.

— Чегән чишмәсе нишли?

— Күмелә, ызначыт...

— Ризван каеннарыныкы?

— Анысы да, ызначыт...

— Фазыл чишмәсе дәме?

— ....ызначыт.

Алар бер-берсен ишетми иде инде, шуңа күрә карт һәр сорауга «ызначыт», дип кенә барды. Егет тагы да ярсыбрак куалады атын. Сорау бирмәде башка. Ә урамнар буп-буш иде, һәркем эштә — эшнең кызу чагы. Әледән-әле Дада абзыйның «Вәт карт тиле», «Вәт карт тиле» дип, үз-үзен тиргәве генә ишетелеп торды.

Түбән очка житеп, су буена каергач, арба шалтыравы ишетелми башлады. Берсеннән икенчесе уздырырга теләгәндәй үкерешеп, бульдозер һәм скриперлар җир актара иде. «Диңгез ясаучы»ларны күрергә җыелган малайлар як-яка сибелеп юл бирде аларга.

— Туктагыз!..— дип кычкырды арба өстеннән сикереп төшкән Рәхимҗан. Аны ишетүче генә булмады. Иләмсез зур трактор йөз яшәр карт тирәкне төбе-тамыры белән аударган да шуны читкә өстерәп маташа иде. Тирәк карыша — китәргә, буйсынырга теләми, юан ботаклары белән, тамырлары белән җиргә, су читендәге вак ташларга ябышып калу җаен эзли, карышмакчы була. Трактор бераз артка биреп, яңадан тарттырып карады — таш өстендә бушка әйләнеп торган тимер башмаклар астыннан бөрөзлексез очкын чәчрәп торды. Алай да барып чыкмагач, тагы бер трактор тагылды тирәккә, икәүләшеп үкерделәр. Түзмәде тирәк — сыкрау авазлары чыгарып, бирешергә мәҗбүр булды.

Ә инешнең аргы ягында, элек чишмә булган турыда, ике бульдозер һаман да җир актара. Берсе артыннан икенчесе чиратлашып йөри-йөри каезлый иде алар чишмәле тау битен. Үз күзләренә ышанмый, күз алдындагы хәлләр куркыныч бер төш кенәдер дип гаҗәпләнеп, исе китеп торды Рәхимҗан. Чишмә, бульдозер үткән саен, балчык һәм ташлар астында күмелеп кала. Ләкин озакка түгел, икенче бульдозер килеп җитәргә өлгерми, ком һәм балчык арасыннан фонтан булып яңадан бәреп чыга чишмә. Тагын күмелә, тагын бәреп чыга. Тагын, тагын... Шул рәвешле, бөрөзлексез үкереп эшләп торган зур-зур ике бульдозер белән тарткалаша иде Карт тирәк чишмәсе. Куеныннан алынган кызыл балчык инде тау кадәрле өелгән булуга да карамастан, һаман бирешми, бирешергә теләми иде тирәксез калган Карт тирәк чишмәсе.

Рәхимҗан яңадан аты янына ыргылды, арбага сикерде. Су буендагы мәхшәрне күреп чарасыз калган Дада абзый читкә тайпылып өлгерде. Чишмәгә таба үкереп, җир актарып килгән бульдозер каршына атылып кергән җигүле ат башын югары чөйде һәм бар көченә кешнәп җибәрде. Йолдыз Кашканың күзләре акайды. Башын каера төшеп, бер хуҗасына, бер үзе өстенә үкереп килгән коточкыч зур бульдозерга каранды ул. Акайган күзләрен кан баскан иде аның.

— Туктагыз!.. Хәзер үк туктагыз...— дип, җан ачуы белән үрсәләнеп кычкырды егет.

Бульдозер тукталып калды, Рәхимҗанның яшьтәше чамасындагы егет кабинадан башын чыгарды.

— Син нәрсә, үз акылыңдамы? Ал атыңны...— дип кычкырды ул трактор гөрелтесен уздырырга тырышып.

— Туктагыз! Үз акылымда мин, туктагыз! — дип кабатлады Рәхимҗан, йөзенә, маңгаена чәчрәгән болганчык суны тельняжка җиңе белән сөртеп.

Җир актарган тракторлар, үкерүдән җиңелчә гөрелтегә күчеп, бөрәм-берәм туктап калдылар. Кабиналардан төшкән трактористлар дилбегәсен чорнап тоткан көйгә һаман арба өстендә басып торган Рәхимҗанга таба атладылар.

— Син нәрсә... Дөньядан туйдыңмы әллә? — дип кычкырды берсе.

— Буаны монда буарга кем рөхсәт итте сезгә? — дип эндәште Рәхимҗан, мөмкин кадәр үзен тынычрак тотарга тырышып.

— Ә син кем буласың? — Сорауга каршы сорау белән эндәште тракторчыларның өлкәнрәге.

— Мин — Айтуганов! — диде ул ачык һәм үз-үзенә ышанган тавыш белән.— Буаны монда буарга ярамый, ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыккан...

Тегеләр икеләнеп калды, бер-беренә каранып алгач, тагы шул ук өлкән тракторчы эндәште:

— Безне баш инженер чакырды. Үтенеп сораганга, чиратсыз — бер көнгә генә килдек авылыгызга. Вакыт юк, бүлдерәсез...— диде. Башкалары да үзләренең эше ашыгыч икәнлекне аңлатып шаулашып алды, сәгатьләренә күрсәттеләр.

— Бераз көтегез, хәзер мин Мирзанур абыйны алып төшәм,— диде Рәхимҗан.

— Анысы кем тагы?..

— Председатель.

— Ә син кем?

— Мин...— Айтуганов!

Күрәмсең, аны колхоз җитәкчесе дип кабул иткәннәр иде. Тракторчылар бер-беренә каранып, иң өсләрен сикертеп алдылар.

— Тиз булыгыз анда, капкалап кына алабыз,— дип калды алар.

— Киттек, Дада абзый,— дип, Рәхимҗан атын авылга таба борды.

Председатель идарәдә юк иде, ындыр табагында таптылар үзен. Сүзне өлкән кеше Дада абзый башлады.

— Бу ничек була инде, Мирзанур? — диде ул.— Авылны чишмәсез калдырырга булдыгызмыни?

— Кем әйтә аны, Дада абзый, нәрсә булган? — дип, аңышмады председатель.

— Белмисең, ызначыт... әллә белмәгәнгә сабышасыңмы? Ә инешне анда Карт тирәк чишмәсе турыннан буып яталар,— диде карт, дулкынлануын яшерә алмыйча.

— Чишмәләрне су астында калдыру дөрес түгел, Мирзанур абый. Әйдәгез, туктарга кушыйк үзләренә,— дип, Рәхимҗан аны тизрәк су буена төшәргә чакырды.

Председатель, эш калдырып йөрисез шунда дигәндәй, кашын җыерып алды, уңга-сулга каранды. Һәм амбар өе янында механизаторларга нидер аңлатып торган баш инженерны үзенә дәште.

Сөйләвеннән тукталып, председатель янына килде баш инженер. Аның шул хәрәкәтеннән үк тәвәккәл һәм энергиясе ташып торган егет булуын күзалларга мөмкин иде.

— Ашыккансың! — диде председатель кырыс тавыш белән.

— Кайда? Нәрсә? — дип, аңышмый торды баш инженер.

— Буа будырырга дим...

— Барыбер будырасы ич аны,— диде баш инженер, «ә-ә, эш шуңарда гынамыни» дигәндәй, җанланып китеп.— Таныш егетләр, сүз тыңлап кына килделәр. Бер көндә әзер булачак.

— Ә проект бармы?

— Юк,— диде баш инженер, һич исе китмичә.— Ләкин булачак. Җир эшләрен язга-көзгә калдырасы килмәгән иде, икеләтә, өчләтә күбрәк каерачаклар. Түләү бездән ич...

— Проект кая? — дип кабатлады председатель, тавышын күтәрә төшеп.— Су буен, чишмәләрне су астында калдырырга кем рөхсәт итте? Төшеп, хет бер күргәнең бармы безнең су буен?

Шунда гына баш инженер, председательнең чынлап сөйләшүен аңлагандай, җитдиләнеп калды. Шулай да тиз генә сер бирәсе дә килми иде аның.

— Чишмә санап йөрмәсәм дә җитәрлек ич минем эш. Авылга су

кертелгән, Мирзанур абый, колонкалар җитәрлек. Югалту юк, барысы да уйланылган.

— Туктатсыннар,— диде председатель, янәшәдә торган җиңел машинага ымлап.— Хәзер үк туктатсыннар эшне. Күпкә түзгәнне, азга түзәрбез буасыз да.— Һәм җәлт кенә машина кабинасына кереп шуган егетнең артыннан кычкырып калды.— Төшкән-төшкән, бер очтан чишмә суын да эчеп кайт...

Кичен, көтү кайтыр вакыт җитеп килгәндә, Рәхимҗан яңадан төште Карт тирәк чишмәсе янына.

— Диңгез ясаучылар китте, абый,— дип кычкырып калды аның су буена төшеп баруын күргән бер бәләкәй малай.

«Кемгә нәрсә...» дип уйлап куйды ул күңеленнән генә. Чөнки теге малайның кәефе тәмам кырылган күренә иде. Шундый зур вакыйга, була дип көткәндә генә, булмый калсын әле...

Су буе иртәнге шау-шудан тынып калган. Вак ташлар белән серләшкән инеш челтерәве генә ишетелеп тора. Кызыл балчык астында калган чишмәдән агып төшкән болганчык су инешкә хәвеф төсе өстәгән. Чәчләренә бәс төшкән берничә агай бер читкә йолкынып ташланган карт тирәк өстендә серләшеп утыра. Баеп барган кояштан инешкә таба аларның күләгәләре сузылган. Бу күләгәләр шул кадәр озын иде ки, алар икенче офыккача барып тоташкан сыман тоелды егеткә.

Чишмә янында беразга тукталып торгач, югарочка су буйлап кына менәргә ният итте ул. Ләкин күп китәргә өлгермәде, Чегән чишмәсе турындагы тыкрыктан бала җитәкләп төшеп килгән яшь хатынны күреп, аяклары атламас булды. Ул хатын — Зәйнәп иде. Әле кайчан гына шушы су буенда, шушы турыда аның белән таң каршылаган Зәйнәп! Тәненнән кырмыскалар чабышып узгандай булды егетнең, эсселесуыклы булып китте.

— Рәхимҗан, синме?..— дип эндәште Зәйнәп.

— Мин, Зәйнәп,— диде Рәхимҗан.

— Син шундый үзгәргәнсең, Рәхимҗан...

— Ә син һаман шул...

— Минем сине диңгезче киемендә күрәсем килгән иде... Сиңа тельняжка килешә, Рәхимҗан.

— Ә сиңа нәрсә кисәң дә килешә...

— Бала дамы? — диде Зәйнәп, елмая төшеп.

— Бала да...

— Рәхмәт, Рәхимҗан, син һаман элеккечә икәнсең.

— Юк, үзгәрдем,— диде егет, бу сүзләренә нинди дер мәгънә сеңдерергә омтылып.

— Әйе, син олыгаеп, чын егет булып киткәнсең, Рәхимҗан.

— Күпкә кайттыңмы? — дип сорап куйды егет, сүзне икенчегә борырга теләп.

— Бер-ике атна ял итәргә исәп,— диде Зәйнәп. Һәм бераз уйланып, аяк очына карап торгач, өстәп куйды тагы.— Безнең авыл шундый матур икән, Рәхимҗан.

— Әле генә белдеңме?! — диде егет, авылның Зәйнәпкә дә охшавына чын күңеленнән куанып.— Ә үзең авылдан тизрәк китәргә ашкындың.

— Ашкындым...— диде Зәйнәп, күз алдына үсмер чагын китереп. Күкрәк тутырып тирән сулыш алды, аннары аяк очында тукталган карашын туры егеткә төбәде.— Авылда яши алмас идем барыбер.

— Нигә?

— Авыл кунакка кайтканда гына әйбәт... Ә сезнең матурлык күрергә, аның табигатенә сокланырга вакытыгыз юк.

— Авыл кешесе дә ике күзле, Зәйнәп. Ялгышасың!

Шунда ул үзенең әлеге матурлыкны яклап бүген генә дә күпме борчылу кичерүе хакында сөйләмәкче булган иде. Ләкин бу ниятеннән кире кайтты.

— Әни, әни, монда су бар,— дип эндәште су читендә кайнашкан баласы.

— Өйләндеңме? — дип сорады Зәйнәп, кызыксыну белдереп.

— Өлгермәдем әлегә,— диде егет. Хәер, Зәйнәп бу хакта үзе дә белә иде булса кирәк.

— Әни, әни, монда таш бар,— дип эндәште вак ташлар өстеннән йөгереп барган бала.

— Нурлы Аланда матур кызлар күп иң,— диде Зәйнәп, егетне шелтәләгән сыман итеп.

— Нурлы Аланда кызлар бар... егетләр дә төшеп калганнардан түгел,— дип, төртмә сүз әйтеп ташлады Рәхимҗан. Үзе шундук әлеге сүзләренең урынсызрак килеп чыгуын чамалады.

— Әни, әни, монда чәчәкләр бар,— дип эндәште тугайда йөгереп йөргән бала.

— Укырга уйламыйсыңмы? — дип сорады Зәйнәп.

— Читтән торып укырмын, ахры,— диде егет.

— Әни, әни, бу нинди абый? — дип сорады алар янына килеп җиткән бала.

— Бумы?.. Бу... бер абый,— дип югалып калды Зәйнәп. Рәхимҗан үз гомерендә беренче мәртәбә аның шулай уңайсызланып, ни әйтергә белми торуын күрде.

— Миңа кайтырга кирәк. Сау бул, Зәйнәп,— диде егет.

Зәйнәп ни дияргә белмәде, тибрәнеп-тибрәнеп тирән сулыш алды — күкрәгендә берьюлы ике җан һавага ашып кире урыннарына кайтты. Тагы! Тагы тибрәнде җан. Күзләрен тутырып, китәргә җыенган егеткә карады хатын.

— Әни, әни, абый нигә китте? — дип сорады бала.

— Абый ашыга, аңарга китәргә кирәк,— диде Зәйнәп.

Рәхимҗан артына борылмады. Алсуланып баеган кояшка таба атлап, ул туп-туры су буйлап китеп барды. Күзләреннән әллә ал шәфәкъ нурлары тамды, әллә нур булып чык бөртекләре йөгерешә...

## 16

Кече Басу астына печәнгә барышлый бүген дә юл уңаена чишмә суы тутырып алды Рәхимҗан. Җәйләүдә кызлар Ризван каеннары чишмәсе суын көтә. Көннең кызу чагында төшереп җиткерәсе иде үзләренә.

«Җәйләүдәге суны элек эчкән өчен рәхмәт, Карамалы яр чишмәсенең суы бидондагы сөтне суытыр өчен генә ярый»,— дип сөйли иде хәзер сыер савучы кызлар. Аларга Ризван каеннарыныкы кирәк! Шуның белән бетсә бер хәл, беркөн Сапияттәй сөйләгәннәрдән соң кайбер кызлар караңгы төшкәч чиләк-көянтә асып чишмәнең үзенә үк йөри башлаганнар, имеш... Исмәгыйле белән үпкәләшкән көнне, моңарчы колонкага йөрергә ияреңгән Нурсылу да, дөрес булса, сыңар чиләк тотып, Ризван каеннары чишмәсенә төшкән...

Рәхимҗан юл читендәге басуның мәһабәтлегенә сокланып, уйга чумып бара иде: әле кайчан гына арба тугымына җитмәгән кукуруз инде ат сыртыннан узып бара. Ә юлның икенче ягындагы бодайдан җилләр искән. Әле кичә генә комбайннар кермәгән дә иде, бүген рәт-рәт булып салам күбәләре генә утырып тора. Нәкъ әкияттәгечә — күз ачып йомганчы әйләндереп тә салганнар.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

. Шунда, искә төшереп, кесәсен капшады ул. Әле иртән генә почтальон хат биреп узган иде, укырга оныта язган. Хат Фаяздан иде: «Сәлам, Рәхимҗан! Бер көе яшәп яткан көн әле. Вакыт, завод белән тулай торак арасында йөреп, үтә дә китә. Буйдаклыктан да туйдым, өйләнәсе дә килми. Йөргән кызлар күп, күңел үз иткәне юк. Их, безнең умырзая җыеп йөргән чаклар... Хәтерлисеңдер бит, малай. Ярый, хәзергә!»

Каядыр якында гына көлү авазы яңгырап китте. Йолдыз Кашка сискәнеп куйды. Егет тә, кабаланып, тавыш килгән якка текәлде. Кукуруз арасыннан аларның каршысына Фаягөл килеп чыккан икән, кулларында бер кочак кыр чәчәге — «зәңгәр тәтәй». Рәхимҗанга атны туктатудан башка чара калмаган иде.

— Ә-ә, син икәнсең...— диде егет, бер дә исе китмәгәндәй. Ә үзе бу очрашуга шатланган иде югыйсә.

— Менә, зәңгәр тәтәй җыйдым, сыерга шифасы була икән,— диде Фаягөл. Ләкин ул күпме генә шаян һәм тыныч булырга тырышса да, кабалануын, дулкынлануын яшерә алмады. Сүзләренең җайсызрак чыгуыннан уңайсызланып, зәңгәр тәтәйдән болайрак зәңгәр күзләре белән бер чәчәккә, бер егеткә каранды. Әйтерсең, Рәхимҗан алдында аның ниндидер гаебе бар иде.

— Ярый, алай булгач мин китәм. Печән дә чабасы бар, төшә торам,— дип, кулыннан ычкынган дилбегә очына үрелде егет. Ул үзе дә зәңгәр тәтәй белән зәңгәр күзләр арасында адашкан, онытылып калган кебек иде бу мәлдә.

— Бер ялгызымны калдырып, җәяү йөгертер идеңмени,— диде Фаягөл якты елмаеп. Ул инде үзен кулга алып өлгергән иде. Арбага башта чәчәкләрен китереп салды. Аннары, утыртасыңмы-юкмы дигән сыман, егетнең каршысына ук килеп аңарга зәңгәр нурларын бөркеде.

Егет Фаягөлгә туры карарга тырышты. Аның сөйкемле булып эчкә батып торган бит алмаларына, алардагы вак сипкелләргә игътибар итте. Аккошныкыдай йомшак муенны, җәйге юка күлмәк эченә түш турында гына кереп югалган серле сызыкларны да сыйдырган иде ул караш. Шул сызыкларның дәвамыдай ике ак күгәрченнең читлекләренә сыеша алмый ирекә ашкынып талпынуын да аермачык абайлады хәтта. Фаягөл исә, ниһаять, иркен сулыш алып, чаяланып, арбага, аның янәшәсенә менеп утырды.

— Я,— диде ул, чарасыз калган егетнең тыгыз беләгенә нәни бармаклары белән нпле генә кагылып,— ашыгадырысың түгелме...

Рәхимҗанның дилбегә какканын да көтми кузгалып китте Йолдыз Кашка. Егет бер яны белән Фаягөлнең җылы иңбашын, ярым ялангач беләген һәм күлмәк итәкләрен тоеп барды. Ат кисәгрәк тартылган саен селкенеп куйган Фаягөл, кисмәктән су чәчрәүне сәбәп итеп, аңар тагы да елыша төшә иде. Рәхимҗанга торган саен рәхәт тә, уңайсыз да була барды. Фаягөлнең түгәрәкләнеп торган билләренә ике куллап ябышасы, аны үзенә таба суырып аласы һәм туйганчы, күзләреннән яшьләр чәчрәп чыкканчы кочаклыйсы, иркәлисе килде. Әмма, кулындагы дилбегәне кая куярга, ни эшләтергә белми аптырады. Ике куллап, чытырдатып дилбегәгә ябышкан иде ул.

Тормыш тәҗрибәсе ягыннан егеттән бер баскычка өстен торган Фаягөл барын да күреп, тоеп торды, әлбәттә. Егетне шулай күзәтүе кызык та, кызганыч та иде аңарга. Ниһаять, дилбегәне үз кулына алыр вакыт җиткәнлеген чамалап, ул атны үзе туктатты.

— Рәхимҗан,— дип пышылдады кыз, сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә нпле бер хәрәкәт ясап, һәм кулларын бер-бер артлы егетнең муенына суздьі. Күзләреннән тагы зәңгәр яктылык бөркелде аның.

Егетнең беләкләренә ташкын булып кинәт кенә җегәр тулды, җегәр өстәлде. Кызны кочагына аласы, күтәреп офыкларга кадәр алып

китәсе, күтәреп йөртәсе килде аның. Әмма көпә-көндез һәм юл уртасында бу турыда уйлау мөмкинме соң... үз уйларыннан үзенә үк оят тоелды Рәхимҗанга. Берәм-берәм үзен Фаягөлнең сарылып торган кулларыннан арындырды ул. Ә кыз үпкәләмәде һәм берни сиздермәде. Рәхимҗаннан кружка сорады, кисмәктән су чумырып алды да, сусаган иреннәренә сак кына тидереп, бер-ике мәртәбә йотып куйды. Ә күзләре һаман егеттә булды. Сынап карый идеме ул, әллә үртәпме...

Шунда Фаягөл яңадан бер кат балкып куйды. Күз иярмәс җәһәтлек белән кинәт кенә дилбегәне тартып атны куалады һәм кружка төбендә калган салкын суны Рәхимҗанның чуендай кызган тәненә сибеп, арбадан читкә атылды. Арба өстендә калай кружка гына тәгәрәп калды. Бу хәрәкәтләр шул тикле көтелмәгән арада булды ки, кызның ни рәвешле боларның барысын да башкарып чыгуын абайламый да калды Рәхимҗан. Үпкәләү булдымы бу, үртәүме... Яңа урылган бодай басуына, чишмә челтерәгән сыман, көлү авазы таралды, алтын сары камыллар өстеннән йөгерде ул көлү.

Салкын тамчылар егетне айнытып җибәрде. Ул аны-моны уйлап тормыйча, кинәт өермәгә, пәри туена охшаш җәһәтлек белән үзе дә кружкага кисмәктән су чумырып алды һәм бәхетле көлү авазына ияреп, чабып китте.

Артыннан Рәхимҗанның куып килүен шундук эчке бер сизенү белән тоеп алды Фаягөл. Адымнарын тагы да ешайтып, яшь кәҗә бәтиедәй уйнаклап, тигез рәт булып тезелгән бодай саламы күбәләре арасыннан йөгереп үтте ул.

— Миңа су сибүче син идеңме...— дип кабатлый-кабатлый поши сыман дәү-дәү атлап куып килгән Рәхимҗан аңарга тиз якынлашты.

Алай гына тоттырырга теләмәде Фаягөл. Әмма егет гел якынлашып үк житкән иде инде. Кыз, житез хәрәкәт ясап, куып килүче су сибим дигәндә генә салам күбәсенең икенче ягына кереп кача. Егет тагын куып житә, кыз, кинәт борылыш ясап, икенче читкә тайпыла. Егет сипкән су тигәндерме-юкмы, шундый борылышларның берсендә Фаягөл, сискәнү авазы чыгарып, салам өеменә сикерде. Ишелеп төшкән салам астында ул шундук күренмәс тә булды. Куышлы уен белән мавыгып онытылган Рәхимҗан да дулкын булып ишелгән салам астына кереп чумды. Дулкын аны шундук эләктереп алды һәм кыз янына илтеп салды. Муенында Фаягөлнең йомшак беләкләрен, аның җиңелчә ыңгырашуга охшаш еш-еш сулыш алуын, иреннәре кайнарлыгын тойды ул. Салам өстенә сикергәндә җил ачып җибәргән күлмәкләрне дулкын берьюлы читкә бәреп атты. Бер-беренең йөрәк тибешеннән башка һични ишетмәде һәм тоймады алар.

Фаягөлнең йомшак иркәләү тавышыннан гына күзен ачты Рәхимҗан. Юл читендә туктап калган җигүле ат көтеп тора. Ә юлда тузан күтәрелгән... Йөрәге «жу-у» итеп куйды егетнең. Алар турыннан гына җиңел машинада председатель узып бара иде.

## 17

Бер-беренә башка күтәрелеп тә карамады алар ул көнне. Сулы кисмәкне урынына елгыр гына илтеп, кызлар йөгерешеп чыкмас борын, печәнлеккә таба атын юыртып китеп тә барды Рәхимҗан. Печән төяп кайтышлый да җәйләүне әйләнеп кенә узды.

Фаягөлне күпме генә уйламаска тырышмасын, булдыра алмады — аның кулларының кайнарлыгы әле дә булса иркәләп тора иде сыман. Берничә сәгать элек кенә үзләре очрашкан урынны абайламый үтеп китүдән курыккандай, йөк өстенә тезәнлекләп үк басты ул. Каядыр шушы тирәдә иде бугай, дип карангалап барганда, Йолдыз Кашка ки-

нәт бер сәбәпсез туктап калды. Рәхимҗан, дилбегәне кагып, аны кузгатырга теләде. Ат кузгалмады — башын борып, дуга аша хуҗасына карап куйды. Бу хикмәтле карашны ни дип юрарга да белмәде егет, йөк өстеннән төшеп, ат янына килде. Кеше ышанмаслык хәл иде — ат туктап калган урында тәгәрмәч эзенә аркылы икс чәчәк, ике зәңгәр тәтәй ята икән! Алар, әйтерсең, җанлы иделәр, Фаягөлнең янып торган зәңгәр күзләрен хәтергә төшерделәр. Димәк, ат та шуны тойган булып чыга... Шатлыгыннан атның яңакларын сыйпап алды, маңгаендагы йолдыз сыман янып торган ак кашкага кунган клевер яфракларын аралады. Каян кушсаң — шуннан йөрергә күнгән атның ике зәңгәр тәтәй каршында тукталып калуына аның әле һаман ышанасы килми иде.

Йөк өстенә менеп сузылып яткач та әле байтак кына Йолдыз Кашканың зирәклегенә сокланып барды ул. Ләкин тора-бара әлеге соклануны башында буталган төрле уйлар басып китте. Иң әлек хуҗасыз ат янынннан узып киткән җинел машина тынгылык бирмәде аңар. Председатель ни уйлады икән, дип борчылды. Ул да түгел, хыялында әле Фаягөлнең чаялыгы, дөньяны оныттырган назы калкып чыга, әле Зәйнәпнең ике як иң өстенә сузылып төшкән шомырт-кара толымнары җилфердәп балкып ала. Әйе, шушы көннәрдә генә су буенда очраган гүзәл яшь хатын түгел, шомырт-кара толымын җилфердәтеп урманда умырзая эзләгән Зәйнәп килде аның хәтеренә. Бер кочак зәңгәр тәтәй арасыннан карап торган зәңгәр күзләр һәм шомырт-кара толымнар, үзара тарткалашып, берөзлексез алышынып торды күз алдында. Һәм шунда, үзе дә абайламастан, күңеленә килгән җырны көйли башлаган:

> ...Һавадагы йолдызларны
> Нигәдер санамадым шул, Зәйнәбем.
> Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
> Рәхәт үтсен җәйләрең...

Үсмер чакларыннан бирле күңелендә йөргән шушы җырның нәкъ менә шушы минутта хәтергә килүенә уңайсызланып куйды ул. Зәйнәп исеменә, аңа булган беренче хисләренә, әлегедәй гүзәл җырга лаек түгел сыман тоелды ул үз-үзенә. Күзе янә кулындагы ике зәңгәр чәчәккә төште, ул аларны иреннәренә, борын очларына тидереп иркәләде, аларның бер үк вакытта гади дә, искиткеч нәфис тә булуына сокланып барды.

Ат инде авылга якынлашып килә иде. Шунда Ризван каеннары ягыннан тук та тук яңгырап ишетелгән балта тавышы сискәндереп җибәрде. Әйе, балта тавышы иде бу. Йолдыз Кашканы ашыктыра төште Рәхимҗан. Әмма өлгермәде — аның күз алдында Ризван каеннарының берсе, сыкрау авазы чыгарып, җиргә мәтәлде. Ничек аңларга, нәрсә дияргә дә белмәде ул — бүгенге көннең саташуга охшаш вакыйгалары дәвамы идеме бу?.. Йөк өстеннән шуып төшеп, җан-фәрман каеннарга табан йөгерде.

— Нишлисез, кабәхәтләр, нишлисез?.. Ризван каеннары бит алар,— дип кычкыра иде ул килә-килешкә.

Каен янындагылар, бу ни хикмәт дигәндәй, сәнәк тотып үзләренә каршы йөгергән егетне күреп, берара югалып калдылар.

— Завклуб кушты, бүген театр була... Ташла әле, болгама шул сәнәгеңне,— дип телгә килде каен очының җиргә авып төшкән ябалдашлары артына поскан ыспай егет. Рәхимҗанның беренче күрүе иде аны.

— Яшьти, кара аны, ул тикле үк куркытма, Хәлил шыр җибәрә күрмәсен,— дип сөйләнә-сөйләнә агач башыннан Рәхимҗанның класстагы Хамис төшеп килә иде.

Кызарып чыккан күзләре иләмсез ялтырый иде Хамиснең. Авызы колагына җиткән. «Шайтан суы артына йөгергән монын»,— дип уйлап

алды Рәхимҗан. Башта шап итеп кулындагы балтасы килеп төште Хамиснең, аннары очсыз калган каен кәүсәсеннән үзе сикерде.

— Яшьти, кызма әле син, әйдә бераз кәефне күтәреп алыйк,— дип, икенче каен төбенә җәелгән газета янына чакырды ул Рәхимҗанны. Хамиснең бөтен килеш-килбәте, кыланышларыннан олы бер эш кырган сыман канәгатьләнү сизелеп тора. Рәхимҗанның үзенә иярмәвен чамалап алгач, ярты шешә аракыга каплап куелган буш стаканны шалтыратып, янәшәсендәге юлдашына дәште ул.

— Хамис тотынса булдырмыймы соң... Менә дигән каен. Мондыйны син көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың,— диде дә голтголт йотып куйды. Җирдә аунап яткан каенның яфраклары арасыннан аралап, кабалана-кабалана бер-ике каен әкәе өзеп капты. Аларны бер тын чәйнәгәннән соң кире җиргә төкерде. Аннары тагы әмерхан бәрәңгеседәй аксыл йөзле теге ыспай егеткә мөрәҗәгать итте.

— Каенның мондыен табарга кирәк әле. Сәхнәгә чыгып Галиябануны кымтырыклау түгел ул сиңа. Күрәсеңме, әнә, яшьти булып яшьти сәнәк күтәреп килгән,— дип, бер читтә торган Рәхимҗанга күз кыскан булды.— Хәлил, имеш, ә чын исемең, брат, бармы соң синең?

— Гелозанджанович,— дип җавап кайтарды тегесе. Ул үзенең исемен әйткәндә тагы да җитдиләнә төште, әйтерсең, сәхнәдә чыгыш ясый.

Шайтан суыннан күркә сыман һаман кызара барган Хамис кабаткабат сораса да, егетнең чын исемен аңлый алмады.

— Гелозанджанович, Гелоз Анджанович...— дип, тамак төбеннән чыккан әче тавыш белән тик кабатлап торды ул.

Рәхимҗан да аңлый алмады бу исемне. Район үзәгеннән килгән әлеге артистлар китеп байтак вакыт узгач кына белде ул ыспай егетнең кем булуын. Күрше Җәке авылыннан кладовщик Галимҗан малае Гөлүс, Гөлүс Галимҗанович булган икән ул.

Хамис исә аңарга һаман да Хәлил дип эндәшүендә булды.

— Галиябануың ничек соң? Галиябануың шәпме?

— Ну, ничек әйтергә сиңа, Галиябану яхшы, Галиябану начар була алмый,— дип җавап бирде артист егет. Исерекнең шаяруын әллә аңламады, әллә аңламаганга гына сабышты ул — бик җитди итеп аңлатырга тырышты.

— Син нәрсә, җен шулай иткән нәрсә... Мин синнән нинди дип сорыйм, ә син миңа «начар була алмый, начар була алмый», имеш,— дип гел чынлап ук бәйләнә башлады Хамис.

— Нәрсә дим соң, әйбәт дим ич инде...— дип шүрли башлады егет.

— «Әйбәт» имеш,— дип, мыскыллап кабатлады Хамис, артист егетнең сөйләмендәге кыланчыклыктан көлеп.— Синең өчен әйбәт булу берни түгел, син аны миңа аңлатып күрсәт. Ягъни мәсәлән, менә болай итеп, кулларың белән, задный мустларын, фарсункаларын, фараларын дигәндәй күрсәтеп әйт. Мине җүләргә санап торган буласың, яшьти каршында бит әле. Беләм мин сезнең ишеләрне...

— Ну, әйбәт инде, әйбәт,— дип, кулларын үз гәүдәсе тирәсендә йөздереп күрсәтте куркуга калган егет.

— Шулай диләр аны,— шайтанга әверелгән Хамис уч төпләрен төкерекли-төкерекли угалап куйды.— Бүген мин Исмәгыйль булам, ишетәсеңме, яшьти, Исмәгыйль булам. Менә бу нәмәрсәнең борын төбеннән суырып алмасам, исемем Хамис булмасын!

Ул дәртләнеп китеп, аягүрә торды. Артист егетнең каршысына килеп басты һәм теленә салынуын дәвам итте. Ә Рәхимҗан, аларның икесенә дә бер дәрәҗәдә нәфрәтләнеп каршыларында басып торган Рәхимҗан, ни әйтергә дә белмәде.

— Тагы бер ярты куймасаң, каеның-ниең белән ботарлап атам,— Галиябануыңны урам уртасында тотып кычкыртам... Ишетәсеңме, Хәлил,— дип дәвам итте Хамис.

— Син нәрсә, Хамис дус, булды, булды — тагы бер ярты синеке,— дип, ярарга тырышуында булды Гелозанджанович.

— Мондый каенны мин генә табам, Галиябануыңа әйт, Хамис тапты диген, яме! Үзем дип мактанасы булма!

— Ярар, Хамис дус, ярар.

Рәхимҗан озак түзде, әмма башка басып торыр хәле калмаган иде инде. Хамискә якынрак килде дә, борын төбенә йодрыгын терәп, тавышын күтәрде:

— Шушы авылныкы бит син... Нинди каен кискәнеңне беләсеңме?

— Каен булгач — каен инде. Кирәк булса, алмагачын да кисәрбез,— дип, авызын ерды шайтанга охшап калган классташы. Аның күзләре, үз-үзен тотышы, бөтен кыланышларына кадәр ямьсез һәм куркыныч иде.

— Ризван каеннары ич, кабәхәт... Изге каеннар.

— Миңа ни, булмагае... Ярты литрдан да изге нәмәрсә юк.

— Кит, ичмаса син юлымда торма,— дип, артист егетне читкә этеп, аны-моны күрми атка таба китеп барды Рәхимҗан.

— Яшьти, син кызма әле, кызма алай,— дип калды аның артыннан сәрхүш классташы.

— Сәнгатьне аңламыйсыз! Карт каенның очы ябалдашлы була,— дип, аңарга кинәт батыраеп киткән Гелозанджанович кушылды. Бу аның үзенә күрә Хамискә ярарга тырышуы иде.

— Тагы бер ярты һәм Галиябану, ишетәсеңме, Хәлил?..

— Булды, килештек, егет сүзе — бер булыр.

— Ха-ха-ха, егет сүзе, имеш,— дип шаркылдап көлгән тавышы ишетелде Хамиснең. Аңарга кушылып Гелозанджанович та көлде. Алар икесе дә көлеп калдылар. Авыл каршындагы тау башында, ботарлап атылган каен янәшәсендә икәү бер булып көлделәр алар, озак көлделәр. Бик озак! Шаркылдап көлгән тавыш түбән төшеп, су буйларын иңләп узды, урамнарны, тыкрыкларны айкады. Шул көлүдән Нурлы Аландагы һәр өйнең тәрәзә пыялаларына тикле озак зеңгелдәп торды...

## 18

Ә иртәгесен Рәхимҗанны идарәгә чакырдылар.

«Председатель белән партоешма секретаре көтә, хәзер үк килергә куштылар»,— дигән хәбәр егетне пошамanга салды. Тәртә арасына кергән атны җигеп бетерә алмый азапланды ул. Кабаланды, ашыкты... Аркалыкны түшлек белән бутады, камыт бавын тарттыра алмый чиләнде. «Кичәге өчендер... Нәрсә әйтергә? Юлда атны калдырып, ни эшләдем дияргә?..»

— Уә, Рәхимҗан, әйдә, түрдән уз! — дип, гадәтенчә колач җәеп каршылады аны председатель. Һәм шундук, кнопкага басып, партоешма секретарен чакырды.

Кабинетта тынлык урнашып алды. Рәхимҗан өчен теләсә нинди орышу сүзләреннән дә авыргарак төшкән тынлык иде бу.

— Я, кәефләр ничек, Рәхимҗан,— дип сүзне партоешма секретаре башлады.

— Рәхмәт, ярап тора иде әлегә...

— Нәрсә син, кыз сорарга килгән кияү егет сыман, коелып төштең әле,— дип председатель дә кушылды сүзгә.— Эшләгәндәге кебек бул! Күтәр башыңны, диңгезче ич син...

Аның сөйләшү рәвеше күңелгә беркадәр җылылык бөркеде бөркүен, әмма «кияү егете» дигәне очраклы гына микән...

— Эшләр болайрак тора, Рәхимҗан,— дип дәвам итте председатель.— Без сиңа бер җаваплылык йөкләргә җыенабыз... Колхозыбыз

якындагы елларда зур мәйданда сугару эшләре башлаячак, ә белгечләр жук. Безгә читтән җибәргән түгел, үзебезнеке кирәк... Озын сүзнең кыскасы шул — быелгысы күздән укырга китәргә кирәк булачак.

Рәхимҗан иркен итеп сулыш алды. Сүзнең башка тирәдәрәк баруы куандырды аны. Әмма җавап бирергә ашыкмады.

— Без сиңа зур ышаныч йөклибез, Рәхимҗан! Институтка һич икеләнүсез барырга кирәк,— дип, председательнең сүзен партоешма секретаре элеп алды.— Авылга синең кебек кешеләр кирәк.

— Мин авылда ич, беркая китәргә дә җыенмыйм...

— Җибәрү турында мыни сүз, сиңа укырга кирәк. Әнә, Мирзанур абыең белән без дә олыгаеп киләбез... Алмаш кирәк! Җирне яратучы егетләр...

— Һич уйламаганда ич, белмим шул..— дип икеләнә калды ул.

— Ике уйлап торды жук, Рәхимҗан. Бу — синең эш! Теләсәң, читтән торып укырсың,— дип урыныннан ук торды председатель. Һәм, килештекме дигәндәй, егеткә кулын сузды.

Рәхимҗан, ризалыгын белдереп, бер-бер артлы икесенә дә кул бирeп чыкты.

— Килештек, димәк?..

— Килештек.

Фаягөлдән ул берөзлексез качып йөрде, аның турындагы уйларын читкә куды, онытырга тырышты. Антлар бирде. Әмма барыбер зәңгәр чәчәк сыман ягымлы нур һәм җылылык бөркеп торган күзләрне оныта алмады. Зәңгәр күзләр төшенә керде аның, зәңгәр күзләр аны таңда йокыдан уятты. Эшкә дә зәңгәр күзләрне очрату уе белән чыгып китә торган булды Рәхимҗан. Көндезен дә, кичләрен дә берөзлексез аны эзләде. Үзе эзләде, үзе качты. Үзе аңарга омтылды, үзе читләште. Ләкин бу хәл озак дәвам итә алмый иде.

Фаягөл әбисе белән икәү генә тора. Көннәрдән бер көнне кичкырын, карчыкның югарочка кич утырырга менеп баруын күргәч, ашыга-кабалана Рәхимҗан түбән очка юнәлде. Ян капка ачык, урамда кеше-кара күренмәде. Фаягөлләр ишегалдына барып кererлек гайрәте дә табылды...

Ишегалдында адашып калган тавык-чебешне кетәклеккә куып йөри иде Фаягөл. Өстендә кыска итәкле җиңсез күлмәк. Үсмер чагыннан калган күлмәк иде күрәмсең. Уңайсызланып, аның итәкләрен күпме генә тарткаламасын — күлмәк барыбер кызның тездән үк йомрыланып киткән тыгыз ботларын каплый алмады.

— Бәрәч, Рәхимҗан, бу нишләп йөрүең,— диде көтелмәгән очрашудан югалып калган Фаягөл. Шундук үзе шатлануын да яшерә алмады.— Кеше күрсә...— дип, мәгънәле генә як-ягына карангалап алды.

Рәхимҗан, үзенең кайда булуын аңышып җиткерә алмаган сыман, бераз тик карап торды. Бөтен кыюлыгы кеше-кара күрмәгәндә капка аша атлап керүгә сарыф ителгән идеме... Егетнең холкын, сәер гадәтләрен үзләштереп өлгергән Фаягөл аны тизрәк үзе янына, тавыклар куышырга чакырды. Бераздан алар тавык тизәге һәм кипкән печән исе аңкып торган абзар алдында иделәр инде.

— Рәхимҗан, Рәхимле җаным,— дип, түземсезләнеп егетнең муенына сарылды Фаягөл.

Рәхимҗанның да «Зәңгәр чәчәгем», «Фаягөлем — Чая гөлем» дип күңеленә җыелып килгән бөтен хисләрен түгеп, яшермичә бернидән оялмыйча сөясе килде кызны.

— Син шушында гына торып тор,— диде Фаягөл, кинәт ниндидер нәтиҗәгә килеп.— Мин хәзер, ишекне генә элеп киләм.— Ул өйгә таба

йөгерде, биленә сыдырылып менгән күлмәк итәкләрен тарткалап кую ихтыяжын да тоймый йөгерде.

Лапас алдында бер ялгызы калып, инде үзләшә төшкәч, очраклы бер кызыксыну белән, моңарчы үзе сөялеп торган баскычтан сәндерәгә күтәрелде Рәхимжан. Кипкән зәңгәр тәтәйләр әйдәдеме аны анда... Кипсәләр дә, зәңгәрлекләрен югалтмаган иде алар. Әллә чәчәк һәм жиләк яфракларының хуш исе бөркелеп торган болын печәне чакырдымы... Үзенең бөтенләй чит-ят сәндерәгә менеп китүен абайламый да калды. Ул арада, сүз куешкан сыман, башына зәңгәр борчаклы ак яулык чөйгән, килешеп торган яңа күлмәк кигән Фаягөл дә күренде.

— Ә-әү-ү, кеше бармы мондау-у,— дип шаярган булды ул.

— Кеше юк, аю гына, синең килбәтсез аюың,— дип җавап кайтарды егет тавышы.

Сәндерәдәге эңгер-меңгергә күзе ияләшеп өлгермәгән Фаягөл, кай арада зәңгәр күбәләккә әйләнеп, Рәхимжанның көчле кулларына килеп кунганын искәрми дә калды. Алар үзләрен урманда, тын, матур алан уртасында калган кебек хис иттеләр. Ул аланда сөеп һәм сөелеп туймас зәңгәр күбәләк белән килбәтсез аю гына иде. Чәчәкләргә күмелеп, җиләк яфракларына төренеп сулыш алды алан... Әйләнде, бөтерелде, чайкалды — туй итте алан... Байтак вакыт узып, түбә ярыкларыннан үтеп кергән ай нурлары бар дөньяны яктыртып җибәргәч кенә алар үзләренең кайда икәнлегенә һәм кем булуларына төшенделәр.

Тар тыкрыкларны иңләп өйләренә кайтып барганда, яңа айның тулылыгына, күкнең зәңгәрлегенә, йолдызларның җемелдәшүенә сокланып туймады Рәхимжан. Әйтерсең лә, авылның шундый матур һәм тын кичен гомерендә беренче кат күрүе.

Фаязның соңгы хаты күңеленә килде. Әллә ул да нәкъ менә шушы кичне, шушы мизгелне юксынамы икән шәһәрдә... «Рәхимжан, малай! Мин сине авылда калды дип кызгана идем, «жүләр» дигән чакларым да булды. Ә син ак сакаллы карт икән бит, малай, торган саен синнән көнләшүем арта бара. Авылның урамнарын, бер кайгысыз калып, аркылыдан буйга гизеп йөрисе килә кайчак. Сызгыра-сызгыра бер йөрисе иде. Минем, авылда үсеп, кызлар озатканым да булмаган икән. Авыл кызларына кайтып, яннарында хет бер кич янәшә утырасы иде, капка төбендә басып торуның ни икәнен беләсе иде... Эх, умырзая жыеп йөргән чакларның кадерен белмәгәнбез...»

Авыл кичләренең кабатланмас матурлыгы бар шул. Менә бүген дә берничә җирдә адашып өйгә кайтмый калган сарык бәрәннәре торып калды. Клуб нигезе буенда кәҗә тәкәсе ята иде, ай нурында аның мөгезләреннән төшкән күләгә ерактан ук тырпаеп күзгә ташланып тора. Бура читләрендә, капка төпләрендә сирәк-мирәк булса да бәхетле пар шәүләләр күренде. Серле тынлыкны бүлеп, түбән оч ягыннан кемнеңдер әтәче саташып кычкырып җибәрде. Җангa сафлык өстәп җил исеп куйды. Су буеннан бөтнек исе катыш салкынча һава дулкыны алып килде ул. Бакалар тел кайрады, чикерткә сайрады. Алар бүленеп торган арада чишмәләр җыры ишетелеп калды. Су буенда шаулап аккан чишмәләр арасыннан Ризван каеннары чишмәсе тавышын танырга тырышып барды Рәхимжан. Күпләгән башка челтерәүләр арасыннан аера башладым дигәндә генә, каеннар белән булган хәл хәтеренә килеп төште. Һәм ул — туңуданмы, әллә болай гына — калтыранып куйды...

Капкадан кергәндә, күпме генә сак булырга тырышмасын, үч иткәндәй, тимер келә гадәттәгедән дә ныграк шалтыраган төсле тоелды. Ул, сискәнеп, ирексездән тагы калтыранды. Зәйнәпләр капкасындагы келәнең дә шулай шалтыравын көткән иде бит ул кайчандыр. Ә ул чакта тимер келә шалтыравын ишетә алмый кайтып киткән иде. Баскыч

төбенә кунаклаган казлар, «йөрисең шунда» дигән сыман, дәррәү кузгалып, шаулашып алды. Төннең тынлыгы һәм матурлыгы артында посып аны күпме борчу һәм тынгысыз уйлар сагалап торган икән. Күзенә йокы кермәде Рәхимҗанның.

## 19

Таң озак кәттермәде. Авыл башына көтү куарга төшкән Рәхимҗанның әнисенә түбән очка тормышка чыккан ахирәте сер сөйләде шул иртәдә. Маллар куып төшкән чыбыгы кулыннан төшеп китте ана кешенең. Ул берара яулык чите белән авызын каплаган хәлдә, катып калды. Ахирәте исә, аның хәленә кереп, гаҗәпләнүен белдерде. Бераздан, тагы нидер өстәргә теләп, ахирәт кеше янә ана колагына үрелде. Икесе дә бер булып башларына тотындылар — башка сыймас хәбәр иде күрәмсең... Рәхимҗанның әнисе үзен кая куярга белмәде.

Нәкъ шул вакытта автобуска утырган сыер савучылар җәйләүгә житеп киләләр иде. Гадәтенчә бер читкә утырган Фаягөл кызларның уен-көлкесенә колак салмады бу юлы, күңеле болай да күтәренке иде аның. Җанын иркәләп торган татлы уйларында булды. Аның күзләрендәге очкынга байтактан игътибар итеп килгән сиртмәле Нурсылу башка түзә алмады, яңалыгы белән уртаклашырга ашыкты:

— Кызлар, күрегезче, безнең Фаягөл яңадан чәчәк аткан бүген,— дип чәрелдәде.

— Минем чәчәк койганым юк, беренче күрүеңмени,— дип елмайды Фаягөл, Нурсылуга туры карап.

— Күр әле, күр, чукынчыкны, күзләре ут яна бит,— дип кабынып ук китте Нурсылу.

— Янмаска... әллә син мине...

— Киявең кайтмагандыр бит? Безгә кайчан күрсәтәсең?

Сүзнең болайга борылуы Фаягөлгә ошамады, ул житдиләнә төште һәм җавап кайтарырга ашыкты:

— Ниткән кияү тагы? Шаярып кына сөйләгән идем бит...

— Яшермә, кызым, үзең сөйләмәсәң дә белерләр. Болар арасында сер саклап буламыни...— дип, сүзгә Сапиятти дә кушылды.

— Нурсылу кияүгә чыккач, Исмәгыйле белән нилэр сөйләшкәненә тикле яшермәде. Сөйләшү генәме әле...— дип, алгы рәтләрдән кемдер усал көлеп алды. Күрәмсең, хак иде — башкалар да кушылып көлде.

Нурсылуның исә мондый төртмә сүзләргә исе дә китми. Киресенчә, үзен искә тәшергәч, күңеле булып, тагы да ачылды гына.

— Булды җанкисәккәем, булды, нәрсәсен яшерәсең аның,— дип, мәгънәле генә кеткелдәп алды үзалдына. Һәм шундук канәгать тавыш белән өстәп тә куйды:— Нәрсәсен яшерим, бирешергә исәп юк әле, боерса...

Ә Фаягөл, юл читендәге кукуруз басуына карап, үзалдына елмаюында булды.

Рәхимҗан атларын алырга көндәгедән дә иртәрәк чыккан иде. Олы елга түрендә утлап йөргән атлар, хуҗаларын күргәч, бер-беренә карашып алдылар. Болай иртә йөрүенә гаҗәпләнделәрме... Иртәнге чыкта коенган яшь курпының иң тәмле чагы иде шул әле. Иң өстенә салып менгән куртканы җәеп, Ялгыз чишмә читенә барып утырды Рәхимҗан. Чишмә дисәң дә инде моны, дип уйлап куйды ул күңеленнән. Исеме дә — Ялгыз, искә алучы да юк үзен.

Олы елга киңлегендә шулай билгесез югалып калган Ялгыз чишмә Рәхимҗанга үзенең онытылып барган малай чакларын искә төшерде: Җәке каенлыгыннан җиләктән кайтышлый алар еш кына шушы урын-

да тукталып хәл алалар иде. Кем күбрәк җыйганын үлчәшәләр, савыт төбенә саркып җыелган хуш исле җиләк суыннан авыз итәләр, түшләренә каплап җиләк кабарталар иде. Тулып җитмәгән савыт белән өйгә кайтып булмый бит, шулай иткәч җиләк күпереп китә... Әйе, әле кайчан гына нәкъ менә шушы урында утыра иде бит ул. Ә як-ягында күрше-тирә малайлары — Барый, Минлегаяз, Хамис, Фаяз, Кавис... Бергә уйнап үскән авылдашлары кайсы-кайда таралышып беткән хәзер... Ул чакта чишмәнең теге ягында куе булып әнис үсә торган иде. Әнис дигәннән, кемне искә алды соң әле ул? Хамисне түгелме... «Вәт исе монын, арасына кереп ятар идем дә, валлаһи гәзим, чыкмасыем»,— дип, Хамис гел шул тирәдә аунар иде. Иөзтүбән сузылып яткан көйгә чәчәктән чәчәккә үрелеп, бал кортыдай безелдәгән булыр иде. Бар нәрсәне онытыр иде Хамис шул әнисләре янына җитүгә... Бервакыт, шул чишмә янына җитеп килгәндә, алданрак йөгергән Хамиснең күцелсезләнеп туктап калганын хәтерләде ул. Әнисләрне сагынып йөгергән җиреннән, чишмәгә җитәр-җитмәс тораташ сыман хәрәкәтсез калды. Чишмә тирәсендәге печән белән бергә кемдер аның яраткан әнисләрен дә чабып киткән иде. Хамис гел мескенләнеп калды шунда. Хуш исле әнисләр үскән җиргә барып бер торды, бер утырды, җанын куяр урын таба алмады. Су да эчмәде, сөйләшмәде, коелып калган әнис чәчәкләрен учына җыйды. Авылга кайтып җиткәнче башкаларның сүзенә катышмады, үзалдына тик уйланып кайтты. Кызганыч бер кыяфәткә кергән иде Хамис шул көндә...

Атлар ерак китмиме дигәндәй, утырган җиреннән борыла төшеп, як-ягына карангалап алды Рәхимҗан. Аларның тыныч һәм җансыз диярлек булып күренгән күксел шәүләләре томанлы җәйге иртәне иңнәрендә күтәреп торадыр төсле иде. Шунда атларның берсе, чыклы үлән тәмен мактагандай, җиңелчә генә пошкырып алды. Йолдыз Кашка пошкыруы иде бу. Пошкырган аваз тирә-юньне уятып җибәргәндәй булды, тын гына эленеп торган аксыл томан офыкка таба тирбәләп куйды.

Рәхимҗанның күз алдыннан, тизләтелгән кинодагы сыман, күренешләр йөгереп узды: сулып, шәлперәеп төшкән әнисләрне иренենә китергән балачак дусты Хамисне Ризван каеннарының ак тәненә балта чапкан исерекбаш алыштырды; чишмә суында йөзеп барган әнис чәчәкләрен — җирдә аунап яткан ап-ак каен кәүсәсе... Балачак дусты белән шайтан суыннан агуланган Хамис арасында бернинди уртаклык таба алмый йөдәде ул.

Ямьсез уйларыннан арынырга теләп, чыклы үләнгә йөзтүбән сузылып ятты. Күзләрен дә йомып карады, әмма саташулы уйларыннан, җанлы сурәт булып күз алдына килгән вакыйгалардан арына алмады — үткән белән бүгенге, бүгенге белән үткәннәр буталды. Хамис турындагы уйларын ашыгып читкә куды. Котылдым дигәндә генә, яшьлегеннән күзләрен мөлдерәтеп карап торган, унҗиденче язларының тәүге умырзаясын тотќан Зәйнәп килеп чыкты. Зәйнәп белән ике арага чабылган каен очы авып төште. Сыкрап ауган ябалдаш астында калгандай хис итте ул үзен. Ләкин шунда, юлда төшеп калган ике зәңгәр тәтәй булып, яктырып, янып, Фаягөлнең күзләре пәйда булды. Фаягөлне искә төшерү аны айнытып җибәрде.

Алсуланып чыккан кояш авылга якты нурларын сирпеде. Рәхимҗан тагы гаҗәпкә калды — алар авылында кояш нәкъ Ризван каеннары турысыннан чыга икән. Моңарчы шуны белмәгән, абайламаган. Өч каенның уртадагысы, очсыз калганы өстеннән карап елмая иде кояш. Әйтерсең лә, алдагы тешләре коелып беткән берәү, мәкер катыш мыскыллы елмаеп, телен күрсәтеп тора иде авылга. Шундый мәгънәсез чагыштыру уена килүдән уңайсызланып куйды ул. Төне буе иректә йөргән атларны, Йолдыз Кашкага атланып, иртәнге авылга куып кай-

тып килгәндә, һәр чык бөртегендә нәни бер кояш елмайган мизгелдә нигә әле шундый уйлар кылә аның башына? Яңа көн туа ич, игенче көтеп алган якты-аяз җәйге көн. Менә озак та үтмәс, кырларда комбайн гөрелтесе башланыр, бункерларга шаулап икмәк агар, чиләкләргә күбекләнеп парлы сөт тулыр, карабодай басуында бал кортлары безелдәшә башлар, бәрәңге бакчасындагы көнбагышлар көнгә борылып, аранда колыннар сикерешеп уйнар... Күпме муллык һәм шатлык вәгъдә итә туып килгән бу яңа көн.

Ә шулай да, тау өстеннән, Ризван каеннары арасыннан, авылга карап торган кояш телен күрсәтеп мыскыллы елмаючы тешсез кешене хәтерләтә иде бүген.

## 20

Киерелеп бер кавым чапкач, хәл алырга утырган иде Рәхимҗан. Кесәсеннән хат чыгарды — Фаяз хаты. Инде ничәнче кат укуы иде аның бу хатны: «Сәлам Рәхимҗан-малай! Эшләр әйбәт бара, акча да шәп. Ә җанга ул гына җитми, шул бер җаныма урын таба алмам, ахры... Күңел һичнәрсәгә ятмый, менә дигән авыл егетләренең шәһәргә килеп юлдан язуын, эчкечелеккә бирелүен аңламый идем мин элек. Бәлки, аларның да җаны бер җирдә, тәннәре икенче җирдә каңгырып йөргәнгәдер ул...»

Хатны укып бетерергә өлгермәде, хатын-кыз җырлаган тавыш бүлдерде. Күтәрелеп караса, тау битендә мәтрүшкә җыеп йөргән Фаягөлне күрде. Хат онытылды. Егет, аяк очларында гына басып, сиздермичә, кыз янына йөгерде, куркыткан булып шаярырга ниятләде. Тик кыймады, чынлап та курка-нитә калса, дип, үзе үк куркуга төште. Арттан килеп күзләрен капласа, я булмаса берәр чыбык ташласа, кызны сискәндерермен дип шүрләде.

— Фаягөл,— дип эндәште ул ягымлы итеп. Фаягөл сискәнмәде, курыкмады. Кулындагы шәмәхә мәтрүшкәләрне иреннәренә китереп, шулар аша, син мондамыни дигәндәй, серле караш ташлады егеткә.

— Мәтрүшкәле чәй яратасыңмы?

— Яратам,— диде Рәхимҗан.

— Ә мине? — дип яктырды Фаягөл.

— Сине дә...

— Мәтрүшкәне ныгракмы, минеме?

— Мәтрүшкәне,— дип, шаярткан булды егет.

Кыз, назланып, үпкәләгән булды. Егет аны тынычландырырга ашыкты, янына килеп чәчләреннән сыйпады. Кыз тынычланмады — Рәхимҗанның кочагына ташланды, ут булып яндырды, җил булып назлады. Шәмәхә мәтрүшкәләрне аралап бер-берен эзләде алар. Мәтрүшкәләр, кулдан төшеп, бал кортлары, төклетуралар очып уйнаган җиләк яфраклары, тукранбаш чәчәкләре өстенә таралды.

— Хәтерлисеңме, Рәхимҗан,— дип, нидер әйтергә теләде Фаягөл.

— Хәтерлим,— диде Рәхимҗан, аны бүлдерүдән кызык табып.

— Беренче умырзаяларны дим...

— Хәтерлим.

— Беләсеңме, мин нинди теләк теләгән идем?

— Юк,— диде Рәхимҗан, йомшак пышылдап.

— Ул теләгем чынга ашты, дөрес икән — беренче умырзая алдашмый,— диде Фаягөл, ярым йомык күзләрен тагы да яба төшеп.

Тәгәрәп яткан егет, иреннәре белән үрелеп, ямь-яшел җиләк яфрагы өзеп алды һәм шуның белән Фаягөлнең муенын, колак очларын кытыклады.

— Ул син идең,— диде кыз, егетнең колагына пышылдап. Һәм, ял-

гышмыйммы дигәндәй, күзләрен аңар текәде.— Син минеке, минеке генә бит иеме, Рәхимле җаным.

— Ие, Чая гөлем...

Мәтрүшкә һәм клевер чәчәкләрендә иркәләнеп, җиләк яфракларын сыйпап ятты алар. Сизелер-сизелмәс кенә искән җилдә баш очындагы яшь каен яфраклары лепердәшеп алды. Күбәләкләр очты, бал кортлары безелдәде...

— Ә син ни теләгән идең? — дип пышылдады Фаягөл бераздан.

Егет икеләнеп калды. Бу очракта дөреслек теләсә нинди ялганнан да яманрак булыр төсле тоелды аңар.

— Сине...— дип пышылдады егет.

Бу ялган Фаягөлгә бик тә ошады. Ялган икәнлеген яхшы белсә дә, җавап аңа янә бәхет китерде, наз өстәде. Шул бәхет һәм назына чорнала-чорнала Рәхимҗанга сыенды ул.

— Рәхимле җаным...

— Чая гөлем...

Мәтрүшкәле яр читендә алар икәүдән-икәү генә иде.

## 21

Нурлы Аланга яңа язлар килде. Кар астыннан яшәреп уҗым чыкты. Бөре ачылды. Урамнарны буйлап аккан гөрләвек артыннан йөгергән малайлар узыша-узыша көймә агыздылар. Сыер мөгерәгән, каз кычкырган, тайлар кешнәгән авазлар яңгырап торды. Кызлар һәм егетләр урманга яңа язның беренче умырзаяларын эзләп менде.

Шундый язларның берсендә су буена, кайчандыр чегән чатыры торган урынга, җиңел машина килеп туктады. Аннан дүрт-биш кеше төште — ир, хатын һәм балалар. Шунда, инеш буенда, көннең-көн буена чишмә суы эчеп, матур ташлар җыеп, аңлашылмаган бер чит, сәер телдә сөйләшеп йөрде алар. Һичкем танымады үзләрен. Бәхетле йөзләрендә — уй, чем-кара күзләрендә моң тулы иде аларның. Кузгалып китәр алдыннан әллә ничә термос тутырып Чегән чишмәсеннән су алдылар, тугайдагы туфракны үптеләр...

Нәкъ шул язны авыл читеннән узган автобустан егетләрчә җыйнак гәүдәле кеше төшеп калды. Юл читеннән озак кына авылга карап торды ул, өстендәге плащын салып кулына элде, күлмәк изүләрен ычкындырды, күкрәк киереп тирән сулыш алды. Шулчак бакча артыннан җигүле ат белән узып барган берәү аны күреп туктап калды. Кулын каш өстенә куеп, юлга карады ат иясе. Юл читендә торганы да аны күреп алган иде. Бер тын тик тордылар һәм икесе дә берьюлы алга тартылып куйдылар. Җәһәт-җәһәт атлап якынайдылар һәм ирләрчә нык итеп кочаклаштылар. Арбада берсеннән икенчесе кечерәк ике малай булган икән. Әтиләренең таныш түгел кеше белән шулай күрешүе кызык тоелды аларга, аяк очларына басып үрелеп-үрелеп күзәттеләр.

— Гелгә кайттыңмы? — дип сорады ат янының килгәне.

— Бөтенләйгә,— диде юл читендә торганы.

— Күрешмәгәнгә дә байтак,— диде ат яныннан килгәне.

— Әйе, күпме язлар үткән,— диде юл читендә торганы.

— Күпме сулар аккан диген... Ә син һаман элеккечә.

— Син чын ир булгансың,— диде юл читендә торганы һәм бакча артында калган атка ымлап сорап куйды: — Үзеңнекеләрме? Арбадагы малайларны әйтәм...

— Минекеләр.

— Кемгә өйләндең?

— Хәтереңдәме, теге чакта дүртәү бергә умырзаяга менгән идек...

— Хәтердә булмыймы... Шул умырзаялар тартты да... Тукта, ә син нигә һаман ат белән соң әле?

— Шулай уңайлырак...

— Мин сине ак «Лимузин» белән йөридер дигән идем инде...

— Кирәксә, анысы да бар. Туктале, ник соң әле без болай басып торабыз... Бөтенләйгә, димәк?..— дип, канатланудан кулларын уып куйды ат яныннан килгәне.

— Гелгә,— диде умырзаяларны сагынып кайтучы һәм, бер карарга килеп, чемоданнарына үрелде.

Ат яныннан килгәне, өлгеррәк булып чыкты, чемоданнарны үзе күтәрде. Гөрләшә-гөрләшә җигүле атка таба кузгалдылар.

* * *

Ризван каеннары бәгыренә чабылган балта үзенекен итте. Язларның берендә алар яфракка бөреләнмәде. Тау өстендә кызганыч шәүләләр генә утырып калды. Авыл өстендәге кояшлы-айлы зәңгәр күкне күпме еллар күтәреп, яңа көн китергән офыкны кочып торган ап-ак ботаклар тораташка әверелеп катты. Шунысы гаҗәп: каен черемәде, таркалмады, аның ак кәүсәләре көзге яңгырга, юеш җил һәм каты суыкларга да бирешмәде. «Мәхәббәткә битарафлык күрсәтеп — мәрхәмәтсезләнүдән, хәтерсез калып — шайтанга әверелүдән сак булыгыз, нурлы аланлылар»,— дигәндәй, авыл каршындагы биек тау башында һәйкәл булып торды каеннар.

Каеннар яфракка бөреләнмәде. Әмма нәкъ шул язны Ризван каеннары чишмәсенең як-ягыннан өч яңа чишмә бәреп чыкты. Ялгыз чишмә чишмәлеккә әверелде. Сулары берсеннән икенчесе сафрак, салкынрак һәм тәмлерәк иде аларның. Һәм шул чишмәлек яны тора-бара Нурлы Аланның иң ямьле җиренә әверелер. Аларның суы белән иң якын дусларын, олы кунакларын гына сыйлый торган булыр нурлы аланлылар. Һәрвакыт туган ягына тартылып торыр, аны ташлап китү турында башына да кертеп карамас ул чишмәлек суын эчеп үскәннәр. Ризван каеннары чишмәләрен татып караучылар шайтан суыннан шундук йөз чөерер һәм андый нәрсәгә бөтән борылып та карамас.

Ә хәзергә, әнә, таң ата. Нурлы Аланда яңа көн туып килә. Тораташ булып каткан каен кәүсәләре арасыннан чыгучы кояшның нурлары иркәли авылны. Нурда коенган зур, якты өйләрнең күзләре чагылып-чагылып куя. Тау итәгендә исәп-хисапсыз күп чишмәләр тезелеп киткән, һәркайсының үз җыры һәм үз моңы. Нәфис итеп үрелгән дүрт толымны хәтерләткән Ризван каеннары чишмәлегеннән инеш өстендәге вак ташлар өстенә берөзлексез йолдыз тәңкәләр коелып тора, чиләккөянтә асып төшкән кызның чулпылары чылтырыймыни... Ялгыз әтәч кычкырып куя, аны башкалар күтәреп ала. Авыл аръягында утлап йөргән атлар кешнәп җибәрә. Җиргә яңа яз, яңа көн килә.

## Гәрәй Рәхим

### Әлли-бәлли бәү итмә

Әлли-бәлли бәү итә,
Балалар йоклап китә.
Балалар йоклап киткәч,
Баштан күпме уй үтә.
Аналар бишек янында
Әлли-бәлли бәү итә.

Әлли-бәлли бәү итә...

Ватан өчен көрәш булып
Узган
Җир бишегендә
Мәңгелек йокыга талган
Ватандашлар, ир-егетләр...
Әлли-бәлли бәү итә.

Әлли-бәлли бәү итә...
Әткәй-әнкәй, кабрегездә
Тыныч йоклагыз сез дә.
Бу — улыгыз,
Көн дә шулай
Сезнең өчен яшен түгә...
Әлли-бәлли бәү итә.

Әлли-бәлли бәү итә...
Гасыр, чор тузанын кагып
Күпме заманнар үтә.
Шауламагыз, тын торыгыз,
Зур курганнарны ябынып
Легендалар, мифлар йоклый,
Алыплар черем итә...
Әлли-бәлли бәү итә.

Әлли-бәлли бәү итә...
Җир тормышы, сизәсеңме,
Язмышың кыл өстендә.
Җирнең һәрбер почмагында,
Җирне үк юк итү өчен,
Күпме атом, ракеталар
Аягүрә баскан көе
Әлли-бәлли бәү итә...

Әлли-бәлли бәү итмә,
Җирем, син йоклап китмә...

* * *

*Җырланмаган җырлар турында*
Х. Туфан

«Туем узган, туным тузган»,— диеп
Әйтер чагы җиткәч адәмнең,
Тормышына сагыш килеп керә,
Моңнар баса хәтта бәдәнен.

«Минем инде ашым ашалган да,
Минем инде яшем яшәлгән...» —
Мондый ачы сүзне әйтә кеше
Гомере сүнеп килгән бер мәлдә.

Кыен инде, кыен мондый хәлләр,
Дошманыңа хәтта язмасын.
...Тик нишләр соң шагыйрь, гомере калып,
Язып бетерсә бар язасын?!

«Минем инде җырым җырланган»,— дип
Әйтү өчен ничек тел барсын?!.
Гомерең бетеп әле җырланасы
Җырың калсын җирдә, ул калсын!

Чын шагыйрьләр шулай булган әнә —
Такташ, Җәлил, Туфан, Тукайлар!
Гомере калып, җыры бетүчеләр —
Шагыйрь түгел, мескен сукбайлар...

Бу шигырем шунда тәмам бугай,
Сюжетымның очы чорналган.
Җитәр... Булды... Дәвам итү хәрам,
Нокта куям — җырым җырланган...

## Автохарактеристика

Мин Геракл кебек бик борынгы,
Компьютерлар кебек өр-яңа.
Яфрак, бөҗәк, диңгез ничек килсә,
Шулай килдем мин бу дөньяга.

Мин туганда яфрак канга баткан,
Диңгезләрдә туплар шартлаган.
Мең тугыз йөз кырык беренче ел —
Мин туган ел.
Каһәр саклаган.

Һәрбер ана минем туган көнгә.
Тумыштан ук мин бер уңмаган —
Туган көнем булган үлем көне,
Туган көнем бәйрәм булмаган.

Тик шулай да гүзәл бу тормышка
Туасы бик килгән ахрысы.
Бу дөньяда чираттагы кеше
Буласы бик килгән ахрысы —
Асфальтларын җимереп бәреп чыктым,
Бөре бәреп чыккан көч белән.
Сыңар үпкә белән озак итеп
Яшәдем мин үҗәт, үч белән.

Кайчак шатлык, кайчак кара кайгы
Бугазыма килеп тулдылар.
Бу дөньяда ни гамь, хәрәкәт бар —
Барысы да тансык булдылар.

Кара эшне кара көе генә
Эшләдем мин төгәл иттереп,
Ак эшләрне башкардым мин һәрчак
Ап-ак итеп, җиренә җиткереп.

Иң булдыксыз, мәхлук кешегә дә
Бер-бер җылы сүзем булды,
Бар.
Шуңа күрә җирдә минем хәтта
Дошманнарым бик аз булдылар.

Ә дусларның исәп-хисабы юк,
Кайчак хәтта алар туйдыра.
(Дусларыма шундый сүз әйтергә
Теле барган тик мин, мин дурак).

Бу тормышның бөтен чынлыгыннан,
Барлыгыннан булдым канәгать.
Сугып егып тартып торгыздыгыз —
Миннән рәхмәт сезгә, җәмәгать.

Мин гашыйк та булдым, тик бәхетсез...
Сөя белдем! Моңа ни җитә?!.
Бәхетсезлегендә бәхет күреп
Яши торган мәхлук мин җирдә.

Дан артыннан куып карасам да,
Ул дан әллә миңа тоттыра?! —
Юангандай итәм: тоттырмыйча
Дан, мөгаен, бик нык оттыра...

Һәм яңадан рәхәт була миңа.
Дөнья шундый тәгәл,
Тамаша:
Яфрак шаулый, бөҗәк йөгереп уза,
Ап-ак көннән күзләр камаша.

Күктә күпме җисем очып йөри...
Җирдә тарих «уһ»лап уяна...
Якын миңа ультрасуперфән дә,
Якын миңа гади куян да.

Мин Геракл кебек бик борынгы,
Компьютерлар кебек өр-яңа.
Яфрак, бөҗәк, диңгез ничек яши —
Шулай яшим мин бу дөньяда.

## Якын килмә

Мин үләргә әле әзер түгел —
Ашый...
Тибә...
Сулый әгъзалар.
Дәфтәремдә, уйда, өстәлемдә
Язылачак күпме язмалар!..

Мин үләргә һич тә әзер түгел —
Гөнаһларым хәтта юмаган.
Иртәгәмдә күпме мәшәкатьләр,
Иң шәп җырым әле тумаган.

Мин бит әле юлда!
Узып барам
Чорның иң-иң кызык төшләрен.
Чорым буйлап таралышып ята
Эшләнәсе күпме эшләрем.

Эш аралый гына,
Аяк өсте
Үлеп китеп булмый бит инде!..
Дус-туганга хәбәр итми генә
Ничек үлим, ертып битемне?!.

Барысын да җыеп бер сыйларлык
Акчаң да булмаган көенчә,
Үлеп китсәң, нәрсә дисен алар:
«Саранлыгын итте»,— димичә?!.

...Рухым, тәнем белән тоямын мин
Туган җирнең татлы һавасын.
Үләннәрнең, яфрак, кайрыларның,
Тамырларның табам дәвасын.

Мин сокланып карыйм гади ташка,
Сабан, көрәк, айга, йолдызга.
Уч төбемдә изрәп йоклап киткән
Энә күзе кадәр коңгызга!

Юк, картаймый, үлем, минем күңел,
Күп яшәгән саен яшәрә!..
...Мин үләргә әле әзер түгел,
Якын килмә миңа, хәшәрәт!..

## Ялгызлык

*Шаяру*

Ялгызлыкның алтын бишегендә
Тирбәләмен инде ничә ай.
Бу дөньяда без — ялгызлар өчәү —
Ялгыз кояш, мин һәм ялгыз ай.

Беркем тыймый, тими һәм борчымый.
Безнең өчен юк ул мәшәкать.
Ялгызлыкта бөек ирек тапкан
Бу җиһанда без ул, без фәкать.

Хәтта кояш ялгыз көндез генә,
Ә ай төнен — кача, атса таң.
Мин көнен дә һәм төнен дә ялгыз —
Бәхетлерәк айдан, кояштан.

Мин үземчә корам көннәремне,
Һәм үземчә сүтәм төннәрем.
Кемнәрем бар, диеп уйламыймын,
Һәм уйламыйм юк дип кемнәрем.

Көндез кояш, төнен ай белән мин
Күз кысышам — күрә күк кенә.
Планета-мазар, метеорлар,
Хатын-фәлән безгә чүп кенә.

Бала-чага, туу, яратышу,
Нәсел калдырулар —
Вак нәрсә.
Орбитадан очып кына кала
Нужа-фәлән безгә иярсә.

Ялгызлыкның алтын бишегендә
Тирбәләбез шулай өч бөек...
...Нидер эзләп шушы буш галәмдә
Очабыз без алга өч боек.

## Сагыну

Мин сагынып кына яшим хәзер:
Туган якны, өйне сагынам;
Дусларымны, яшьли сөйгәнемне,
Яшьли откан көйне сагынам.

Сагынамын күптән вафат булган
Туган-тумачалар, картларны;
Әткәй-әнкәй әле исән булып,
Үзем тәпи йөргән чакларны.

Мәктәбемне, классташларымны,
Авылдашларымны сагынам.
Яшьлегемдә иңнәремә баскан
Авыр ташларымны сагынам.

Җәйләр, кышлар, язлар сагындыра,
Газапларсыз үткән көннәрем.
Сагынамын иртә-кичләремне,
Сагынамын татлы төннәрем.

Бу хис мине бик нык биләп алды,
Киләчәгем — тоташ сагыну.
И, тормышым, җаным, бердәнберем,
Сагнуым ул — сиңа табыну!

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Эльвира Ларичева

# АТОМНАРГА АТОМ БӘЙЛӘНЕР

Соңгы елларда Татарстан җирендә берсеннән-берсе зуррак төзелешләр гөрләп торды: ул нефтьчеләр өчен салынган шәһәрләр, ул Казандагы «Оргсинтез» корылмалары, ул Түбән Камадагы нефть-химия берләшмәсенең цехлары, ул мәшһүр КамАЗ, ул Түбән Кама ГЭСы — барысы да шушы 20—30 ел эчендә салынды. Без инде башкасына әллә ни өмет тә тотмый идек, җиткәндер, моннан соңгылары әллә ни хикмәтле булмас, торак йортлар, культура сарайлары, балалар бакчалары төзүдән һәм кайбер заводларга яңа цехлар өстәүдән узмаслар, дип уйлый башлаган идек. Юк, төзүчеләрнең алай тиз генә тынычланырга исәпләре юк икән. Кама елгасының Брежнев шәһәре турысында яңа ГЭС үзенең беренче чиратын эшләтә башлау белән үк, алар өр-яңа ике зур объектка тотындылар. Берсе — Менделеев шәһәре янындагы химия заводы, икенчесе — Кама Аланы куенындагы атом электр станциясе.

КПСС Үзәк Комитетының 1983 елгы июнь Пленумы бу төр станцияләр төзелеше мәсьәләсенә аерым тукталды, аларның безнең ил энергетикасы киләчәгендә хәлиткеч роль уйнаячакларын билгеләп үтте. Димәк, бездәге бу төзелеш бик вакытлы кузгалган.

Төзелеш мәйданының бүгенге хәленә күз салсаң, хәйран калырлык: бу күренеш зур яу кырын хәтерләтә. Тирә-юньдә барысы да хәрәкәттә, барысы да ашыга, бердәм омтылыш уннарча күтәрү краннарын, көчле экскаваторларны эшкә җиккән. «КамАЗ»лар, «КрАЗ»лар бу якка әллә кайлардан төзелеш материаллары ташыйлар. Эш бөтен колачына җәелгән. Югыйсә аның башлануына әллә ни күп вакыт та узмаган бит әле. 1981 елның кар-буранлы февраль көнендә бу мәйданнан беренче экскаватор беренче батман туфракны кубарып алды. Истәлекле бу вакыйгага катнашучылар арасында КамАЗ салуда зур мактанычларга ирешкән оста бригадир Өмет Нәүрбаев та бар иде.

Шушы көннәрдән соң төзелеш шактый алга китте. Дистәләрчә чакрымнарга сузылган юллар бетон белән капланды, электр челтәре булдырылды, беренче йортлар, мәктәп файдалануга тапшырылды. Иң четерекле эшләрне КамАЗ һәм ак каланы салуда сыналган уңганнар әйдәп алып китте. Атомчылар яшәячәк яңа каланы Брежнев шәһәрен торгызуда даннары бөтен илгә таралган стахановчылык хәрәкәтенең ветераннары белән элемтәгә кереп, аларның фатихасын алып хезмәт иткән Рәис Сәләхов җитәкчелегендәге участок төзи башлады. Бу коллективның алга куйган максаты мондый: «Эшебез гасырларга калырлык булсын! Без киләчәкне күздә тотып төзибез. Димәк, без киләчәк өчен дә җаваплы!»

Рәис Сәләховның төзүчеләре арасында һөнәрләре ягыннан да, тәҗрибә-осталыклары җәһәтеннән караганда да төрледән-төрле егет-кызлар бар. Шушы төрлелеккә дә сылтау ясамыйча, шактый тиз арада бердәм коллектив туплау — әлбәттә, участок начальнигының уңганлыгы нәтиҗәсе. Прораб Александр Киселек, мәсәлән, Рәис турында:

— Без вакыт-вакыт аны якын туганыбыз, сердәшебез, киңәшчебез итеп тоябыз,— дип сөйли.— Эшкә кагылышлы мәсьәләгә килсәк, ул — бик принципиаль җитәкче!

Александр белән Рәис Брежнев шәһәрендә үк дус булганнар, йортлар төзү ком-

бинатында бергә эшләгәннәр. Александрның Кама Аланына килүенә дә Рәис сәбәпче булган.

Күпләр бу төбәккә, гомергә шунда яшәячәкбез, дип урнашалар. Монтажчы Владимир Пласкин да гаиләсен бөтенләйгә шушында алып килергә әзерләнә. «Менә, яңа йорттан бер бүлмә бирсәләр, ике дә уйламыйм, тәйим дә киләм хатын белән балаларны!» ди. Владимирны монтажчылар бригадасында бик хөрмәт итәләр. Көче ташып торучы, ачык йөзле бу төзүчене партбюро составына да сайлаганнар. Бригада хәзер арматура цехын монтажлауны тәгәлли, аннары кислород цехына тотыначак. Монда норма үтәми калу турында сүз дә чыкмый. Норманы ничә процентка арттырулары хакында гына рапорт бирәләр, бер айда 120 процент булса, икенчесендә — 125 яки 130 процент. Шул ук вакытта монтажлауның сыйфатына да тел тидерерлек түгел. Егетләр тырыш, хезмәтләренә намус белән карыйлар, кагыйдә бозучыларга алар арасында урын да юк. Монысын һәркем чамалап тора.

Атом станциясе төзелешендә йөргәндә, коллективның бүгенгесе, киләчәкка планнары белән танышканда, күңелгә республикада барган төзелешләрнең тагын бер әһәмиятле билгесен раслаучы фикер туа. Мондый зур башлангычлар безнең кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне, эшчән итеп, халыкка һәм ил мәнфәгатьләренә бирелгәнлек рухында тәрбияләүдә бик яхшы чара булып тора. Төзелешләр кешеләрне төрле яклап сыный, чыдамлыкка, сабырлыкка, фидакарьлеккә өйрәтә.

Иң куанычлысы шул: кешеләр үзләре дә бик мөһим объект салуда катнашулары белән горурланалар, үзләренә тапшырылган бурычның ерак киләчәккә юнәлдерелгән бик җаваплы эш икәнен тирәннән аңлыйлар. Бу хис, минем уемча, кызлар холкында аеруча нык сизелә. Беренче карашка, юаш кына күренгән бригадир Ольга Макарова, мәсәлән, сөйләшә киткәч, монда эшләүләренә сөенеп яшәвен яшерергә дә теләмәде. Сүзе саен ялкынлана, дәртләнә генә барды. Үз бригадасының Зәй энергетикларына, Түбән Кама нефтехимикларына, Брежнев автомобильчеләренә шәһәрләр салып калдырганын тәфсилләп сөйләде. Аның зур коңгырт күзләре очкынланып-очкынланып китә, сүзләре җитдиләнә бара. Аның бригадасы, кайда гына булса да, тел-теш тидерерлек эшләми икән. Бригадирга бирелгән Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Хезмәт Даны орденының өченче дәрәҗәдәгесе, үзенең КПССның XXV съездына делегат булып катнашуы — шуңа дәлил. Партбюро составында Ольга Макарова идеология мәсьәләләре, тәрбиянең тиешле югарылыкта торуы өчен җавап бирә. Кешеләр белән һәрчак уртак тел таба ала ул. Төзүчеләр аны ярты сүзеннән аңлыйлар кебек.

Бу коллективта урнашкан дустанә мөнәсәбәтне беренче танышудан ук сизәсең. Дөрес, дуслык, ярдәмләшү кебек эшкә иң кирәкле мөнәсәбәтләрне һәрчак яңартып, ныгытып торырга туры килә. Чөнки бригадада элекке тәҗрибәле кешеләр генә түгел, яңа гына килеп кушылган кызлар да бар. Гөлисә Хисматуллина белән Хәмдия Мөхәммәтҗанова Ольга Андреевна янында эшли башлаганда, аларның бер һөнәрләре дә юк иде. Бригадирга укытучы булырга да, остазлык вазифасын башкарырга да туры килде. Кызлар бригадада һөнәргә генә түгел, коллективта үз-үзеңне ничек тотарга да, гомуми мәнфәгать өчен тырышканда, кайбер шәхси отышларыңнан баш тарта белергә дә өйрәнделәр. Аларга хәзер яңа килгән яшьләрне тәрбияләү бурычын да ышанып тапшырырга була.

Төзелеш шартларында монысы да бик кирәк, чөнки төзүчеләр саны һаман арта тора. Алар илнең төрле якларыннан җыела: Таҗикстаннан, Украинадан, Үзбәкстаннан, Ростовтан, Липецкидан киләләр. Әнүрә Әхмәтова — таҗик, Елена Петрова — украинка. Барысын да санап-аралап чыгу бирәдә мөмкин түгел, бригадада утыз җиде кеше. Бригадир шуларның һәммәсенең тормышын да, нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен дә, холыкларындагы үзгәлекләрне дә бик яхшы белә. Шулай өйрәнмәсәң, кайчан, кемгә мөрәҗәгать итәргә икәнен чамаламасаң, эшеңне ничек көйгә салырсың?! Аларның хезмәте нифрат та җаваплы, биналарны соңгы кабат күздән кичереп, бизәп, агартып чыгып китәләр алар. Алардан соң ишекләр бикләнә, ә бераздан ачкычны бинаның төп хуҗаларына тапшыралар.

Без очрашкан көннәрдә, кызлар зур ашханәне бизәп бетерәләр иде. Күңел биреп тырышканлыклары йөзләренә язылган.

— Монда механизмнардан файдаланып булмый, гел кулдан буйыйбыз,— диеште-

ләр.— Көнгә җидешәр квадрат метр ялтыравыклы плитә ябыштырабыз, уникешәр квадрат метрны сыларга өлгерәбез...

Кызлар ашыгалар инде. Төзүчеләрнең төшке ял сәгатен кечкенә вагоннарга гына көйләнгән ашханәдә чират көтеп уздыруларын күреп торалар бит. Тормышның бу ягын җайга салу инде менә алар бригадасына гына бәйләнеп калган. Ничек ашыкмыйсың?! Ашханә эшли башлагач, аңарда берьюлы 220 кеше ашап-эчеп чыга ала. Бу инде — бик зур, авыр мәсьәлә хәл ителде дигән сүз.

Ольга Макарова бригадасын һәр чак шундый җаваплы һәм салынып бетүе тиз арада, ашыгыч рәвештә кирәкле урыннарга куялар. Яшелчәләр саклау келәтен буяпсылап башкаруны да аларга куштылар. Анысының да кирәге зур, ашханәнекеннән артыграктыр да әле — яшелчәсе булмаса, ашханәнең ашы ләззәтле була аламы соң?..

Татарстан атом станциясе төзелеше әле яңа гына башланып китте кебек. Әмма төзелеш мәйданнарын урый башласаң, зур-зур мөһим әзер объектларны күреп шатланып туя алмыйсың. Күңелдә төзүчеләребезнең өлгерлегеннән горурлану хисе кабына, аларның осталыгы артканлыкны тоеп, республика өчен шатланасың. Билгеле булганча, төзелештәге эшләр гаҗәеп киң тармаклы. Бөтен осталыгыңны бер ноктага туплап, оештыру ягын карамасаң, таралыр да җыеп ала алмассың кебек. Бәхеткә каршы, атом станциясе төзелешендә шактый җитез оештыручылар бар. Транспорт һәм, гомумән, автохуҗалык мәшәкатьләрен генә алып карыйк. Төзелешкә әллә нинди төрдәге машиналар сорала. 3 нче автотранспорт хуҗалыгы начальнигы Александр Сюткин шул ихтыяҗларны тирәннән аңлап эш итүче җитәкче булып танылып килә. Ул моңарчы Красноярск ГЭСын төзүдә катнашкан. Атомчыларның эшен җайга салышканда Александр Ильичның Красноярскида очраткан кыенлыкларны чишү тәҗрибәсе бик кирәк булып чыккан. Аның карамагындагы хуҗалыкта иң көчле машиналар, үзбушаткычлар йөзәрләп исәпләнәчәк. Ныклы тәртип, уңайлы шартлар турында вакытында уйлап җиткермәсәң, күпме зыян китерергә мөмкин. Әлегәчә мондый күңелсезлекләр чыкканы юк. Машиналар өчен җайлы мәйдан ясалган, эштә бригадаларның вахта методы кертелгән, төп девиз итеп: «Атом төзелешен удар темп белән тәэмин итик!» дигән өндәмә сайлап алынган. Бригадалар арасындагы социалистик ярышка элекке рәвештә нәтиҗә ясап барыла. Соңгы айларда Габделбәр Гибадуллин бригадасының үзбушаткыч машиналар йөртүче егетләре алда бара.

Атом станциясе төзелешендә яшьлек дәрте бөркелеп торса да, коллективның шактыйны күргән тәҗрибәле осталары, дистә еллар буе энергетика өлкәсенә хезмәт күрсәткән ветераннары да бар. Арадан казаннар машинисты, тагын берничә өстәмә һөнәргә ия булган Михаил Королевны аерып алып күрсәтергә мөмкин. Ул үз группасында партия оешмасын җитәкли. Эштә авария булдырмау, бер-береңә ярдәмләшү, намус белән хезмәт итү кебек иң изге максатларны алга сөрә ул. Яшь егетләр аңа киңәш сорап та килгәлиләр, бу инде — аларның өлкән кешене үз итүе, якын күрүләре.

Төзелешнең партия оешмасы секретаре, нигездә әнә шундый тәҗрибәле остазларга таяна. Бу җитәкче өстенә бик зур бурыч йөкләтелгән. Аңардан атом станциясе төзелешенең уннарча километрларга сузылган мәйданында һәр ноктаны ныклы контроль астында тоту сорала. Бер генә урында да төзелеш агымына тоткарлык килмәскә тиеш. Секретарь бу хакыйкатьне тирәннән аңлап, төзүчеләр белән партия оешмасы арасында тыгыз элемтә булдырып, эшне ритмлы көйгә салырга омтылып яши. Һәр яңалыктагы кебек үк монда да иң алда коммунистлар атлый. Хәмзә Баһаветдиновның:

— Станция, нәкъ дәүләт планында каралгандагыча, үз вакытында сафка басачак!— дигән сүзләре күңелдә тирән ышаныч уяталар.

«Озак та үтмәс, Татарстан атом электр станциясенең беренче реакторы сафка басар,— дип уйлап куясың.— Такташ әйтмешли, атомнарга атом бәйләнер һәм республикабыз ил энергетикасына тагын да зуррак куәт өстәп тора башлар...»

**Тәлгат Галиуллин**

# ШИГЪРИЯТ ҮРЛӘРЕ

Хәрәкәттәге, үсештәге шигърият турында язу шактый кыен. Үтеп киткән унъеллыклар хакында фикер йөртү күп тапкырлар җиңелрәк. Чөнки вакыт инде ул чорга бәяләмәсен биргән, мөһерен суккан, әдәби процессның төп үзенчәлекләре, билгеләре ачыкланган. Әйтик, илленче еллар поэзиясендә вакыйгалы, тасвирый сюжетлы шигырь, поэмада эпик талгынлык, характер тудыруга омтылыш өстенлек итте. Шул фонда уңышлы лирик әсәрләрдә халык җырларыннан килгән, халык моңыннан саркыган эчке җылылыкның, садәлекнең җанлы йөрәге типте. Алтмышынчы елларда поэзия сәхнәгә менде, метафора, куе һәм төсле чагыштыру, шашкын хиссилек, зиһен ташкынын чагылдыру алга чыкты. Поэма күләме белән кыскарып, чор һәм олы дөнья проблемаларын гомумирәк планда сурәтләү юлына басты, баллада жанр буларак позициясен ныгытты, сатира-юмор тернәкләнде. Ә инде җитмешенче елларда поэзия, образлылык хасиятен, динамиклыгын, романтик дәртен, эчке җегәрен саклаган хәлдә, хис белән фикер синтезына омтылды, шул юлда кыю ачышлар ясады...

Ә соң сиксәненче елларга нәрсә кала? Барыр юллар ачыкланган, барлык стиль юнәлешләре хәрәкәткә китерелгән, яңача яңгырашлы метафоралар, рифмалар табылып беткән түгелме? Ачышларның, эзләнүләрнең мәгълүм чиге юкмы?.. Юктыр, алай түгелдер! Һәр чор үзенең сынын мәңгеләштерерлек үзенчәлекле талантларын тудыра, җырчыларын үстерә.

Чор һәм аерым шәхес... Шәхестән башка әдәбият юк. Иҗат кешесе чор вакыйгалары эчендә яши-яши дә, үзенең уй-хыяллары, борчулары белән өстәле артында берүзе кала. Биредә аңа берәү дә ярдәм итә алмый. Әлбәттә, бу процесста иҗатчының тормыш тәҗрибәсе, биографиясе, чынбарлыкны һәм андагы кичерешләр дөньясын сиземләве тиңсез әһәмияткә ия. Әдәбиятны иҗтимагый аңның башка төрләреннән аерып торган «индивидуальлек» дигән күренеш төбендә дә художникның шәхес буларак өлгергәнлеге ята.

Үткән съездан соң поэзиябезнең аксакаллары Сибгат Хәким белән Нури Арсланов җитмеш яшьлек юбилейларын уздырдылар. Ләкин алар һаман да тынгысыз иҗат рухы, эзләнү дәрте белән яшиләр. С. Хәкимнең соңгы елларда иҗат ителгән шигырь-поэмаларын туплаган «Эзлиләр Европа буйлап», Н. Арслановның «Илем — Иделем» җыентыклары шуңа ачык мисал.

Бу елларда Г. Афзал да алты дистәсен тутырды. Ш. Галиев, И. Юзеев, М. Шабаевлар буыны илленең өске ягына чыкты. Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Р. Харис, Р. Фәйзуллиннар да дүрт дистәне алыштырып, ир уртасы дип йөртелә торган кодрәтле чорларына аяк атладылар.

Поэзиянең ике съезд арасындагы табышлары, ачышлары, кеше җанына салынган яңа сукмаклары да югарыда саналган буыннар белән бәйле. Яшьләргә әле дөньяга карашның төплелеге, фәлсәфи тирәнлек җитенкерәми. Яшьләр поэзиясе бер тонлылыгы белән дә оттыра.

Кыскасы, поэзиянең төп йөге һаман өлкәннәр җилкәсенә төшә. Шуннан чыгып күңелдә бер сорау туа: поэзиябез олыгая бара түгелме? Дөрес, безнең чорда «шигърият ул — яшьлек» дигән гыйбарә үзен акламый, совет поэзиясенең үсешенә һәр чорда өлкән яшьтәгеләр зур өлеш кертә килделәр. Бәлки әле сиксәненче еллар башы поэзиясенең төп хасияте булган җитдилек тә, дөньяны һәм кеше кичерешләрен тыйнак һәм төпле итеп, фәлсәфи тирәнлек белән иңләргә омтылу да өлкән буынның активлыгы җирлегеннән үсеп чыга торгандыр?

Әйе, хәзерге поэзиядә анализ, уйлану рухы — кешенең туктаусыз үзгәрә, үсә, яңара килгән рухи дөньясына игътибар көчәйде. Анда фикернең бәясен, кадерен, сүзнең тәмен, урынын белеп, тормыш һәм кеше турында җитди уйланып язылган сабыр холыклы, әмма тирән эчке янулы, үзе артыннан ияртеп китәрдәй кешелекле хисле шигырьләр арта бара. Тыгыз, кыска, сыгылмалы композицияле әсәргә дөнья гаме, ил язмышы белән кеше язмышы бергә килеп керә.

Г. Афзал поэзия алдына тормыш куйган яңа таләпләрне төгәл әйтеп бирә:

*Бу чапкын елларга*
*Нинди җыр җырларга,—*
*Моң белән йөрәкләр яралы.*

*Озын сүз сөйләмә,*
*Вакыт юк тыңларга.*
*Озын уй, кыска сүз заманы.*

М. Шабаев «Карап торам мин...» шигырендә олы дөнья белән кеше язмышы арасындагы бәйләнеш турында уйлана:

*Бер карасаң — гади генә кебек:*
*Яшә, эшлә, гомер итә бел.*
*Бу мәңгелек тормыш елгасының*
*Тере тамчылары икән без...*

Һәр шагыйрь олы дөнья проблемалары каршында үзен җаваплы саный. Бу җаваплылыгын тарихи аң алып килгән образлар ярдәмендә укучысына җиткерергә тырыша. Бик күп мисаллардан берсенә тукталыйк.

Г. Афзал «Прометейга үпкә» шигырендә кешелеккә ут бүләк итеп тә, аны изге ниятләрдә генә файдалануны оештыра белмәгән өчен Прометейны әрли («Сине кабат тимер кадак белән Кадакларга кирәк кыяга»). Р. Гатауллин исә, киресенчә, «Прометейга табындым мин һәрчак» дип яза («Гомер уртасыннан хатлар» поэмасы). Ләкин ике шагыйрь фикерләвендәге тышкы каршылык безне алдый алмый: алар икесе дә сугыш афәтенә каршы күтәрелеп, иҗтимагый актив, заман проблемаларын үз кулына алырдай кешене раслап чыгалар.

Олы проблемаларны, тынычлыкны саклау идеясен публицистик рух белән калкытып куйган шигырьләр белән бергә, бик күп лирик әсәрләргә халык җырларына якын йөгерек, самими стиль, олы фикерне образлы һәм гади итеп ача белү хас. Поэзия кешенең көндәлек тормышына, яшәешенә элек күрелмәгәнчә якынлашты. Киң мәгънәсендәге җиргә якынлык, конкүрешкә игътибарлылык, дөреслекне реалистик буяулар ярдәмендә ачу — электән үк татар поэзиясенең магистраль юлы, горурлыгы булды. Ләкин бу — поэзиянең бердәнбер юлымы? Шигърият күп төрлелеге белән кадерле түгелме? Әйтик, Тукай янында Дәрдмәнднең фәлсәфи, акыллы, «нечкә иләк» аша үткәрелгән образлылыгы һәм С. Рәмиевнең шашкын йөрәкле, романтик поэзиясе дуламаса, XX йөз башы татар әдәбияты оттырып кына иде.

Мәгълүм бер яклылык шагыйрьләрне борчый, уйландыра, яңа юллар эзләргә мәҗбүр итә. Берәүләр йолдызлар, галәм белән сөйләшә башлый, икенчеләре тарихка юл ала, өченчеләре үтә шартлы алымнарны эшкә җигә, «фонетик символизмнарга» таяна.

Поэзиягә хас җитдилек, әхлакый һәм фәлсәфи нигезнең ныклыгы поэманы әдәби мәйданның алгы сызыгына алып чыкты. Әле берничә ел элек кенә бу жанрның артта калуы, бәйгедә беренчелекне шигырьгә, лирик бәйләмнәргә бирүе турында яздык. Гражданлык өлгергәнлеген һәм табигый талантка ия булуны таләп иткән бу жанр, күрәсең, киләчәк көннәр өчен көч туплаган, яңа юллар барлаган. Хәзер поэма үзенең яңа үсеш чорына кереп бара һәм анда тормыш материалын үзләштерү, иҗтимагый-тарихи тематикага игътибар үсү, ерак үткәнне һәм бүгенгене яшәешнең мөһим проблемалары белән бәйләп тасвирлау юнәлешендә җитди эзләнүләр ясала.

Башка шагыйрьләрнең иҗат казанышларын инкарь итмәстән, бирерә иң соңгы вакытта дөнья күргән биш поэмага игътибарны юнәлтәсе килә: С. Хәким. «Эзлиләр Европа буйлап», И. Юзеев. «Мәңгелек белән очрашу», Зөлфәт. «Йөрәкләрдә үлмәс дастан», Р. Гатауллин. «Гомер уртасыннан хатлар», Р. Харис. «Ат иярләү». Бу әсәрләрдә поэма жанры тагын да югары күтәрелде, тормышның рухи офыкларын киңәйтеп, карашын еракка төбәде.

Бөек Ватан сугышы темасын хәтер гел яңартып, намус әледән-әле искә төшереп тора. Бу яктан С. Хәкимнең «Эзлиләр Европа буйлап» поэмасы игътибарга лаеклы.

Юл язмалары формасы шагыйрьгә авыр югалту, кайгы хисен калку итеп тасвирларга мөмкинлек бирә. Тойгының мондый тыгызлыгы — күңелдән ихтыярсыз ташып-актарылып чыккан әрнү, җинаять эзләрен үз күзең белән күрүдән тетрәнү, шигъри җанның сыкрануы ул.

«Әзлиләр Европа буйлап» әсәре күләме буенча зур түгел. Ул — поэма белән психологик баллада алымнарына, шуларның синтезына таянып язылган. Авторның «Бакчачылар», «Үрләр аша...», «Дәверләр капкасы» кебек лиро-эпик әсәрләреннән аермалы буларак, биредә әзлекле вакыйга да, шагыйрь хыялы тудырган герой да юк диярлек. Поэманың сугыш һәм иминлек, вакыт һәм ара, мәңгелек һәм мизгел кебек төшенчәләрне, яшәүнең мәгънәсе турында фәлсәфи-әхлакый уйлануларны бәйләп алып баручы көче — шагыйрь шәхесе, хәтер, кешелек киләчәге турында уйланулар.

Сибгат Хәким ерак илләрне, чикләрне үтеп, яшьлек дусты Муса Җәлил эзләре буйлап китә. Герой шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым белән алар Дрезденга килеп чыгалар. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре утырган төрмәдә, империянең суд залы бинасында хәзер университет урнашкан. Вакыт канлы эзләрне юган, камералар ватылган, сүтелгән. Һәммәсе үзгә төс алган. Ләкин бу тышкы үзгәрешләр шагыйрьне алдый алмый, аның хыялы Мусалар утырган вакытны күз алдына бастыра. Горур үнбер тәрәзә... Язмышлары һәммәсенең бер: Плетцензееда башларын кисәчәкләр... Моңа ышанасы килми, әле һаман да «Тәрәзәләреннән карый кебек Мусалар».

*Дрезден галереясе*
*Түгел сезгә суд залы.*
*Коридор буенча алып*
*Киләләр күк Мусаны.*

Поэманың эчтәлеге, мәйданы, офыгы киңәя бара. Шагыйрь Муса Җәлил батырлыгының нигез чыганаклары турында уйлана, аны Фучик һәм башка халыкларның олы уллары белән янәшә куя («Дрезден. Фучик Мусага үзенең урынын биргән»). Испаннар, итальяннар фашизмга каршы көрәшәләр. Алар белән янәшә татарлар да көрәшеп һәлак була:

*Үзә французлар, поляклар...*
*Татарлар мыскыллау күк*
*Ишетелә, бөек халыклар*
*Эшенә кысылган күк.*

Юк, тоткын татарлар үзләренә мәрхәмәт, ниндидер искәрмә сорамый, алар дөнья азатлыгы өчен соңгы тамчы кан акканчы көрәшергә ант итәләр.

*Ә синең, татар? Әйтерләр:*
*Син мескен халык, иел...*
*— Иелермен, кипсә җиде мең*
*Елганы җыйган Идел.*

Илнең төрле почмакларыннан чыккан үнбер батыр суд залында. Ләкин гаҗәеп хәл: алар елмаеп утыралар. Судья аптырашта кала: «Билгесез нинди рух бу халыкта?» Ә баксаң — төрмәгә нур ерактан, туган илнең түреннән, Урал һәм Үзбәкстаннан, Казахстаннан, Мусаның берөзлексез төшенә кереп, сагындырып йөдәткән Казаныннан агыла икән.

Хисләр киеренкеләнә. Шагыйрь бу картинадан кискен сикереш ясый, киләчәккә күз ташлый:

*Бушатып үнбер татарны,*
*Иң түрдән урын биреп,*
*Хөкемгә үнбер палачны*
*Тартачак Нюрнберг...*

Лирик герой хыялга, хискә бирелеп, җир шарының тоташ бер иген кырыннан торган чорын күз алдына китерә.

Ләкин бу — ерак хыял. Алдагы юлларда поэмага бөтенләй үзгә — тынычлык өчен барлык чаралар белән актив көрәшү мотивлары килеп керә.

*Тынычлык... Кайда бар аның*
*Көрәшсез бирелгәне?*

Бу олы тартыштан җир шарының алдынгы уллары читтә калмый: «Баралар Лорка, Җәлилләр һәм Пабло Нерудалар...»

Сәяхәтнамә, юл истәлекләре, яшьлекләре бер чорда үткән элеккеге дусларын хөрмәтләп искә алу, Европада, Дрезденда, Моабит нигезендә Муса эзләрен, Фучик-Җәлилләр рухын табу максаты белән башланып киткән поэма дөньяның иң олы проблемаларына килеп чыга. Күрәсең, олы шагыйрь башкача булдыра да алмый. Заман утлары аның йөрәге аша үзә. Тирән эз калдырып үзә...

И. Юзеевның «Мәңгелек белән очрашу» шигъри трагедиясендә табигый булмаган әйберләр күп: хәрәкәт урыны — тулаем җир шары, галәм, күк, мәңгелек; вакыт — ерак мифик чор һәм безнең көннәр; катнашучылар — Зевс һәм башка аллалар,

космонавт, археолог; конфликт — кешеләр белән аллалар бәрелеше. Атлантиданы эзләүгә бәйләнешле хәлләр...

И. Юзеев бу өлкәдә кабатлау юлына басмый. Аның максаты да, бурычы да үзгә. Дөрес, антик аллаларны тасвирлаганда автор безгә таныш төшенчәләрдән читкә чыкмый. Алар — усал, явыз, мәкерле, вак, көнче... Алар бер-берсеннән «профессиональ» билгеләре белән генә аерылалар (Зевс — Җир-Күк белән идарә итүче Баш алла, Арей — сугыш алласы, Анан — Язмыш алласы, Аид — Җир асты алласы һ. б.). Ләкин аллалар турындагы миф яңа, заманча эчтәлек өчен бер алым гына.

Хыялый Атлант югалган утрауны эзләгәндә, сугыштан калган снаряд кыйпылчыгы белән яраланып, җир асты патшалыгына килеп эләгә һәм аллалар белән «бил алышырга» мәҗбүр була. Җир асты алласы Аид кеше тормышының бәясез һәм мәгънәсез икәнлеген исбатлау нияте белән, җир улына чәчне үрә торгызырдай саннар китерә:

*Эш итсәм дә гомер-бакый*
*Гел үле җаннар белән,*
*Сөйләшергә яратам мин*
*Конкрет саннар белән.*
*Кабул иттем Европадан —*
*Дөнья сугышларыннан:*
*17 гасырда — 3,3 млн. кеше,*
*18 гасырда — 5,4 млн. кеше,*
*19 гасырда — 5,7 млн. кеше,*
*I бөтендөнья сугышыннан — 4 млн. кеше,*
*2 бөтендөнья сугышыннан — 50 млн. кеше.*

Музыка тораташ булып каткан корбаннарның зиһеннәрен һәм тавышларын кайтаргач, Атлант үз илләренең бәйсезлекләрен яклап һәлак булган батырлар белән сөйләшеп китә. Атлантның җирдәге бәхеткә инанган чыгышы хисси һәм ышандырырлык булуы белән аерылып тора. Борынгы, бүгенге һәм киләчәк заманнарны тоташтыручы, бәйләүче бу образ безнең көннәрнең гуманистик эчтәлеген ачып сала.

Пьеса фаҗига белән тәмамлана. Кешегә ярдәме өчен Афина җәзага тартыла. Атлант һәлак була.

Шул рәвешле, И. Юзеев мифик-фантастик образлар, ситуацияләр ярдәмендә явызлыкка каршы чыга, җирне, кешелекне яклап күтәрелә.

И. Юзеев әсәрләрендә социалистик реализмның киң иҗат мөмкинлекләре рамкасында реализм белән романтизм, лиризм белән драматизм үзара якынлаша, кешенең хакыйкатькә омтылышында очраган фаҗигаләргә, сынауларга игътибар арта.

Тәнкыйтьтә әле һаман да, тасвирлау — проза эше, дигән фикерләр ишетелә. Бу, әлбәттә, хата караш. Уңышлы шигъри әсәрдә тасвирый сюжет, вакыйга яңа тормыш ала, үзгәчә яңгырый башлый.

Шул ук вакытта бу төр поэма элгәреләренең вакыт сынавын үткән ачышларына таянып, чор алып килгән яңа сыйфатларга бай. Яңачалык поэманың лиризм белән тирәнтен сугарылуында да, шәхси башлангычның мәгънәви, структур роле үсүдә дә күренә. Ләкин монда да поэма үзенең жанрлык хасиятләрен югалтмый, лирика эчендә «эреми».

Хәзерге поэманың иң төп үзенчәлекләреннән берсе — ирекле формага омтылыш, төрле башлангыч һәм юнәлешләрнең үзара кушыла, аралаша баруы.

Р. Харисның «Ат иярләү» дип исемләнгән тыгыз социаль эчтәлекле, кеше психологиясенең иң тирәндә «качып» яткан катлауларын хәрәкәткә китергән, композицион уйланылган поэмасы шуңа дәлил була ала.

Әсәрнең үзәк алымы — шартлылык. Поэманың төп герое Кәрам сугыш юлыннан качып кайткан атына тирән серләрен ача, улының Украина җирендә ятып калуын хәбәр итә. Күз яше атка күчә, «адәм җаны, хайван җаны аңлашырлык тел таптылар». Ат шунда, нәкъ әкияттәгечә, телгә килә һәм туган ягына тарткан хисләре, ничек итеп сугыш афәтеннән котылып калуы турында сөйли. Шуннан кинәт кискен көчеш ясала:

*Сугышның иң авыр йөген*
*тартыйм тыныч юллар буйлап*
*монда гына...*
*Синең кебек...*

Шартлы әдәби алымның иҗтимагый мәгънәсе, асылы, юнәлеше соңгы ике сүздә ачыла да куя. Шуннан игътибар кешенең зиһен эшчәнлегенә, бу сүзләр тудырган эффектны сурәтләүгә юнәлә: «Ә йөрәге чәйнәлгәндә кеше бик тиз аңга килә», «Ә йөрәге өтелгәндә кеше җавапны нык эзли», «Йөрәгеннән кан саугланда кеше җавапны тиз таба».

Бусы әле психологик халәтнең тышкы билгеләмәсе, күбрәк шагыйрьнең үз фәлсәфи сөземтәсе. Икенче психологик рәттә Кәрамның эчке дөньясы, ситуацияне үз бәяләве ачыла.

*«Малы иясенә охшар,—*
*дип әйткәннәр борынгылар.*
*Димәк, мин дә аңа охшаш.*
*Бу ат, димәк, ат кына түгел,*
*бу ат, димәк — минем күңел...»*

Үз алдына уйланудан, үзенең ялгышын, иленә, намусына хыянәтен танудан «ул оят төсле» кызара, «аптырау төсле» агара. Һәм шуннан атны кыйнарга керешә (дөресе, ул үзен кыйный). Аннары, кинәт карар кылып, сугышка чыгып китә, батыр җиңүче булып кайта.

Монысы поэманың тышкы сюжет канвасы. Чынлыкта «Ат иярләү» сугыш чорын тасвирлаудан бигрәк, һәр заманда актуаль һәм һәр дәвердә үзенчә, яңача яңгыраган: кешедә кешене раслауга багышланган әсәр. Шуңа күрә шагыйрьнең үз героена мөнәсәбәте кискен, кырыс, ул буш кызгануны өнәми. Аның ачуы кеше күңеленә кереп утырган куркаклыкка, олы галәмнең җил-давылларыннан читтәрәк калып, тынычта, «иярсез алаша» янында калырга тырышучыларга каршы юнәлтелгән. Ә бит кеше үзенең шул ниятен яшерергә, кабык астында тотарга, үзен төрле сылтаулар белән акларга тырыша (Кәрамга 51 яшь, малае сугышта, ул колхоз өчен кирәкле кеше һ. б.).

Кәрам шикеллеләрнең туң йөрәгенә барып җиту теләге белән язылган әсәрнең төбендә кешегә мәхәббәт, тормышны һәм кешене матуррак, ямьлерәк, сафрак итеп күрү теләге ята. Бу тема Р. Харис иҗатының буеннан-буена үтә. Бу поэма тагын бер кат шуңа инандыра: социалистик реализм сәнгате максат һәм ниятләрнең иҗтимагый активлыгы белән характерлана, шуны сурәтләү юлында чикләнмәгән эстетик мөмкинлекләр бирә. Шартлы алым (поэманың исеме дә метафорик) шагыйрьгә кеше рухының иң тирән катламнарына үтеп керергә ярдәм итә. Кеше ахыр чиктә үзен җиңә.

Поэмада физиологиягә игътибар көчле. Ләкин автор шунда да физиологик, матди, тән детальләрен рухи дөньяны ачуга хезмәт иттерә белә. «Ат иярләү» хәтердә калырлык кискен образларга бай. Ул «Рәссам» поэмасы рухында, динамик сурәт белән кинәт башланып китә:

*Качып кайтты Кәрам аты...*
*Киткәннән соң ун көн узгач...*

Шул хәбәр киң психологик картинаны күз алдына бастырырга булыша («Күзләре кизләү булдылар, сузләре — сыктау»). Шагыйрь күперту — градация алымына киң таяна, аны поэманың икенче үзәк алымы дәрәҗәсенә күтәрә. Атны озату процессы күңелгә сеңеп кала:

*...Шул чагында күземнән*
*ак томан агып чыкты,*
*ул җәелде, куерды,*
*вокзалны күмеп китте,*
*бугазыма төелде,*
*күзләрне ачыттырды...*

Поэма тәнкыйтьтә уңай бәя алды. «Социалистик Татарстан» газетасындагы фикер алышуда Ф. Мусин белән З. Мансуров «Ат иярләү»нең иҗтимагый әһәмиятенә дә, сәнгатьчә ачышларына да киң тукталдылар. Поэманы тагын да камилләштерү юнәлешендә әйтелгән теләкләр дә изге. Шуңа өстәп, бер фикерне генә калкытып куясы килә.

Әсәрнең композициясе уйланылган, иң мөһиме, ул авторның алда әйтелгән төп фәлсәфи-этик ниятен ачуга буйсындырылган. Шулай да «Ат иярләү»нең башлангыч өлеше (атны армиягә озату, аның истәлекләре һ. б.) ышандыра төшә, тыгызрак эшләнгән, ә соңгы кисәкләрендә аны тизрәк тәмамлап, «котылып» куярга ашыгу сизелә. Аннан соң сугыштан качып, үзенә охшаган аты ярдәмендә әхлакый өлгереп, үзен, намусын тапкан кешене герой ясау кирәкме икән? Аның шул изге теләк белән өеннән чыгып китүе җитмәдеме икән?

Зөлфәт белән Р. Гатауллинның «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» һәм «Гомер уртасыннан хатлар» поэмалары арасында уртаклык бар. Аларның эпик оеткылары нык. Әмма аерым тормыш эпизоды, яшьлек хатирәләрен яңарту, тиз үтүчән гомер истә-

лекләре, тарихка сәяхәтләр—берсе дә шагыйрьләр өчен үзмаксат түгел. Эпик сәбәп һәр урында лирик кичерешләр, уйланулар, иркен чигенешләр белән аралаша. һәр бүлекчә үзенә бер мөстәкыйльлеккә ия балладаны яисә лирик монологны хәтерләтә. Структуралары буенча алар хәтергә өелгән вакыйгалар фонында чор һәм кеше язмышы турында уйлануларга, дәверләр арасындагы җанлы җепләрне эзләүгә корылган әсәрләр.

Зөлфәт поэмасы фикри колачлылыгы, үтә шартлылыгы, иркен композициясе белән И. Юзеев әсәренә дә якын тора. «Йөрәкләрдә үлмәс дастан»ның пафосы кешене вак-төяк хәсрәтләр ташкыныннан арындырып, әхлакый кыйммәтләрне, мәңгелек хакыйкатьләрне аңлауга чакырудан гыйбарәт. Аның эчке мәгънәсе хыял белән иҗат шатлыгын ачу, әкият белән тормыш, шигърият белән чынбарлык арасындагы эчке уртаклыкны, якынлыкны раслау. Ахыр чиктә бит кешене кеше иткән сыйфатларның күбесе рухи сферада.

Зөлфәт иң борынгы ырымнарга, ышануларга таянып, «салкын акылга», кешеләр арасындагы табигый мөнәсәбәтләрне какшатуга алып килгән коры техницизмга каршы чыга. Кеше кодрәтле техника дөньясына тирәнрәк үтеп кергән, информация ташкынына ныграк чумган саен үзенең беренчел хисләрен, бөтенлеген, самимилеген, табигый ямен саклый белергә тиеш, ди шагыйрь.

«Йөрәкләрдә үлмәс дастан»да Зөлфәтнең иҗтимагый яктан өлгергәнлеге, чорның катлаулы проблемаларына үткен карашы үзенә лаеклы сурәтлелек чараларын да таба алган. Шагыйрь төрле чорларга үтеп керә.

Лирик-романтик хисле Р. Гатауллин поэмасы белән чагыштырганда, «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» әсәрендә панорамлык һәм вакыты белән предметларны, идеяләрне артык шәрә тасвирлау көчле. Ул — реаль тормышта хыял күрә, хыялда, мифологиядә бүгенге кешене борчыган сорауларга җавап эзли.

Г. Гатауллинда мондый киң панорамлык юк. Бер тормыш картинасы икенчесен алыштыра, бер фикер икенчесен тудыра. Максат — чор белән шәхес арасындагы якынлыкны күз алдына бастырган поэма тудыру.

Дөрес, Зөлфәт артык эре планга омтылып, вакыйга-хәлләрне конкрет-хисси образлар ярдәмендә ачыкламыйча, югалтуларга да дучар була. Урыны белән «китапчыллык»ның басымы арта, композицияне аңлы рәвештә катлауландыру үзен сиздерә.

Әмма «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» әсәре чорның әхлакый, фәлсәфи проблемаларын шигъри формага салып, гомумиләштереп укучыга җиткерергә омтылуы белән кызыклы һәм гыйбрәтле поэма булды.

И. Юзеев, Р. Харис, Зөлфәт поэмалары шартлы алымның, фантастик образларның, катлаулы ассоциацияләренең социалистик реализмның асыл хасиятләренә каршы килмәвен тагын бер кат раслады. Бу чаралар совет әдәбиятының иҗат методының төп принципларына буйсыналар, гомуми сурәтләр реалистик конкретлык, легенда элементлары заманча эчтәлек белән кушыла. Беренчеләре ярдәмче роль уйный, чорның иҗтимагый пафосын, тенденциясен ачуга хезмәт итә.

Р. Гатауллин поэмасы лирик садәлеге, эчкерсезлеге, үз буыны турында ачыктан-ачык диалог алып баруы белән хәтердә кала.

Ул «минем егерме ел яныш, җан атканым — шигырьләрем, һаман дәвам иткән бу хатларым»,— дип яза. Шагыйрь поэмасын багышлаган кешеләрнең исемнәрен дә тәгаен әйтә: «Сезгә: соңгы тапкыр, бәлки, ялапаяк — урам чирәмендә үскәннәргә, этиләләр, этисезләргә, катык тәмен онытмаганнарга, авыр елларда да гел шат булганнарга...» Теләге дә изге: «Минем хисләр әйләнсә иде сезнең хискә».

Документаль җирлекне, үз шәхси биографиясен, мизгелне үзәккә алган тәгәл фотография ысулын нигез итеп алып, һәр хат-шигырьне еллары, айлары белән билгели. Шагыйрь туачак буынга, киләчәк тарихка мөрәҗәгать итә. Шагыйрь үз-үзенә тәнкыйть белән карау сәләтенә дә ия: «Сез күрергә теләгәнчә, яңа Такташ — бунтарь Гаташ була алмадым».

Чыннан да, поэмага Такташ киңлеге, аның публицистик ялкыны, гомумиләштерү тирәнлеге җитенкерәми. Икенчедән, поэмада илаһи моментларны, шигъри идеалны гына түгел, тормыш прозасын һәм драматизмын реаль хәлләрдә тасвир үзәгенә алганда әсәр тагы да отар иде. Ә мондый борылыш өчен җирлек җитәрлек. Әмма тулаем алганда, «Гомер уртасыннан хатлар» поэмасы шагыйрьнең поэзиядә алып барган күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсе.

Әле карап үткән биш поэманы якынлаштырган төп хасият — бер чорда язылган булулары гына түгел. Үзәкләрендә тарихи материал, үткәнне иңләү ята. Ләкин аларны чал сәхифәләргә багышланган әсәрләр дип атау дөрес булмас иде. Тарихилык принцибы, социалистик реализм методының чикләнмәгән иҗат мөмкинлекләре, заман төшенчәсен киң мәгънәсендә аңлау чорның иң киеренке, иң актуаль проблемаларын кыю рәвештә калкытып куярга мөмкинлек биргән. Тормыш дөреслегенә тугрылык хә-

тернең әхлакый офыкларын киңәйтә, ватан һәм аның киләчәк бәхетле язмышына ышаныч шагыйрьләрне киң гомумиләштерү юлына алып чыга. Сүз осталары вакыйга-хәлләр турында гына сөйләп бирү юлына басмыйча, шартлы, фантастик алымнарга киң таянып, тарих белән бүгенге һәм киләчәк арасындагы якынлыкны, каршылыкны аңларга тырышалар.

Хәзерге поэма җәмгыятьнең рухи тормышын, халәтен яктырту белән генә чикләнмичә, тарихи тәҗрибәгә, тарихи аңга мөрәҗәгать итеп, совет кешесенең эчке дөньясы нинди нигезгә таянып үсүен күрсәтә. Заманны борчыган шатлык-хәсрәтләр тарихка алып чыга.

Шагыйрь язмышы җиңелдән түгел. Ул тирән эчке кичерешләрен, уй-фикерләрен сүзгә ышанып тапшырып, укучыга җиткерә белергә тиеш. Кеше күңелендә җавап тойгылары уятып, аның белән аңлашу юлларын гел яңартып тору да шагыйрь өчен мөһим. Шуның өстенә язганнарын укучыга ирештерү һәм иҗатын яхшы мәгънәсендә пропагандалау да еш кына авторның үз җилкәсенә төшә.

Әйтик, С. Хәким, Н. Арсланов, Г. Афзал, Ш. Галиев, И. Юзеев кебек каләм осталарына үзләренә реклама ясау кирәк тә түгел кебек. Ә шулай да... Әле бит кайчандыр бер яулаган үрендә калу да җиңел түгел. Шигъри үр бер урында тормый, ул хәрәкәтчән мишень кебек, күчеп, урынын, сыйфатын үзгәртеп, алыштырып, яңартып тора.

Хәзерге яшь көчләр арасында табигый сәләткә ия шагыйрьләр аз түгел. Поэзиягә алтмышынчы елларда килгән буын дәрәҗәсендә торганнары да бардыр арада. Ләкин аларда ирешкәннәр белән канәгатьләнү, үзләренең тыйнак урыннарына «ябышып» яту хас. Ә бит яхшы солдат кесәсендә генерал билгесе йөртә, диләр.

Ә менә алтмышынчы елларда поэзиядә ярыш рухы, хәрәкәт көчле иде. Бераүнең дә гомуми ташкында йомычка буласы килмәде. Шул сәбәпле поэзия үзе дә олы тарихи вакыйгалар, «киңәйтелгән» галәм сферасына керде. Шул фонда кеше дә масштаблы, рухи ихтыяҗларга бай, киң колачлы шәхес буларак ачылды. Укучы да поэзия кичәләренә йөри башлады.

Һәм әйтергә кирәк, шигырьгә алтмышынчы елларда килгән буын кемнеңдер мәрхәмәтен, кайгыртуын көтеп ятмыйча, әсәрләрен русчага тәрҗемә итүне һәм бастырып чыгаруны үз кулына алды. Нәтиҗәдә аларның шигырь китаплары русча басылып чыгып, җәмәгатьчелекнең уңай бәясен алды. Аларның хәзер кулга-кул тотынып, бер-берсен аңлап эшли торган тәрҗемәчеләре бар.

Һәр стильнең, фикерләү алымының үз чоры, үз базары була. Вакыт сөрешен, ихтыяҗлар үзгәрүен сизми калса, язучы үзе оттыра. Бер мисал белән генә чикләнәм. И. Юзеев үзенчәлекле лирик шагыйрь булу өстенә, дистәгә якын шигъри драма, тарихи поэма авторы. Чор таләбен, халыкның эстетик үсеш дәрәҗәсен вакытында тоеп, шагыйрь тарих белән заман, мәңгелек белән мизгел арасындагы мөнәсәбәтне яңача, үзенчә ачты. Татар поэзиясе өчен алар зур казаныш булдылар. Ләкин рус укучысы бу әсәрләр белән бөтенләй диярлек таныш түгел. Мәскәүдә басылып чыккан «Тихое утро» («Советский писатель», 1980) китабына кергән «Язылмаган поэма»дан башка күләмле әсәрләре И. Юзеевны ачып бирә торган поэмалар түгел. Хәзер шагыйрьнең тарихи драмалары тәрҗемә ителеп, басылып ята. Төкле аяклары белән. Ләкин бит алар хәзер рус укучысы өчен яңа сүз була алмыйлар инде. Ил җәмәгатьчелеге Ю. Марцинкявичюс, М. Кәримнәрнең шул рухта язылган поэмалары белән күптәннән таныш. Алар үз әсәрләрен инде күптән русча яңгыраттылар. М. Кәрим каләме тудырган Салават Юлаев образы башкала сәхнәләрендә менде, радио-телевидениеләрдән яңгырады. Ә И. Юзеевның Муса Җәлил, Тукай кебек тарихи шәхесләре Татарстан чикләрендә калды. Ә кем гаепле? Эзли калсаң, сәбәпләр булыр. Бу проблемалар хакында да Татарстан язучыларының X съездында җитди сөйләшү булыр дип ышанасы килә.

* * *

Бүгенге тормыш, бүгенге әдәби ситуация лирик әсәрләр өчен дә, эпик әсәрләргә дә зур мөмкинлекләр бирә. Эзләнүләрнең төрле юнәлешләрдә баруы — шуның ачык мисалы. Безнең көннәр татар поэзиясе кешенең, җәмгыятьнең, олы дөньяның рухи тәҗрибәсен тулырак ачуга, галәм белән табигать, хыял белән чынлык арасындагы якынлыкны яңача ачуга омтылышы белән көчле.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ҖИЛӘКЛЕ АЛАННАР ЭЗЛИМ!

Безнең прозаны бүген берничә сыйфатка аерып төркемләп булыр иде. Бу бүленеш, бәлки, якынчадыр, әмма — шулайрак.

Беренче юнәлеш: проза телен бик яхшы белгән, җөмләне искиткеч матур төзеп язган авторларыбыз бар. Теленә сокланасың, гаҗәеп—көмеш табакка энҗе койгандай! Язучыны шул ягыннан гына бәяли башласаң — бу авторлар беренче планда инде. Кая ул Шәриф Камалга андый тел! «Терсәге чыгып» торган җөмләләр Ф. Әмирханда, хәтта Г. Ибраһимовта да бар. Әмма, матур җөмлә төзеп язган бүгенге прозаикларның кеше укымый торган ялтыравыклы әсәрләре янында тегеләр — зенитта. Чөнки аларда тормыш бар, типлар бар. Ялтыравыклы купшы җөмлә төзүчеләрдә исә тормыш һәм шуннан суырып алынган типлар зәгыйфь, шуңа күрә укучы ул әсәрләрне актарып кына чыга. Кызганычка каршы, мондый матур җөмлә белән өстән шуып бару бүгенге яшьләргә дә килеп керде. Яшьләр белемле — Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек кене түгел, һәр яшь язучының хәзер вуз дипломы бар. Алар инде җөмлә төзи беләләр — белем зур! Тик — әсәрдә тормыш юк.

Икенче бер юнәлеш: әдәби әсәр хикмәтле тел белән язылырга тиеш дип ышанган кешеләр. Болар гади итеп язсак хикәя булмый, дип уйлап, очын-очка ялгап бетерә алмаслык бөдеркәле-көдрәле җөмлә белән язалар, аларның әсәрендәге механизатор яки фуражир бәллүр, өрфия, мәгәр, ханым, коры шәраб, сөтбикә дип сөйләшә — баш әйләнә. Автор үз җөмләсенә урта мәктәптә алган геометрия, физика, химия буенча мәгълүматларын тутыра, бүгенге газеталардан алган информациясен дыңгычлый — моны «татар әдәби телеме икән бу?» дип, сәерсенеп укыйсың. Шул вакытта гап-гади итеп язып кеше рухын ача белгән Ш. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар, бүгенге В. Белов, В. Распутин, В. Быковлар искә төшә. Шәрәфи карт («Акчарлаклар»), Хәят («Хәят»), Нури карт («Татар хатыны ниләр күрми?») гап-гади, әмма йөрәгеңә үтеп керерлек итеп сөйләшәләр бит! Ә В. Беловның Иван Африканычы? Ч. Айтматовның Танабае? Мәэмүн карты? В. Распутинның Дарьясы яки Аннасы? В. Быковның барлык геройлары? Барысы да халыктан, барысы да тормыштан... Кыскасы, прозаны «икенчел продукция» баса башлады. Безнең прозаиклар хәзер тормышның үзенә түгел, ә тормыш турындагы информациягә кереп батты. Шул информация белән матур сюжет корып, дөрес композиция белән яза башлады. Мин үземдә сәер бер тойгы сизәм: узган елда басылып чыккан кайбер хикәя, повесть, романнарга караганда миңа диңгезче М. Юнысның диңгезче язмалары, игенче Ф. Галиевнең игенче язмалары күбрәк ошады. Боларның соңгысы — язучы түгел, әмма аның язганын мин тетрәнеп укыдым. Чөнки, теге төзек, ялтыравыклы әсәрләрнең авторлары, прозаик Георгий Семенов әйткәнчә, бары тик «Әдәби тышкы кием турында гына кайгыртып, тормыштагы әшәкелек, ялган, явызлык белән бер тапкыр да пычакка-пычак килмиләр, әсәрләрендә күпме генә матур әдәби кием белән ялтырасалар да, һаман да матур малайлар булып калалар, ирләр була алмыйлар».

Әдәбиятның формасы, жанры турында сөйләшкәнче, беренче чиратта каләмең

белән тормышка актив тәэсир итү турында кайгыртырга кирәктер. Кайбер әсәрләрне укыганда, уйлап куясың: эре масштаблы геройлар кирәк! «Миңа һәрвакытта да Андрей Княэко җитми» ди Ю. Бондаревның «Яр» романында Вадим Никитин. Сугышның соңгы көнендә үзенең күңел чисталыгын саклап, өлкән фашистлар тарафыннан совет солдатлары өстенә атарга чыгарылган малай-фашистларның гомерен җәлләп үзе һәлак булган Андрей җитми аңа. Миңа да шулай. Проза турында сөйләшүдә катнашкан тагын берничә иптәшкә шундый геройлар җитми икән.

Тагын уйлап куясың: прозаик тормыштан никадәр ерак китсә, шулкадәр уйлап чыгара, шулкадәр ясый. «Ә ни өчен уйлап чыгарып язарга,— дип Иван Бунин.— Герой һәм героиняләр ни өчен? Ни өчен бәйләнеш һәм чишелешле роман, повесть? Мәңгелек дан казанганнарга җитәрлек дәрәҗәдә охшамаган булып күренүдән куркып яшәү? Һәм мәңгелек газап — мәңге дәшмәү, нәкъ үзеңнеке (ихлас синеке) булган, бердәнбер чын, катгый әйтелергә тиешле, ягъни эз калдырырга, сынланырга, сүздә генә булса да, сакланып калырга тиешле нәрсә турында язмау?»

Аннан соң безнең кайбер әсәрләрдә шундый нәрсә күзәтелә: аларда еш кына автор шәхесе әсәрдәге персонажларны йота, икенче планга этәрә. Геройлар үз холык-фигыльләре белән авторның талантына буйсынып бетәләр, үз йөзләрен югалтырга мәҗбүр булалар. Ә менә В. Распутин, В. Быков әсәрләрендә алай түгел. Анда геройлар мөстәкыйль эш итәләр, авторлар аларга үзләрен күрсәтеп бетерергә тулы мөмкинлек бирәләр.

Бәхәстә катнашучыларның күбесе авторның үз стиле мәсьәләсенә кагылмады. Теләсә кайсы авторның стиле аның эчке дөньясы, рухы белән шулкадәр бәйле ки, моны тәҗрибәле күз генә күреп ала һәм форманы өйрәнеп, әсәрнең эчтәлеге тирәнлегенә төшә ала. Язучының стиле бердәм, эчке бер бөтен система буларак өйрәнелергә тиеш. Кызганычка каршы, безнең әдәбият белемендә проза әсәрләре бу юнәлештә әлегә тикшерелми. Алдарак мин бүгенге прозадагы бер-ике төсне аерып алырга тырышкан идем. Өченчесе дә бар, дүртенчесе дә... Тагы да бар... Шулардан берсе: телне белмәү, әзер трафаретлар белән, блоклар белән язу. Язучы — телне белми? Тракторист — трактор йөртә белми? Аш пешерүче — табада бәрәңге кыздыра белми? Димәк, әлеге иптәш тракторист, бу иптәш — повар түгел. Ә теге, язгалаучы иптәш?

Бәхәстә катнашкан авторларның берсе «безнең прозада котылгысыз рәвештә өчпочмак яши» дип борчылды. Шекспир, Толстой, Шолохов, Г. Ибраһимовларда булган бу «өчпочмак» — тормыштан. Автор, теләсә, аны дүрт яки биш почмаклы итә. Хикмәт бу өчпочмакларның санында түгел, ә ул почмаклар ярдәмендә тормышны кемнең ничек чагылдыруында. Күренеп тора, журналда сүз алган автор үзенең нәрсә әйтергә теләгәнен аңламаган көе кулына каләм тоткан. Бик кызганыч... Лев Толстойның бер фикере хәтердә калган: шундый бер вакыт килер, дип язган ул, язучы уйлап чыгарып түгел, нәрсә белсә, күрсә — шуны яза башлар. Чыннан да, шундый вакыт килеп җитә түгелме соң? М. Кәримнең «Озын-озак балачак», М. Алексеевның «Драчуны», В. Беловның «Кануны», Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Р. Гамзатовның «Мой Дагестан», В. Астафьевның «Последний поклон» һ. б. бик күп әсәрләр шуңа мисал түгелме соң?

Минемчә, проза турындагы бәхәстә шушы яңа формалар турында сөйләшү дә җитмәде. Һәм чагыштырмача сөйләшү җитмәде. Без, прозаиклар, соңгы дүрт-биш елда «бездә барысы да шәп, без шәп темалар күтәрәбез, бездә елына фәлән китап чыкты», дип сөйләнергә өйрәнеп киттек.

Мин исә, прозаик буларак, үз иҗатымнан риза түгел: тормышның калын, тирән катламнарын алып, зур геройлар тудырып, яхшылыкны явызлык белән бәрештереп, яшен утлары чыгарып бүгенге тормышны күрсәтә алганым юк. Ә тормыш катлаулы, тормыш бүгенге Җәмиләнең үзенә беркетелгән сыерыннан көненә бер пот сөт биргүе, механизатор Рәдифнең үз эшен намус белән башкарып йөз илле процент биргүе турындагы роман, повестьлардан алгарак китте. Кешелек җәмгыяте әдәбият алдына зур бурычлар, зур мәсьәләләр китереп куйды. Ихти-

мал, ул мәсьәләләрне күтәргән язучы инде милли рамкаларда гына кала да алмый торгандыр.

Күпме генә мактанмыйк, хакыйкать бер: зур полотнолы әсәр, бөтен бер буынны, киләчәк буыннарны да тәрбияләрлек проза әсәре иҗат итәргә кирәк! Кызганычка каршы, бездә бу әле юк. Якын арада гына булыр дип тә әйтүе кыен. Бәхәснең төп темасы әнә шул мәсьәлә тирәсендә иде, моны төрле яктан килеп, төрлечә өрфия белән төрделәр, әмма — хакыйкать шул гына.

...Евгений Евтушенко үзенең «Җиләкле урыннар» дигән романында бүгенге көннең иң гадәти күренешләрен алып кешелеклелек белән кешелексезлекне рәхимсез бәрелештерә, тормышның кырыс шартларында кеше матурлыгын — җиләкле урыннарны эзли.

Мин дә бу бәхәс барышында үзебезнең прозадагы җиләкле аланнарны эзләдем. Аланнар әлегә кечкенә, җиләкләр әлегә эре түгел... Ләкин өметне өзмик!

## Рахмай Хисмәтуллин

# ТЕМА ДА БИК МӨҺИМ!

Ул чагында без аның белән бергә эшли идек. Университетның тарих факультетын тәмамлаган укытучы иде ул. Авылдан шәһәргә күченеп килгән. Балалары әйбәт кенә укый... Машинасы бар. Дөньялары җитеш, түгәрәк.

Минем әдәбият белән шөгыльләнүемне белә һәм ул турыда сүз чыкса, еш кына өнәмичә берәр сүз кыстырып җибәрә. Туган телдә газета-журналлар алдыруга да бик исе китми.

Мин төрле күренекле язучыларның исемнәрен, данлыклы әсәрләрен атап карыйм, файдасыз. Ул аларны белми. Аның өчен чыннан да татар әдәбияты юк төсле.

Әмма минем аңа безнең әдәбиятыбызның көчле булуын, аңа битараф яшәүнең яхшы түгеллеген ничек тә исбат итәсем килә. Тик ничек?

Уйлана торгач, мин «Казан утлары»нда басылган бер әсәрдә тукталдым да бер кичне шуны күтәреп аларга кердем. Чит кешегә кереп китап укуы читендерсә дә, әсәр үз йөрәгемдәге хисләрне дә әйткәндер, мин аны илһамланган, дулкынланган хәлдә кычкырып укый башладым.

Башта теләр-теләмәс кенә тыңларга риза булган «тамашачыларым» тора-бара җанланып киткәндәй булдылар, пошмас кына диванга сөялгән урыннарыннан тураебрак утырдылар, бөтен дикъкатьләрен миңа биреп, колакларын торгыздылар.

Яртысына җитәрәк, бераз тын алырга тукталдым. Куршемнең күңелендә кайчандыр булып та сүрелә, сүнә башлаган моңнар уянды ахры.

— Ничава гына укыйсың икән син, ә?!— дигән булды. Сизәм, аның тавышы эчке бер дулкынланудан калтырый иде.

Кухняда әнисе дә безне мыштым гына тыңлап утырган икән:

— И, улым, кемнәр язган аны җанга үтәрлек итеп? Бигрәкләр дә моңлы икән.

— Әмирхан Еники!— дидем мин горурланып.

— Кем соң ул Әмирхан Еники? Бер дә ишеткәнем юк,— диде укытучы. Аның кызыксына башлавына куанып, мин очына-очына аңлатып бирдем. Читенсенүем бетте. Мин ахырын тагын да илһамланыбрак укып чыктым.

— Да-а, кызык яза икән бу. Белеп бетермибез шул,— диде куршем.— Мондый әйберләр басылган журналга язылсаң да ярар иде дә бит.

Әмма аның авызыннан мондый сүз ишетү дә минем өчен зур җиңү иде. Ул безнең әдәбиятны таныды бит тәки!

Уку барышында залга ук чыгып утырган ананың күзләрендә энҗе яшь бөртекләре шәйләп алдым һәм уңайсызланып киттем.

— Бигрәкләр дә дөресен язган инде. Һәр ананың йөрәк түрендә бар ул әйтелмәгән васыятьләр. Менә бит, әйтеп биргән балакаем. Бик әйбәт кешедер, бик вөҗданлы кешеләр моны язган кеше,— диде ана, күз яшьләреннән тартынмыйча. Аннары

улына мөрәҗәгать итеп:— Менә, улым, безнең оныклар да шулай булып үсә күрмәсеннәр. Шул яккарак каерасың түгелме соң? Белмиләр бит... Мин бик борчылам. Минем сүземә дә колак салырга кирәк икән бит әнә... Шәһәребездә аерылышулар да ешайды дип сөйлиләр. Әнә шул олыларның васыятьләрен саңга сукмаганнан да ул, улыкайларым,— дип сөйләнде.

Гүя, бу ана күптән йөрәгендә йөргән һәм беркайчан да сүзен, көчен табып әйтә алмаячак васыятен шушы әсәрдән куәт алып әйтә иде.

Биредә «Әйтелмәгән васыять» әсәре укылуын укучым, шәт, аңлагандыр инде. Иҗат ике яклы процесс ул. Язучы кайнап торган рухлы укучы ихтыяҗын тойганда, үз әсәрен дүрт күз белән көтеп торганнарын белгәндә тагын да дәртләнебрәк эшкә тотына. Укучы илһамы, аның «биотогы» язучының иң тирәндәге вөҗданын уята, офыгын киңәйтә, аны күтәрә. Бары тик укучы гына язучыны бөек итә. Ч. Айтматов, Р. Гамзатов, В. Распутин кебекләрнең союзкүләм популярлыгы да нәкъ менә актив, таләпчән, оптимистик рухлы рус укучысына хәерле сәгатьтә барып ирешү нәтиҗәсендә мөмкин булды. Аларны киң мәйданлы укучы күтәрде.

Ә безнең проза турында сөйләшүебездә әлеге проблеманың нәкъ менә шушы аспектын ныклап яктыртмадылар шикелле. Безнең проза артта кала дип дөрес чаң сугылды. Тик, нишләптер, аның гаебен урта кул язучыларда гына күрделәр.

Миңа калса, эш уртакуллыкта гына түгелдер. Сәбәпләр тирәнрәк, зуррак. Шул сәбәпләрне китереп чыгарган шартларны, мохитне тикшерү турында сүз алып барырга кирәктер. Акыллы гына фикер йөрткән әңгәмәдәшләрнең кайчак үзара гаепләшүдә генә калулары, булган хәлне раслап ияк кагып утырулары мәсьәләне җитди аспектта һәм киңәйтеп караудан читләштермәде микән дип борчылам мин.

Әйтик, ул чаңны кем ишетә? Аны тыңлаучы күпме? Проза нәрсәдән үсеп чыга? Аны кем үстерә? Үстерелгән продукциягә нинди ихтыяҗ? Бу продукциянең югары сыйфатлылыгын кемнәр таләп итә? ОТКсы кем?

Кайчак яңа әсәрне укып чыккач, рәхмәт әйтеп басылган хатларны исәпләп карасаң, безнең әдәбият белән күбрәк әллә пенсионерлар гына кызыксынамы икән кебек тәэсир калуы да мөмкин бит. Чыннан да, әдәбиятыбыз турында райком секретарьлары, алдынгы инженерлар, галимнәр, Социалистик Хезмәт Геройлары, яшь эшчеләр дә кайгырталармы?

Моның өстенә безнең әдәбиятны мәктәпләрдә нинди хәзерлекле кешеләр укыта? Ул предметның абруе нинди? Урта мәктәпне тәмамлап чыккан бала бүгенге прозаның чын-реаль агышын, юнәлешен, аның казанышларын да белеп чыгамы? Әгәр бала мәктәптә андый сүз ишетмәсә, ул аны үзлегеннән генә хөрмәт итә алырмы?

Сөйләшүдә «уртакул»лылар адресына тегеләй дә, болай да тәнкыйть сүзләре яуды. Туфан Миңнуллин да: «Бүгенге әдәбиятыбызның иң төп проблемасы да — урта кул әсәрләр икән. Шулар басып китмәсен иде», дип язды. Аннары уртакуллыкның төп чыганагы итеп теманы санап, ул: «Тема дип аталган саламга тотынучыларның хәйләсен тәнкыйть тиз фаш итәргә... тиеш» дип тә өстәде.

Артык кызып кителмәде микән?

Тема дип, үзе шул өлкәдә эшләмичә, аны йөрәгеннән кичермичә генә язучылар да бардыр бәлки. Әмма, гафу итегез, шинчылар темасы, нефтехимия темасы, КамАЗ темасы — изге темалар. Бу меңләгән кешеләрнең язмышы. Монда аларга гына хас кичерешләр дөньясы, монда халкыбызның интернациональләшә барган һәм шул ук вакытта милли дә булып калырга тиешле үзенчәлекле характерлары чарлана. Ничек итеп бу рухи катламнарны, турыдан-туры шедеврлар тудыра алмый, дип кенә читтә калдырырга мөмкин?

Телисеңме-юкмы, космоска кадәр күтәрелгән кешелек яңадан-яңа профессияләр, әр-яңа производстволар, яңа фәннәр тудыра тора. Димәк ки, яңа төр психология туа тора, кешенең кичерешләре катлаулана бара. Менә шушы яңа төр дөньяларга барып кергән язучылар үзләренең бәлки әлегә өлгереп җитмәгән язмаларында яңа өлкәдәге кешеләрнең бер төрле генә булып бетә алмаячак холыкларын, психологик климатны өйрәнәләр, бу өлкәләргә үтеп керергә вакыты да, физик мөмкинлеге дә булмаган «даһиларыбыз» өчен психологик чимал тудыралар. Прозаның артта калуының сәбәбен әнә шул эшләрне эшләп ятучы «уртакул»лыларга өеп, аларны гаепләү дөрес микән?

Әйтик, Э. Касыймовның Менделеевск химиклары турындагы әсәре бик үк шедевр да булып бетмәде ди. Ә соң шул кул тимәгән үзе бер специфик психологияле дөньябыз, разведка формасында булса да язылган шул әсәрсез дә, бөтенләй онытылып калса, нәрсә, бу яхшырак булыр идемени?! Бик начар булыр иде. Инде хәзер икенче яшь язучы, әйтик, нефтехимия турында әсәр язарга тотынса, Касыймов әсәренә дә таянып, аның хаталарын да искә алып бер баскыч югары күтәреләчәк. Бөтен өлкәләрдә дә өйрәнү, тикшеренү шулай этаплап бара ич инде! Бөек язучы тусын өчен йөзләгән язучының каләмгә тотынуы, санның сыйфатка әверелүе кирәк диләр түгелме соң?

Аннары, ахыр чиктә, тәнкыйтьләүчеләр үзләре дә урта кул язучының әсәрләре кирәклеккә тану белән тәмам итәләр. «Кай яктандыр кирәкле, әһәмиятле булган сыйфатлар аларда, әлбәттә, бар. Сурәтләргә алынган материал кызыклы, заманча, актуаль булырга мөмкин». (Ф. Ганиева.)

Һәм, ниһаять, Т. Миңнуллин үзе дә: «Урта кул әсәрләр күп дип никадәр бәргәләнсәк тә, алар бетмәячәктер» дип танырга мәҗбүр булды. С. Шәмсинең талантлылар да «уртакул»лылардан үрнәк алып, «нишләп интегим соң әле мин» дип әсәрләрен ашыкпошык эшләп бастыра башладылар дигән фикере белән һич тә килешеп булмый. Чын талант ул алай гына күңел төшермәс тә иде, алай дип кенә өлгермәгән әсәрен дөньяга чыгармас та иде. Монда объектив сәбәпләр бардыр. Беренчедән, шәһәрләшү процессы үзе үк безнең өчен яңа дөнья. Моның өстенә бүгенге көнгә чаклы бездә эшчеләр сыйныфы, промышленность, шәһәрләшү дөньясын чын-чынлап үзенеке итеп санаган язучыларыбыз күп түгел. Гәрчә, Г. Бәширов үзенең әдәбият турындагы бер мәкаләсендә шәһәр һәм промышленность дөньясының үз теле, үз стиле, үз язучылары туарга тиеш дип зур оптимизм белән язган иде.

Прозаның артта калуының сәбәбен тагын мин түбәндәгедә күрәм. Без бик еш тормыш эченә керү, аны өйрәнү, производствога бару дибез. Ләкин М. Горький, Ш. Камаллардан үрнәк алып, күнегелгән тормыш шартларын ташлап торып, каядыр шаулы төзелешләргә, конфликтлар кайнап торган көрәшле мәйданнарга бик сирәкләр генә китә. Күпләр үзе күргән, кичергән тормыш запасы җитәрлек дип саный, күрәсең. Ә бит кеше нинди генә даһи булмасын, аның әсәре үз язмышы аша кайнап тумаса, тормыш аны үзе мәҗбүр итеп яздырмаса, кешеләрне сөйләтеп яки бармак фантазиясеннән чыгып кына бөек әйбер тудыра алмый.

Әйтегез, табыгыз, язучының кайнар биографиясе чагылмаган берәр бөек әсәр бармы дөньяда?!

Сөйләшүдә беравык тискәре геройлар турында язылган әсәрләрне хуплап чыгыш ясадылар. Бәлки андый әсәрләр дә кирәктер. Әмма алар күпкә китсә, күңелле булмас. Тискәре герой белән параллель рәвештә көчле рухлы, якты күңелле, олы хәсрәтләрне дә көлеп каршы ала һәм җиңә торган шашкын геройлар да бирелсә, бик отышлы булыр иде. Кеше тормышы болай да бик кыска. Ул болай да кырыслыкны һәм авырлыкны шактый күрә. Инде китапларда да аны без гел явыз күңелле кешеләр белән генә очраштырсак, һаман да шул һәлакәтләр, мәңге бетмәс гайбәтләр, мәкерләр турында гына сөйли башласак, матурлык һәм кешелек нурын каян алыр ул? Без, партиянең уңай геройны алга чыгарырга кушуын искә алып, тормыш ыбыр-чыбырларын җиңеп чын кеше булып кала алган, газапта, оттырышта да күңеленнән нур сибә алган фидаи җаннарның ягымлы яшәү көчен укучыларыбызга җиткерик, геройларның шашкынлыгына Горькийча дан җырлыйк.

Көрәштә әлсерәгән күңелләр геройның рәхим-шәфкатьле иңен тойсын, алардан җанын җылытсын, шау-шулы, кысан нервылы шәһәрләр генә түгел, ә иркен җилләрдә шатланып-тирбәлеп утырган чәчәкле далалар барлыгын, водопровод суы гына түгел, ә гөбердәп аккан саф сулы чишмәләр, тау елгалары барлыгын, тар коридорлар гына түгел, кояшлы, мәһабәт, серле таулар барлыгын да тойсын.

Минем прозабызны ялгышканны дөрес юлга чыгаручы, рәнҗегәнне яклаучы итеп, боекканның күңелен ачучы, арып калганга тормыш элексиры бирүче итеп, өшегән җаннар кешелек җылысы эзләп сыена торган учак итеп, һәм, ниһаять, Бөек Вөҗдан сакчысы итеп күрәсем килә.

Әйе, чын язучы ул Бөек Вөҗдан чакыруына җавап яза, бөтен кешелек өчен, барлык гасырлар өчен.

Ул күрә, әнә: алдаудан шаша язган, «быть или не быть?» дип сыкранган Гамлет-

лар, сөйгәне хыянәт итте дип яла ягудан җаны сукырайган Отеллолар, революция давылларында вөҗдан кууыннан беркая да качып котыла алмыйча әлсерәп, үз капкасы төбенә кайтып егылган Григорий Мелеховлар һәм башка бик күпләр белән бергә «Намус»тан гүзәл җанлы, намуслы Нәфисәләр, «Әйтелмәгән васыять»тән һаман да сүзен әйтергә ымсынып соңгы сулышын алып яткан Акъәбиләр, «Буранлы полустанок»тан гади кеше күңеле буранарын бөтен дөнья биеклегенә менгергән Идегәйләр, «Җомга көн, кич белән»нән вөҗдансыз балаларның йокыларын качырган Бибинурлар, М. Мәһдиев әсәрләреннән бихисап мөлаем пакь күңеллеләр, «Табу һәм югалту»дан, «Юлда уйлануллар»дан М. Юнысның моңлы уйлары вөҗдан байрагы күтәреп яңа үрләргә менеп баралар.

Никадәр Вөҗдан! Әмма кешелеккә һаман да вөҗдан җитешми!

Һәм әле һаман да кайсы гына язучы нинди генә тема күтәрмәсен, гаделлекнең бәләкәй генә чишмәләрен ачамы ул, саф мәхәббәт инешләренә юл ярамы, хәрамлыкны, рәнҗетелүләрне фаш итәме, дуслык, кешелеклелек елгаларын тирәнәйтәме, ахыр чиктә барысы да бер бөек диңгезгә — кешене кеше иткән, кешелек җәмгыятен яшәткән әнә шул Бөек Вөҗдан дигән олы диңгезгә коя.

## КЫЮЛЫК КИРӘК!

«Казан утлары» журналында бүгенге проза турында укучылар бәхәсен укыгач, мин дә кулыма каләм алырга булдым. Мин язучыларның һәрбер әсәрен, шул исәптән «Казан утлары»нда басылып барган повесть-хикәяләрен, кызыксынып укып барам, андагы геройлар белән шатланам, аларга кайгы килсә, алар белән бергә кайгырам.

Хәзерге заман прозасын күз алдына китергәндә, берничә язучының уңышлы әсәрләре алга килеп баса.

Аларның әсәрләрен укыгач, тормышка яңадан кайткандай буласың, тормышның четерекле якларын күрәсең, уйлыйсың. Сүз дә юк, аларның әсәрләре тормышчан, чынбарлыктан алынып, язучы фантазиясе белән, чын әдәби тел белән язылган. Мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Исәнме, Кәшфи абзый», Аяз Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» повестьларын укыгач, күңелләр сөенеп куя. Өлкән буын язучыларыбызның традицияләрен дәвам итүчеләр бар дип, күңелләр куана.

Тормыш сәхнә уены гына түгел, анда төрле хәлләр: куанычлар, сөенечләр, авыр кайгылар булып тора. Әнә шул кайгыларга бирешмәүче, тормыш энтузиазмы белән яшәүчеләрне китап дөньясына алып керүче язучыларыбызга рәхмәт.

Аяз Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» дигән повестенда әһәмиятле тема кызыл җеп булып сузылган. Ике туганның мал артыннан куы мена-мена фаҗигага әйләнәсен искәртә әсәр. Кешеләрне зиннәтле келәм, паласларга, машинага табынырга түгел, ә бәлки болындагы чәчәкләргә, кошлар сайравына сокланырга өнди. Мөхәммәт Мәһдиев тә бу теманы читләтеп узмый. Аның әсәрләрендә бу бик ачык чагыла.

Ә менә Фәүзия Бәйрәмованың «Болын» әсәрендә бу тема мәхәббәт темасы белән бергә бәйләп бирелгән дисәң, бер дә ялгыш булмас. Анда Алсу дигән саф, гөнаһсыз кыз, болындагы чәчәкләргә, кошлар сайравына гашыйк кыз, үзенең идеалларына тугры булып, шәһәр бүлмәсенең шыплап тутырылган зиннәтле җиһазлардан өстен калып, авылдагы шул чәчәкле болыннарга, сафлыкка, яктылыкка ялан тәпи йөгереп китүен язучы бик тормышчан сурәтләгән. Менә шундый тормышчан язылган әсәрләрне укыгач, язучыларыбызга укучыларның ихтирамы һәм ышанычы торган саен арта төшә.

Шушындый тормышчан язылган әсәрләребез арасында әле прозабызга кыяр-кыймас кына килүче язучыларыбыз да бар, алар әйтәсе фикерләрен кыю әйтмиләр, тормышны аллы-гөлле чәчәкләргә генә төреп бирәләр, ә тормышның тискәре якларын күрсәтергә ничектер батырчылык итмиләр. Кыяр-кыймас кына язылган шома әсәрләрне укыйсың да, күңелдә берни дә эз калмый, ә бары тик бушлык кына кала.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә, урта кул язылган әсәрләргә караганда, тормышчан әсәрләр күбрәк туа. Хөрмәтле язучыларыбыз тагын да шулай уңышлы, тормышчан әсәрләр иҗат итсеннәр иде, урта кул әсәрләргә, коеп куйган «шома» әсәрләргә урын булмасын иде.

Язучыларыбызга иҗатларында уңышлар телим.

**Бакый СӘЛӘХОВ.**

Арча районы, Пешәңгәр авылы.

*Ильяс Кудашев-Ашказарскийның туууына 100 ел*

# СӘХНӘ ФИДАКАРЕ

Егерменче гасырның башы татар әдәбияты һәм сәнгатендә җанлану, яңа тармаклар барлыкка килү белән характерлы. Әнә шул чорда культурабыз үсешенең яңа бер баскычы буларак, профессиональ театр сәнгате дә туа. Бу хәрәкәтнең көчәеп, үсеп китүенә 1905—1907 еллардагы беренче рус революциясе зур этәргеч ясый.



Халык тормышындагы яңа күренешләр билгеле бер тарихи шартлар нәтиҗәсендә барлыкка килү белән бергә, һәр яңа эшнең башлап йөрүчесе дә була. Татар профессиональ театрының оешып, формалашып китүе, һичшиксез, И. Кудашев-Ашказарский исеме белән тыгыз бәйле.

Культурабыз тарихында үзенчәлекле роль уйнаган бу шәхеснең эшчәнлеге әлегә кадәр тиешле бәяне алган дип әйтеп булмый. Шуны искә алып, бу мәкаләдә аның турында мөмкин кадәр күбрәк, төгәлрәк мәгълүмат бирү, аның оештыру эшчәнлегенә ныграк игътибар юнәлтү күздә тотыла.

Күп санлы материаллар И. Кудашев-Ашказарскийның беренче адымнарыннан ук үз алдына татар профессиональ театрын барлыкка китерү шикелле олы максат куеп эш итүе, төрле каршылыкларны җиңә-җиңә шул юлдан каһарманнарча баруы турында сөйли.

Ул 1884 елның 3 мартында (яңа стиль белән) элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе Богады волосте Шыланлыкул авылы крестьяны Батыргәрәй семьясында туа. Тиешле белем алганнан соң, 1899 елны 15 яшендә Казанга килеп, Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Бу исә әлеге мәктәп сәхнәсендә татар студентлары рус телендә спектакльләр куя башлаган чор.

Яңалыкка омтылучы яшүсмер Ильяс та бу хәрәкәткә бик тиз кушылып китә. Ул спектакльләрдә катнаша, әдәби-музыкаль кичәләрдә гармунда, скрипкада уйный, җырлый. Бу эштә иң актив студентлардан берсе булып әверелә һәм татар телендә спектакль кую турында да уйлана башлый. Аның бу изге теләген шушы ук мәктәпнең югары курсларында укыган Г. Коләхметов, Х. Ямашев кебек революцион рухлы алдынгы яшьләр аеруча хуплый. Ләкин татар телендә спектакль кую әле хыялда гына булып, И. Кудашевка да байтак көтәргә, күп киртәләрне үтәргә туры килә.

Укытучылар мәктәбен 1904 елда тәмамлап И. Кудашев Оренбургка китә. Бирегә ул татар мәктәбендә төрле фәннәр укыта, башка милләт балаларына татар телен өйрәтә. һәм тиздән Казанда кузгалган теләген тормышка ашыру чарасына керешә. Башта театр белән кызыксынган мәктәп-мәдрәсә шәкертләреннән сәхнәгә чыгарлык көчләр эзерли. Спектакль кую өчен А. Н. Островскийның «В чужом пиру похмелье» комедиясен тәрҗемә итә. Бу әсәр аңа шул чор тормышына хас булган ком-

сызлык, тупаслык, наданлыкка каршы юнәлдерелгәнлеге, мәгърифәтчелек идеяләрен үткәрүе белән ошый. Тәрҗемә «Наданлык илә галимлек» дип исемләнә. Персонажлар татар исемнәре белән бирелә. Һәм И. Кудашев пьесаны сәхнәдә күрсәтү артыннан йөри башлый. Ләкин төрле каршылыкларга очрый. Татар телендә ачык спектакль куярга иң элек җирле администрация рөхсәт бирми.

И. Кудашев Петербургка китә һәм Эчке эшләр министрлыгы каршындагы матбугат эшләре буенча баш идарәгә мөрәҗәгать итә. Төрки телләрдәге әсәрләрне тикшерүче цензор В. Д. Смирнов, кульъязманы оригинал белән чагыштырып караганнан соң, монда зур үзгәрешләр кертелмәвен әйтә һәм тәрҗемәне сәхнәгә куярга тоткарлык юк, дип нәтиҗә ясый.

Татар культурасы тарихында беренче тапкыр ачык спектакль куярга рәсми рөхсәт бирелә.

Петербургтан рухланып кайткан И. Кудашев үзе туплаган һәвәскәрләр белән байтак әзерлек эшләре алып барганнан соң, спектакльнең көне билгеләнә. Шәһәр театры бинасы арендага алынып, спектакль кайчан, кайда, ничек булачагы турында беренче тапкыр типографиядә бик тәфсилле белдерү бастырып таратыла. Анда рус телендә «1905 елның 3 декабрендә И. Б. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге мөселман драма артистлары тарафыннан Россиядә беренче мәртәбә рус һәм мөселман телләрендә спектакль куелачак» дип языла. Рус телендә А. С. Грибоедовның «Акыллылык бәласе» һәм Н. В. Гогольнең «Ревизор» комедияләреннән өзекләр бирелеп, Чацкий һәм Хлестаков рольләрен Ашказарский уйнаячагы татар телендә исә милли костюмнарда һәм ике пәрдәдә «Наданлык илә галимлек» комедиясе куелачагы хәбәр ителә. Катнашучыларның исемнәре һәм рольләре күрсәтелә. Антракт вакытларында кыллы оркестр уйнап торачагы, ахырда бик зур программалы кинематограф картиналары күрсәтеләчәге турында әйтелә. Шәригать законнарын истә тотып, театрга килгән мөселман хатын-кызлары өчен махсус чаралар күрелгәнлеге турында белдерү ясала.

Куелачак спектакльне — татар тормышында булачак шундый зур яңалыкны — алдынгы җәмәгатьчелек, рус матбугаты да хуплап каршылый. «Оренбургская газета»ның беренче битендә иң түрдә рус һәм татар телләрендә зур итеп анонс (белдерү) бирелә, өченче битендә исә мондый адымны югары бәяләгән мәкалә урнаштырыла. Ләкин, икенче яктан, көткән көтелгән бу спектакль кара көчләрдә яңалыкка каршы дошманлык хисен куертып җибәрә. Фанатик динчеләр, сәхнәгә чыгарга ярамый дигән сылтау белән, Ашказарскийга каршы хәрәкәт башлыйлар. Шәһәр башлыгына вәкилләр җибәрелә. Губернаторга И. Кудашев «...шушы елның 18 октябрь демонстрациясенә катнашты.— Яшәсен хөррият! Бетсен царизм! — дигән язулы кызыл байрак күтәреп барды» дигән доносләр җиткерелә [1].

Кара көчләр үз максатларына ирешә, спектакль куйдырылмый. Реакцион динчеләр һәм патша чиновниклары бергәләп рәсми татар театрын тудыру юлындагы беренче җитди адымга шулай киртә салалар.

Куелмый калса да, Ашказарский әзерләгән беренче рәсми спектакль гаять зур тарихи фактка әверелә. Аның шундый язмышка дучар булуы киң җәмәгатьчелеккә, бөтен Россиягә ишетелә. Нәтиҗәдә, гүя шуңа җавап итеп, әле моңа кадәр мәктәп-мәдрәсә, өй шартларында гына уйналып килгән театрны киңрәк аудиториягә чыгару омтылышы башка шәһәрләрдә көчәя. 1906 елның 21 апрелендә Уфада, 5 май һәм 22 декабрьда Казанда, 1907 елның 13 гыйнварында Әстерханда бер-бер артлы зур театр биналарында татар телендә беренче ачык спектакльләр уйнала. Ләкин әле эш һәвәскәрлектән узмый. Татар театрын профессиональләштерү мәсьәләсе алгы планга баса. Бу эш шулай ук Ашказарскийга барып тоташа.

Рәсми театр тудыру юнәлешендә беренче бозны кузгаткан Ашказарский Казан, Уфа, Әстерхан шәһәрләрендә ачык спектакльләр куелу хәбәрен ишетү белән эшкә яңадан һәм ныклап тотына, театрны киңрәк мәйданга чыгаруның яңа юлларын, яңа формаларын эзли. Ул 1907 елның 10 февралендә Оренбургның Халык йорты бинасында зур кичә оештыра. Кичәнең беренче бүлегендә, рус егетләрен катнаштырып, Н. В. Гогольнең «Өйләнү» комедиясен сәхнәгә чыгара. Әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә башлаган «Вакыт» газетасы шул уңайдан мәкалә урнаштырып, баш каһарман Кочкарев ролендәге Ашказарский уенына юга-

---

[1] Госман Х. Беренче татар спектаклена 35 ел.— Кызыл Татарстан, 1940, 15 декабрь.

**Городской АНОНСЪ театрЪ.**

**ТОЛЬКО НА ОДНУ ГАСТРОЛЬ**

# ѢДЕТЪ

ТРУППА

**мусульманскихъ драматическихъ артистовъ**
**подъ управленіемъ И. Б. Кудашева-Ашкадарскаго.**

اعلان

الله نصیب ایلاسه

اورنبورغ قالاسینك تشقی عبرت خانه‌سی (تیاتری)

برگنه غاستروله (کونگه) کیله‌در

مسلمانلری درامانیچسکی ترویپا آرتیستلری

ا. ب. قوداشف - آشقادارسکی نك تصرفنده.

*Татар театры турында матбугатта беренче рәсми белдерү. — «Оренбургская газета». 1905, 27 ноябрь.*

ры бәя бирә, бер татарның рус публикасы каршына чыгып көчле алкышлар белән кабул ителүен анык зур сәхнәдәге уңышлы дебюты дип саный[1].

Рус телендә уйналган спектакльдән соң татарча концерт бирелә. Сәхнәгә татар егетләре чыгып «җанлы картина» күрсәтәләр. Бер урынга эре хәрефләр белән «К свету — Яктылыкка» дип язып куела.

Ашказарскийның башлап йөрүе нәтиҗәсендә ясалган мондый зур программалы һәм киң катлау тамашачыны чакырып үткәрелгән музыкаль-драматик кичәләр тагын кабатлана. Даими бер үзеге булган театр труппасы оешып килә. Шул ук Халык йорты сәхнәсендә 1907 елның 3 апрелендә Ф. Халидинең «Морат Сәлимов» драмасы һәм А. П. Чеховның «Кыз сорау» водевиле куела. Бу — Оренбургта, зур сәхнәдә татар телендә уйналган беренче спектакль, бу — соңрак «Сәйяр» дип исемләнәчәк атаклы труппаның башлангычы, туган көне. Бу фактны Оренбургта Х. Ямашев җитәкчелегендә чыга торган татар телендәге беренче большевистик «Урал» газетасы аеруча күтәреп ала, театр мәйданга килүне зур эш дип бәяләп, катнашучыларны тәбрикли[2].

Иҗат юлын шушы вакытта башлап җибәргән һәм зур театр эшлеклесе булып киткән Вәли Мортазин-Иманскийның язмаларына караганда, «Бу елны Оренбургтагы татарча спектакль, әдәбият-концерт кичәләренең барысы да дип әйтерлек, Оренбург социал-демократлар оешмасы кирәкләре өчен акча табу уе белән куела»[3]. Димәк, татар театры үзенең башлангыч чорында ук большевиклар партиясе белән бәйләнештә була, алар йөзендә үзенә теләктәшлек итүчеләрне, яклаучыларны таба.

Социал-демократлар яки уралчыларның театраль яшьләр белән тыгыз бәйләнешендәге җепнең очы, һичшиксез, Х. Ямашев һәм Ашказарскийның, әйткәнебезчә, әле Казанда татар укытучылар мәктәбендә үк якыннан таныш булулары, милли театр турында да бергәләп уйлануларына барып тоташа. Профессиональ театрның татар культура үзәкләреннән берсенә әверелә барган Оренбургта оешып китүе дә юктан гына булмаска тиеш. Күпмедер вакыт бер тирәдә яшәгән-эшләгән бу ике шәхеснең театр мәсьәләләрен дә бергәләп хәл итмәве һич мөмкин түгел.

1905 елгы афишага «бары бер генә гастроль» дип язылу, спектакльне «читтән килгән мөселман драма труппасы» исеменнән тәкъдим итү ул вакытта ук Ашказарскийның күчмә театр төзүне күздә тотып эш иткәнлеге турында сөйли. Бу планын ул Оренбург, Казан, Уфа, Уральск һ. б. төбәкләрдәге һәвәскәрләрне бер тирәгә җыеп тормышка ашырырга, көчлерәк труппа белән Россия шәһәрләренә зур гастрольгә чыгарга уйлый. Бу турыда газетада белдерү дә ясала.

Билгеле, төрле яклардагы табигый талантларны бергә туплау җиңел эш булмый. Әлегә аларның һәрберсе «үз казанында кайный». Мәсәлән, бу вакытта Казанда көчле генә труппа оешып килә. Алар инде «Кызганыч бала», «Гыйшык бәласе», «Оят яки күз яше», «Өйләнү» һ. б. катлаулы гына әсәрләрне сәхнәгә куеп, уңай нәтиҗәләргә ирешә. Алар турында матбугатта күп языла, уңай фикерләр әйтелә. Ләкин бу труппада катнашучыларның берсе дә профессиональ артист булып әверелми. Мәсәлән, Ф. Әмирханның аяклары авырта башлый һәм ул ныклап язучылык эшенә бирелә, Г. Коләхметов революция юлын сайлый, С. Рәмиев тәп игътибарын поэзиягә юнәлтә. Башкалары кайсы журналист я матбугат хезмәткәре, кайсы врач, укытучы яисә юрист булып китә.

[1] Вакыт, 1907, 13 февраль.
[2] Урал, 1907, 5 апрель.

[3] Мортазин В., Ченәкай Т. Татар театры тарихыннан. Мәскәү, 1926, 34 б.

Димәк, Казандагы инде беркадәр өзерлекле көчләрнең дә күбесе, төрле сәбәпләр аркасында, артистлык хезмәтеннән аерыла.

Ашказарский куелган максатны тормышка ашыру юлындагы активлыгын арттыра гына бара. Гастроль өчен татар телендәге әлегә бик аз санлы пьесалардан сайлап алып, репертуар булдыра. «Оят яки күз яше», «Надалык илә галимлек» һәм «Денщик Гали» кебек әсәрләрне сәхнәгә куеп, артистларны олы юлга әзерли.

Труппа әлегә алты-җиде кешедән артмый. Аның нигезен Ашказарский үзе, мәдрәсә ташлап чыккан яки шәкертләр хәрәкәтендә катнашкан өчен мәдрәсәдән куылган Нурулла Гайнуллин, Әхмәт Ишморатов-Кулалаев, Нуретдин Хәйретдинов-Ахундов, кием чистарту мастерское хезмәткәре Вәли Мортазин-Иманский кебек яшьләр тәшкил итә. Болар — профессиональ татар театр труппасының беренче карлыгачлары, ил буйлап билгесез сәяхәткә чыгарга тәвәккәлләгән беренче сәхнә каһарманнары. Бу кечкенә коллектив үзен «Россиядә И. Б. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге беренче мөселман драма артистлары труппасы» дип атый, игълан, программаларда шул исем кулланыла, вакытлы матбугатта да шулай дип языла.

Труппа 1907 елның май аенда Бозаулык, Самара, Сембер, Казан, Чистай, Нижний Новгород маршруты белән юлга чыга. 1905 елгы революциянең үткен кылычы ярдәмендә реакцион даирәләрнең театрга каршы торуы азмы-күпме сындырылса һәм беркадәр иркенлек тоелса да, революциянең шифалы җилләре тәэсирендә рухланып эшләргә күпмедер мөмкинлек туса да, труппа тормышында иң катлаулы, иң авыр чор башлана. Шуның белән бергә труппа һәрьяктан да иң кызыклы дәвергә килеп керә.

Ашказарскийның татар театрын киң мәйданга чыгару, профессиональләштерү юлындагы тырышлыгын алдынгы җәмәгатьчелек һәр урында бердәм хуплый. Труппаның эше, куйган спектакльләре турында татар һәм рус матбугатында да күп санлы уңай мәкалә, рецензияләр басыла. Билгеләнгән маршрут буенча Казан, Нижний Новгородта тукталу Ашказарскийның рухын аеруча күтәрә. Аның мондый эш башлавын, мәсәлән, Н. Ф. Юшков, Г. Камал, Г. Кәрам кебек драматург һәм тәнкыйтьчеләр дә югары бәяли, «Надалык илә галимлек», «Оят яки күз яше», «Указ баласе» кебек үз чорының актуаль мәсьәләләрен, тормыш-көнкүрештәге каршылыкларны чагылдырган спектакльләрен карап, файдалы киңәшләр белән чыга [1].

Шул рәвешле, Ашказарскийның тырышлыгы белән татар культурасы тарихында даими эшли торган беренче профессиональ театр труппасы мәйданга килеп, иң элек халыкны агарту бурычын алга куйган хәлдә, ил буйлап төрле шәһәрләрдә гастрольдә йөри башлый. Труппага сәләтле көчләр өстәлә. С. Гыйззәтуллина-Волжская, Габдулла Кариев кебек булачак сәхнә йолдызлары да театр дөньясына 1907 елда Ашказарский ярдәмендә килеп керә.

Тиздән Ашказарский труппаны Петербург, Кырым, Кавказ, Урта Азия маршрутын күздә тотып Касыйм һәм Рязань шәһәрләре аша Мәскәүгә алып китә. Мәскәүдә 1907 елның ахырында труппа икегә бүленеп, бер өлеше Ашказарский белән Петербургка, икенчесе Г. Кариев җитәкчелегендә Уральскига китә. Ашказарскийның да, төп көчләрне туплаган һәм тиздән «Сәйяр» дип исемләнәчәк труппаның да тормышында яңа этап башлана.

Эшнең шундый юнәлеш алуына да карамастан, татар театры тарихында төп рольне уйнаячак труппаны оештырып киң мәйданга чыгаруда, җәмәгатьчелеккә таныттуда Ашказарскийның роле зур. 1905 елда беренче спектакльгә рөхсәт алудан башлап 1907 елның ахырына кадәр булган кыска гына вакыт эчендә ул гаять күп эшләр башкара. Үзенең кыюлыгы, рус телен яхшы белүе һәм башка сәләтләре аркасында теләсә кая үтеп керә, үз фикерен куәтли, максатына ирешә. Труппага сәләтле яңа көчләрне җәлеп итү юнәлешендә дә ул актив эшли. С. Гыйззәтуллина-Волжская белән Г. Кариевны табып труппага кертеп җибәрү, аларга үсәргә юл ачу үзе генә дә аерым игътибарга лаек.

Әлбәттә, Ашказарский бу труппадан аерылу белән сәхнәне ташламый, яңа труппа оештыра. Аны ул үз труппасының беренче исеме белән дә йөртә, «Фаҗига вә музыкаи исламия» дип тә атый. Труппа башлыча музыкаль-драматик юнәлеш ала.

Ашказарский рус, Европа культурасын яхшы үзләштергән, үз заманының белемле бер кешесе булу белән бергә, күп-

---

[1] Юшков Н. Ф. Восточный праздник.— Казанский вечер, 1907, 14 июль; Камал Г. Татарча театр.— «Йолдыз», 1907, 15 июль; Кәрам Г. Мәкаржадан мәктүб.— «Йолдыз», 1907, 12 сентябрь.

кырлы сәләте белән дә аерылып тора: җырлый, пианино, скрипка, мандолина һәм төрле гармуннарда уйный, нәфис сүз сөйли. Әнә шулар аны сәхнәнең эстрада тәренә дә этәрә, ул драма һәм эстрада төрен бергә аралаштырып алып бара. Аның Татарстан дәүләт музеенда сакланган архивындагы җыр-шигырь китаплары эстрада белән күп шөгыльләнүе турында сөйли. Труппа белән беренче мәртәбә Мәскәүгә килгәч үк ул төрле шигырьләр, сатирик хикәяләр сөйләп, скрипка һәм тальян гармунында «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Кабан өсте», «Хөррият» көйләрен уйнап, пластинкага яздырып калдыра.

Сәхнәгә аяк басуының беренче көннәреннән үк Ашказарский гастрольче артист булып китә. Кариевлардан аерылганнан соң да ул үзенең труппасы белән илебезнең төрле төбәкләренә барып чыга. Һәр урында сәләтле яшьләрне эзләп табып, алар белән бергә спектакль, концертлар куя. Һәр урында типографиядә басылган программа һәм афишалар тарата, бигрәк тә рус матбугаты белән тыгыз бәйләнешкә керә. Театрны пропагандалауга ул зур игътибар бирә. Сәхнә фамилиясе итеп мәһабәт Ашказар елгасы һәм халыкта киң таралган «Ашказар» көенең исемен алуы да туып килә торган театрга игътибарны ныграк юнәлтү өчен эшләнә. Ашказарский төрле формалар кулланып, яшьләрнең фикерен кузгатучы, күпләрне сәхнәгә тартучы тынгысыз бер театр эшлеклесе була. З. Солтанов, С. Байкина, Г. Адаков, Г. Донской һ. б. популяр артистлар да үз вакытында аның труппасы аша үтә. Мәсәлән, 1914 елның гыйнварендә ул Урта Азия, Кавказ якларына йөреп килеп, Петербургта Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын куя. Бу спектакльдә Октябрьгә кадәрге чорда бердәнбер театраль белемле һәм соңыннан талантлы артистка булып үсеп чыккан Әшраф Синяева катнаша.

Драматик артист, режиссер буларак Ашказарский, әлбәттә, Кариевлар дәрәҗәсенә күтәрелми. Аңа төрле характердагы тәнкыйть сүзләрен дә байтак ишетергә туры килә. Әмма ул халыкны агарту юнәлешендә үз мөмкинлекләреннән чыгып эш итә. Аның репертуарында катлаулы, зур әсәрләргә караганда җиңелчә водевильләр, эстрада номерлары күбрәк урын ала. Шулай да аның «Надanлык илә галимлек», «Оят яки күз яше», «Кызганыч бала», «Бәхетсез егет», «Уйнаш», «Дәҗҗал» кебек җитди әсәрләрне дә уңышлы итеп куйганлыгы, болардагы төп рольләрдән бай сәүдәгәрләрне уңышлы гәүдәләндергәнлеге мәгълүм.

Ашказарский — бөтен гомерен сәхнә сәнгатенә багышлаган, театр эшенә фанатикларча бирелгән шәхесләрдән берсе. Октябрьдан соң ул фронт труппаларында, Оренбург һәм Казан сәхнәләрендә, төрле культура-агарту оешмаларында эшли. 1926 елда аңа Татарстан хөкүмәте тарафыннан Хезмәт батыры дигән мактаулы исем бирелә. И. Кудашев-Ашказарский 1942 елның 31 декабрендә Казанда үлә.

Гомумән алганда, Ильяс Ашказарский үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән культурабыз тарихында сизелерлек эз калдырды.

Башлап юл яру беркайчан да җиңел эш түгел. Бу авырлыкны Ашказарский каһарманнарча җиңеп чыкты. Без сәхнәбезнең пионеры исемен башка күренекле шәхесләр белән рәттән горурланып искә алабыз.

Һәнүз МӘХМҮТОВ.

# БАШЛАП ЙӨРҮЧЕЛӘРДӘН

Билгеле булганча, татар театрына мәгънәви нигез салучы, дип хаклы рәвештә Габдулла Кариевны таныйбыз. Ул бер буын талантлы артистларны сәхнәгә күтәрде, реалистик татар сәхнә мәктәбен тудырды. Ләкин театр кебек зур сәнгатьне тудыруда бер яки ике кешенең генә түгел, күпләгән фидакарьләрнең иҗат көче, армый-талмый шул өлкәдә хезмәт итүе сорала. Татар театрын башлап җибәрү һәм үстерүдә зур тырышлык күрсәткән шәхесләрнең берсе — Ильяс Кудашев-Ашказарский иде.

Татар театрын башлап җибәрүче, аңа нигез ташы салучылар турында фәнни тикшеренү эшләре, истәлекләр чыгып тора. Мин исә тарихи документларның һәрбер иҗат кешесенең тормыш юлын һәм иҗатын яктыртуда, өйрәнүдә иң кирәкле чыганаклар булуын искә алып, И. Кудашев-Ашказар-

скийга мөнәсәбәте булган кайбер материалларны укучылар игътибарына тәкъдим итмәкче булам.

1907 елның 19 нчы маенда Оренбургның «Тополь бакчасында» 1905 елны ук хәзерләнә башлаган «Наданнар илә галимнәр» спектакле куела. Шуннан соң И. Кудашев-Ашказарский труппасы Идел буе шәһәрләре: Самара, Сембер, Казан һәм Нижний Новгородка юнәлә.




Труппа беренче гастролендә спектаклен берәр генә тапкыр куеп китә диган (игъланнарда шулай язылган) мәгълүмат әдәбиятта еш очрый. Хәлбуки, документларга караганда, алай ук түгел икән. Мәсәлән, безнең кулыбызда И. Кудашев-Ашказарскийның Сембер шәһәре мещанкасы, җәйге театр хуҗасы Мария Михайловна Чарушева белән 1907 елның июнь аенда төзегән килешүе бар. Анда Сембер шәһәренең Владимирский исемендәге җәйге бакчадагы театрда 24 нче июньдә спектакль кую шартлары күрсәтелгән. Шул ук килешүдә Ашказарскийның дүрт спектакль куярга хакы булганлыгы күрсәтелә.

Афишалардан күренгәнчә, И. Кудашев-Ашказарский труппасы спектакльләрне ике телдә: татар һәм рус телләрендә куя. Рус авторларының (мәсәлән А. П. Чеховның) әсәрләрен сәхнәләштерүдә И. Кудашев-Ашказарскийның рус телен камил белүе дә зур роль уйнаган. Ашказарскийның үз кулы белән язган төрле документлар да шул хакта сөйлиләр. Мисал өчен алда искә алынган М. М. Чарушева белән төзелгән килешүне, Оренбург җәмгыяте хәйрия советы әгъзалары исеменә язган гаризасын, татар көйләрен граммафон пластинкасына яздыру турында Мәскәү фирмасының Г. Кеммлер әфәндегә язган хатын һәм башка документларны китерергә була. И. Кудашев-Ашказарскийның хатыны Фәхрия ханым Арскаяның да русчасы бик яхшы иде. Ул заманында профессор Груздева шәфкать туташы булып эшләгән.

Документаль чыганаклардан күренгәнчә, И. Кудашев-Ашказарский оештырган музыкаль-драматик кичәләрдә ул вакыттагы татар тормышы өчен яңалык булган тагын бер нәрсә — кинокартиналар куела торган була. Тынгысыз җанлы Ашказарский бу өлкәдә дә кайбер тәҗрибәләр ясап караган. Мәсәлән, аның Гербинг фамилияле бер кеше белән 1905 нче елның 24—31 декабрендә Оренбург шәһәренең Николаевский урамында, Страде фамилияле кеше йортында синематограф (киноның искечә исеме) куюы мәгълүм. Карагруһчылар татарча спектакль куюга кискен каршы килгән чорда кинокартиналар күрсәтү, татар халкын сәнгатькә икенче юл белән тарту диган сүз.

Бөек Октябрь социалистик революциясен шатланып каршылаган Ашказарский 1924—1925 елларга кадәр гастрольләрдә йөрүен дәвам итә. Аннан соң ул Казанга бөтенләйгә кайтып, театр-концертлар оештыру, кино күрсәтү белән шөгыльләнә, җәмәгать эшләренә катнаша.

И. Кудашев-Ашказарский үзенең бөтен гомерен татар культурасын үстерүгә багышлады, театрны фанатикларча яратып хезмәт итте.

Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.

# ХАЛЫК БӘХЕТЕ ХАКЫНА

*Камил Якубовның тууына 90 ел*

Күренекле җәмәгать эшлеклесе Вәли Шәфигуллин 1920 елда «Кызыл шәрык» журналының 5—6 санында чыккан, Камил Якубов истәлегенә багышланган мәкаләсендә:

«...Ул безнең тарихыбызда мәңгелек үрнәк булырга тиеш. Аны һәр коммунист, һәрбер революционер искә төшерергә, аңардан һәрчак үрнәк алырга тиеш.

Революция тарихы аның кеби чәчәкләр белән бизәлмәсә, бүген капиталистлар йөрәге ярылырлык булып котырмас, буржуалар ачуланмас иде»,— дип яза. Бу сүзләр халкыбызның батыр улларына булган мөнәсәбәтен бик ачык чагылдыралар.



Камил Якубов — ленинчы революционерларның беренче буыны вәкиле. Ул үзенең бөтен гомерен, көчен, акылын, сәләтен социалистик җәмгыять төзүгә багышлады. Шушы бөек максатны тормышка ашыру юлында ул үзе дә һәлак булды. Ә бу вакытта аңа нибары 25 яшь иде.

Камил Лотфрахман улы Якубов 1894 елның 21 мартында Самара губернасы, Бөгелмә өязе (хәзерге Куйбышев өлкәсе, Шентала районы) Әбдеки авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туып үсә. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Чистайда укый, ләкин һәрчак аның күңелен Казан тарта. Габдулла Тукайның: «И, Казан, дәртле Казан!..» кебек сүзләре аның хәтереннән китми. Ниһаять, ул — Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте. Ә берәздан Камил, мәдрәсәдә укуын дәвам итеп, кичләрен рус телен дә өйрәнә башлый, русча китаплар укый, үзлегеннән татар мәктәпләре өчен рус теле укытучылары әзерләүче мәктәп (Татарская учительская школа) программасы буенча имтиханга әзерләнә. Каникул вакытларында «Болгар» чәйханәсендә официант булып эшли. Тырышлык җиңә. Камил имтиханнарны уңышлы тапшыра һәм укытучы булып чыга. Ләкин аңа халык мәгарифе өлкәсендә эшләргә туры килми. Бөтендөнья империалистик сугышы башлана.

Камил Якубов ике елдан артык Көнбатыш фронтның 2 нче армиясе составында күп кенә канлы бәрелешләрдә катнаша. Армиянең зур югалтуларын үз күзләре белән күрә. Солдатлар арасында капиталистлар файдасы өчен кан коюдан ризасызлык көчәюен дә тоеп тора. Большевиклар бу чорда империалистик сугышны гражданнар сугышына әверелдерергә агитация алып бара башлыйлар. Камил Якубов, аларны тыңлап, бу чакыруларның дөреслегенә ышана, үзе дә большевик булырга әзерләнә.

Патша самодержавиесе бәреп төшерелү хәбәре армиядә яшен тизлеге белән тарала. Солдатларда сугышның бетүе мөмкинлегенә өмет уяна. Ләкин буржуаз Вакытлы хөкүмәт сугышны «җиңгәнчегә кадәр» алып барырга омтыла.

Армиядә большевиклар йогынтысы көчәя. Алар алдынгы карашлы солдатларны да үз сафларына алалар. Камил Якубов та Февраль революциясенең беренче көннәреннән үк большевиклар партиясенә керә. Хәзер ул үзе дә, агитатор буларак, солдатларны революциянең икенче, социалистик этабына хәзерләүдә актив катнаша.

Татар буржуазиясе бу чорда татар һәм башка төрки халыкларның хезмәт ияләрен үзенә буйсындырып тоту өчен төрле мәкерле планнар кора, аларны тормышка ашыруда төп таяныч итеп татар-башкорт офицерларын һәм солдатларын файдаланмакчы була. Шушы максат белән 1917 елның июлендә Казанда Бөтенроссия мөселман хәрбиләренең беренче съезды чакырыла. Делегатларның күпчелеген офицер киемендәге алпавыт, капиталист яки сәүдәгәр малайлары тәшкил итсә дә, арада солдатлар тарафыннан сайланып җибәрелгән демократик карашлы кешеләр, хәтта большевиклар да була. Съездга 2 нче армиядән Камил Якубов та катнаша, ул хәтта съезд сайлаган Бөтенроссия мөселман хәрби шурасына да кертелә һәм Казанда калдырыла.

Якубов Казан большевиклары белән тыгыз бәйләнешкә керә, Мулланур Вахитов оештырган Мөселман социалистлар комитетында актив эшли. Бу элементләр аңа контрреволюцион татар буржуазиясенең хәрби органы булып исәпләнгән Бөтенроссия мөселман хәрби шурасы эчендә большевиклар юлыннан баручы сул фракцияне оештырырга, аны җитәкләргә ярдәм итә. Хәрби шура утырышлары тора-бара, Камил Якубовның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, сул фракциянең контрреволюцион күпчелегенә каршы көрәш мәйданына әверелә. Хәрби шура үзенең төп вазифасын үти алмый башлый.

Камил Якубов җитәкчелегендәге сул фракция членнары, Казан большевиклар комитеты күрсәтмәләрен үтәп, гарнизондагы татар солдатлары арасында зур политик агарту эшләре җәелдерәләр.

Кыю революционер Камил Якубов үзе актуаль темаларга ялкынлы публицистик чыгышлар бастыра. 1917 елның 13 октябрендә ул «Советларның съезды» исемле мәкалә яза. Автор Петроградта эшче, солдат һәм крестьян Советларының Икенче Бөтенроссия съездын чакыру турында карар чыгуын хәбәр итә, кадетлар, уң эсерлар һәм башка буржуаз партияләрнең каршылыгына карамыйча, ул съездның зарурилыгын аңлата. Мәкаләсен: «Бу съезд демократиянең иң ахыргы вә иң каты теләкләрен әйтәчәк»,— дип тәмамлый.

Якубовның бу сүзләре нәкъ 12 көннән соң, 25 октябрьдә, тормышка ашты. Бу көнне кич Смольныйда ачылган Советларның Икенче Бөтенроссия съезды кешелек тарихындагы яңа эпоханы, коммунизм эпохасын башлап җибәрде. Съездда буржуаз Вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелгәнлеге, властьның Советлар кулына күчкәнлеге тантаналы рәвештә игълан ителде. Съезд тынычлык һәм җир турында декретлар кабул итте, В. И. Ленин җитәкчелегендәге Совет хөкүмәтен оештырды.

1917 елның 15 октябре. Казан тимер юл вокзалы артындагы болында гарнизон солдатларының зур митингы була. РСДРП(б)ның Казан комитеты каршындагы хәрби оешмасы тарафыннан чакырылган бу митинг «Бөтен власть — халыкка, бөтен власть— эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларына!» лозунгысы астында үтә, большевистик резолюция кабул итә, гарнизон солдатларын кораллы восстаниегә әзерләүдә зур адым булып тора.

16 октябрьдә гарнизондагы биш мөселман ротасына тупланган 3 меңләп татар солдатлары аерым митингка җыела. Алар алдында большевиклар Камил Якубов, Вәли Шәфигуллин, Якуб Чанышев ана телендә чыгыш ясап, солдатларны Советлар власте өчен көрәшергә чакыралар. Большевистик резолюция кабул ителә.

Шул рәвешле Камил Якубов Казанда Октябрь кораллы восстаниесен әзерләүдә актив катнаша. Гарнизондагы татар солдатлары башка солдатлар һәм Кызыл Гвардия отрядлары белән берлектә, кораллы восстаниегә күтәреләләр. Восстание нәтиҗәсендә 26 октябрьның иртәсендә, Петроградтагы тарихи хәлләрдән нибары 6 сәгатькә генә соңарып, Казанда да Совет власте урнаштырыла.

Шул көнне Хәрби шура утырышында Камил Якубов шураның Советлар белән бергә барырга тиешлеге турында сөйли. Күпчелек тавыш белән Хәрби шура Советлар

властен таныргa һәм аңа теләктәшлек итәргә, дип карар чыгарырга мәҗбүр була.

Шул ук көнне кич Казан Советларының киңәйтелгән тантаналы утырышында Казан шәһәренең һәм губернасының Революцион комитеты сайлана. Комитет составына Камил Якубов та кертелә, губерна җитәкчеләренең берсенә әверелә.

1918 елның январе. Хәрби шура чакыруы буенча Казанда мөселман хәрбиләренең Икенче Бөтенроссия съезды җыела. Съездга 200 дән артык делегат килә. Купчелеге—татар буржуазиясе вәкилләре. Большевик, сул эсер һәм аларга теләктәшлек күрсәтүче делегатлар, берләшеп, сул фракция оештыралар. Фракциядә 40 лап кына кеше булса да, алар инануларының ныклыгы, политик яктан тәҗрибәле, оештыруга сәләтле булулары белән аерылып торалар. Фракция башында Камил Якубов, Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Бәдри Җиһаншин кебек большевиклар тора.

Сул фракция вәкилләре Казан гарнизоны солдатлары арасында да зур агитацион эш алып баралар, хәрби съездга җыелган купчелек делегатларның контрреволюцион йөзен ачалар, Хәрби шура тоткан политиканың татар буржуазиясе файдасына гына эш итүен раслап күрсәтәләр.

Съезд утырышларында һәр мәсьәлә буенча каты бәхәсләр була, карарлар контрреволюцион купчелек файдасына кабул ителәләр.

РСДРП(б)ның Казан комитеты белән киңәшкәннән соң, сул фракция съезд эшләрендә катнашмаска карар кыла. Камил Якубов, Сәхибгәрәй Сәетгалиев һәм тагын берничә кеше тарафыннан съезд делегатларының купчелегенең контрреволюцион йөзен фаш иткән декларация төзелә һәм ул 17 февральдә съезд утырышында игълан ителә. Шуннан соң сул фракция съездны ташлап чыга.

Берничә көннән соң сул фракция членнарының турыдан-туры катнашы белән Казан губерна Советы каршында Мөселман комиссариаты төзелә. Камил Якубов Комиссариатның хәрби бүлек җитәкчесе итеп билгеләнә. Бу бүлектә Галиулла Касыймов, Хәсән Урманов, Латыйф Гомәров зур эш башкаралар.

Хәрби бүлек ирекледәрдән Кызыл Армиянең татар роталарын төзи, татар буржуазиясе игълан иткән «Болак арты җөмһүрияте» тар-мар итүдә актив катнаша.

1918 елның 12 сентябрендә Камил Якубов Хәрби эшләр буенча Халык комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены итеп билгеләнә һәм бераздан Мәскәүгә күчеп китә. Коллегия члены булу белән бергә, биредә мөселман коммунистларының Беренче Бөтенроссия съездын хәзерләүдә һәм аның эшләрендә актив катнаша. Съездда ясаган чыгышында Солтангалиев, Фирдәвес кебекләрнең, аерым мөселман коммунистлар партиясе төзергә кирәк, дигән милләтчелек рухындагы чыгышларына отпор бирә. Съезд РКП(б)ның мөселман оешмаларының Үзәк бюросын төзи. Камил Якубов бюрога һәм аның президиумы составына сайлана.

1918 елның декабре. Көнчыгыш фронт гаскәрләре ак чехларны һәм акгвардиячеләрне Урал-Себер якларына куа баралар. Көн тәртибенә азат ителгән урыннарда политик оештыру эшләрен тиешле дәрәҗәдә алып бару мәсьәләсе килеп баса. Үзәк бюро һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе, зур полномочиеләр биреп, Камил Якубовны Көнчыгыш фронтка җибәрә. Ул Арзамаста фронт штабында, Казанда, Сембердә, Бөгелмәдә, Уфада, Бәләбәйдә, Самарада була, һәр җирдә митинглар җыя, анда докладлар ясый, төрле оештыру эшләре башкара. 31 декабрьда дошманнан азат ителгән Уфага Якубов 1919 елның январь башында килә. Ул анда Совет власте органнарын торгызуда катнаша, 5 нче армиянең политбүлеге каршында мөселман бүлекчәсе, коммунистларның губерна комитеты каршында мөселман секциясе оештыра, 20 көнлек агитаторлар курслары ача, ул курсларда лекцияләр укый, бик күп митингларда төрле актуаль темаларга чыгышлар ясый. Колчак бандалары Уфага куркыныч салгач һәм шәһәрнең вакытлыча калдырылачагы билгеле булгач кына, Якубов 13 мартта соңгы поезд белән аннан китә.

Мәскәүгә Якубов мартның егермеләрендә генә кайта.

Тиздән Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Мәскәүдән Казанга күчерелә. Камил Якубовка үтә җаваплы эш — коллегиянең политик бүлеге мөдире вазифасы тапшырыла. Якубов үзенә хас энергия белән бу бүлекнең эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Коллегиянең моңа кадәр сирәк кенә һәм бик кечкенә тираж белән чыгып килүче «Кызыл Армия» газетасы атнага өч тапкыр, бераздан көн саен 30—40 мең тираж белән басыла башлый. Күп санлы брошюралар, өндәмәләр зур тираж белән чыгарылып таратылалар.

Камил Якубов инициативасы белән политбүлек каршында агитаторлар курсы ачыла.

Ул кызылармиячеләр арасында агитация-масса эшләре алып баруга нык игътибар итә. Башка коммунистларны да бу эшкә тарта. Казанда еш булып торган митингларда чыгышлар ясый. Фронтның алгы сафында, кызылармиячеләр арасында була. 1919 елда Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясендә татар театр труппасы җитәкчесе булган Локман Аитов үзенең истәлекләрендә Камил Якубовның армиядә нинди киң тармаклы эшләр алып баруын бик тәфсилләп яза.

1919 елның 25 июлендә Казандагы татар запас батальонының бер төркем сугышчысы, контрреволюцион буржуазия агентлары коткысына бирелеп, фетнә күтәрәләр. Бу хәбәрне ишетү белән Камил Якубов казармаларга ашыга. Ул ярсыган сугышчыларны тынычландырырга омтыла, аларга материаль кыенлыкларның сәбәпләрен аңлата. Талантлы ораторның тормышчан сүзләре тәмам кызып җиткән фетнәчеләрне шактый сүрелдерә. Фетнәнең оештыручылары, эшнең кайсы якка китүен аңлап, Якубовка ташланалар. Халыкның батыр йөрәкле улы, Ленин идеяләрен армый-талмый тормышка ашыручы ялкынлы революционер һәлак була.

Ил Камил Якубов кебек көрәшчеләр яулап алган якты көннәрдә яши. Коммунистик идеаллар һаман җиңә баралар. Камил Якубовның якты истәлеге исә халык күңелендә яши.

Мидхәт МӨХӘРРӘМОВ,
тарих фәннәре докторы.
Илдус ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,
тарих фәннәре кандидаты.

# ЯКТЫЛЫККА ОМТЫЛЫП

*Габдрахман Сөнгатинең тууына 90 ел*

Демократик татар поэзиясен совет поэзиясенә китереп тоташтыруда зур роль уйнаган иҗат көчләренең берсе — Г. Сөнгати.

«Аң» журналының 1915 елгы 20 нче санында басылган «Сугыш һәм язучыларымыз» дигән редакцион мәкаләдә аның исеме дә телгә алына. Г. Ибраһимов «Берничә сүз» (1921) исемле мәкаләсендә Г. Сөнгатине реакция дәвере язучылары рәтенә кертә. «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956) Г. Сөнгати шигырьләренә урын бирелгән, туган елы итеп 1893 ел күрсәтелгән. Татарстан үзәк Дәүләт архивындагы метрика дәфтәрендә исә Габдрахман Фәтхулла улы Сөнгатуллин 1894 елның 10 мартында Тәтеш өязе Балчыклы авылында указлы имам гаиләсендә туган дип язылган.

Габдрахман туган авылында укыганнан соң, Казанга килеп, «Халидия» мәдрәсәсенә керә. «Ак юл» журналы чыга башлагач, 1914—1915 елларда журналда экспедитор булып эшли, җаваплы секретарь вазифасын үти. 1915 елның көзендә солдатка алынып, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, Көнбатыш фронтта сугыша.

Беренче шигыре «Иске җыр», «Аң» журналының 1914 елгы 4 нче санында дөнья күрә. Г. Сөнгати фронттан да үзенең шигырьләрен даими рәвештә газета-журналларга җибәреп тора. Соңгы шигыре «Утлар соңында...» «Аң»ның 1917 елгы 1 нче санында басыла. Шуннан соң матбугат битләрендә аның исеме очрамый. Революция булып, бәхетле көннәр килер вакыт якынлашканда, ул хәбәрсез югала.

1914 елдан алып 1917 елга кадәр, нибары өч елга сузылган иҗат дәверендә Г. Сөнгати гаять актив һәм нәтиҗәле эшли. «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында, «Кояш», «Халык» газеталарында Г. Сөнгать, Г. Сөнгати имзасы белән күп санлы шигырьләр, халык мифологиясенә нигезләнгән «Хозыр», «Бөтен җиһанда мәҗлес»

исемле ике поэма, «Су анасы» (А. Дружининның «Русалка»сына тәкълид) исемле баллада, «Ил фәрештәсе» исемле хикәя бастыра.

Якыннан белүчеләр Г. Сөнгатинең аз сүзле, йомшак күңелле, уйчанрак кеше булуын әйтәләр. Аның поэзиясе дә уйчан. Шигырьләрендә вакыт-вакыт төшенкелек мотивлары да сизелеп китә. Поэзиясен тулаем алганда исә ул үз шәхси кичерешләре эчендә генә бикләнеп калган шагыйрь түгел.

Г. Сөнгати — моңсу лирик, шуның белән бергә, традицион шагыйрь. Ритм-рифма оештыруы, шигырь үлчәме, эпитет һәм метафоралары — барысы да халык иҗатына якын торган классик стильдә, Тукайлар стилендә.

Г. Сөнгати Тукай белән шәхсән таныш булган, аңа махсус мәдхия дә багышлаган:

*Калыкты күктә бер йолдыз нурын чәчте уйнап өскә,*
*Күмеп куйды караңгы дөньябызны ак көмеш төскә,*

— ди ул «Сүнде!» шигырендә. Г. Сөнгатинең сөекле шагыйрьгә мәхәббәте шулкадәр зур булган ки, «Гыйшык» исемле шигырендә «Тукайга тәкълид» дип куйган. Мәгърур шагыйрь образы Г. Сөнгати иҗатының шактый өлешен алып тора. Шагыйрьне ул халык бәхете өчен көрәшүче көчле шәхес итеп күрә, аныңча, шагыйрь күңелендә заманның төрле каршылыклары белән кисешә.

*Минемчә, шулай, шагыйрь минем каршымда бик зур ул,*
*Шулай гали, шагыйрь көчле, минем каршымда*
*Җәбраил ул!..*

— мондый фикерләрне әйтү өчен Г. Сөнгатигә Тукай шәхесе азмы-күпме азык бирми калмагандыр, әлбәттә.

Гомумән, Г. Сөнгатинең лирик герое халык мәнфәгатен алга куйган көчле шәхес. Зур галим Мәрҗани образына мөрәҗәгать итүе дә шул турыда сөйли. «Мәрҗани хәзрәтләре» дигән шигырендә галимне ул «Хакыйкать диңгезендә ак нур чәчүче» итеп бәяли.

Г. Сөнгати поэзиясендә мәхәббәт лирикасы, хатын-кыз образы үзенә бер линия тәшкил итә. «Туташка», «Ана иркәсе», «Мәхәббәт», «Сызлам...», «Елмаю» шигырьләрендә хатын-кыз саф күңелле, рухи яктан бай, олы мәхәббәткә лаеклы булган илаһи бер зат. Шагыйрь иҗтимагый тормышта аларга зур өметләр баглый: «Аңлагыз, милләт хәзер сездән арысланнар көтә»,— ди ул «Туташка» шигырендә. «Ил фәрештәсе» исемле хикәясендә шәхси мәнфәгатьләрен бер читкә куеп, караңгы ерак авылга мөгаллимә булып киткән батыр йөрәкле татар кызы образын иҗат итә.

Г. Сөнгати иҗатының зур өлеше табигать турында. Аның пейзажы — авыл табигате: язы, көзе, кышы, җәе, урманнары, болыннары, кырлары, чылтырап аккан чишмәләре. Табигатьнең шаулы һәм тыныч чаклары, шагыйрьнең дөньяга, туган туфракка мөнәсәбәте. Г. Сөнгатине кешеләрнең мәрхәмәтсезлеге, тупаслыгы борчый. Бер очракта ул табигатьнең җылы, йомшак вакытларын кырыс, ыгы-зыгылы дөнья тормышына контраст куя. Тормыштан табу кыен булган тынычлыкны, рәхәтлекне шуннан эзли. «Бөтен җиһанда мәҗлес» поэмасында тупас адәмнәр кагып-сугып рәнҗеткән карт хәерче белән кечкенә малай киң, яшел сахрада гына җаннарына тынычлык табалар, үзләрен кеше итеп сизәләр.

Г. Сөнгати иҗатында империалистик сугышка ризасызлык сизелеп тора. Ләкин бу — турыдан-туры әйтелми. «Һәлакәт чокырыннан», «Сугыш», «Шәфкать туташларына», «Авылда көзге төн», «Яз көткәндә», «Куркыныч бойрык» шигырьләрендә табигатьнең төрле мизгелләре аша окопларда интегүче солдат кичерешләре чагыла.

Г. Сөнгатинең балалар өчен язган пейзаж шигырьләре дә байтак.

Г. Сөнгатинең 1916 елда «Ил фәрештәсе», 1921 елда «Хозыр» исемле китаплары дөнья күрә. Шушы китапларын, газета-журнал битләрендә сибелгән шигырьләрен туплап, бер җыентык чыгару көн тәртибендә тора.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА.**

# ГЕЛ ИСТӘ...

*Рифгать Бикчәнтәевнең тууына 60 ел*

Театрга тамашачылар ябырылып йөри торган шушы март аенда Рифгать Әхмәтҗан улы Бикчәнтәев үзенең 60 еллык юбилеен уздырыр иде. Һәм без, Бикчәнтәев-артистның оста уенын күреп сокланган, ул куйган спектакльләрне яратып караган тамашачылар, аның белән бергә иҗат иткән сәхнәдәшләре, Бикчәнтәев-педагог укыткан шәкертләре, якын дуслары — һәммәбез юбилярга, тирән ихтирамыбызны белдереп, чәчәкләр китерер, аны алкышлар һәм озын-озак гомер, яңадан-яңа иҗат уңышларына ирешүен теләр идек.

Әмма Рифгать Әхмәтҗанович безнең арабызда юк инде. Ул безнең хәтеребездә генә яши. Тормышка гашыйк иде ул... Туксаннан узган әбисе хакында сокланып сөйли, җае чыккан саен үзенең дә иркен сулышлы, нык булуы турында искәртеп узуны һич гаеп санамый иде. Мәсәлән, Муса Җәлил һәйкәле артындагы мәрмәр баскычларны бер тында йөгереп менеп тә, берни булмагандай сөйләшеп торуын хәтерлим.

Әтнә районы, Түбән Бәрәскә авылының унбиш яшьлек малае сәнгать дөньясына Казан художество училищесы аша килеп керә. Училищеның 2 нче курсында укыганда Бөек Ватан сугышы башлана. Рифгатьнең дә фашист илбасарларына каршы сугышка китәсе килә. Аны җибәрмиләр. Ул берничә тапкыр качып та карый... Ниһаять, унҗиде яшьлек егеткә вертолет заводына керү мөмкинлеге ачыла. Шулай итеп, фронтка ул да кулыннан килгән кадәр ярдәм итә башлый. Үз-үзеңне аямыйча, бөтен барлыгыңны биреп эшләүне таләп иткән сугыш еллары. Рифгатьнең шушы авыр чорда да рәсем училищесын ташламавы, вертолет заводында эшләү белән бергә, әлеге уку йортын 1944 елда тәмамлап чыгуы үзенә күрә бер бәләкәй генә батырлык булып саналырга хаклыдыр.

Сугышның бетү ягына барган чаклары. Үзенең җиңүенә ышанган Ватан-ана киләчәккә якты планнар кора. Шуны сизенгән Рифгать, укуын тагын да дәвам итү нияте белән, Мәскәүгә яки Ленинградка китәргә хәзерләнә башлый. Хыялы — зур рәссам булу. Баш-аягы белән иҗат дөньясына чумасы килә аның. Әмма сугыш елларының кырыс кагыйдәләре Рифгатьнең теләгенә каршы төшә. Заводны ташлап, укырга китүе белән цех начальнигы да ризалашмый. Рәсем училищесын бергә тәмамлаган дусты Празат Исәнбәт белән алар уйга калалар... Цех начальнигы корган киртә, чыннан да, җиңел генә үтәрлек түгел. Бары очраклы бер хәл генә булыша Рифгатькә. Үзешчән көчләргә багышланган смотрда аны Хөсәен ага Уразиков күреп ала. Артист, режиссер һәм педагог булган әлеге талант иясе Рифгать катнашкан скетчны бик игътибар белән карап утыра һәм соңыннан Бикчәнтәевкә хат язып сала. Анда Мәскәүнең атаклы театр институтына абитуриентлар җыелуы хакында әйтелә һәм өметле яшь егеткә имтиханнар биреп карарга киңәш ителә. Рифгать бу хатны алгач рәхәтләнеп көлә һәм үзенең дусты янына йөгерә. Празат аңа, шулай да уйлап кара син, ди. Уйлыйсы юк, ди, Рифгать, кырт кисеп, мин нинди артист инде. Ни тавыш, ни кыяфәт. Бик теләсәң, әнә үзең бар. Буең да ике метрлы, тавышың да патша кыңгыравыныкы кебек, кыяфәтең дә сөбханалла гына. Ә мин, малай, бары рәссам булам. Минем дә күңел артистлыкка тартмый шул, ди Празат. Алай да Мәскәүгә эләккәч, күз күрер әле, тотарбыз да «үзебезнең» институтка күчәрбез. Әнә шундый уйлар белән килеп, имтихан тапшыра башлый болар. Һәм, ни гаҗәп, тур арты тур узып, иң соңгы турны да җиңеп чыгалар. Комиссиянең әйтеп бетергесез канәгать булуы егетләрне аптырашта калдыра. Карале син аны, дип көлешәләр алар үзара, без артистлар да икән, шуны белми йөргәнбез... Көлү көлү белән, ә яшерен теләкләре — Мәскәүгә барып урнашкач, «үз институт»ларына күчү уе әлегә үз көчендә кала.

Бикчәнтәевнең театр институтына имтихан бирүе дә шаккатыра алмый цех начальнигын. Тоткарлый ул Рифгатьне. Тарткалаша, якалаша торгач, январь ае да якынлаша. Ахырда начальник, тәмам туеп булса кирәк, Бикчәнтәевне үзенә чакырып ала да: «Менә художник икәнсең, цехны яңа елга хестәрлә, шуннан дүрт ягың кыйбла булыр»,— ди. Рифгать, рәхмәт әйтеп, шунда ук эшкә дә керешә. Алны-ялны, көннетөнне белмичә, цехны яңа елга хәзерли ул. Һәм менә цех әзер. Цех начальнигы

килә, карый: әллә кайларгача сузылып киткән цех бәйрәмчә бизәлеп, йөзләгән тиеннәре, куяннары, аюлары, шүрәлеләре белән яңа елны көтеп тора. Цех начальнигы, куйган шартының җиренә җиткерелеп үтәлүен күрсә дә, бар, энекәш, инде укырга китсәң дә була, дип әйтергә ашыкмый. Бары берничә көннән соң гына, үзенең кабинетына чакырып: «Әнә шунда, каршыга, даһи юлбашчыбызның шәп кенә портретын ясап бирсәң, артык тотмаячакбыз»,— дип, тагын бер шарт куя. Бәхеткә каршы, портрет бер диген була...

Мәскәү. Сугыштан соңгы еллар. Атаклы ГИТИС... Йөзләрчә талантларны илебез театрларына тәрбияләп тапшырган театр институты. Ике дус икенче курсны тәмам итәләр, өченчесенә, дүртенчесенә җитәләр, әмма «үз институтлары»на качып китәргә ашыкмыйлар. Киресенчә, торган саен ныграк кына гашыйк була бара алар. Иге-чиге булмаган театр дөньясы үзендә сәнгатьнең бөтен тармакларын да очраштыра-берләштерә икән. Аңа бөтен гомереңне багышлаганда да театрның барлык серләрен ачып бетерү мөмкин түгел... Әнә шул хакта сөйли аларга институт. Өстәвенә, алар укыган татар студиясе зур югарылыктагы студия була. Әлеге студия хакында остазлары профессор О. Пыжова менә болай язган: «Татар студиясе бик тиз арада ГИТИСыбызның горурлыгына әверелде. Аларга барлык педагогларыбыз да гашыйк. Татар студентлары гаҗәп темпераментлы булулары, үз осталыкларын арттыру өчен армый-талмый тырышып эшли алулары белән таң калдыралар. Иң мөһиме: алар барысы да, чын мәгънәсендә, талант ияләре»... Остазлары ялгышмыйлар: диплом спектакльләрен карарга җыйналган Мәскәү тамашачылары яшь артистларга кайнар рәхмәтләрен белдерәләр, аларга зур киләчәк баглыйлар.

Студиядә уку чорында ук: Соллогубның «Йомшак күңелле булу бәласе»ндә Саша, Леоновның «Ябырылу» драмасында Федор, Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» әсәрендә Болконский, Лермонтовның «Маскарад»ында Князь Гнездич, Хәмзә Хәкимзадәнең «Бай һәм хезмәтче»сендә Хезмәтче, Мольерның «Тартюф» исемле сатирик комедиясендә Данис, Мөсреповның «Козы Көрпеш һәм Баян Сылу»ында Җантык, Гоццины «Болан-патша»сында Леандро һәм Труфальдино, Аппаковаңың «Бишек җыры»нда Сираҗи, Горькийның «Васса Железнова»сында Прохор кебек гаять төрле рольләрдә үзен сынап караган Р. Бикчәнтәевтә артист булу теләгенең тулаем өлгереп җиткәнлеге күренә. Хәзер инде ул артистның сәхнәдә «гәүдә күрсәтеп» кенә йөрмәвен яхшы аңлый. Яшь артист тамашачының карашын аңлы рәвештә образның эчке дөньясына юнәлтә. Тамашачының күңел күзе диген катлаулы әгъзасын ярдәмгә чакырырга өйрәнә, барлык эзләнүләрен тамашачыларны тетрәндерү максатына юнәлдерә.

60 нчы елларда театр училищесында актерлык осталыгына укытканда, Бикчәнтәев-педагог үзенең шәкертләренә: кеше күңеле фәкать чын сәнгать белән очрашканда гына тетрәнә, дия иде. Тамашачы яки тәгәри-тәгәри көлсен, яки үксеп-үксеп еласын; спектакльнәнән битараф чыгып киттеме, аны кабат театрга алып килүе ансат булмаячак. Татар ТЮЗына кайтып эшли башлаган чорда (1949 елда алар бөтен студияләре белән Казанда яңа гына ачылган татар ТЮЗына кайтып төшәләр; татар ТЮЗы, кызганычка каршы, нибары бер ел эшләп кала) һәм аннан соң академия театрына күчеп эшли башлагач та, Бикчәнтәев шул «тетрәндерү» максатына тугры кала. Бикчәнтәев хакында кемнән генә сорасам да, ул кеше миңа: Бикчәнтәев искиткеч артист иде, дип җавап бирде. Барлык кешеләр күңеленә ничек шулай бердәй үтеп керә алган соң ул? Моңа җавап табуы беренче карашка гына җиңел кебек тоелган икән. Һәр иҗат кешесе — үзенә күрә бер табышмак. Бикчәнтәевне дә, биш бармагымны белгән кебек беләм, диюче табылмады. Әйе, бу шәхескә якынрак килә төшкәч, мин дә шуны аңладым: Р. Бикчәнтәевне яхшы беләм дип йөреп ялгышканмын икән. 1962 елдан 1975 елга кадәрге арада язмышым мине Рифгать абый белән гел очраштырып торгач, әйтик, Бикчәнтәев-режиссер кул астында миңа унга якын спектакльдә катнашырга, Бикчәнтәев-педагогтан дәресләр алырга, Бикчәнтәев-артист белән сәхнәдә партнерлар булырга, күп еллар гастрольләрдә бергә фатирга йөрергә туры килгәч, шул вакыт эчендә күргәннәремне сөйләп бирә алырмын дип кулыма каләм алган идем, әмма каушап калдым. Бу талант иясе бер генә кеше иңләп алырлык шәхес түгел икән, монда бик күпләрнең уртак тырышлыклары салынган хезмәте кирәк икән.

Миңа калса, Бикчәнтәев драмада да, комедиядә дә бердәй тигез уйнаучы күпкырлы артист булганлыктан, тар чикләрдә бикләнеп утырмаска, аларны киңәйтергә

өйрәнгән. Чикне ул, әлбәттә, чама белеп үзгәрткән. Тетрәндергән иҗат чикләрне ничек үзгәртүне сораса, шуның чаклы... Ничегрәк күзалларга була соң моны? Кызыксынган кешеләргә мәгълүм: бүгенге көн актерлары ике категориягә бүленә: тышкы гәүдәләнешкә игътибар күбрәк кирәк дип санаучылар һәм бары эчке дөньяны гына табуны, хәтта гримсыз ук уйнауны хуп күрүчеләр. К. Гоццинның «Болан-патша» дигән әсәрендә дә моңа охшаш хәл бар. Бер явыз тышкы кыяфәте белән патшага әверелә. Тик патшаны чиксез сөйгән кыз, тышкы яктан бик нык охшаса да, күңеле белән кара эчле әлеге явызның үзе сөйгән кеше булмавын сизенеп, аңардан баш тарта... Артист та, кат-кат гримнар салып, тышкы кыяфәте белән әлеге уйныйсы кешесенә охшарга мөмкин, әмма тыштан охшап та, эчке дөньясы буш калса, яки, киресенчә, эчтән охшап, тыштан бөтенләй килмәсә, тамашачы аны кабул итмәячәк. Бикчәнтәев иҗатында исә, ягъни аның эш методында, уйнау стилендә һәр ике якның да уңай яклары бергә яши... Мисал өчен аның ике спектакльдәге эшенә тукталыйк. Беренчесе — драма һәм комедия театрында 1972—1973 ел сезонында дөнья күреп, 500 дән артык уйналган «Әтиең мин синең» спектакле (авторы Ялунер, режиссеры һәм баш рольдә уйнаучысы Р. Бикчәнтәев). Икенчесе — Нәкый ага Исәнбәтнең «Һиҗрәт»ендәге Абдул Абдулыч роле (режиссеры П. Исәнбәт). Бу әсәр академия театрында 1945 елда куелган иде.

«Әтиең мин синең» спектаклендә, әйтеп үткәнебезчә, төп роль — эшче Разилов ролендә Р. Бикчәнтәев уйнаган иде. Һәрчак күпне күрә торган артист Гата Нуруллин Бикчәнтәевне сәхнәгә кереп барганда туктатты да: «Грим да салмагансың бүген, Рифгать»,— диде. Рифгать абый шунда көлеп: грим белән кем дә уйный, син менә гримсыз уйнап кара, дип сәхнәгә узып китте. Тамашачылар аны, әлбәттә, таныдылар, әмма... әмма озак та үтмәде, артист «онытылды», сәхнәдә әле генә станогы янынннан килгән, гап-гади генә булса да, үзенә ни кирәген яхшы аңлаган яхшы күңелле Риза Разилов кына торып калды. Спектакль беткәч, Рифгать абый, әлеге сүзен дәвам иткәндәй: «Ысул-алымнардамыни хикмәт, алар гел үзгәреп тора,— диде.— Һәм аларның яңарулары табигый. Менә үтәр вакыт, диде ул, мин әле спектакльләрне бөтенләй башкача куя башлармын һәм башкача уйнармын да... Чөнки һәр заман үз театрын тудыра. Үз алымнары, үз тасвирлау чаралары булган яңа театр. Театрны моңа тамашачыларыбызның туктаусыз үсештә булган эстетик зәвыклары этәрә. Бүгенге көндә тамашачыларны элек сокландырган «нәкъ тормыштагыча», «бигрәк охшаган» белән генә канәгатьләндереп булмый. Әйе, хак, теләгән режиссер сәхнәгә абзарның үзен дә чыгарып утырта ала, артистлар, мәсәлән, кушсаң, мәчедән дә остарак мияулый ала, мәгәр тамашачыбыз театрга артистның мәче белән ярышуын карарга киләме икән?!. Минемчә, бүгенге көндә башкарак театр туып килә. Мисал өчен, әнә, Празат Исәнбәт спектакле «Акчарлаклар»ны алырга була... Кая карама — җәтмәләр... Спектакльнең бөтен атмосферасы болганып, пычранып, агуланып беткән диңгезне хәтерләтә. Яшәргә бөтенләй мөмкинлек калмаган диңгез белән ярдагы меңләгән җәтмәләр арасында өзгәләнә-елый акчарлаклар — хезмәт халкы бәргәләнә. Яки гаять зур яңгыраш алган икенче спектакль — Марсель Сәлимҗановның «Сүнгән йолдызлар»ы. Яңа театрның төп тасвирлау чаралары да һәм шул барлык төп чараларны бер үзәккә, бер максатка, бер Иделгә туплаучы көч — бүгенге режиссура да житәрлек анда. Иң гаҗәбе, әле «башланырга өлгермәгән» спектакль сине тынып калырга, чуалган хәтереңне тупларга һәм театр дулкынында уйларга мәҗбүр итә. Ә бит сәхнәдә һәр пәрдә саен яңа ягы белән борылып баса торган өч кырлы өч багана һәм дөм кара төндәй караңгы фоннан гайре берни дә юк. Хәер, сугыш тудырган фаҗига, өч кешенең драматик язмышы, халык күңеленең иң түреннән ургып торган моңлы җыр-аһәң инде алдагы постановка-куелышларда да булган. Бу куелышта да режиссер шул материал белән эш итә, дикуем. Бары режиссура гына тиешле югарылыкта... Нарат агачына утын итеп кенә караучы кочегар булудан узган, нарат агачында скрипка күрүче остага әверелгән. Әйе, татар театр дөньясында яңа театр канат кага. Ул — «охшаганлык», «нәкъ тормыштагыча» гына булудан сәнгатьчә дәреслек театры дәрәҗәсенә күтәрелгән театр. Берниндн ясалма эффектлары, бернинди «охшаганлык», «тормышчанлык» шаккатризмнары да булмаган «Сүнгән йолдызлар», «Акчарлаклар», белгәнебезчә, тамашачыны соң дәрәҗәдә тетрәтә».

Әгәр Бикчәнтәев иҗатындагы «гримсыз гына» дип аталган беренче як белән тирәнрәк танышып үтәргә уйласак, күз алдына шундый бер күренеш килеп баса. Әле

гено искә алып үтелгән уйлану-фикерләр аңарда кинәт кенә тумаган. Аларның матур ярылгылары әлеге сәхнә остасының иҗат тәҗрибәсендә гел очрый, рольдән-рольгә яңа кыры белән ачыла, үсә килгән.

«Һиҗрәт». Сәхнәнең урта бер өлешендә катып беткән икмәк кисәге ята. Шуның янында мулланың бер симез генә хатыны. Әллә кайдан, күсе баласыдай йөгерә-поса, бер «әдәмкәй» килеп керә һәм идән уртасында яткан «ипекәй ведь бу»га тиз-тиз елыша башлый. Шушы берничә хәрәкәт, бөкрәеп каткан гәүдәгә эленгән сәләмә-өтек киемнәр һәм кайдадыр кысылып калган күсе баласыныкыдай тырналып-сыдырылып кына чыккан тавыш, тамашачыны көләргә, димәк, игътибарына да билгеле бер юнәлеш бирергә тулысынча җитә. Әмма артист, Нәкый Исәнбәтнең: качаклар җырлап чапмыйлар, качаклар елап чаба, дигән мәкалең дә исендә тота... Күп тә үтми, тәмам җен алыштырган бит моны, ди-ди, егыла-егыла көлгән зал каршында, артистның ап-ак булып агарынган ябык йөзе күтәрелә. Мәетнекенә тартым чырайда, туган якларыннан аерылып, куыла-сөрелә йөри торгач, туган телен дә онытып, чит җирләрдә тәмам изелеп, тапталып беткән бер бәндәнең, төссез, йөрәк өзгеч җансыз күзләрен дә күргәч, тынып, сәгаеп калган тамашачылар сискәнеп китәләр. Һәм шундук үзләрен әле генә Абдул Абдулычтан өстен санап көлүләргә ниндидер бер моңсулык авазы килеп кушыла.

Бу шартлы рәвештә «гримлы» дип саналган категориягә Абдул Абдулыч белән тиң булырлык Җантык та («Козы Көрпеш һәм Баян Сылу»), эчкече бозык Прохор да («Васса Железнова»), һавалы Гофмаршал да («Мәкер һәм мәхәббәт»), комсыз һәм хәйләкәр Сиражи да («Банкрот»), бай малае карак Нигъмәтҗан да («Гөлҗамал») керә.

Рифгать Әхмәтҗанович Бикчәнтәев хакында сөйләгәндә, аның режиссура сәнгатенә керткән өлеше хакында да әйтеп китми булмый. Чөнки халкыбызның зур бүләге — Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе аңа нәкъ менә режиссерлык хезмәтендәге уңышлары өчен бирелде.

Бу язмада Р. Бикчәнтәевне иң тыйнак кеше дип исбатларга җыенмыйм. Мактанырга да күп сорап тормый иде ул. Әмма режиссура хакында, режиссурага үзе керткән өлеше хакында сүз чыкканда, шактый тыйнаклык күрсәтә торган иде. Артистлык сәнгате буенча искиткеч мәктәп узган сәхнә остасының үзен режиссура өлкәсендә бер өйрәнчек кенә итеп санавы, мөгаен, дөреслеккә якын да булгандыр. Ул режиссерлыкка укып, махсус белем алып кайткан кеше түгел иде. Бу аңа, әлбәттә, күп нәрсәне капшанып табарга, сиземләү аша эшләргә мәҗбүр итә иде. Яки, язгы ташу вакытында ярларына гына сыймый аккан елга берни белән дә хисаплашмаган шикелле, Бикчәнтәевнең искиткеч көчкә ия булган фантазиясе дә, артык ташып, режиссерны ялгышрак юлларга өстерәп керткәли иде. Әмма сүз уңаеннан тагын шуны да әйтеп үтәргә кирәктер: укып кына режиссер булып булмый. Ел саен күпләгән режиссерлар укып чыга. Шуларның бик азы режиссерлык эшендә кала. Уку ул талантың булса гына булыша. Кыйммәтле ташка кыса куйган кебек.

Әсәрләрен Р. Бикчәнтәев куйган авторлар күп түгел. Алар: Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Х. Вахит, Р. Ишморат, М. Кәрим, М. Әмир, Р. Батуллин, В. Розов, К. Әмиров, С. Җамал, Ялунер. Бикчәнтәев-режиссерның гомере артык кыска булды шул. Тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, ул — бөредә генә калды, диярлек... Әйе, безгә аны тулаем ачылган килеш күрергә насыйп булмады. Шулай да ул «бөре», үзен кырау сукмаган тәкъдирдә, искиткеч гүзәл чәчәк бүласына безне ышандырып өлгерде.

Шушы урында нокта куярга да булыр иде. Һәм ул нокта бик шыксыз авыр таш кебек укучының йөрәгендә ятып калыр иде шикелле. Шуңа да мин, нокта куюдан элек, тагын берничә сүз әйтергә булдым. Бу сүз Р. Бикчәнтәевнең улы Фәрит Бикчәнтәев хакында булыр. Бүгенгесе көндә академия театрында артист булып эшли башлаган бу яшь егетне тамашачылар инде артист итеп танырга, яратырга ук өлгерделәр. Тик мин әйтәсе сүз хәзергә башка нәрсә хакында: Фәрит Бикчәнтәев үзен режиссура өлкәсендә дә сынап карарга булды. Театрда ул үзе кебек эшләргә атлыгып торган яшь артистлар белән бергә планнан тыш спектакль куя башлады. Артистлар белән бик тиз арада уртак тел табуы, тырышлыгы, бай фантазиясе белән ул безгә үзенең әтисен хәтерләтте. Димәк, Бикчәнтәев дәвам итә.

**Юныс САФИУЛЛИН.**

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

27 декабрьда ачык партия җыелышында Язучылар союзы каршында эшләп килүче хәрби-патриотик әдәбият комиссиясенең отчеты тыңланды. Комиссия председателе язучы Шамил Рәкыйпов доклад белән чыкты. Ул КПСС Үзәк Комитетының июнь Пленумы (1983 ел) карарлары яктылыгында язучыларыбыз тарафыннан иҗат ителгән, яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүдә зур роль уйнаган әсәрләргә төпле анализ ясады һәм әдәбиятыбызның бу өлкәсендә яшәп килгән җитешсезлекләргә тукталды.

Фикер алышуларда язучылар А. Шамов, С. Шакир, Н. Орешина, Г. Паушкин, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Р. Харис, тәнкыйтьчеләр Р. Мостафин, Ф. Миңнуллин, Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясап, әдәбиятның хәрби-патриотик жанры алдында торган актуаль мәсьәләләр турында сөйләделәр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

16—20 январьда Сарман районында татар әдәбияты көннәре булып узды. Татарстан язучыларының X съездын каршылап уздырылган бу әдәби бәйрәмдә Казаннан, Брежнев, Әлмәт язучылар оешмаларыннан шагыйрьләр, прозаиклар Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Ренат Харис (җитәкче), Мәдинә Маликова, Разил Вәлиев, Әхәт Гаффар, Роберт Миңнуллин, Клара Булатова, Нур Әхмәдиев һәм Сарман язучылары Хәниф Хәйруллин, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Илгизәр Кушаев катнаштылар.

Язучылар «Тукай» совхозы, Муса Җәлил, Ильич, Серго, Тукай исемендәге, «Мәгариф», «1-Май», «Җиңүче», «Коммунизм», «Искра» колхозларында булып, көндезләрен мәктәпләрдә, терлекчелек фермаларында, «Сельхозтехника» берләшмәсе бүлекчәләрендә, кичен клубларда чыгыш ясадылар, бүгенге татар әдәбияты һәм сәнгате турында әңгәмәләр уздырдылар, әдәби әсәрләр турында авыл хезмәтчәннәренең фикерләрен ишеттеләр. Татарстан язучыларының май аенда булачак X съездына әзерлек, язучыларның аны каршылап нинди яңа әсәрләр язулары турында сөйләделәр, үзләренең иҗат планнары белән уртаклаштылар.

## РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВ ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ

11 январьда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы конференц-залында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән Татарстан Язучылар союзының берләштерелгән гыйльми совет утырышы булып узды. Күренекле мәгърифәтче галим, тарихчы, язучы һәм журналист Риза Фәхретдиневнең тууына 125 ел тулуга багышланган бу фәнни җыелышта Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм Госманов «Риза Фәхретдиневнең тормыш һәм иҗат эшчәнлеге», филология фәннәре кандидаты М. Әхмәтҗанов «Галимнең тормышына кагылышлы яңа материаллар», Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Ә. Хәйруллин «Риза Фәхретдиневнең Уфа шәһәрендәге архивы» дигән докладлар белән чыктылар. Утырышта Риза Фәхретдиневнең кызлары — Зәйнәп Фәхретдинева, Әсма Шәрәф, галимнең оныгы — Арслан Шәрәф, туганнан туган — Нәҗип Фәхретдинев һәм башка туганнары, язучылар, галимнәр һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнаштылар. Соңыннан Риза Фәхретдиневнең тормышына һәм иҗади эшчәнлегенә караган кызыклы истәлекләр белән аның кызы Әсма Шәрәф чыгыш ясады.

Утырышта катнашучылар игътибарына Риза Фәхретдиневнең тарихи һәм әдәби эшчәнлеген яктырткан басма һәм кульязма китапларыннан күргәзмә оештырылган иде.

Риза Фәхретдиневнең юбилее туган ягы Әлмәт районында да киң билгеләп үтелде.

21—23 январьда Әлмәт шәһәрендә, Мәмәт һәм Кичүчат авылларында узган тантаналы кичәләрдә Казаннан килгән әдәбият галимнәре М. Әхмәтҗанов һәм Ә. Хәйруллин атаклы мәгърифәтченең тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләделәр. Кичәләрдә Риза Фәхретдиневне күреп белүчеләр үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Бу көннәрдә Мәмәт авыл Советы карары белән Кичүчат авылының Риза Фәхретдинев туган һәм яшәгән урамына аның исеме бирелде.

## ЯШЬ ИҖАТ КӨЧЛӘРЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

19 январьда, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында, мәктәп яшендәге авторларның I республика конференциясе үткәрелде. Анда иҗат эшләре активрак булган 27 районнан делегатлар укучы балалар катнашты.

Моңа кадәр, Язучылар союзының ВЛКСМ өлкә комитеты һәм республиканың Мәгариф министрлыгы белән берлектә кабул иткән карарын тормышка ашыру йөзеннән, Бреж-

нев һәм Әлмәт зоналарында һәм күпчелек районнарда конференцияләр үткәрелгән иде инде.

Мәктәп яшендәге авторларның I республика конференциясен Татарстан Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү буенча идарә председателе урынбасары, шагыйрь Илдар Юзеев ачты.

Конференциядә катнашучылар алдында ВЛКСМ өлкә комитетының пропаганда һәм культура-масса эше бүлеге мөдире Р. М. Вахитова, «Яшь ленинчы» газетасы редакторы Р. Р. Туфнтулова, «Ялкын» журналының баш редакторы Р. С. Хафизова, шагыйрь Сибгат Хәким, язучы Нонна Орешина, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире тәнкыйтьче Азат Әхмәдуллин чыгыш ясадылар.

Конференцияне ачу тантанасында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Аннары конференция үзенең эшен секцияләргә бүленеп дәвам итте. Соңыннан яшь авторлар республикабызның танылган язучылары, шагыйрьләре белән очраштылар.

## «ЯЛКЫН»ГА — ОЛЫ БҮЛӘК

Пионерларга һәм мәктәп укучыларына коммунистик тәрбия бирүдә нәтиҗәле эшләве өчен ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз Пионер оешмасының республика советы органы «Ялкын» журналы СССР Верховный Советы Президиумының 5 январь, 1984 ел Указы нигезендә, «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 24 январьда ВЛКСМ өлкә комитетында әлеге олы бүләкне тапшыруга багышланган тантана булды.

ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов «Ялкын» журналы редакциясе коллективын, аның редколлегия членнарын, күпсанлы хәбәрчеләрен хөкүмәтебезнең олы бүләге белән кайнар тәбрикләде һәм журнал байрагына «Почет билгесе» орденын беркетте.

Тантанада КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире А. И. Афанасьев, КПСС өлкә комитетының матбугат, радио һәм телевидение секторы мөдире Р. Г. Гыймадиев һәм башка иптәшләр катнашты.

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

26 декабрьда Казандагы М. Горький урамының 13 нче йорты янында композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә мемориаль такта куелуга багышланган тантаналы митинг булды. Анда шәһәрнең партия, профсоюз һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, композиторлар, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, күп санлы казанлылар җыелды.

Тантаналы митингны ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев ачты. Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе М. Яруллин, шагыйрь Р. Фәйзуллин, композитор А. Миргородский, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов, композитор Б. Мулюков, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре М. Нигъмәтҗанов чыгыш ясадылар.

Скульптор В. Маликов иҗат иткән мемориаль тактага композиторның силуэты төшерелгән, рус һәм татар телләрендә: «Бу өйдә 1930—1954 елларда композитор Салих Сәйдәшев яшәде».— дип язылган.

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

16 январьда Мамадыш районы Олыяз авылы культура йортында күренекле татар совет язучысы Шәйхи Маннурның туган көненә һәм иҗатына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Олыяз урта мәктәбе укытучысы З. Габдуллина, терлекче З. Гайниева, китапханәче В. Зәйнетдинова һ. б. әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләделәр. Кичәгә килүчеләр күренекле язучы Гомәр Бәширов һәм тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең Шәйхи Маннур турындагы истәлекләрен дулкынланып тыңладылар.

Жюри карары нигезендә, Олыяз авылының Шәйхи Маннур исемендәге китапханә премиясенә 1983 елда язучы Марсель Галиевнең «Ерак урман авазы» дигән повесть һәм хикәяләр җыентыгы, шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның «Айбагарлар» исемле шигырьләр китабы, елның алдынгы тракторчылары Зиннәтулла Галимуллин белән Габделәхәт Зиннуров, алдынгы савымчы Рәис Зарипов һәм халыкка коммунистик тәрбия бирүдә нәтиҗәле эшләгән өчен укытучы Зәкия Габдуллина лаек табылган иде. Яңа лауреатларга бүләк һәм дипломны колхоз председателе, ТАССРның атказанган культура работнигы Галимҗан Җиһаншин тапшырды.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен драматург Риза Ишморатка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 16 декабрь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет балаларының сөекле язучысы Аркадий Петрович Гайдарның тууына 80 ел тулу уңае белән ВЛКСМ Үзәк Комитеты балаларга һәм яшүсмерләргә идея тәрбиясе бирүдә, алар арасында фәнни-техник һәм әдәби иҗатны үстерүдә, спорт һәм хәрбипатриотик эш алып баруда зур хезмәт күрсәткән иптәшләрне А. П. Гайдар билгесе белән бүләкләү турында карар игълан итте.

Бүләкләнүчеләр арасында республикабыздан танылган балалар шагыйре Шәүкәт Галиев тә бар. Шагыйрь бу югары бүләккә балалар дөньясын тынгысыз иҗат күзлегеннән өйрәнеп язган матур-матур шигырьләре өчен, кабатланмас әдәби геройлар тудырганы өчен лаек булды.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Фирдәвес Хәйруллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 20 декабрь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## УТ КҮРШЕЛӘРНЕҢ ӘДӘБИЯТ ФОРУМЫНДА

24—25 октябрьда Уфада Башкортстан язучыларының IX съезды булып узды. Анда кунак булып Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе Гариф Ахунов һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис бардылар. Г. Ахунов съездда чыгыш ясап, татар һәм башкорт әдәбиятының тарихи бердәмлеге турында сөйләде.

Съездан соң Г. Ахунов Уфа университетында, Р. Харис пединститутта студентлар белән очрашып, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар, бик күп сорауларга җавап лар бирделәр.

## ГАДЕЛ КУТУЙНЫ ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

25 ноябрьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында үткәрелә торган әдәби җомгаларның чираттагысы Гадел Кутуйның тууына 80 ел тулуга багышланды. Әдипне искә алу кичәсендә Әмирхан Еники, Гариф Галиев, Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Шакир Абилов Ватан азатлыгы хакына сугыш кырында ятып калган язучы турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичәдә Г. Кутуйның апасы — РСФСРның һәм ТАССРның атказанган врачы З. М. Кутуева, улы Р. Кутуй, кызы Гөлшат, туганнан туган энесе Д. Вәлиев катнашты.

## БӨЕК ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

Узган елның ноябрь аенда бөтендөнья әдәби җәмәгатьчелеге төрекмән халкының бөек шагыйре Мәхтүмколыйның тууына 250 ел тулу бәйрәмен билгеләп узды. Шул уңай белән Ашхабадта тантаналы бәйрәм кичәләре булды. Анда Татарстаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин да катнашты һәм чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында бөек шагыйрьнең беренче басма әсәрләре иң әүвәл Казанда басылып чыгуын әйтеп узды һәм шулай ук совет чорында да аның әсәрләренең татар телендә шактый басылып чыгуын белдерде. Мәхтүмколый юбилееннан тыш Равил Фәйзуллин Ашхабадта «Прогрессив милли традицияләр һәм бүгенге совет поэзиясе» дигән темага уздырылган бөтенсоюз конференциясендә чыгыш ясады.

## ГАЛИМНЕҢ УҢЫШЫ

7 декабрьда Мәскәүдә СССР Фәннәр Академиясенең А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтындагы филология фәннәре буенча специальләшкән Совет утырышында әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче Флүн Мусин «Татар совет прозасында әдәби тәҗрибәнең күчемлелеге һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясе яклады.

Фәнни оппонентлар буларак чыгыш ясаучылардан илебезнең күренекле әдәбият галимнәре А. Иезуитов, З. Кедрина, филология фәннәре докторы М. Хәсәнов диссертациягә һәрьяклап фәнни анализ ясадылар. Ф. Мусинның бүгенге әдәби хәрәкәтне тарихилык белән фәнни нигезләп ышандырырлык итеп бәйләвен, СССР халыклары әдәбиятлары арасындагы социалистик бәйләнешләрне оста чагылдыруын һәм бүгенге прозаның үсеш юлындагы мөмкинлекләрне анык билгеләвен әйтеп үттеләр.

Фәнни Совет Ф. Мусинга филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә бирергә карар кабул итте.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

7 декабрьда Әлмәт язучылары һәм шәһәр партия, хуҗалык оешмалары җитәкчеләре «Табигатьне саклау — Ватанны саклау» дигән темага «түгәрәк өстәл» янында зур сөйләшү уздырдылар. Язучылардан Г. Афзал, Ә. Маликов, Э. Мөэминова, К. Булатова, Х. Хәйруллин, Ә. Гаффар һәм башкалар республикабызның нефть регионында табигатьне саклаудагы уңай тәҗрибә һәм бу эшнең киләчәк проблемалары, аны әдәбиятта чагылдыру мәсьәләсе турында сөйләделәр.

26 октябрьда Әлмәт шәһәренең икенче номерлы китапханәсендә Әлмәт шәһәренә — 30, Әлмәт язучылар оешмасы төзелүгә 20 ел тулуга багышланган укучылар конференциясе булды. Конференциягә яшь нефтьчеләр, уку комбинаты укучылары, беренче номерлы мәктәпнең өлкән класс укучылары килгәннәр иде. Әдәбият бәйрәмендә Гамил Афзал, Клара Булатова, Роберт Рәкыйпов, Дмитрий Матвеев катнашты.

Шул ук көнне язучы Рафаил Төхфәтуллин Әлмәт шәһәренең яшь эшчеләре белән очрашты, аларга әдәбиятыбыз, сәнгатебез турында сөйләде, яңа повестеннан өзекләр укыды, күп кенә сорауларга җаваплар бирде.

# АКВАРЕЛЬ ОСТАСЫ

Беренчеләр... Гайшә Абдрахмановна Рахманкулованың иҗат язмышына әнә шундый мактаулы һәм шул ук вакытта җаваплы миссия туры килде: ул татар хатын-кызларыннан беренче рәссам булып санала. Татарстанда акварельнең мөстәкыйль графика сәнгате буларак үсешкә ирешүе аның исеме белән бәйле. Бөтенсоюз акварель эшләре күргәзмәләрендә дә ул 1976 елга кадәр бердәнбер хатын-кыз рәссамыбыз буларак катнашты.

Бала чагын революциядән соңгы елларда татар авылында үткәргән Гайшәгә Бөек Ватан сугышы вакытында да шактый авырлыклар кичерергә туры килә. Тормыш юлындагы кыенлыкларга газаплы һәм татлы иҗат эзләнүләре ялгана. Һәм ул инде кырык елдан артык сынлы сәнгатьне үстерүгә үзеннән армый-талмый өлеш кертә.

Шунысы үзенчәлекле: Г. Рахманкулова акварельгә гомеренең шактый өлгергән чорында мөрәҗәгать итә, һәм аның дөньяга шатлыклы карашы, сурәтләрне кәгазьгә эчке бер ярату белән төшерүе, буяуларның җегәр-куәтеннән нәтиҗәле файдалана белүе күпләрне сокландыра. Әйе, төсләрне ул «ат уйнаткан кебек» уйната белә һәм иң әһәмиятлесе, аларны үз иркенә буйсындыра ала. Менә шуңа күрәдер дә, без аның әсәрләрендә күпшы буяулар белән сурәтләнгән ниндидер идиллик яшәеш иркәсен түгел, тормыш сынаулары аша үткән тынгысыз кеше язмышын күрәбез.

Акварель пейзажлар, натюрмортлар, портретлар, интерьерлар... Үзенең күпчелек эшләрендә Г. Рахманкулова акварельнең бай сурәтләү чаралары арсеналыннан оста файдалана. Якты һәм җете буяулар тышкы декоративлыгы белән «ялтырап», күзгә бәрелеп тормыйлар. Кәгазь өстенә генә «сылангаң» буяулар иксез-чиксез тирәнлеккә иядер кебек тоела.

Рәссамның акварельче буларак йөзе натюрмортларда ачыграк чагыла. Бу уңайдан аның «Әңгер төшкәч», «Умырзаялар» кебек әсәрләрен генә искә төшерик. Табигатьнең манзаралы мизгелләре аларда бик нечкә тоемлана. Шигърилек күзлегеннән караганда, «җырлай» сүзенә рифмадаш булган Кырлайга, Тукайның туган ягына багышланган лирик пейзажлар сериясендә дә авторның табигать һәм кеше халәтләре, төсләр һәм хисләр гармониясенә ирешүе күренә.

«Балалар дөньясы» натюрморты да рәссамның әлеге жанрны аеруча үз күрүен һәм бу өлкәдә үзен иркенрәк тотуын раслый. Гадилек һәм җыйнаклык. Бизәкле келәм өстендә — мавыктыргыч уенчыклар. Алар К. Чуковскийның «Урланган кояш» әкиятенә иллюстрация фонында сурәтләнгән. «Ирекле кул хәрәкәтләре белән» генә диярлек ясалган бу композициягә кувшиндагы чәчәк бәйләме тәгәлләнеш бирә. Әсәрдәге предметларның эчке бәйләнеше күңелдә бөтен бер эмоциональ сурәт тудыра, кызыл, ак, зәңгәрсу, саргылт төсләрнең үзгә балкышы шатлыклы балачак илен күз алдына китерә. Акварель остасы Гайшә Рахманкулованың иҗаты, гомумән, һәркемнең күңеленә якты нур иңдерә, яшәүне яратырга чакыра.

Диләрә САДЫЙКОВА,
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Әлфия Афзалова.

Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)